Тәхәллүс тәртибе

НАИЛ ГАЕТБАЙ

Комедияләр

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ

Каләмнәр туганлыгы

НАИЛ ГАЕТБАЙ

Комедияләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2012

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Баш)-6
Г17

«Каләмнәр туганлыгы» сериясе
1994 елда булдырылды.

Башкортчадан Данил Салихов тәрҗемәсе

Гаетбай, Н. А.

Г17 Комедияләр / Наил Гаетбай ; [тәрҗ. һәм кереш сүз авт. Д. Салихов]. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. — 320 б.
ISBN 978-5-298-02293-4

Драматург һәм прозаик, Башкортстан Республикасының М. Акмулла исемендәге премия лауреаты Наил Гаетбайның бу китабына төрле елларда иҗат ителгән, башкорт һәм татар театрларында куелып уңыш казанган комедияләре туплап бирелде.

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Баш)-6

ISBN 978-5-298-02293-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2012
© Гаетбай Н. А., 2012
© Салихов Д. Х., тәрҗ., 2012

ТАТАРСТАНДА ДА УЛ ҮЗ КЕШЕ

Башкорт драматургы Наил Гаетбай пьесалары буенча Татарстанның профессиональ театрларында куелган спектакльләр моннан егерме еллар элек күренә башлады, һәм аларны халык бик яратып кабул итте. Татарстанда аның пьесалары хакында «Наил Гаетбайның әсәрләре бик кызык, аны мотлак карарга кирәк» дигән фикер дә киң таралган. Шуңа күрә аның пьесалар җыентыгының Казанда нәшер ителүе юкка түгел.

Наил Гаетбай соңгы вакытта, нигездә, комедия жанрында уңышлы эшли. Әмма драматург комедияләрен тамашачыны көлдерер өчен генә язмый. Аның һәр әсәрендә бүгенге заманның типик көнүзәк проблемасы күтәрелә. Автор үзе болай ди: «Мин тамашачының спектакль буена геройларның сүзләреннән, холыкларыннан туктаусыз көлеп утыруларын телим. Ә инде театрдан кайтып барганда болай дип уйлансыннар: «Тукта, тукта! Көлүен көлдек тә ул, пьесада бик җитди проблема күтәрелә. Аны ничек тә хәл итәргә кирәк бит!»

Мәсәлән, «Авылга кызлар килде, яки Моңнар кайтсын авылга» комедиясе авылларыбызның юкка чыга бару проблемасын күтәрә. Кызлар, бәхет эзләп, шәһәргә китә, шуңа егетләр өйләнә алмый, авылларда туйлар уйналмый, балалар тумый, мәктәпләр ябыла. «Ничек кияүгә чыгарга?» Бүген яшьләр арасында бу мәсьәлә аеруча кискен тора. Тамашачы, комедияне карагач, нәкъ шул хакта уйлана. Автор шушы күренешнең сәбәпләрен эзли һәм җәмгыятьтәге бу бәладән үзенчәлекле котылу юлын тәкъдим итә. «Үз хатыныма өйләнәм» дигән комедия бүгенге кешеләрнең бик җитди проблемасы – каты күңеллелек, битарафлык, бер-беребезгә, якыннарыбызга игътибарсызлык турында.

Мин хәзер укучыны авторның үзе белән таныштырырга телим. Наил Гаетбай – язучылар дөньясында шактый

үзенчәлекле шәхес. Ул кызыксынган өлкәләр бик күп. Әгәр язучы булып китмәсә, башка юнәлештә дә ул үзен данлый алыр иде, чөнки нинди генә эшкә тотынмасын, һәрчак уңышка ирешә. Мәктәп елларында, мәсәлән, ул спортның бик күп төрләре – чаңгы, футбол, җиңел атлетика, шахмат белән шөгыльләнеп, аларның күбесеннән югары разрядлар ала, шахмат буенча «Сибай шәһәре чемпионы» исемен яулый. Студент елларында хәтта Магнитогорск шәһәренең «Металлург» командасы өчен футбол уйнап йөри.

1972 елда Магнитогорск тау-металлургия институтын тау инженер-механигы һөнәре буенча тәмамлагач, Н. Гаетбай Кемерово өлкәсе Киселёвск шәһәрендәге машиналар төзү заводында эшли башлый. Өч елда мастердан заводның баш механигы дәрәҗәсенә күтәрелә.

1972–1975 елларда Наил шахмат белән җитди шөгыльләнә, спорт мастерлыгына кандидат булып китә, мастерлыкка дәгъва итә башлый, «Киселёвск шәһәре чемпионы» исемен яулый. Әмма 1975 елдан ул иҗатка күчә.

Бу өлкәдә дә тырыш хезмәте белән Наил Гаетбай бик тиз уңышка ирешә. 1976 елда аның «Әлфия» дигән тәүге повесте дөнья күрә һәм укучылар арасында зур популярлык яулый. Тиздән яшь язучы тәүге китапларын нәшер итә. Мәскәүдә үткән Бөтенсоюз яшь язучылар киңәшмәсендә катнаша (Юрий Трифонов семинары). 1980 елда аны СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларга укырга җибәрәләр. Шуннан соң Наил Гаетбай җиң сызганып проза өлкәсендә эшли, җитмештән артык хикәя, дистәләгән повесть, ике роман яза, Уфада һәм Мәскәүдә егермедән артык китап бастыра.

1987 елда язучы балалар өчен маҗаралы-фантастик повестьлар язарга тотына. «Серле сандык» дигән бу повестьлар сериясе тиз арада балаларның яраткан әсәрләренә әверелә.

1986–1987 елларда Наил Гаетбай Мәскәүдә Югары театр курсларында укый. Укуын тәмамлаганнан соң, прозаны бер читкә куеп, тулысынча драматургиягә күчә. 1988 елдан 2011 елгача драматург дүрт дистәләп пьеса иҗат итә, алар зур уңыш белән Башкортстан, Татарстан, Русия театрларында сәхнәләштерелә, Урта Азия, Төркия,

башка чит илләрдә куела һәм авторга талантлы драматург даны китерә.

1992–1998 елларда Наил Әсгать улы Гаетбай мәдәният министры урынбасары, аннан беренче урынбасар вазифасында эшли. Башкортстан мәдәниятен һәм сәнгатен үстерү өчен күп мактаулы эшләр башкара. Шушы чорда ул Башкортстан белән Татарстан арасында мәдәни бәйләнешләрне ныгытуга күп көч сала – ел саен театрларның алмаш гастрольләрен оештыра, рәссамнар күргәзмәләрен тугандаш республикага чыгара, уртак фестивальләр, конкурслар үткәрә.

Башкортстан сәнгатен күтәрүдә Наил Гаетбай башкарган эшләр гаять күп. Ул үз инициативасы белән Сибай шәһәрендә – филармония, «Чулпан» балалар театры, сәнгать колледжы, сәләтле балалар өчен махсус музыка лицейлары, Уфада республика музыка мәктәпләренә җитәкчелек итү максатында уку-методик үзәк ача; мәдәният һәм сәнгатькә багышланган «Тамаша» (башкортча) һәм «Рампа» (русча) журналлары нәшер итә башлый, ел саен үтүче «Театр язы» республика фестивале (анда катнашырга күп кенә Татарстан театрларын да чакыра), яшь драматурглар әзерләү теләге белән драматургия мәктәбе оештыра, яшь иҗатчылар өчен Талкас күле буенда ел саен ике атналык семинарлар үткәрә.

Наил Гаетбайның эшләре республика белән генә чикләнми. Мәдәният министры урынбасары буларак, ул Татарстанда, Самара, Саратов, Свердловск, Чиләбе, Ырынбур, Курган өлкәләрендә, ике тапкыр Төркиядә үткәрелгән Башкортстан мәдәнияте көннәренең оештыру комитетын җитәкли, ул бәйрәмнәрне югары дәрәҗәдә үткәрә. Наил Гаетбайның мәдәният министры урынбасары вазифасында оештыру талантын күрсәткән иң олы чараларның берсе булып Мәскәүдә 1997 елда үткән Башкортстан көннәрен әйтер идек. Илебезнең башкаласына республикадан 1200 артист, музыкант һәм башка сәнгать әһелләре бара.

Шул ук вакытта Наил Гаетбай тыныч, тыйнак холыклы, кешеләргә ярдәмгә килергә әзер тора. Мәсәлән, танылган драматург булгач, үз тәҗрибәсеннән чыгып, «Ничек пьеса язарга?» дигән китап нәшер итте. Бу җыентык бик популяр булып китте, күп кенә башкорт һәм татар язучыларына

драматургия дигән авыр жанрның асылына төшенергә бүген дә ярдәм итә.

Хәзер Наил Гаетбай бөтен көчен иҗатка сала. Соңгы елларда Уфа, Стәрлетамак, Сибай, Туймазы, Казан, Әлмәт, Минзәлә, Яр Чаллы театрларында премьералары булды, әсәрләре республиканың иң яхшы пьесалары конкурсларында алдынгы урыннар яулады. Бүген Наил яңа иҗади планнар белән яши, һәм без аның сәхнә әсәрләре белән Башкортстан, Татарстан һәм Русия тамашачыларын куандырачагына ышанабыз.

Данил Салихов,
драматург

ЯУЧЫ ҖИҺАН,
ЯКИ
НИЧЕК КИЯҮГӘ ЧЫГАРГА?

Комедия-уйлану, ике пәрдәдә

Катнашалар:

Җиһан.
Вазыйфа.
Сания.
Фәния.
Гыйльман.
Илмар.
Сәйфулла.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Җиһан. Алло, Омск? Сезне коллегагыз яучы Җиһан борчый. Миңа Урманшин Сәйфулла исемле егет хакында белешергә кирәк иде. Өй адресы: Омск каласы...

Беренче күренеш

Шәһәр фатиры. Вазыйфа табын әзерли.
Гыйльман керә.

Вазыйфа. Гыйльман, кара әле. Инде ничә көн күрәм: әнә ул ике тургай, оя корсалар да, кемнедер көткән кебек утыралар.

Гыйльман. Парларын көтәләр, шунсыз бала чыгара алмый бит алар.

Вазыйфа. Кара, кошлар да кешеләр кебек икән. Йә, шуннан?

Гыйльман. Булмады, Вазыйфа.

Вазыйфа. Булмагач, кайда йөрдең моңа кадәр?

Гыйльман. Озаграк торылган икән шул. Күрше Сафа очрады. Такта алган. Шуны төяшергә чакырды.

Вазыйфа. Синең шул булыр инде. Кеше монда икегә ярылырдай булып йөри. Бүген бит Сания кияү белән таныштыра! Оныттыңмыни?

Гыйльман. Онытмадым. Юл буе шуны уйлап кайттым. Кичә – таныштык, иртәгә – туй, берсекөнгә – бергәләп Себергә! Шулай буламы?

Вазыйфа. Гыйльман, куан, Себердә бит бар егетләр эчкече, сугыш чукмарлары. Әллә кемгә барып эләгер иде, Алла сакласын. Хәзер башлы-күзле итеп җибәрәбез. Ичмасам, күңелебез тыныч булыр.

Гыйльман. Бәлки, Фәнияне дә алар белән Себергә җибәрергәдер. Монда бит эш юк.

Вазыйфа. Әз генә булса да оят түгелме сиңа? Төпчегеңә тулай торагы булган эш тапты, шуңа рәхмәт әйтәсе урынга! Фәниягә Уфада үзең эш тап.

Гыйльман. Ярый, ярый. Бу кияү буласы бәндә ниндирәк кеше икән? Хәзерге яшьләр бит... Өченчекөн бер яшь кенә егет эчеп алган да тукталышта бер иргә тик торганда бәйләнеп, тукмап китте. Шундый егет булмасын димен.

Вазыйфа. Начарга юрап торма әле, яме! Әтисе – инженер, әнисе – укытучы. Андый кешеләр начар бала тәрбияләмәс. Менә фотосын кара. Үзе чибәр, күзләре янып тора, таза. Бик гадел егеткә охшаган.

Гыйльман. Кечкенәбезгә кияү дә, эш тә була. Ә бит гореф-гадәт буенча, Вазыйфа, кияүгә башта өлкән кыз чыгарга тиеш.

Вазыйфа. Чыгарга тиеш дип, анысына кияү таптыңмы соң?

Гыйльман. Тапмадым. Яучылардан ярдәм сорарга була. Хәзер бит алар бар.

Вазыйфа. Сания яучыларыңның Фәниягә кияү тапканын көтеп утыралмый. Аңа өч көннән Нефтеюганскида булырга кирәк.

Гыйльман. Ашыктырсак, бер көндә табып бирә алар кияүне. Икесенә дә туйны бергә үткәрер идек. Гореф-гадәтне дә бозмас идек. Йолабызны саклар идек. Шуны үтәмәгәнгә бозыла бит дөнья.

Вазыйфа. Кит әле, әкият сөйләп утырма. Акчаңны көрәп алып, кызың белән үзеңне төп башына утыртып китәр. «Башмагым»дагы Җиһан әбиең кебек.

Ишектә звонок. Гыйльман чыга да Җиһан белән керә.

Җиһан. Исәнмесез!

Вазыйфа. Сау гына әле. Бәй, Җиһан, син түгелме соң?

Җиһан. Мин инде, мин, башка кем булсын? Йә, ничек яшәп ятасыз?

Вазыйфа. Әйбәт. Үзең ничек? Сине күрмәгәнгә ун еллап булыр.

Җиһан. Әйе. Төп-төгәл тугыз ел.

Вазыйфа. Ничек килеп чыктың безнең калага?

Җиһан. Ярты ел инде монда күчеп килүемә.

Вазыйфа. Шулаймыни? Кайда эшлисең? Кем булып?

Җиһан. Яучы булып эшлим.

Вазыйфа. Яучы? Ничек «яучы»? Андый эш буламыни?

Җиһан. Әлбәттә. Фирма «Син»! Син плюс мин! Ялгыз егет-кызлар бит хәзер буа буарлык. Шуларны кавыштырам. Сездән – акча, миннән – букча! Сез түләгез, мин табам.

Вазыйфа. Шундый эш өчен күпме аласың инде?

Җиһан. Төрлечә. Яшенә, матурлыгына карап. Һәр яучының үз хакы. Уртача биш мең сум.

Вазыйфа. Күпме?

Җиһан. Биш мең! Ә нигә? Мин бит аларны бәхетле итәм. Аларның язмышын хәл итәм бит. Ялгызлыктан интеккәннәрне парлы итәм. Шуның өчен биш мең күпмени?

Вазыйфа. Үзеңә берәрсен таптыңмы соң? Без белгәндә син аерылышкан идең бит.

Җиһан. Әлбәттә, Уфаның иң әйбәт, иң бай киявен сайлап чыктым. Бәхетлемен. Әйткәнемчә, мин бит сезгә тиккә килмәдем. Ишетеп килдем, кечкенә кызыгызны кияүгә бирергә йөрисез икән. Ә олы кызыгызны башлыкүзле итмәгәнсез. Бу дөресме?

Вазыйфа. Дөрес.

Җиһан. Кит! Оялмый да, «дөрес» дип тора. Бу гореф-гадәттә булмаган хәл. Йола, әдәпне бозу! Шуның аркасында халык аза!

Вазыйфа. Шуның аркасында халык азып бармагае... Кечесен алдан бирсәк ни була?

Җиһан. Начар була! Олы гөнаһ! Өлкән кызыгыз һаман да кияүгә чыкмаганына болай да кайгырып йөри. Хәзер сеңлесе алдан чыкса, ул депрессиягә биреләчәк, тормышка, әти-әнисенә, ир-атка ачуы кабарачак. Шуның аркасында гомергә ялгыз калуы бар. Статистика менә нәрсә сөйли. Сеңлесе алдан чыкса, апаларының 85 проценты кияүсез кала икән. Ягъни сеңлесеннән соңга калса, унысының берсе генә кияүгә чыга.

Вазыйфа. Аңлавымча, син безнең олы кызга кияү тапкансың.

Җиһан. Ун кандидатурам бар. Теләгәнен сайлап алыгыз. Ул әти-әнисе шәп, ул үзе әйбәт...

Вазыйфа. Тик... биш мең!..

Җиһан. Сезгә кызыгызның бәхете кадерлерәкме, әллә биш меңме?

Вазыйфа. Андый акча түләгәнче, ялгыз утырсын.

Җиһан. Сөйләштек, килештек! Күпме түли аласыз?

Вазыйфа. Бер сум да түли алмыйбыз.

Җиһан. Дүрт мең!

Вазыйфа. Юк, бер тиенебез дә юк! Мин мондый сөйләшүгә каршы!

Җиһан. Минем дә хәлне аңлагыз. Бу бит минем эшем. Шушы акчага яшим.

Вазыйфа. Тапкан җиңел кәсеп! Башка кәсеп эзлә.

Җиһан. Мин табар да идем. Ялгыз кызлар, буйдак егетләр күреп күңел әрни. Бөтен йолалар онытылды. Кая килеп төртелдек?

Вазыйфа. Син генә төзәтә аласыңмыни ул хәлне? Хөкүмәт төзәтсен.

Җиһан. Төкерә сезгә хөкүмәт! Өч мең ярым!

Вазыйфа. Юк!

Җиһан. Вазыйфа, егетләр хакында информация җыюга биш мең акчам китте. Ә күпме нервы! Ул егетләрне өйләндерергә күндерү – мең бәла. Хәзер бик ансатка өйрәнеп алды ир-ат. Өйләнми һәм вәссәлам. Гаилә юк – кайгы юк! Ансат яшәмәкче, сволочьлар! Бөтенесен дә өйләндереп бетерәбез. Өч мең!

Вазыйфа. Ай Алла! Кара бу бәйләнчекне! Юк, дидем бит мин сиңа акча!

Гыйльман. Вазыйфа, әллә ике мең түләп бәхетне сынап карыйбызмы?

Вазыйфа. Акча кайда? Хәзер туй үткәрергә торабыз.

Җиһан. Күпме түли аласыз?

Вазыйфа. Бер мең.

Җиһан. Бер мең? Сез көләсезме әллә? Мең ярым һәм вәссәлам! Мең ярым – таныштыру өчен һәм мең ярым – яхшы яшәп китсәләр, бер елдан. Ризамы?

Вазыйфа. Ә яшәп китмәсәләр?

Җиһан. Бер елдан аерылышсалар, мин мең ярымны кайтарып бирәм. Йә?

Вазыйфа. Нишлибез, Гыйльман?

Гыйльман. Ризалашыйк, яши алмасалар, акчаны кире алырбыз, ичмасам.

Вазыйфа. Ярый, риза. Хәзер кит. Безгә булачак кияү килә. Төштән соң килерсең.

Җиһан. Ә кем ул? Әгәр кирәксә, мин аның кемлеген, әти-әнисенең нинди кешеләр икәнлеген әйтеп бирә алам. Картотекада барысы да бар.

Вазыйфа. Бер яшь инженер.

Җиһан. Фамилиясе ничек?

Вазыйфа. Фамилиясен белмибез шул.

Җиһан. Ничек белмисез? Ә ата-анасы кем?

Вазыйфа. Атасы – инженер, әнисе – укытучы, дия иде Сания.

Җиһан. Профессиясен сорамыйм, нинди кешеләр?

Вазыйфа. Каян белим? Ата-анасын түгел, егетнең үзен дә күргәнебез юк. Хәзер Сания таныштырырга алып килә.

Җиһан. Коточкыч! Ә туй кайчан?

Вазыйфа. Берсекөнгә!

Җиһан. Нигә шулай ашыгасыз? Башта ата-анасы, туганнары, үзе хакында белешик. Нинди кешеләр икән? Шул арада өлкән кызыгызга кияү табам. Ике туй бергә була.

Вазыйфа. Вакыт юк. Алар өч көннән бергәләп Себергә китә.

Җиһан. Соңрак китәрләр.

Вазыйфа. Нефтеюганскидагы абыем өч көн эчендә килеп җитәргә куша, аларның автобазасында фельдшер урыны бушаган. Теләүчеләр бик күп, ди. Фәниябез – ике ай, Саниябез биш ай эшсез утыра бит.

Җиһан. Мин сезне аңлыйм. Тик сез кәҗә сатасызмы, әллә кыз бирәсезме? Гөлдәй күреп үстергән балагызны белмәгән-нитмәгән кешегә биреп җибәрергә йөрисез бит!

Вазыйфа. Кызыбыз бит гашыйк булган, яратам, ди. Шулай булгач, ничек каршы буласың. Бөтен кеше дә кызын шулай бирә ләбаса.

Җиһан. Алайса, яхшылап белергә кирәк, кем ул? Исеме ничек? Хәзер картотекадан табам мин аны! Кем икәнлеген әйтәм.

Вазыйфа. Исемен Илмар дидеме әле?

Гыйльман. Әйе, Илмар.

Җиһан. Йа Хода! Менә ул хәзерге ата-ана! Илмар? Сирәк исем. Табам! Тик сез моның өчен түләргә тиеш.

Гыйльман. Тап, тап! Түлибез!

Җиһан. Илдар... Илһам... Сездән – акча, миннән – букча. Юк, Илмар!.. Гаҗәп! Исемлекне бит... Димәк...

Вазыйфа. Нигә «димәк»?

Җиһан. Ярый, иртәгә үк Илмарның картотекасы миндә булачак.

Вазыйфа. Әйе, тап. Белик әле кемлеген.

Җиһан. Тик түләргә кирәк.

Вазыйфа. Тагы түләргә! Син безне таларга килгәнсең.

Җиһан. Хәзер берни бушка эшләнми, кадерлем. Мин сезгә – бәхет, сез миңа – акча!

Вазыйфа. Күпме?

Җиһан. Хәзер дөньяда иң кыйммәт товар – информация! Ике мең!

Вазыйфа. Нәрсә? Юк, кирәге юк! Белмичә генә бирәбез.

Җиһан. Кемлеген әйтеп бирәм. Соңыннан соң була. Мең ярым!

Вазыйфа. Ай Алла! Үтерә бит бу! Көпә-көндез талый! Каян килеп керде? Бар, ку! Ялангач калдыра бит безне!

Җиһан. Әгәр кызыгыз җәл түгел икән, куыгыз! Бәхетсез итәсегез килсә. Бер мең!

Вазыйфа. Биш йөз!

Җиһан. Сигез йөз!

Вазыйфа. Алты йөз! Бер тиен дә артык түгел!

Җиһан. Таныш булганга гына. Риза!

Фәния керә.

Фәния. Исәнмесез! Юк эш, юк. Беркайда да юк.

Җиһан. Исән әле.

Гыйльман. Бу безнең олы кызыбыз Фәния.

Җиһан. Бик матур кыз.

Фәния. Рәхмәт. Ә сез кем буласыз, апа?

Гыйльман. Безнең яшьлек дусты.

Вазыйфа. Хәтта атаңны яшь чагында ата-анасы чак-чак кына шушы апаңа өйләндермәгәннәр.

Фәния. Чынмы? Менә кызык.

Гыйльман. Чын. Тик Җиһан апаң мине ошатмады.

Җиһан. Әйе. Атаң бигрәк юаш, кыюсыз иде. Әткәйәнкәйгә мине көчләп бирергә кирәк булган да бит. Юк!.. Мин икенче егеткә гашыйк булдым да шуңа чыктым. Танышыйк: Җиһанбикә.

Фәния. Җиһан... Бикә? Исемегез кызык. Әллә «Башмагым»дагы кебек сез дә яучымы?

Җиһан. Сизгер икәнсез, Фәния. Әйе, яучы мин, яучы! Фирма «Син», син плюс мин! Менә сеңлеңнең кияүгә чыгарга йөргәнен ишеттем дә килеп җиттем. Башта сине кияүгә бирәбез.

Фәния. Нәрсә?

Җиһан. Ун кандидатурам бар.

Фәния. Ха-ха-ха! Сез әллә болайракмы?

Җиһан. Егерме алтыга җитеп кияүгә чыкмаган кыз болайрак. Хәзер сайлыйсың, ярты сәгатьтән танышасыз.

Фәния. Сез нәрсә, чынлапмы?

Җиһан. Иртәгә – туй!

Фәния. Ә кайчан аерылышабыз?

Җиһан. Үлгәч.

Фәния. Әни, каян таптыгыз бу экземплярны?

Вазыйфа. Кызым, сорама. Сизгән кебек бит. Каршы тора алмыйбыз.

Җиһан. Сөйләштек. Вазыйфа, Гыйльман, чыгып торыгыз. Безгә сөйләшергә кирәк.

Гыйльман, Вазыйфа чыгалар.

Димәк, болай...

Фәния. Давай, давай!

Җиһан. Сеңлем! Нигә кыланган буласың? Сиңа кияү кирәкме, юкмы?

Фәния. Кирәк булса, ул синең эшең түгел. Үземнең күзем бар.

Җиһан. Син дура, белдеңме? Шушы яшькә җитеп кияүгә чыкмагач, настоящая дура!

Фәния. Дурадан ишетәм! Бар, чыгып китегез!

Җиһан. Куркытма! Талашмыйк! Бу – бизнес, сездән – акча, миннән – букча! Җүләрләр генә талаша. Акыллылар эмоциясез эшли. Дөресме?

Фәния. Дөрес ди. Шуннан?

Җиһан. Беләсеңме күпме егетләр буйдак йөри! Менә дигәннәре бар! Әгәр үзем яшь булсаммы!

Их!.. Менә картотека, фотолары, биографиясе, эше, зарплатасы – бөтенесе бар. Кара, фикереңне әйт, җаның теләгәнен алып киләм.

Фәния. Монда мин теләгәне юк. Миңа утызны үтмәгән, югары белемле, фатирлы, машиналы...

Җиһан. Озын буйлы, киң җилкәле, бөдрә чәчле, мыеклы, чибәр, эчмәгән, тартмаган егет кирәк!

Фәния. Дөрес!

Җиһан. Андый кияү кирәк булгач, сеңлем, унҗидедә үк чыгалар! Шушы яшеңә егетеңне фатирлы да, машиналы да итәр идең!

Фәния. Аңлашылды. Алай булгач, кандидатураларыңны карап та тормыйм.

Җиһан. Ярый, үпкәләмә, фотоларны кара. Көмеш калакка салып йотардайлары бар!

Фәния. Ничә яшьләрдә алар?

Җиһан. Белеп тор. Ир-ат утыз бишләрдә генә аякка баса, фатиры, акчасы барлыкка килә, гаилә алдында җаваплылык тоя башлый. Аны яклап та, саклап та кала ала.

Фәния. Утыз биш минем өчен карт!

Җиһан. Һич тә карт түгел. Синнән сигез яшькә генә олы. Ә ир кеше хатыннан ким дигәндә ун яшькә олы булырга тиеш, дигән борынгылар. Статистика да шуны сөйли. Син бит инженер. Статистикага каршы барып булмый. Өйләнүче егет белән кыз яшьтәш булса, мондый гаиләләрнең 80 проценты аерылу белән тәмамлана. Ир-ат хатын-кыздан биш яшькә өлкәнрәк гаиләләрнең 50 проценты таркала. Ә инде ирләре ун яшькә өлкәнрәк гаиләләрнең 5 проценты гына аерылыша. Данлыклы шәхесләрне алыгыз. Аларның күбесе утызны узгач өйләнә: Пушкин – утыз өчтә, Толстой – утыз дүрттә, Достоевский хәтта кырык дүрттә.

Фәния. Алай булгач, миңа утыз алты яшьлек егет кирәк булып чыгамы?

Җиһан. Әйбәт яшәп китим дисәң, әйе.

Фәния. Аларның барысы да берәр хатын алып аерылгандыр бит?

Жиһан. Андыйлары да бар!
Фәния. Юк! Аерылган ир миңа кирәкми.
Жиһан. Өйләнмәгәне кирәк икән, рәхим ит!
Фәния. Күзләре бик хәйләкәр күренә. Кем ул?
Жиһан. Инженер. Цех начальнигы хәтта. Фатиры, машинасы бар. Кара, кара, бу син таләп иткән шартларга туры килә бит!
Фәния. Коточкыч! Өстәвенә өйләнмәгәнме?
Жиһан. Юк.
Фәния. Ә нигә?
Жиһан. Өйләнмәгәч өйләнмәгән инде. Үзеннән сорарсың.
Фәния. Бик шикле бу. Җитмәсә, карт. Давай икенчене.
Жиһан. Заказчикның сүзе – закон. Сездән – акча, миннән – букча. Менә!
Фәния. Юк! Монысының борыны бәләкәй.
Жиһан. Сиңа әрмән кирәкмени?
Фәния. Әрмән кирәкми, тик борыны нормальный булсын.
Жиһан. Менә бу ошарга тиеш. Борыны – коеп куйган! Яше – утыз алты!
Фәния. Бик симез күренә. Авырлыгы күпме?
Жиһан. Авырлыгы... 95! Менә, ичмасам, ир дисәң дә ир!
Фәния. Кит әле! Сез әллә көләсезме? Бер нормальный кешегез юк!
Жиһан. Алайса, менә! Утыз биш яшь. Самый пешкән җиләк!
Фәния. Пеләш бит!
Жиһан. Карама беләккә, кара йөрәккә! Омскида яши, фатиры бар. Өйләнмәгән.
Фәния. Омскида яшәгән кешене сез каян беләсез?
Жиһан. Аның ата-анасы монда, әле үзе дә килгән, отпускыга. Ата-анасы, кәләш тап, дигәч, Омскига коллегаларыма шалтыраттым. Белештем, бик әйбәт егет. Әгәр Башкортстанда кәләш тапмасагыз, монда Омскида бирәрсен димләрбез, диләр.

Фәния. Пеләш бит, пеләш! Ә кем булып эшли?

Җиһан. Балта остасы!

Фәния. Кем?

Җиһан. Ә нигә?! Үз эшенең остасы. Бик хөрмәт итәләр фирмасында.

Фәния. Җиһан апай, сез аңлыйсызмы ни сөйләгәнегезне? Мин – аспирантура бетереп биш минуттан фәннәр кандидаты булырга йөргән кеше һәм балта остасы! Нәрсә хакында сөйләшим мин аның белән?

Җиһан. Ул бит рәссам! Ул ясаган әйберләрне күрсәңме? Сезнең мебельләр аныкы янында чүп!

Фәния. Юк, Җиһан апа, юк! Бу егетең дә бармый. Бетте, җитәр!

Җиһан. Ашыкма, Фәния! Әгәр хәзер мине тыңламасаң, беркайчан да кияүгә чыга алмаячаксың. Мәскәй әбигә әйләнәчәксең! Усал, ямьсез, нервный карт кызга. Менә мин әйтте диярсең! Ә ялгыз яшәве, Фәния, ай-һай, кыен бит ул. Ай-һай, авыр! Таяныр дустың, кайгыңны сөйләр кешең юк! Менә шулай. Сиңа кеше кияү табам дип торганда, үзең утырган ботакка балта чапма! Сиңа башкача беркем дә: «Менә егетләр, теләгәнеңне сайлап ал»,– дип тормас. Ә бит сиңа инде егерме алты яшь! Карт кыз. Әйе, әйе! Егетләргә дә бит андыйлар кирәкми. Хәтта әнә шул син карт дигән утыз алты яшьлек цех начальнигы да, миңа егерме өчтән өлкән булмаган кыз, кыз кирәк, дип утыра. Менә шулай, Фәния сеңлем, давай уйла да хәл ит!

Фәния. Нәрсә уйларга? Нәрсә хәл итәргә?

Җиһан. Киңәш биримме?

Фәния. Йә?

Җиһан. Хәзер шушы балта остасын чакырабыз!

Фәния. Юк!

Җиһан. Тукта! Син аны күр генә, күр! Очраш, сөйләшеп кара! Мин аның ата-анасын беләм! Менә дигән кешеләр! Юаш, итагатьле! Уллары – фәрештә! Әгәр аз гына ошаса... Синнән дә бәхетле кеше булмаячак! Ант менә! Йә?!

Фәния. Пеләш бит, пеләш!

Җиһан. Ай Алла! Парик кидерерсең!

Фәния. Ансат кына уйлыйсыз! Ул үзе, ичмасам, беләме үзен шушылай димләүләрен?

Җиһан. Әлегә белми! Хәзер аны монда китерү өчен күпме үгетләргә туры киләчәк! Тик сез пар килгәнсез, пар! Әгәр бер-берегезне югалтсагыз!.. Димәк, бетте! Син әзерлән. Без ярты сәгатьтән монда булабыз!

Фәния. Туктагыз! Ә аның биеклеге күпме?

Җиһан. Нинди биеклеге?

Фәния. Ну, буе?

Җиһан. Ә-ә! Баһадир, 165 сантиметр.

Фәния. Нинди баһадир? Ул бит миннән кыска!

Җиһан. Ничек «кыска»? Синеке күпме?

Фәния. 166 сантиметр.

Җиһан. Кит әле! Бер сантиметр да булдымы сан? Биек үкчәле туфли кияр! Кыскасы, без хәзер киләбез. Матур күлмәгеңне киеп куй. Ул сиңа бер күрүдә гашыйк булырга тиеш!

Фәния. Туктап торыгыз! Исеме ничек?

Җиһан. Дөньядагы иң матур исем! Сәйфулла!

Фәния. Йа Ходай! Сәйфулла?! Ну Җиһан апа! Ну фирма «Син»! Каян табасыз сез шундый егетләрне? Ярый! Комедия булгач комедия булсын! Алып килегез! Очрашам! Шунсыз котылып булмас сездән!

Җиһан. Ай, афәрин! Вай, афәрин! Күптән шулай кирәк иде! Хәзер бизән, ясан. Син аңа ошарга тиешсең.

Фәния китә.

Стерва!.. Гыйльман! Вазыйфа!

Вазыйфа белән Гыйльман керә.

Гыйльман. Йә, ничек?

Җиһан. Булды! Килештек! Киемен алмаштырырга кереп китте. Очрашырга риза!

Гыйльман. Чынмы? Рәхмәт, Җиһанбикә!

Җиһан. Тукта әле! Очрашу өйләнешәләр диган сүз түгел!

Вазыйфа. Ниндирәк егет соң?

Җиһан. Менә дигән егет! Ул әтисе, ул әнисе! Ярый, килгәч күрерсез! Ярты сәгатьтән монда булабыз!

Җиһан китә.

Вазыйфа. Йа Хода! Әгәр икесенә дә туй үткәрергә туры килсә!.. Күпме акча кирәк! Каян алырбыз?

Гыйльман. Җүләркәем! Куан! Ике кызың да кияүгә чыга! Котылабыз!

Сания белән Илмар керә.
Илмар озын буйлы, чибәр егет.

Илмар. Исәнмесез!

Сания. Таныш булыгыз: Илмар!

Вазыйфа. Бик шатбыз, бик шатбыз!

Гыйльман. Исәнмесез!

Илмар. Миннән танышу бүләге. Вазыйфа апа, сезгә!

Вазыйфа. Ой! Кирәкмәс иде лә. Зур рәхмәт!

Илмар. Гыйльман абый, сезгә!

Гыйльман. Хәзер шундый йола бармыни? Рәхмәт, рәхмәт!

Илмар. Ә... Фәния кайда?

Вазыйфа. Ул киемнәрен алмаштыра.

Илмар. Бу – Фәниягә.

Сания. Ә миңа?

Илмар. Сиңа? Мин үзем!

Сания. Үзең генә?

Илмар. ...Һәм шушы!

Сания. О! Рәхмәт!

Вазыйфа. Рәхим итегез, утырышыгыз. Күптән көтәбез. Сания, чакыр Фәнияне.

Сания. Апа!

Фәния чыга.

О! Нинди бәйрәм?

Фәния. Бер сиңа гына кияүгә чыгарга димәгән. Хәзер миңа да кияү килә.

Сания. Апа, чынмы?

Фәния. Ышанмасаң, әти-әнидән сора.

Гыйльман. Дөрес.

Вазыйфа. Әйе, килергә тиеш бер егет.

Фәния. Сания, таныштыр.

Илмар. Исәнмесез!

Сания. Илмар, Фәния.

Фәния. Молодец, Сания! Егетнең менә дигәнен эләктергәнсең!

Илмар. Сез бик матур, Фәния.

Фәния. Рәхмәт!

Вазыйфа. Җитәр, утырабыз! Гыйльман, шампанскийны ач.

Гыйльман. Бу бер бәла инде.

Илмар. Бирегез, үзем. Оп-ля!

Вазыйфа. Кара, ничек оста ачты! Югыйсә Гыйльман бөтен өстәлгә түгеп бетерә иде.

Гыйльман. Яшьләр!

Илмар Гомәр Хәйямнең бер шигырен укый.

Вазыйфа. Искиткеч! Үзегезнең шигырьме?

Сания. Әни!

Илмар. Гомәр Хәйям!

Вазыйфа. Ярар инде. Без яшь чакта Гомәр Хәйямне ишеткән дә юк иде.

Гыйльман. Илмар, энем, син кайда эшлисең?

Илмар. Машзаводта эшли идем. Бүгеннән эшләмим.

Гыйльман. Ничек эшләмисең?

Сания. Әти!

Гыйльман. Нәрсә? Ә-ә, әйе бит әле. Минем кызыксынуым әллә безнең заводта эшләдеңме икән диюем. Мин сине кайдадыр күргәнем бар шикелле.

Илмар. Ә сез кайда эшлисез?

Гыйльман. Тимер-бетон заводында. Ремонт цехында.

Илмар. Сезнең начальник Хәбировмы?

Гыйльман. Әйе.

Илмар. Ул бит минем икетуган абыем. Аңа баргалап йөрим. Шунда күргәнсездер.

Гыйльман. Юк, мин бик якыннан, яхшылап күрдем. Кайда күрдем соң? Менә бөтен кыяфәтең, күзләрең – барысы да күз алдымда тора. Ә хәтерли алмыйм.

Илмар. Хәтерләмә мине, хәтерләмә!
Хәтереңә төшмәм барыбер.
Яннарыңда чакта тырышсам да,
Белмәдең бит минем кадерне!

Вазыйфа. Искиткеч! Бу да Хәйямме?

Илмар. Юк, бу – Илмар Хәбир!

Вазыйфа. Әллә син шигырь дә язасыңмы?

Сания. Әни, Илмар – шагыйрь. Аның киләсе елда китабы басылып чыгарга тиеш!

Вазыйфа. Рәхмәт!

Гыйльман. Вәт хәтер, ә?!

Вазыйфа. Әй, куй әле! Кайда күрсәң дә барыбер түгелмени? Әйдә, тост әйт. Күрмисеңмени, безнең өйгә нинди кадерле кунак килгән. Язучы!

Гыйльман. Язучы? Нинди язучы?

Вазыйфа. Колак! Ишетмәдеңмени, Илмар яңа гына үзенең искиткеч шигырен укып ишеттерде.

Гыйльман. Шулаймыни?

Фәния. Ә миңа атап шигырь чыгара аласыңмы?

Илмар. «Ә» дигәнче!

Сания. Юк, башта миңа!

Илмар. Саниягә бирде Ходай
Гомерлек сөеклесен!
Һәм бу егет яхшы аңлый
Саниянең бөеклеген!

Сания. О, Илмар! Зур рәхмәт!

Илмар. Фәниягә дә бирсен Ходай
Гомерлек сөеклесен!
Һәм ул булсын аңлар егет
Фәниянең бөеклеген!

Фәния. Сания! Егетең – во!

Гыйльман. Йөзе күз алдында тора, ә кайда – хәтергә төшми.

Вазыйфа. Җитәр инде сиңа!

Фәния. Ә нигә кудылар әле сине институттан?

Сания. Апа, син Илмарны беләсеңмени?

Илмар. Без кайчандыр бер институтта укыдык. Фәния – өлкән курсларда, мин – беренчедә.

Фәния. Шуннан син юкка чыктың.

Илмар. Урысның бер мәкале бар: «Не было бы счастья, да несчастье помогло». Әгәр шул чакта куылмасам, хәзер йөрер идем беркемгә кирәкмәгән инженер-эколог булып. Ә мин икенче институтны бетердем. Хәзер инженер-механик. Кайда барсам да, эш муеннан. Вазыйфа апа, Гыйльман абый! Без Сания белән бер-беребезне яратабыз. Һәм өйләнер өчен сезнең фатиханы сорыйбыз.

Вазыйфа. Без ни, риза. Шулай бит, Гыйльман?

Гыйльман. Ризалыгын риза. Тик әти-әниләреңне күрергә иде бит әле. Кемнәр алар, кайда эшлиләр?

Илмар. Минем әти – инженер, әни – укытучы.

Гыйльман. Алар беләме синең өйләнергә җыенганыңны?

Илмар. Белә. Алар командировкада. Ырымбурда. Шалтыратып рөхсәт сорадым. Ризалар.

Вазыйфа. Ә кайчан кайталар? Безгә бит очрашып, туй хакында сөйләшергә кирәк.

Илмар. Иртәгә кайтырга тиешләр. Кайталар да сезгә киләләр. Төшкә.

Вазыйфа. Бик әйбәт.

Илмар. Минемчә, тост күтәрергә вакыт җитте. Рәхмәт, Вазыйфа апа, рәхмәт, Гыйльман абый! Миңа ышанып искиткеч матур кызыгызны биргәнегез өчен. Мин сүз бирәм: аны һичкайчан җәберләмәм! Өрмәгән җиргә дә утыртмам. Менә шушылай күтәреп кенә йөртермен! Рәхмәт сезгә!

> Рәхмәт сезгә кызыгызны биргән өчен!
> Рәхмәт сезгә аны үстергән өчен!
> Рәхмәт сезгә аны тәрбияләп,
> Аны шундый акыллы иткән өчен!

Гыйльман. Рәхмәт, рәхмәт! Вәт хәтер!

Вазыйфа. Ә туйны кайчан, кайда үткәрербез икән?

Сания. Берсекөнгә. Кафеда.

Вазыйфа. Алай булгач, бүген үк барысын сөйләшеп куярга кирәк. Акчасын түләргә. Расход уртактыр бит?

Илмар. Әлбәттә!

Вазыйфа. Бер кырык кешегә заказ бирсәк җитәр бит?

Илмар. Җитәр. Минем әти белән әни дә кырык кешедән артмасын, ди. Бездән – егерме, сездән – егерме.

Фәния. Ә син, Илмар, нигә куылганыңны тәки әйтмәдең.

Ишектә звонок, Вазыйфа чыга һәм Җиһан белән
Сәйфулланы алып керә.

Сәйфулла. Исәнмесез!

Бөтенесе. Исән әле.

Җиһан. Таныш булыгыз: Сәйфулла Урманшин. Бу – Фәния. Вазыйфа, Гыйльман – Фәниянең әти-әнисе. Сеңлем, син Сания бит әле?

Сания. Әйе, Сания.

Сәйфулла. Сәйфулла.

Җиһан. Ә бу егет, аңлавымча, Илмар була. Шулаймы?

Илмар. Шулай. Ә сез каян беләсез?

Җиһан. Сезнең өйләнергә йөргәнегезне бөтен Уфа белә.

Сания. Ә сез кем буласыз?

Җиһан. Таныш булыйк. Исемем – Җиһан. Фирма «Син». Син плюс мин.

Илмар. О, фирма!
Ялгызлыктан бөлгәннәр,
Пар кирәк дип үлгәннәр!
Фирма «Син» бар, белсеннәр,
Яр кирәксә килсеннәр!

Җиһан. Шәп! Кемнең шигыре?

Илмар. Минеке. Әле генә чыгардым.

Җиһан. Афәрин! Язып бирегез әле. Рекламада файдаланырмын.

Илмар. Рәхим итегез!

Сания. Ә сез апамны яучыларга килдегезме?

Җиһан. Нәкъ өстенә бастың. Сездә – товар, миндә – сатып алучы. Вазыйфа, Гыйльман, менә мин әйткән егет. Үзе әйбәт, әти-әнисе акыллы, тыйнак. Өйләндерәбез Фәниягә!

Сания. Апа, син ризамы?

Җиһан. Сеңлем, тик кенә тор! Сиңа сүз бирелмәгән!

Сания. Сез нәрсә, элекке заманча кияүгә бирмәкчеме? Көчләп?!

Җиһан. Әйе. Элек, ата-анасы көчләп биргән чакта, аерылышулар булмаган. Дискотекада үзләре табышып теләсә кемгә өйләнгәннәрнең 80 проценты аерылыша, сеңлем.

Сания. Апам, ул бит синнән көлә! Чыкма аңа!

Фәния. Монда кияүгә чыккан кеше юк. Таныштырырга гына алып килгән.

Илмар. Бер егеткәй магазинга
Кукәй алырга килгән.
Кукәй беткәч, акчасына
Кәләш алырга булган!

Фәния. Ха-ха-ха! Ә сиңа ничә яшь?

Сәйфулла. Миңамы?

Фәния. Әйе.

Сәйфулла. Э-э...

Җиһан. Утыз алты.

Фәния. Ә нигә моңарчы өйләнмәдең?

Сәйфулла. Минме?

Фәния. Мин түгел инде!

Җиһан. Әйбәт, матур кәләш очрамаган аңа, Фәния. Менә синең кебек. Шуңа өйләнмәгән.

Фәния. Җиһан апа, үзе әйтсен.

Сәйфулла. Мин... мине кызлар ошатмый, Фәния.

Фәния. Ә нигә ошатмый?

Сәйфулла. Э-э... пеләшмен!

Фәния. Ә мин сине ошатыр дисеңме?

Сәйфулла. Юк.

Фәния. Шулай булгач, нигә килдең?

Җиһан. Фәния! Тукта әле! Син башта мине тыңла! Сәйфулла иң талантлы...

Фәния. Балта остасы! Илмар, синең балта остасы хакында шигырең бармы?

Илмар. Булмаса, язабыз аны!

Сәйфулла дигән, ай, батырның
Уң кулында булыр балтасы.
Бар Башкортстанны телсез итә
Аның эшләгән, ай, кумтасы*!

Фәния. Ха-ха-ха! Шәп бит!

Сәйфулла. Мин кумта ясамыйм.

Фәния. Ә шигырь язасыңмы?

Сәйфулла. Шигырь? Юк.

Фәния. Алайса, ичмасам, яттан берәр шигырь беләсеңме?

Сәйфулла. Яттан? Берне беләм.

Фәния. Сөйлә әле!

Сәйфулла. Әй тышта буран!
Мин өйдә торам!
Тәрәзә аша
Тик авыз ерам!

Фәния. Беттеме?

Сәйфулла. Бетте.

Фәния. Менә нәрсә, Сәйфулла. Син хәзер кайт, яме!

Җиһан. Фәния, тукта! Син бит акыллы кыз. Бала-чага түгел. Сиңа тыштан ялтырап торган уенчык кирәкме, әллә...

Фәния. Әйе, Җиһан апа! Миңа ялтырап торган уенчык кирәк. Минем аңа карап сокланасым, куанасым, башкалар алдында мактанасым килә.

Гыйльман. Кызым, ашыкма әле. Менә яшь чагымда мин дә бер шигырь дә белми идем. Юаш идем.

Җиһан. Әйе, әйе, хәтерлим. Шуңа кызлар синнән кача иде, җүләрләр. Хәзер үкенәләрдер дә...

---

* Кумта (*башк.*) – савыт, тартма; шкатулка.

Вазыйфа. Юк, Җиһан! Миңа да ошамады бу егетең. Мең ярым түлә дә кызыңны шушыңа бир, имеш. Юк!

Җиһан. Ай Алла! Яши алмасалар, бер елдан кайтарырмын акчаңны! Аның бит әти-әнисе...

Вазыйфа. Нәрсәгә безгә аның әти-әнисе, әгәр Фәниягә егет ошамый икән?

Җиһан. Ул ни белә? Ул бит бала! Бакырны алтыннан аера белмәгән бала! Аңа нәрсә тоттырабыз...

Фәния. Юк, Җиһан апа, мин күптән инде бала түгел. Хушыгыз! Миңа егетегез кирәк түгел.

Гыйльман. Тукта, Фәния! Егет тәтәй тел түгел, әмма күренеп тора – ышанычлы. Ир-ат өчен бу иң шәп сыйфат...

Сания. Әти! Син мәхәббәт дигән нәрсәне беләсеңме?

Гыйльман. Беләм. Ул, төтен кебек, акылны томалый да бер айдан юкка чыга. Тю-тю! Кешегә ихтирам гына торып кала! Хөрмәт! Әгәр ул булмаса...

Сания. Әти, алай түгел! Мин дә элегрәк мәхәббәт юк дип уйлый идем. Ә бүген! Мин – дөньяда иң бәхетле кеше! Үземне канатланган кебек тоям! Атлап түгел, очып йөримен! Чөнки мин яратам! Гашыйк булу ул шундый бәхет! Аны әйтеп, сөйләп, аңлатып булмый! Моны гашыйклар гына аңлый! Ә яратмыйча гына яшәү – мин хәзер аңладым – ул үлем белән бер! Юк, апам, яратмыйсың икән, чыкма! Бәхетсез булачаксың! Көт! Килер ул мәхәббәт! Барыбер килер! Һәм син миңа бүген туктаткан өчен рәхмәт әйтерсең!

Сәйфулла. Мөмкинме миңа сүз әйтергә?

Җиһан. Әйт әле, Сәйфулла, әйт!

Сәйфулла. Мин монда килгән чакта ук моның шулай бетәчәген белдем. Тик әти-әниемне борчуга салмыйм дип кенә килгән идем. Алар, өйлән дә өйлән дип, пеләш иттеләр бит мине! Ә бүген Җиһан апа! Ул бит сагыз кебек! Сания, Вазыйфа апа, тынычланыгыз. Без беркайчан да Фәния белән өйләнешмәячәкбез.

Җиһан. Сәйфулла!

Сәйфулла. Юк, Җиһан апа, кирәкми. Гафу итегез мине. Акламадым өметегезне. Мин шундый инде. Яратмый мине кызлар. Мин бит пеләш, кыска, юан... Ә син бит, Фәния, шундый... Тик күзләрең генә нигәдер... Кайгырма, Фәния, сине менә дигән матур егет яратачак.

Фәния. Син изге күңелле, Сәйфулла. Рәхмәт. Тик... Мин аңа кайгырмыйм. Эш таба алмыйм, шунысы кыен!

Ут сүнә.

Икенче күренеш

Шул ук урын. Бер көн үткән. Вазыйфа өстәл әзерли. Гыйльман керә.

Вазыйфа. Гыйльман, кара теге ике тургайга, яннарына ике тургай килде. Чыр-чу киләләр.

Гыйльман. Парларын тапканнар, димәк. Туй үткәрәләр.

Вазыйфа. Без дә кызларыбызны башлы-күзле итсәк иде... Йә? Нигә озакладың? Вокзалга гына барып киләм, дип киткән идең?

Гыйльман. Күрше Яппар очрады.

Вазыйфа. Ул такта төяшергә чакырды.

Гыйльман. Диван сатып алган. Төяшергә кешесе юк.

Вазыйфа. Гыйльман, кайчан гына шушылай кеше өчен йөрүеңне ташлыйсың? Өеңдә пожар! Иртәгә – туй. Бүген танышырга, сөйләшергә, кодалар килә. Мин берүзем өлгерә алмыйм. Ә син...

Гыйльман. Соң, кеше ярдәм сорый, берүзе төйи алмый. Шул чакта ничек...

Вазыйфа. Шуннан? Булдымы билет?

Гыйльман. Юк.

Вазыйфа. Билет тапмаган, кешегә диван төяшеп йөри!

Гыйльман. Булмагач ни эшлим? Бармаган-күрмәгән кешем калмады. Отпускы беткәч очар, диләр.

Вазыйфа. Шуннан, хәзер ни эшләргә?

Гыйльман. Нәрсә диярга дә белмим, Вазыйфа.

Вазыйфа. Өч көннән барып җитмәсәләр, Сания дә эшсез кала!

Гыйльман. Аңлыйм, аңлыйм! Мин теләмиммени Саниянең тизрәк барып җитеп, эшкә урнашуын. Санияләр кайтсын, уйлашырбыз. Берәр җае килеп чыгар әле.

Вазыйфа. Каян чыксын? Син таба алмаганны, ул бала каян тапсын?

Гыйльман. Вәт замана килде! Кайда барма, блат кирәк! Ничек шушылай яшәргә мөмкин?

Вазыйфа. Синең генә танышың да, блатың да юк. Башка ирләрнең барысы да бар. Шуңа да мин каршы Фәниянең әнә ул арыш боламыгына чыгуына. Соңыннан утырырлар үзләренә дә, балаларына да ярдәм итә алмыйча.

Телефон шалтырый.

Алло! Сания, синме? Билет алдыгыз? Ничек? Илмармы? Ай рәхмәт төшкере! Менә көтеп утырабыз, өстәл әзерләп. Нәрсә? Алай ничек була инде? Тизрәк кайтыгыз!.. Әй Аллам!

Гыйльман. Ни булды?

Вазыйфа. Илмарның әти-әнисе килми ди бүген.

Гыйльман. Ничек «килми»? Ә туй?

Вазыйфа. Белмим.

Гыйльман. Менә сиңа яңалык! Аларсыз ничек туй үткәрергә? Кайда булган соң алар?

Вазыйфа. Командировкадан кайта алмыйлар.

Гыйльман. Ул нинди командировка? Монда малайлары өйләнә, ә алар!.. Алайса, туй да булмый!

Вазыйфа. Ничек «булмый»? Мин кичә кафега туйның акчасын түләдем.

Гыйльман. Әгәр Илмарның әти-әнисе туйга килмәсә? Аларсыз үткәрәсеңме?

Вазыйфа. Үткәрәбез! Хәзер соң! Соң, аңлыйсыңмы? Акчасы түләнгән! Поездга билет алынган.

Гыйльман. Ә билетын каян алганнар?

Вазыйфа. Илмар тапкан! Менә ичмасам егет! Әгәр аны кулдан ычкындырсак, без – җүләр! Үткәрәбез туйны аларсыз! Иң мөһиме: загс аша үткәреп, ирле-хатынлы итеп, Себергә җибәрергә. Әти-әнисе теләсә, шунда барып күрер киленнәрен!

Гыйльман. Нинди дөнья китте бу? Егетнең ата-анасын күрмичә кызны тоттырып җибәрәбез! Адәм мәсхәрәсе! Әгәр аның ата-анасы эчкече, алкаш яки карак булып чыкса?

Вазыйфа. Тфү! Авызыңнан җил алсын! Илмар әйтте бит...

Гыйльман. «Илмар әйтте»! Ул әйтер! Без аларны үз күзләребез белән күрергә, сөйләшергә тиеш.

Вазыйфа. Шулай килеп чыккач ни эшлисең? Илмарга ышанмасаң, Җиһан әйтер. Иртәгә үк белешәм, дигән иде бит.

Ишектә звонок.

Әнә килеп тә җитте.

Вазыйфа чыга да Җиһанны ияртеп керә.

Җиһан. Исәнме, Гыйльман!

Гыйльман. Исәнме!

Вазыйфа. Әйдә, үт.

Гыйльман. Йә, нәрсәләр белештең?

Җиһан. Аптыраган идем шул шундый әйбәт егет нигә картотекамда юк икән диеп. Мин бит картотекага әйбәт егетләрне генә кертәм. Ә ул юк!

Вазыйфа. Ай Алла!

Гыйльман. Сузма, әйт!

Җиһан. Әйттем мин сезгә, ата-анасын күрмичә ризалашмагыз, дип.

Гыйльман. Син сөйлисеңме-юкмы?

Җиһан. Күршеләре белән сөйләштем. Эшләгән җирләренә бардым. Онытмагыз. Мин бөтен эшемне калдырып, шушының белән ярты көн чаптым.

Гыйльман. Ничә сум әле?

Җиһан. Алты йөз!

Гыйльман. Бир шуңа.

Җиһан. Карагыз әле! Нигә шулай кызасыз? Ул Илмарыгыз хакында информация миңа кирәкме, әллә сезгәме?

Гыйльман. Безгә, безгә!

Вазыйфа. Мә!

Җиһан. Сезгә булгач, тыныч кына түләгез. Мин хәерче түгел кешедән бушлай акча алырга. Эшем өчен алам. Димәк, болай: фатирлары бер бүлмәле, Илмарның әтисе чыннан да инженер, тик бик еш эчә, айныткычтан чыкмый. Әнисе – укытучы. Бөтен кешене бала-чага кебек күреп өйрәтергә ярата, бик усал, еш кына өйрәтү урынына тупас итеп ачулана, скандал күтәрә икән. Шуңа да күршеләре, бергә эшләгән кешеләре аннан уттан курыккандай курка, аралашмаска, мөмкин кадәр аннан ераграк торырга тырыша. Иренең эчүе, хатынының усаллыгы аркасында гомер буе талашып-сугышып яшәгәннәр. Әллә ничә тапкыр аерылышып, кире кавышканнар. Илмар – аларның бердәнбер малае. Ул кече яшьтән шушыларны күреп үскән. Шуңа да әтисе белән дә, әнисе белән дә бик тупас кылана, аларны санга сукмый икән. Ә бер тапкыр исерек әтисенә кул да күтәргән.

Вазыйфа. Йа Хода!

Гыйльман. Әйттем мин сиңа! Ә син – туй да туй! Менә хәзер үткәр инде туй.

Вазыйфа. Алар чыннан да командировкадамы?

Җиһан. Нинди командировка? Өйдәләр! Ишек төбенә барып тыңлаган идем, дөбер-шатыр киләләр. Тавышлары бөтен подъездга ишетелеп тора. Әллә талашалар, әллә сугышалар.

Вазыйфа. Ай Аллам! Малайларының өйләнергә йөргәнен беләләрме, ичмасам?

Җиһан. Белмиләр һәм белергә дә теләмиләр. Мин күршеләренә: «Илмар өйләнергә йөри»,– дигәч, «Андый гаиләгә кыз бирүдән Алла сакласын»,– диләр. Әнисе Илмарга: «Теләсә кемгә өйлән, тик туй үткәрәм дип, акча сорап, хатыныңны монда китереп йөртмә!» – дип, күптән әйтеп куйган икән.

Вазыйфа. Коточкыч! Хәзер туй белән ни эшлибез? Мин бит кафега акча түләдем.

Гыйльман. Нинди туй? Нинди туй? Кызыңның башы исән каламы, шул хакта уйла. Ул бит, җүләр, үлеп гашыйк! Хәзер аларны ничек аерырга?

Вазыйфа. Әй Ходаем, күрәселәрем бар икән. Ни эшлибез инде хәзер?

Гыйльман. Туй булмый, менә шул! Бар, хәзер үк кафедан акчаңны барып ал.

Вазыйфа. Ничек алыйм? Алар минем күз алдымда ук ул акчаларга продукты алырга җибәрделәр. Йа Ходаем! Каян килеп төште соң бу бәла? Күпме акчаны җилгә ыргыттык!

Җиһан. Фәниянең туен үткәрәбез. Егете табылган. Ул хәзер монда килә.

Гыйльман. Чынлап та! Шәп идея!

Вазыйфа. Нигә килә? Ничә әйттек бит – Фәнияне аңа бирмибез.

Җиһан. Килгәч белерсез.

Сания белән Илмар керә.

Сания. Ой, әни! Беләсеңме билетларны ничек алдык? Беркайда да билет юк. Унбиш көнгә алдан сатып бетергәннәр. Ни эшләргә дип аптырап калган идек, Илмар тотты да кассир кызга шигырь сөйләде. Илмар, укы әле шул шигырьне. Искиткеч шигырь!

Илмар. Сыек кына шигырь инде. Касса янында уйлап чыгардым. Кассирның күкрәгендәге кәгазьдән исемен укыдым да... Болай:

Билетлар юк. Хәлне аңлап Наза
Табып бирде безгә билетны.
Безгә ярдәм иткән өчен, аңа
Бирсен Ходай олы бәхетне.

Сания. Илмар! Син – талант! «Ә» дигәнче шундый шигырь уйлап тап әле! Шуннан теге кыз эреде дә төште. Әллә кайларга шалтыратып бетерде. Һәм тапты билет! Тапты! Илмар, син – гений! Менә! Иртәгә – туй!

Берсекөнгә юлга! Тукта, сезгә ни булды? Нигә шулай боектыгыз? Әти? Әни?

Гыйльман. Илмар, синең әти-әниең килмимени сөйләшергә туй хакында? Без монда өстәл әзерләп аларны көтәбез.

Илмар. Мин шалтыраттым, кайта алмыйлар.

Гыйльман. Туйга да кайтмыйлармыни?

Илмар. Юк шул, булмый, диләр, безсез генә үткәрегез туйны, диләр.

Гыйльман. Ничек инде аларсыз? Бу бит туган көн түгел, туй! Гомергә бер була торган вакыйга! Син ел саен үткәрәсеңмени туйны?

Сания. Әти! Син нигә Илмарга ачуланасың? Ул үзе дә кайгыра әти-әнисенең килә алмавына. Тик кайта алмыйлар, аңлыйсыңмы?

Гыйльман. Син тик тор, мин аннан сорыйм. Ә туйның ярты хакын кем түли?

Илмар. Мин түлим. Күпме кирәк?

Гыйльман. Их син, чибәр егет! Без бит белештек, синең әти-әниең командировкада түгел, алар Уфада. Шушы минутта алар бар подъездны тутырып талашалар.

Сания. Нәрсә? Командировкада түгел? Илмар, чынмы бу?

Илмар. Сания, эш шунда...

Сания. Дөресме бу, түгелме?

Илмар. Дөрес!

Сания. Дөрес? Ничек «дөрес»? Син алдаштыңмы?

Илмар. Сания! Саниякәй, гафу ит мине! Мин алдашырга мәҗбүр булдым. Минем әти – эчкече, әни... Мин бер тапкыр өйләнергә ниятләгән идем, кызның әтиәнисе минекеләрнең кем икәнлеген белгәч, кызларын бирмәделәр. Әгәр син минем әти-әниемнең кемлеген белсәң, миңа кияүгә чыкмас идең! Гомер буе изаландым мин әти-әнием аркасында. Мин аларны дусларыма, укытучыларыма күрсәтергә ояла идем. Ләкин бит аларның шулай булуында минем гаебем юк. Хәзер минем гаилә корып яшәргә хакым юкмыни?

Сания. Илмар!

Вазыйфа. Гыйльман! Чынлап та, Илмарның гаебе юк бит монда.

Сания. Әти, әни, без Илмар белән тыныч, матур гаилә корырга телибез. Ир белән хатын бер-берсен хөрмәт иткән гаилә! Без бу хакта сөйләштек.

Вазыйфа. Гыйльман, алар бит Илмарның әти-әнисе белән яшәми, Себергә китә.

Илмар. Мин әти-әнием кебек яшәргә теләмим. Гыйльман абый, Вазыйфа апа, мин Саниянe яратам. Без тату гаилә корачакбыз, ышаныгыз миңа.

Гыйльман. Җиһан, син бит бу яктан күпне күргән, тәҗрибәле кеше. Нәрсә диярсең?

Җиһан. Минем үз фикерем бар. Ул сезгә, бәлки, ошап та бетмәс.

Гыйльман. Анысы безнең эш. Син турысын әйт.

Җиһан. Турысы шул: алма агачыннан ерак төшми.

Вазыйфа. Җиһан, син Илмарның әти-әнисе хакында белешкән өчен акча алдың. Калганын үзебез хәл итәрбез. Хуш!

Җиһан. Тукта! Минем эшем бетмәгән.

Вазыйфа. Нинди эш тагын? Ике яшь йөрәкнең мәхәббәтен җимерергә телисеңме?

Сания. Нигә безнең өйгә ояладыгыз әле? Җитмәсә, акча алып...

Җиһан. Сеңлем, мин әйткәннәрне колагыңа киртеп куй. Файдасы тиюе бар.

Сания. Китегез!

Җиһан. Кычкырма! Хуҗа әйткәч китәрмен.

Вазыйфа. Кара, нәрсә ди, кара! Гыйльман, нәрсә карап торасың? Ку шуны!

Гыйльман. Аны мин чакырдым, Вазыйфа. Вакыты җиткәч китәр.

Вазыйфа. Монда хәзер кем хуҗа? Улмы, әллә минме? Кем?

Фәния керә.

Фәния. Исәнмесез! Кермәгән җир, күрмәгән кеше калмады – эш юк! Ни булды? Нигә тынып калдыгыз? Илмар, әле генә синең элекке курсташыңны очраттым. Ул теге вакытта сине ни өчен институттан куганнарын әйтте. Комиссия тулай торакны тикшергәндә, сине исерек килеш тотканнар. Дөресме?

Гыйльман. Илмар! Мин исемә төшердем сине кайда күргәнемне! Тукталышта бер ирне тукмап киткән егет син идең! Дөрес бит?

Илмар. Дөрес! Дөрес! Минем әтием – эчкече, әнием – скандалистка! Ә мин эчеп институттан куылдым, тукталышта сугыштым! Дөрес! Сания, минем сиңа өйләнергә хакым юк! Гафу итегез мине барысы өчен дә... Хушыгыз. Хуш, Сания!

Сания. Илмар! Кая барасың? Китмә! Мин синсез... Мин җибәрмим сине! Әти, әни! Сез белмисез, Илмар шундый... әйбәт. Риза булсагыз да, булмасагыз да, мин Илмарга чыгам.

Ишектә звонок. Вазыйфа чыга да
Сәйфулланы ияртеп керә.

Сәйфулла. Исәнмесез!

Барысы бергә. Исәнме!

Сәйфулла. Фәния, син эш таптыңмы?

Фәния. Юк.

Сәйфулла. Мин бүген Омскига шалтыраттым. Үзем эшләгән фирмага. Аларга инженер кирәк. Тулай торакта бүлмә бирәләр. Тик ике-өч көннән килеп җитәргә куштылар.

Җиһан. Ишеттегезме?

Фәния. Сәйфулла, чынмы?

Сәйфулла. Ышан, Фәния.

Фәния. Әти, әни, миңа нишләргә? Уфада юк бит эш!

Гыйльман. Сеңлең упкынга ыргылырга курыкмый бит, син дә курыкма!

Вазыйфа. Син, егет, Фәниягә көчләп өйләнү өчен чакырмыйсыңмы Омскига?

Сәйфулла. Вазыйфа апа, борчылмагыз. Мин Фәниягә өйләнмим. Эшкә урнаштырам. Һәм бетте!

Вазыйфа. Алай булса, Фәния, бар! Инде ярты ел эшсез азапланасың.

Фәния. Ә нигә, барам! Рәхмәт сиңа, Сәйфулла. Чын егет икәнсең. Кайчан юлга?

Сәйфулла. Иртәгә!

Җиһан. Афәрин, Сәйфулла! Менә бу – егет! Сез биш ай эш таба алмагансыз, ә ул бер көндә тапты. Фәния, чык син аңа кияүгә. Үкенмәссең!

Фәния. Җиһан апа, җитте!

Җиһан. Әй, сезнең белән сөйләшкәнче... Гыйльман, син атамы, түгелме, әйт сүзеңне!

Вазыйфа. Юк! Сүзне мин әйтәм! Үз фирмасында эш тапкан икән, бу берни аңлатмый. Йөзеннән күренеп тора: пешмәгән синең бу егетең! Пешмәгән. Фәния аның белән гомер буе азапланачак! Балалары булса, ул эш таба алмаячак! Юк! Үзем гомер буе азапландым, кызымны азаплатмыйм. Ир булгач, тәтелдәп торсын, сөйләп сүзе бетмәсен! Җырласын да, көлсен дә. Күңелендә ни бар, ачып салсын. Әнә шундыйларның кулыннан эш килә. Акчасы да бар аларның, карьера да ясый андыйлар. Ә атагызның һәр сүзен ялынып, сорап алдым. Шул холкы аркасында гомере буе блаты булмады, эшендә мастердан югары күтәрелә алмады, бүген кызларын эшкә урнаштыра алмый. Юк!

Җиһан. Вазыйфа, эш андамыни?

Вазыйфа. Юк инде, булмагач булмый. Егетеңне ал да, бар, кит. Сау булыгыз!

Гыйльман. Минем блатым булмаса, күңелем чиста, Вазыйфа! Бар дөньямны шушы кулларым белән гадел эшләп таптым. Беркайчан да урлашмадым, алдашмадым. Ә кызларымны эшкә урнаштыру өчен юха, ялагай булырга, взятка бирергә кирәк. Мин моны гомергә дә эшләмәячәкмен. Бу егет миңа охшаган. Матур сүз сөйләми, юхаланмый. Ул сүзендә тора торган ышанычлы егет! Ә сез сукырлар, шуны да күрмисез. Ул миңа ошый! Белеп торыгыз шуны! Фәния, кил әле монда!

Фәния. Нигә?

Гыйльман. Гомер буе азапландым, имеш! Ялганчы, юха белән яшәп карарга иде сиңа! Кил!

Фәния. Әти!

Гыйльман. Кил, дим, мин сиңа! Минем сүзем шул: чыгасың шушы егеткә! Иртәгә туй! Бетте! Нигә карап торасыз? Ябыгыз пәрдәне! Тәнәфес!

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Өченче күренеш

Җиһан телефоннан сөйләшә.

Җиһан. Алло, Омск! Сезне Уфадан коллегагыз яучы Җиһан борчый. Мин Урманшиннар гаиләсе хакында белешүегезне үтенгән идем. Әйе, Фәния белән Сәйфулла ничек яшәп яталар?

Сәхнәдә Фәния белән Сәйфулла пәйда булалар.

Фәния. Кайда йөрисең моңа кадәр?
Сәйфулла. Эштә бер абзыйны пенсиягә озаттык.
Фәния. Ичмасам, искәртер идең.
Сәйфулла. Өлгермәдем.
Фәния. Фу, эчкәнсең. Кит...
Сәйфулла. Бу нинди күлмәк?
Фәния. Бүген сатып алдым. Килешәме?
Сәйфулла. Миннән сорамыйча?!
Фәния. Җүләр...

Юкка чыгалар.

Җиһан. Алло! Нефтеюганск!..

Сания белән Илмар пәйда булалар.

Сания. Кайда йөрисең моңа кадәр?
Илмар. Эштә, начальникның туган көне булды.
Сания. Ичмасам, искәртер идең.
Илмар. Өлгермәдем.
Сания. Ой, эчкәнсең, кит!

Илмар. Бу нинди күлмәк?

Сания. Бүген сатып алдым. Килешәме?

Илмар. Миннән сорамыйча?!

Сания. Җүләр!

Чыгып китәләр.

Шул ук урын. Вазыйфа өстәл әзерли. Гыйльман керә.

Вазыйфа. Кара әле былтыргы тургайларны. Берсе – парлы, икенчесе – ялгыз.

Гыйльман. Тургайлар да кешеләр кебек. Акыллылары табыша, җүләрләре аерылыша...

Вазыйфа. Шуннан?

Гыйльман. Бетте, карчык! Бабаең синнән башка беркемгә дә кирәкми!

Вазыйфа. Цех начальнигына күтәрәм, дигән иде бит кода.

Гыйльман. Күтәрә. Өстән боерык килде, дип, тик утыра. Картларны куарга, яшьләрне алырга!

Вазыйфа. Син нинди карт инде? Типсә тимер өзәрдәй ир.

Гыйльман. Пенсиягә чыкканмын, димәк, карт.

Вазыйфа. Хәзер здаравай ир ничек яшәргә тиеш икән барлы-юклы пенсиягә?

Гыйльман. Аларның анда эше юк. Миңа соңыннан аңлаттылар: кодагызның ниндидер туганы кайткан икенче каладан. Минем урынга шуны ала, диделәр.

Вазыйфа. Оятсыз! Ә былтыр туйда ничек кыланды. Сине кочаклап, иң кадерле туган, дип сөйләгән булды. Ярый, ичмасам, Илмарыбыз әйбәт кеше булып чыкты.

Гыйльман. Утыз ел гомеремне биргән завод! Кирәкмәгән әйбер кебек чыгарып ыргыттылар.

Вазыйфа. Ярый, куй, кайгырма, Гыйльман. Икебез дә пенсия алабыз, бакчабыз бар. Яшәрбез әле ничек тә. Иң мөһиме – кызларыбызны башлы-күзле иттек, яшәргә урыннары, эшләре бар. Икесе дә бәхетле.

Гыйльман. Әйе, әйе.

Вазыйфа. Әй, онытып та торам! Котлыйм!

Гыйльман. Нәрсә белән?

Вазыйфа. Туган көнең белән.

Гыйльман. Рәхмәт, карчыккаем. Әллә шуңа табын әзерлисең инде?

Вазыйфа. Әлбәттә.

Гыйльман. Кунаклар да киләме әллә?

Вазыйфа. Сәйфулла кияүнең аталарына шалтыраткан идем.

Гыйльман. Алар килсә, бик шәп булыр.

Вазыйфа. Килмиләр шул. Авылга киткәннәр. Илмарныкына эндәшеп тормадым.

Гыйльман. Кирәкләре юк!

Вазыйфа. Исеңдәме, кызларыбыз белән бергә яшәгәндә, берәребезнең туган көне булса, гел шушылай мул итеп өстәл әзерли идек.

Гыйльман. Шуннан кызларыбыз концерт күрсәтә иде, ә без аны карый идек.

Вазыйфа. Аннан торттагы шәмнәрне, кемнең туган көне, шул өреп сүндерә иде. Нинди бәхетле булганбыз!.. Хәзер без ялгыз, бер ел үтте, кызларыбызның безне кайтып күргәннәре дә юк. Ничек кенә яшәп яталар икән бәләкәчләрем? Хатларында, барысы да әйбәт, дип язалар да соң ул... нигәдер соңгы вакытларда күңелем урынында түгел.

Вазыйфа магнитофонны куя. Шунда ике кечкенә генә кыз шигырь сөйли.

Гыйльман. Карчыккаем! Кайгырма, кайтырлар. Якын түгел бит. Юлга гына күпме акча кирәк.

Вазыйфа. Сагындым икесен дә...

Гыйльман. Менә отпускыга чыгарлар да дүртәүләшеп кайтып төшәрләр. Тынычлан...

Вазыйфа. Ярый, утыр. Икәүләшеп кенә бәйрәм итик.

Гыйльман. Өченче кешенең килеп чыгуы бар.

Вазыйфа. Кем?

Гыйльман. Әле кайтып килгәндә Җиһанны очраттым.

Вазыйфа. Нәрсә кирәк аңа монда?

Гыйльман. Әйтмәде.

Вазыйфа. Бик еш очрый башлады әле ул сиңа.

Гыйльман. Очрагач нишлим соң? Сөйләшми үтеп китә алмыйм бит.

Вазыйфа. Ә нигә ул миңа беркайчан да очрамый?

Гыйльман. Мин каян белим?

Вазыйфа. Былтыр туйдан соң ураган саен килеп аптыраткан иде. Катырак сөйләшкәч югалган иде, тагын башланамы?

Ишектә звонок.

Вазыйфа. Әнә килеп тә җитте, бар, каршы ал.

Гыйльман чыга да Җиһанны ияртеп керә.

Җиһан. Исәнме, Вазыйфа!

Вазыйфа. Исән әле. Әй өлгерсең дә инде! Табын әзерләүгә киләсең дә җитәсең!

Җиһан. Минем борын шулай сизгер шул. Гыйльман! Туган көнең белән котлыйм! Синең кебек кешеләр юк хәзер. Син бит ялагай да, хәйләкәр дә түгел. Әнә шуның өчен кешеләр сине хөрмәт итә... Ярата. Һәрчак шулай гадел бул. Сау, матур, гадел бул. Һәм тагын илле алты ел яшә! Бу әле беренче генә бүләк!

Гыйльман. Кирәкмәс иде лә. Рәхмәт!

Вазыйфа. Беренче бүләк дип... Тагын ни бүләк итәргә җыенасың?

Җиһан. Тагын бер... зур бүләк була. Икегезгә дә. Сюрприз! Аз гына көтегез.

Гыйльман. Иң зур бүләкне син былтыр эшләдең инде, Җиһан! Фәниябезгә уйламаган җирдән менә дигән кияү табып бирдең бит. Зур рәхмәт шуның өчен!

Вазыйфа. Ул нинди бүләк булсын?! Аның өчен уч тутырып акчасын алды бит.

Гыйльман. Әй, аны акча белән чагыштырып буламыни?

Вазыйфа. Тик Шомбай шул киявебез. Шалтыратса да, «исәнмесез, хәлегез ничек»тән артык сүз әйтә алмый.

Гыйльман. Һәркемнең үз кимчелеге.

Җиһан. Ә сез онытмаган идегезме, былтыр ничек сөйләшкән идек?

Вазыйфа. Ничек?

Җиһан. Бер елдан аерылышсалар, мең ярымны кире кайтарам, әйбәт яшәп китсәләр...

Вазыйфа. Безнең акча юк.

Җиһан. Миндә договор бар. Анда икегез дә кул куйган.

Вазыйфа. Таларга килгән безне!

Гыйльман. Вазыйфа, тынычлан! Җиһан, син дә!.. Вакыты җиткәч түләрбез. Бер ел үтмәгән бит әле!

Вазыйфа. Акча, акча! Тончыгып үләсең бит шул акчага. Әйдә, утыр. Икәүләшеп кенә бәйрәм итәрбез дигән идем, булмады.

Гыйльман. Вазыйфа!

Җиһан. Эшләп алынган акча, Вазыйфа. Борчылма. Икенче бүләкне тапшырам да китәм.

Вазыйфа. Кайчан була икенче бүләгең?

Җиһан. Аз гына көтәргә кирәк. Шуннан? Хат язалармы? Кызларыгызны әйтәм.

Вазыйфа. Язмый ни эшләсеннәр. Әти-әниләре бит без. Шалтыраталар да, хат та язалар.

Гыйльман. Фәния сиңа хаты саен сәлам әйтә. Ә бер хатында, халык театрында «Башмагым» пьесасын карадым, яучылар – иң изге кешеләр, дигән. Ул спектакльдә яучы ялгыш күрсәтелгән, дигән.

Җиһан. Кара син аны! Дөрес әйткән бит! Яучы беркайчан да яхшы кешегә начарны димләми. Имиджын саклый. Шуның өчен акча ала бит ул. Әгәр, «Башмагым» пьесасындагы кебек, яучы бай кызын ярлы приказчик белән кавыштырса, башка беркем дә аны якын китермәс иде. Иң әйбәт йолалардан көлеп, мыскыл итеп бетерделәр. Минем исемем Җиһан, изге йолаларны реабилитировать итәм.

Вазыйфа. Сиңа киңәшем шул: ике яшь йөрәк үзләре табышып, яратышып кавыша икән – кысылма.

Җиһан. Әгәр күрә торып яхшы гаиләдә үскән балага начар гаиләдән чыккан баланы кушарга йөрсәләр, кысылмый булмый, Вазыйфа.

Вазыйфа. Син кем шулкадәр монысы яхшы гаилә, монысы начар гаилә дип атарга? Кем сиңа кешеләрне сортларга бүләргә хокук бирде?

Җиһан. Ну, анысы бер карауда күренеп тора бит.

Вазыйфа. Әйе, башкаларга күренми, ә сиңа барысы да күренеп тора. Ә менә Илмар кияү белән бит син ялгыштың. Әти-әнисе начар булса да, үзе әйбәт булып чыкты.

Җиһан. Нәрсә дим инде мин? Ашыкмыйк әле, дип кенә әйтә алам, Вазыйфа.

Вазыйфа. «Ашыкмыйк» дип нәрсә әйтергә телисең? Сания белән Илмар яхшы яшәгәч яши инде. Син ни эшләтә аласың аларны?

Җиһан. Алайга китсә, син дә Сәйфулланың Фәниягә өйләнүенә каршы идең бит. Алар да әйбәт яши.

Вазыйфа. Тик мин, синең кебек, мин генә дөресен сөйлим, мин генә акыллы, башкалар ахмак, гел ялгышалар дип мактанмыйм.

Гыйльман. Вазыйфа, куегыз әле, юк нәрсә аркасында бәхәсләшәсез!

Вазыйфа. Нигә «Вазыйфа»? Аңа әйтергә ярый да, миңа ярамый. Алайса утырыгыз икәүләшеп шушында, мин чыгып китәм.

Җиһан. Вазыйфаның бүген кәефе юк.

Гыйльман. Алай кыланма инде, Вазыйфа. Мин бит сине яратам... кызларын сагынган ул. Шуңа нервылары беткән карчыккаемның!

Вазыйфа. Мин сиңа карчык түгел!

Гыйльман. Вазыйфакаем!.. Гомер буена бер айдан озакка җибәрмәде кызларын һәм капыл гына бер елга югалтты! Аз гына түз, Вазыйфакаем! Бер айдан кияүләрне ияртеп отпускыга кайтып төшәрләр. Ну бәйрәм итәрсез дә соң шул чакта. Әйе бит!..

Вазыйфа. Ничек кенә яшиләр икән бәләкәчләрем чит җирдә, минсез...

Ишектә звонок. Гыйльман чыга да кире керә.

Гыйльман. Әнисе, сөенче! Хәзер егылып китәчәксең!

Вазыйфа. Нәрсә? Бәләкәчләремме?

Гыйльман. Сания белән Илмар кияү!

Сания белән Илмар керә.

Сания. Әни!

Вазыйфа. Бәләкәчем минем!

Сания. Әни! Мин дә сагындым, елама! Алайса, минем дә елыйсы килә.

Вазыйфа. Куанычтан ул, кызым, куанычтан! Бер ел күрмәдем бит мин сезне... Ябыгып киткәнсең! Исәнме, кияү!

Илмар. Исәнме, әби!

Җиһан. Исәнмесез! Исәнме, Илмар! Исәнме, Сания!

Сания. Нәрсә булды? Берегез дә авырмыйммы?

Вазыйфа. Нигә алай дип сорыйсың?

Сания. Котны алдыгыз бит! Уйламаган нәрсә калмады. Ә сез син дә мин яшәп ятасыз.

Гыйльман. Нәрсә сөйлисең? Бернәрсә дә аңламыйбыз.

Сания. Ә без нигә кайткан дип уйлыйсыз?

Гыйльман. Отпускы алгансыздыр.

Сания. Отпускыга хәтле тагын бер ай бар, телеграмма алдык бит. Менә!

Гыйльман. «Ашыгыч рәвештә кайтып җитегез. Әтиегез Гыйльман». Һай, кем җибәргән моны?

Сания. Син җибәрмәдеңмени?

Гыйльман. Юк! Сезне вакытсыз-нисез эштән аерырга башыма тай типмәгән.

Сания. Менә сиңа мә! Ә без әллә нәрсәләр уйлап бетердек.

Вазыйфа. Чыннан да син түгелме, Гыйльман?

Гыйльман. Юк, дим бит инде мин сезгә.

Вазыйфа. Берәрсе шаярттымы икән? Хәер, кем җибәрсә дә дөрес эшләгән! Бик сагындым бит мин сезне, кызым, кияү, килегез, икегезне дә бер кочаклыйм әле!

Сания. Әни, җитәр инде.

Вазыйфа. Ничек кайтып җиттегез?

Сания. Илмар бит кичә үк кайткан иде. Эш буенча. Мине яңа гына каршы алды.

Вазыйфа. Ничек «кичә кайтты»? Ә нигә безгә хәбәр итмәдегез?

Илмар. Без бит... Мин этиләрдә йокладым. Ә бүген көне буе эш белән йөрдем.

Вазыйфа. Ичмасам, шалтыратыр идең.

Сания. Мин шалтыратмаска куштым, көтмәгәндә бергә килеп кереп шатландырыйк дидем.

Вазыйфа. Ай, бәләкәчем минем. Рәхмәт, кияүне ияртеп алып кайткансың. И кияүкәем! Бигрәк озынаеп киткәнсең! Йә, ничек яшәп ятасыз? Сездән хат килмәгәнгә шактый вакыт узды. Шалтыратып та карамыйсыз. Әнә Фәния апаң аена ике хат язып тора. Кияү, әгәр Сания язмаса, тот та үзең яз. Оялып торма!

Илмар. Ярар.

Сания. Бик әйбәт яшибез, әни. Илмар, кил монда. Элеккечә бер-беребезне яратабыз. Ә нигә?

Вазыйфа. Җиһан, син нәрсә дигән идең әле узган ел? Дискотекада танышкан егеткә чыккан кыз бәхетсез була, дигән идеңме әле? Менә, кара, нинди матур, ничек бәхетле алар.

Җиһан. Андый гаиләләрнең унысының сигезе аерылыша, фәкать икесе генә яшәп китә. Сания белән Илмарның бәхетле ике гаилә санына... эләгүенә... мин бик шатмын.

Вазыйфа. Ә бит сине тыңласак, шушы матур гаилә тумас, ике яшь йөрәкнең язмышлары чәлпәрәмә килер иде! Мин аңладым сине, Җиһан. Сиңа, иң мөһиме, уйлап чыгарган теорияң генә дөрескә чыксын! Сиңа кешеләрнең язмышлары чәлпәрәмә килүе чүп тә түгел.

Җиһан. Мин бит сиңа, минем сүзләргә ышан, димим. Теләмәсәң ышанма. Кем дөрес икәнлеген тормыш күрсәтер.

Вазыйфа. Нигә син үзеңнең ялгышканыңны танырга теләмисең? Тормыш — менә! Күрсәтте бит инде — син дөрес түгелсең! Таны инде шуны!

Гыйльман. Вазыйфа, ни булды әле бүген сиңа, зинһар, тынычлан!

Вазыйфа. Үзен башкалардан акыллы санамасын! Вәт шул!

Сания. Ә нигә килгән ул безгә? Бәлки, сезгә китәргә кирәктер? Күрмисезмени, әниемнең нервысына тиясез.

Җиһан. Вакыты җиткәч китәрмен, Сания. Илмар, ә нигә син шигырь сөйләмисең әле?

Илмар. Илһам юк, Җиһан апа, илһам!

Җиһан. Аңлашылды!

Сания. Илмар! Сумкаларны эчтәге бүлмәләргә кертеп куй!

Ишектә звонок. Гыйльман чыга да Фәнияне ияртеп керә.

Фәния. Әни!

Вазыйфа. Фәния! Өнемме бу, төшемме?

Гыйльман. Искиткеч!

Фәния. Сания!

Сания. Апам!

Фәния. Шундый сагындым бөтенегезне дә! Илмар, исәнме! Җиһан апа! Сез дә монда! Сезне шундый күрәсем килгән иде! И-и, ничек күңелле яшисез! Тукта, ә ни булды?

Вазыйфа. Берни дә булмады. Әллә син дә телеграмма алдыңмы?

Фәния. Котны очырып шундый телеграмма сугалармы? «Ашыгыч рәвештә кайтып җитегез!» Бөтенегез дә исән-саумы соң?

Вазыйфа. Аллага шөкер! Нинди изге кешенең эше икән соң бу? Минем кызларымны үлеп сагынганымны белгән кебек суккан! Фәния, син ялгыз кайттыңмыни?

Фәния. Тукта! Ә Сәйфулла сездә түгелмени?

Вазыйфа. Ничек бездә булсын ул?

Фәния. Йа Хода! Берәр хәл булдымы икән?

Вазыйфа. Яхшылап аңлат! Кайда калдырган идең соң аны?

Фәния. Телеграмма килгәндә, Сәйфулла Екатеринбургта иде, командировкада. Мин аңа шалтыраттым. Сәйфулла Екатеринбургтан бүген иртән килеп төшәргә дә мине каршы алырга тиеш иде. Ә ул... каршы алмады.

Вазыйфа. Әй Алла! Куй, Фәния, елама.

Гыйльман. Бәлки, самолёты очмагандыр?

Фәния. Очкан, очкан, мин белештем. Гамьсез! Шомбай! Берәр җирдә сыра эчеп утырадыр әле! Килеп кенә күренсен!

Вазыйфа. Оятсыз! Менә сез мактаган кияү!

Җиһан. Фәния, борчылма шулай! Бәлки, Сәйфулланың ашыгыч эше килеп чыккандыр.

Фәния. Аның монда нинди ашыгыч эше булсын?!

Вазыйфа. Балта остасының! Эше булса, әнә Илмар кияүнеке кебек булсын. Ул бит эшен дә эшләгән, хатынын да каршы алган!

Җиһан. Тынычланыгыз, хәзер килеп җитәр ул. Сәйфулла соңлый дип бәйрәмне бозмыйк әле.

Сания. Бәйрәм?

Фәния. Нинди бәйрәм?!

Вазыйфа. Оныттыгызмыни?

Җиһан. Вазыйфа, тукта! Үзләре хәтерләр микән?

Фәния. Әтинең туган көне бит!

Сания. Әти! Кил әле, үбим берне!

Фәния. Котлыйм, әти!

Гыйльман. Рәхмәт, рәхмәт, кызларым!

Илмар. Котлыйм!

Гыйльман. Рәхмәт!

Вазыйфа. Йә, утырышыгыз инде. Белгән кебек табынны киң итеп әзерләгән идем.

Гыйльман. Бик шатландырдыгыз әле кайтып төшеп. Рәхмәт. Хәтта күзләремә яшьләр килде. Тик менә эштән генә кудылар...

Сания. Ничек?

Фәния. Кайчан?

Сания
Фәния } *(бергә)*. Ни өчен?

Вазыйфа. Пенсиягә чыккан дигән булып, Илмар кияү, синең икетуган абыең, үзебезнең кодабыз куган бит.

Фәния. Кода? Әти бит шундый егәрле, эшчән. Нигә куган?

Вазыйфа. Илмар, сөйләшеп кара әле абыең белән. Кодасын куып читтән кайткан туганын алган, диләр. Аңа китсә, бабаң да аңа туган бит...

Сания. Үз туганын?..

Илмар. Ярар, сөйләшермен... Сания, миңа... Гафу итегез, миңа эш буенча китәргә кирәк...

Вазыйфа. Ул ни дигән сүз, кияү? Бабаңның туган көнен бәйрәм итәбез бит...

Илмар. Миңа бик-бик...

Вазыйфа. Юк-юк! Яраткан киявемне беркайда да җибәрмим! Әйдәгез, утырышыгыз!

Илмар. Минем вакытым юк.

Сания. Чак кына... көт, Илмар!

Ишектә звонок.

Фәния. Сәйфулла!

Фәния чыгып китә дә Сәйфулла белән керә.

Сәйфулла. Исәнмесез!

Фәния. Кайда йөрдең? Нигә каршы алмадың?

Гыйльман. Фәния, тукта. Кешегә тын алырга бир.

Вазыйфа. Берәү булса сине өйгә дә кертеп тормас иде!

Гыйльман. Вазыйфа!

Вазыйфа. Нәрсә «Вазыйфа»! Кызың, өстәл зурлыгы ике чемодан күтәреп, чак кайтып керде, ә ул!.. Оятың юк икән, кияү!

Сәйфулла. Исәнме, әби!

Вазыйфа. Исәнме, исәнме! Бер-берегезне сакларга тиешсез, ихтирам итәргә! Шунсыз гаилә корып булмый ул!

Сәйфулла. Аңладым, әби. Бабай, исәнме! Туган көнең белән! Бу — Фәния белән икебездән!

Гыйльман. Исәнме, кияү! Кара, кызларым оныткан, ә кияү хәтерли минем туган көнемне. Рәхмәт, кияү!

Сәйфулла. Сания, Илмар, нигә болай боегышып торасыз? Исәнмесез!

Илмар. Сәлам!

Сания. Вәт җизнәй, ә! Кайда югалдың?

Сәйфулла. Җиһан апа! Исәнмесез!

Җиһан. Исәнме, Сәйфулла! Шуннан?

Сәйфулла. Булды!

Фәния. Исәнлекләрен сорашып бетердеңме?

Сәйфулла. Бетте, хатын!

Фәния. Хәзер аңлат! Кайда йөрдең?

Сәйфулла. Тукта, Фәния. Хәзер аңлатам.

Фәния. Йә, нигә сузасың? Көтәбез!

Сәйфулла. Фәниякәй, үпкәләмә. Эшем булды.

Фәния. Нинди эш? Мине каршы алудан мөһимрәк нинди эш ул? Мин бит сиңа әйттем, сумкаларым авыр дип!

Сәйфулла. Фәния, соңыннан аңлатырмын. Хәзер... әйтә алмыйм.

Фәния. Нигә әйтә алмыйсың? Юк, сөйлә! Хәзер үк! Күрсеннәр синең кемлегеңне!

Сәйфулла. Фәния, бәйләнмә инде, әйттем бит!

Вазыйфа. Кара, нәрсә ди! Юаш, симерсә, капкага сыймый, дигәннәр борынгылар.

Фәния. Ни өчен? Аңлат, ни өчен?

Сәйфулла. Уңайсыз була.

Фәния. Ничек «уңайсыз»? Кемгә?

Сәйфулла. Э-э... Мондагы бер кешегә.

Вазыйфа. Син, кияү, уратып сөйләшмә. Әйтсәң әйт турысын, әйтмисең икән, әнә барыр юлың!

Җиһан. Әйтә бит, вакыты җиткәч сөйләрмен, ди. Нигә бәйләнәсез әле кешегә?

Вазыйфа. Ә син нигә кысыласың? Син кем монда? Бер ел элек эшлисе эшеңне эшләдең, кесә тутырып акчасын алдың. Хәзер ни кирәк сиңа бездә? Әгәр алар аерылышса, мең ярымны кайтарасың, белеп тор! Хәзер, бар, чыгып кит.

Гыйльман. Вазыйфа! Ул бит кунак!

Вазыйфа. Нигә аны яклыйсың? Ул сиңа кадерлерәкмени? Әйт! Кызларың, кияүләрең алдында әйт!

Гыйльман. Вазыйфа, җүләрләндеңме әллә?

Вазыйфа. Әйе, мин – җүләр! Синең Җиһаның гына акыллы!

Фәния. Әни, тынычлан! Нигә алай итәсең?

Вазыйфа. Җитте! Түземлегем бетте! Күпме түзәргә мөмкин? Атагыз гомер буе шушы хатын дип үлде! Ул акыллы, ул матур! Ул шулай да, ул болай! Нигә шуңа өйләнмәдең? Ул җүләр түгел шул сиңа чыгарга! Синең бит кулыңнан бер эш килми. Шәп булсаң, балаларыңны җәһәннәмгә җибәрми, янында калдырыр идең.

Гыйльман. Вазыйфа!

Вазыйфа. Кит! Сибайдан китеп, монда ун ел тыныч яшәгән идем, тагы эзләп тапкан, чәчрәгере! Кызларыбызга кияү эзли, имеш! Алар узган елны ук кияүле булды. Бүген ни кирәк сиңа монда? Аерырга килгән ул безне, Гыйльманны тартып алырга!

Җиһан. Кирәкми миңа синең Гыйльманың! Минем ирем бар.

Вазыйфа. Синең кебек хатыннар...

Гыйльман. Тукта хәзер үк!

Вазыйфа. Әйе, миңа туктарга, аңа сөйләсә дә ярый. Шултикле яраткач, бар, кит алайса янына, яшәгез бергәләп! Мине мыскыл итеп нигә аны өеңә чакырдың? Чыгып китегез. *(Чыгып китә.)*

Гыйльман. Ну, Вазыйфа!.. Юк җирдән!.. Җиһан, үпкәләмә аңа... Фәния, Сания! Аңлыйсызмы... әниегез бик сагынды сезне... Шуңа күрә...

Җиһан. Җүләр! Сезгә ярдәм итсәм, аның өчен акча алдым. Әгәр бушка эшләсәм, әйтер иде...

Сания. Акчаны алгач, бүген сезгә ни кирәк?

Фәния. Сания! Ул бит олы кеше!

Сания. Ул әнинең нервысына тия! Китсен!

Фәния. Юк! Җиһан апа миңа иң кадерле кеше! Җиһан апа, ачуланмагыз...

Сания. Эгоистка син!

Гыйльман. Сания! Җитте сиңа!

Сания. Синме? Син яратмыйсың әнине! *(Китә.)*

Гыйльман. Җүләр!

Җиһан. Ярый, Гыйльман! Мин, чынлап та, китим...

Гыйльман. Ичмасам, син кыланма, Җиһан. Берни белми сөйләнәләр. Туган көнне үткәрәбез бит. Хәзер тынычлана алар...

Илмар. Менә сиңа талашмаган тату гаилә!

Гыйльман. Нәрсә?

Илмар. Минем әти белән әнидән көлгән буласыз! Ә үзегез соң! Мәсхәрә!

Гыйльман. Син!.. Кабатла әле!

Илмар. Картлач, әтәчләнмә! Клоуннар! Кыланган буласыз. Без болай!.. Без шулай! Клоуннар!

Гыйльман. Мин бит сине!..

Фәния. Әти!

Сәйфулла. Илмар!

Җиһан. Син, чибәр егеткәй, нигә батыраеп киттең әле?

Илмар. Кабатла, имеш! Кирәк икән, йөз тапкыр кабатлармын!

Гыйльман. Молокосос! Югал күземнән!

Илмар. Ой, курыктым! Беләсегез килсә, без Сания белән...

Сания керә.

Сания. Илмар! Тукта!

Гыйльман. Тотма! Китсен! Андый киявең булганчы...

Вазыйфа керә.

Вазыйфа. Эндәшмә! Кияү, кил! Монда миңа иң якын кеше син, Илмар! Кил яныма. Ярый, бетте! Талашып дөнья үзгәртеп булмас. Яшәргә кирәк. Утырышыйк.

Гыйльман. Туган көн булмады бу!.. Күрәсең, минем чынлап та кирәгем калмагандыр... Эштә дә, өйдә дә...

Җиһан. Гыйльман, тынычлан. Сине бит эшкә кире алдылар.

Гыйльман. Эшкә? Кире алдылар?

Илмар. Каян беләсез?

Җиһан. Сәйфулла, сөйлә! Хәзер яшермәсәк тә була.

Сәйфулла. Бабай, мин әле генә сезнең завод директорында булдым. Хәлне аңлаткан идем, шунда ук цех начальнигын чакырды да сезне эшкә кире алырга кушты. Ә урыныгызга алынган... туганны куарга.

Гыйльман. Нәрсә? Чынмы бу?

Сәйфулла. Чын, бабай. Иртәгә үк эшкә чыгарга.

Гыйльман. Кияү! Зур рәхмәт!

Җиһан. Менә бу ичмасам бүләк!

Вазыйфа. Рәхмәт, кияү!

Илмар. Син нәрсә? Чынлап сөйлисеңме?

Сәйфулла. Әлбәттә.

Фәния. Ә син каян белдең әтинең эштән куылганын?

Җиһан. Кичә кич Екатеринбургка мин шалтыраттым. Завод директоры Сәйфулланың классташы бит. Ярдәм ит, дидем.

Фәния. Сәйфуллакаем! Кил, үбим үзеңне!

Сәйфулла. Фәния, гафу ит. Үч иткәндәй, синең поезд килер чакта гына кабул итте директор. Соңрак барыр идем янына, Мәскәүгә ашыга.

Фәния. Ә нигә аны килгәч тә аңлатмадың?

Сәйфулла. Чөнки... чөнки бабайны куып, аның урынына...

Илмар. Мин урнаштым. Шуннан?

Сания. Син?!

Вазыйфа. Нәрсә? Юк! Ышанмыйм! Син бит шаярасың, кияү. Шулай бит?

Илмар. Ул бит күптән пенсиядә! Ә яшьләргә эш юк!

Фәния. Котлыйм, әти!

Илмар. Иртә куанасың! Мин моны бу килеш калдырмыйм.

Вазыйфа. Коточкыч! Илмар кияү! Нәрсә сөйлисең син? Син бит Нефтеюганскида эшләп йөрисең. Кайчан кайттың? Нигә?

Илмар. Без аерылыштык.

Вазыйфа. Нәрсә? Аерылыштыгыз? Юк-юк! Мин ышанмыйм! Сез бит пар килгәнсез! Сания! Илмар! Мин каршы! Аерылышмыйсыз! Юк!

Сания. Син бит берни дә белмисең! Мин яшәмим аның белән!

Илмар. Кирәгең бар иде. Синең белән беркем дә яшәмәячәк, дура!

Сания. Син үзең!.. Ул миңа... кул күтәрә, әни!

Вазыйфа. Йа Хода!

Илмар. Сабак булыр! Икенче авызыңны үлчәп ач!

Сания. Пошёл вон!

Илмар. Үрнәк гаилә! Бәхет телим! Ха-ха! Пока! *(Чыгып китә.)*

Фәния. Оятсыз!

Сания. Әни, әнием!

Вазыйфа. Әй, кызым! Нәрсә эшләп беттегез соң?

Сания. Ул миңа... сукты! Мин заводына барып әйттем. Шуннан эшеннән кудылар... Без аерылыштык!

Вазыйфа. Әй, кызым! Шундый матур пар идегез бит... Мин сезгә карап куанып туя алмый идем. Ә сез...

Гыйльман. Аерылышкач, нигә аны монда алып килеп йөрисең?

Сания. Сезне җәлләдем... Шундый матур туй үткәрдегез. Ә без... Бер ел да яшәмичә... Оялдым... Илмардан үтендем, әлегә сиздермик...

Фәния. Менә сиңа кирәк булса...

Вазыйфа. Ярый! Булды!.. Бетте!.. Бүген без өстәл артына утырабызмы-юкмы?

Гыйльман. Әйе, утырабыз. Бер дурак китте дип бәйрәмне бозып булмас. Башта шуны ачыклыйк. Кызларга телеграмманы, Җиһан, син җибәрдеңме?

Җиһан. Әйе. Мин бит күреп йөри идем сез кызларыгызны ничек сагынганыгызны. Аларны кайтарып алырга кирәк дип уйлый идем. Шулчак сәбәп табылды. Туган көн! Һәм телеграмма суктым.

Гыйльман. Рәхмәт! Тик моның өчен нигә акча сорамадың?

Җиһан. Их син, Гыйльман! Бу сиңа икенче бүләгем.

Гыйльман. Рәхмәт!

Җиһан. Коллегаларым аша мин Фәниянең дә, Саниянең дә ничек яшәгәннәрен белә идем. Санияләргә ашыгыч ярдәм кирәк иде. Шуңа күрә чакырдым мин аларны. Ләкин без соңардык.

Гыйльман. Моның шулай бетәсе былтыр ук билгеле иде.

Сания. Әти!

Гыйльман. Бетте! Моны сызып ташладык һәм оныттык!

Вазыйфа. Сания кызым, үзебез гаепле. Җиһан, гафу ит мине! Син хаклы булып чыктың. Сәйфулла кияү, чын егет икәнсең! Бәхетле булыгыз!

Сания. Гашыйк булу гына мәхәббәт түгел икән шул...

Фәния. Мәхәббәт хөрмәт итүдән башлана. Җиһан апа миңа Сәйфулланы тапмаса, әтием мине аңа көчләп бирмәсә, мин бүген иң бәхетсез кеше булыр идем. Рәхмәт сезгә!

Сания. Җиһан апа, миңа да тап әле шунда берәр балта остасы!

Җиһан. Булдырабыз аны! Сездән – акча, миннән – букча! Сез сорагыз, мин табам! Кызлар, егетләр! Кемгә акыллы кияү, әдәпле кәләш кирәк? Фирма «Син», син плюс мин! Шалтыратыгыз! Безнең телефон: 252–97–02!

Музыка.

Пәрдә.

Талкас, 1999

ӘСТӘГЪФИРУЛЛА!

Комедия, ике пәрдәдә

Катнашалар:

Иркә.
Бикә.
Шәмсия.
Ләлә.
Даян.
Азат.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче күренеш

Бүлмә. Иркә берүзе.

Иркә. Җиденче ярты!.. Кайда йөрергә мөмкин?

Телефон шалтырый.

Алло? Альберт?.. Исән әле... Иремме?.. Юк, командировкада түгел. Эшләп йөри. Хәзер кайтырга тиеш... Юк... Юк, дим! *(Трубканы куя.)* Кара син аны!.. Оятсыз!.. Җиде тула!.. Ни булды икән?

Ишектә звонок. Иркә чыга һәм Бикә белән керә.

Бикә. Фатирыгыз котлы булсын, Иркә!
Иркә. Рәхмәт, Бикә апа.
Бикә. Мин яшәгән подъездга әләгүегезне әйт әле. Иреңне бер генә күреп калган идем. Хәзер яхшылап таныштырырсың.
Иркә. Ярый.

Бикә. Әллә таныштырырга теләмисеңме?
Иркә. Мин риза да ул. Даян...
Бикә. Нәрсә?
Иркә. Сәер холыклы бит. Теге чакта бер күрде дә... Бу... хәйләкәр апага охшый,ерактарак йөре, диде.
Бикә. Кеше аерган була икән, хөрәсән! Хәйләкәр булмасаң, яшәрсең бу дөньяда. Ярый. Аңа калган кәнебез юк. Бүген кич нәрсә эшлисең?
Иркә. Концертка билет алган идем. Даян нигәдер озаклады.
Бикә. Ирләр шул инде ул. Өйләнгәч, бер ай вакытында кайталар да... Зарплатасы күпме?
Иркә. Йөз дә илле.
Бикә. Дворникмы әллә?
Иркә. Инженер.
Бикә. Бахыр! Бездән, хәерче сатучылардан, йөз сумга кимрәк икән, ә? Җитмәсә, син бушка май, колбаса... Ә аның читтән керер җир юк инде.
Иркә. Кайдан булсын?
Бикә. Акча таба алмый икән, өй эшләрен куш. Идән юдыр, кер. Ашарга пешерсен. Баланы – яшьтән, ирне – баштан, дигән олылар. Онытып торам. Сиңа йомыш белән килдем бит мин.
Иркә. Әйт, Бикә апа.
Бикә. Ни бит әле. Менә син концертка билет алгансың, көтәсең. Ә ул шушы минутта, мөгаен, икенче хатын белән...
Иркә. Юк, Даян андый түгел.
Бикә. Бөтен ирләр дә шулай.
Иркә. Без бер-беребезгә тугры булырга сүз куештык.
Бикә. Хи-хи-хи...
Иркә. Нигә көләсез?
Бикә. Альберт исемә төште.
Иркә. Андамы... Анда мин Даянга чыкмаган идем.
Бикә. Ярый, кызарма инде. Мин бит берни әйтмим. Булган да беткән. Даян белми бит.
Иркә. Анда да сез, артист, дип, сөйләшеп утырабыз, дип алып бардыгыз да...

Бикә. Матурлыгың гаепле, Иркәкәй. Чибәр булмасаң... Әйткәнемчә, бүген базарда ике әрмән белән таныштым. Ул матурлыклары, ул акчалары... Ресторанга алып кергән иделәр. Илле сумны ташладылар да: «Сдача не нада!» – диделәр.

Иркә. Нәрсәгә сөйлисең боларны?

Бикә. Алар мине кичкә кунакка чакырды. Яшьрәге бигрәк чибәр. Көмеш калакка салып йот! Ул бөдрә чәч, ул сын, ул төс... Миңа матур гына подругаңны алып кил, дигән була.

Иркә. Мин бармыйм.

Бикә. Озак булмабыз. Әзрәк сөйләшеп утырырбыз да...

Иркә. Минем ирем бар.

Бикә. Даян берни сизмәс. Көттем-көттем дә эзләргә чыктым, диярсең.

Иркә. Юк, дидем бит.

Бикә. Җүләр! Синдәге матурлык миндә булса...

Иркә. Юк-юк, үгетләмәгез. Альберт янына барганыма үкенеп бетә алмыйм.

Бикә. Ул сине алтынга күмәчәк!

Иркә. Әйттем бит.

Бикә. Әгәр бармасаң... Даянга Альберт хакында...

Иркә. Нәрсә?.. Әйтегез. Юк, үзем әйтәм.

Бикә. Җүләр, шаяртам бит. Ярый. Шулай да аларның телефон номерын калдырам. Әгәр кире уйласаң шалтыратырсың.

Иркә. Кирәкми.

Бикә. Яшь чагыңда йөреп кал, җүләр! Гомер узгач аңларсың әле. Ярый, мин киттем. *(Китә.)*

Телефон шалтырый.

Иркә. Алло? Кем? Альберт? Тагын синме? Нәрсә кирәк? Мин кияүгә чыктым! Беләсеңме? Миңа аннан башка беркем дә кирәкми! Шалтыратма башка! Әйе, соңгы сүзем! *(Трубканы куя.)* Вот нахал!.. Билет аласымны белә иде бит... Юри соңлыймы?..

Даян керә.

Даян. Иркә!
Иркә. Нигә озакладың?
Даян. Футболга билет алдым. Ярты сәгатьтән башлана.
Иркә. Без кичә ничек сөйләшкән идек?
Даян. Яшьләр уйный! Шундый кызык булачак!
Иркә. Бүген Уфа артистлары килгән. Мин билет алдым!
Даян. Күрмәгән концертыбызмы? Ә менә футбол...
Иркә. Сөйләмә шул футбол хакында! Концертка барабыз, белдеңме?
Даян. Ну, Иркә! Мин бу матчны күрмәсәм...
Иркә. Син аны күрмәячәксең!
Даян. Бу... Бу мөмкин түгел.
Иркә. Мөмкин.
Даян. Иркә, без бар егетләр...
Иркә. Бетте, җыен.
Даян. Юк, мин концертка бармыйм.
Иркә. Барасың!
Даян. Мин бу уенны ярты ел көттем.
Иркә. Беләсең килсә, шушы билетны син барып алырга тиеш идең. Ә аның артыннан ярты көн мин йөрдем. Син шуңа карамастан... Барасыңмы-юкмы?
Даян. Иркә, аңла...
Иркә. Алайса... Менә концерт! Бар футболыңа!
Даян. Иркә!..
Иркә. Син җансыз! Күралмыйм сине! Кит яныймнан. Кит! Бар, бар, йөгер футболыңа! Ә мин... Ә минме! Кайда барырга белермен! Алло! Бикә апа! Бу мин — Иркә! Син андамы? Мин хәзер барам.
Даян. Иркә! Тукта! Мин бит...
Иркә. Иярмә! *(Китә.)*
Даян. Их!.. Нәрсә эшләргә? Хәзер футболга да барасы килми... Иркә!

Даян китә. Шул ук урын. Сәхнә буш. Азат керә.

Азат. Ишекләре ачык. Беркем юк. Менә кайда ул коммунизм!.. *(Телефоннан сөйләшә.)* Алло! Хәким? Хәлләр ничек? Әллә тулай торакка барып чыгабызмы?

Кызлар янына. Даянның фатирыннан. Үзе күренми әле. Хатынымы? Анысы да юк. Иркәме? Ха-ха... Шәп инде, шәп. Синең генә күзең төшмәгән аңа... Шәһәрнең иң матур кызы. Үзең беләсең, артыннан күпләр йөгерде... Ә ул тотты да шушы бозауга... Үземә каратам да аерам әле Даяннан! Ничекме? Даянны командировкага җибәрәм, шуннан тотынам. Ха-ха-ха! Өйләнергә башыма тай типмәгән. Теге противогаздан чак котылдым. Ярый фатирлы булдым. Әтисе туйга ике бүлмәле фатир бүләк иткән иде бит. Шуны бүлештек... Өйләре ничего. Келәмнәре бар. Иркә сатучы бит. Таба инде. Әнә офыкта хуҗа күренде. Ярый, пока.

Даян керә.

Азат. Шәп яшисез икән, ишек ачык, беркем юк.

Даян. Онытканмын бикләргә...

Азат. Кайтып барам да, тукта, кереп чыгыйм әле, нигә футболга килмәде икән дим.

Даян. Футбол кайгысы юк әле.

Азат. Ни булды?

Даян. Иркә югалды.

Азат. Ничек?

Даян. Чыгып киткән иде, таба алмыйм.

Азат. Үпкәләштегезме?

Даян. Әйе.

Азат. Ярый, кайгырма. Төнлә ярашырсыз.

Даян. Нигәдер борчак пешми безнең. Ул бер төрле, мин – икенче...

Азат. У-у! Шулай укмыни? Аерылышыгыз.

Даян. Ничек? Мин бит аны яратам.

Азат. Әй беркатлысың да инде! Кара әле, син нигә бүген Барташевская белән минем арага кысылдың?

Даян. Нигә гаризага кул куймадың?

Азат. Димәк, шулай кирәк.

Даян. Кеше перевод белән Киевка күчәргә тели. Нигә каршы төшәсең?

Азат. Нигә аның өчен борчыласың? Әллә күзең төштеме? Шук малай! Кара син аны! Өйләнүеңә кай-

чан. Шәһәрнең иң чибәрен эләктердең. Шуңа да карамастан... Оятсыз!

Даян. Юкны сөйләмә әле. Ире үлгәч, Татьяна ялгыз калды. Ул әти-әнисе янына күчәргә тели. Гаризасына кул куй.

Азат. Юк.

Даян. Нигә?

Азат. Сәбәбе бар.

Даян. Нинди сәбәп?

Азат. Күпне белсәң, тиз картаерсың.

Даян. Сәбәбең юк синең. Үзеңне начальник итеп күрсәтәсең килә.

Азат. Бар шул сәбәп... Мәсәлән, Татьяна бик чибәр.

Даян. Нәрсә?

Азат. Чибәр, дим. Ишетмәдеңмени?

Даян. Бу сәбәп түгел.

Азат. Дөресен әйтәм. Ул миңа ошый.

Даян. Әһә, аңладым, син аны яратасың. Бик шәп. Сез бик матур пар булыр идегез. Өйлән.

Азат. Бик кызык кеше син. Һәр ошаган хатынга өйләнә башласаң...

Даян. Мин сине аңламыйм. Өйләнергә теләгең юк, үзең «ошый», дисең. Алайса, нигә тотасың аны? Аңла, аңа хәзер монда кыен. Һәрнәрсә үлгән ирен хәтерләтә. Кул куй, Азат.

Азат. Кешечә сөйләшсә куям.

Даян. Нәрсә эшләде ул сиңа шулкадәр?

Азат. Чибәрмен дигәч тә... Перевод булмаячак! Эшләсен положенный ике аен. Шуннан Украинасына кайтыр. Вот так!

Даян. Аңламадым.

Азат. Кунакка чакырган идем, баш тарткан була. Хан кызы!

Даян. Ә нигә чакырдың?

Азат. Шашка уйнарга.

Даян. Аның ире үлгәнгә биш көн!

Азат. Ул ирен күмгәч тә онытты. Украинада кемедер бар. Тизрәк кайтып шуңа чыгарга ашыга.

Даян. Син ничек... Бу бит кайгылы кешедән көлү!

Азат. Дивана! Хатыннарны белмисең, сөйләнәсең.

Даян. Беләм! Алар чәчәк сыман матур...

Азат. Алар кычыткандай яман!

Даян. Алар сөт кебек саф.

Азат. Барысы да хыянәтче!

Даян. Юк! Сине бер кыз алдаган. Шуңа барысына да ачуың килгән.

Азат. Синең ничә хатын-кызың булды?

Даян. Ничек?

Азат. Ну... Күпмесе белән йокладың?

Даян. Бергәме?

Азат. Аерым!

Даян. Иркәдән башкага якын барганым юк.

Азат. Кит, чынмы?

Даян. Нигә аптырыйсың? Ә син үзең күпме белән?

Азат. Туксан бише белән. Авызыңны яп.

Даян. Син шаярасың.

Азат. Сана.

Даян. Бу нәрсә?

Азат. Донжуан исемлеге. Минем белән булган хатын-кызлар.

Даян. Сәлимә, Зилә, Нәсимә, Өммия, Галия, Галия, Галия... Нигә өч тапкыр?

Азат. Өч Галияне яраттым. Ә иң күбе Света исемләре булды. Унике.

Даян. Света, Света, Света... Иркә?

Азат. Курыкма, синең хатының түгел.

Даян. Ә кем?

Азат. Ял йортында килеп эләккән иде. Стәрледән. Ире бар. Чат ябышты. Чак котылдым.

Даян. Ире бар көе?

Азат. Ирлеләр ишшу да яман.

Даян. Иренә, иң якын кешесенә хыянәт итеп... Соңыннан ничек күзенә карар?

Азат. Башта гына өч тапкыр каравы кыен, диләр. Соңыннан күнегәләр.

Даян. Юк. Бөтен хатыннар да алай түгел. Ышанмыйм.

Азат. Мулла! Белеп тор: бөтенесе дә хыянәт итә. Шуңа, энем, үзең дә йоклап йөрмә. Белдеңме?

Даян. Юк-юк! Гаиләдә гаделлек юк икән, нигә яшәргә? Бер-берсенә тугры кешеләр санап бетергесез. Мәсәлән... Иркә белән мин. Без бер-беребезгә гомергә тугры булып калачакбыз.

Азат. Хе! Барташевская, ире үлгәч, биш көн тугры булып маташа. Ә Иркә, син үлә калсаң, ярты сәгатьтән кияүгә чыгачак.

Даян. Юкны сөйләмә.

Азат. Әйдә бәхәсләшәбез.

Даян. Моны тикшереп булмый.

Азат. Була.

Даян. Ничек?

Азат. Сине үтерәбез.

Даян. «Үтерәбез»?

Азат. Юк, үзең үләсең.

Даян. Агу эчепме?

Азат. Юк-юк, курыкма...

Даян. Асылын, димәкчесеңме?

Азат. Тынычлан. Син үлмисең. Үлгән булып кыланасың.

Даян. Ә-ә... Шуннан?

Азат. Ә мин Иркәгә: «Миңа чык»,— диям.

Даян. Ул сиңа ачуланачак.

Азат. Әлбәттә, башта кыланачак.

Даян. Куып чыгарачак!

Азат. Янә ялгыштың, дускай.

Даян. Ә нәрсә эшләячәк?

Азат. Риза булачак.

Даян. Иркәме?

Азат. Әйе. Синең сөекле хатының. Син үлүгә ярты сәгать үткәч.

Даян. Мин аңлыйм, бер елдан риза булуы мөмкин. Әмма бүген үк... Юк.

Азат. Бәхәсләшәбезме?

Даян. Тукта... Иркә... Бүген үк... Ышанмыйм. Әйдә!

Азат. Булды. Әнә Иркә кайтып килә. Ят шушында.

Даян. Ничек, хәзер үкме?

Азат. Әлбәттә. Башлыйбыз экспериментны.

Даян. Тукта. Син чынлапмы?

Азат. Куркасыңмы?

Даян. Нигә куркыйм ди?

Азат. Дөрес булыр дип шүрлисең?

Даян. Беренчедән, дөрес булмаячак!

Азат. Ят!

Даян. Менә бәйләнде! Ятам, ятам! Ялгышуыңны исбат итү өчен ятам!

Азат. Диванга түгел. Син хәзер мәет. Идәнгә. Күзләреңне йом!

Даян «үлде». Тик ул үзенең «үлек» эпизодында тик ятмый. Сәхнәдәге вакыйгаларга һәм репликаларга реакция бирә. Иркә күрмәгәндә торып утыра, хәтта торып китә, сүзсез генә Азат белән сөйләшә, бәхәсләшә, хәтта кизәнеп тә ала. Азат та җавапсыз калмый. Ул, йә Иркәне кочаклаган килеш, йә Иркәнең артына чыгып, Даян белән тавышсыз гына сөйләшеп ала. Даянның тере икәнлеге сизелердәй булса, Азат Иркәгә артына әйләнеп карарга бирми. Иркә Азатның сәер кыланышларын күрә, нидер сизенә, әмма эшнең төп сәбәбен ахыргача аңлый алмый.

Иркә керә.

Азат. Исәнме, Иркә!

Иркә. Исәнме, Азат!

Азат. Иркә... син әзерлән.

Иркә. Нәрсәгә?

Азат. Эш шунда... Дөньяда төрле хәлләр була.

Иркә. Нәрсә сөйлисең?

Азат. Егылган артыннан егылып булмый. Киткән артыннан китеп булмый.

Иркә. Нәрсә булды?

Азат. Тынычлан, Иркә. Бөтенесе дә әйбәт. Хәзер мин сиңа бер сүз әйтәм. Син башта утыр.

Иркә. Нигә?

Азат. Утырган кеше егылмый.

Иркә. Тукта. Даян кайда?

Азат. Китте.

Иркә. Кайда китте?
Азат. Бик еракка.
Иркә. Футболга!
Азат. Юк! Ераграк.
Иркә. Кайда? Кайчан кайта?
Азат. Аннан кайтып булмый.
Иркә. Нигә?
Азат. Ул гүргә керде.
Иркә. Нәрсә?
Азат. Дөнья белән хушлашты.
Иркә. Ничек?
Азат. Үлде.
Иркә. Даян! Үлде?
Азат. Әйе, ятты да үлде.
Иркә. Алдыйсың.
Азат. Чын, Иркә.
Иркә. Кайда ул?
Азат. Менә ята.
Иркә. А-а!
Азат. Тынычлан, Иркә. Үлгән артыннан...
Иркә. Ничек инде? Ул яңа гына...
Азат. Чүкеч кебек иде.
Иркә. Врач чакыртырга кирәк!
Азат. Алар булды.
Иркә. Кайчан?
Азат. Унике минут элек.
Иркә. Үлгән... диделәрме?
Азат. Алып китәргә маташтылар. Морг буш тора икән. Бирмәдем.
Иркә. Юк, ышанмыйм.
Азат. Мин дә ышанмыйм. Тик менә — тотып кара.
Иркә. Нәрсәне?
Азат. Йөрәген.
Иркә. Юк, куркам.
Азат. Аның нәрсәсеннән куркырга? Менә — сукмый. Кил.
Иркә. Юк-юк!.. Ул, нәрсә, башка терелмәячәкме?
Азат. Медицина... андый хәлне белми.

Иркә. Мин... ирсез калдыммы?

Азат. Тол хатын.

Иркә. Нигә калдырдың? Кемгә ташлап киттең мине, Даян?..

Азат. Тынычлан, Иркә.

Иркә. Нигә үлде ул? Ни өчен?

Азат. Футболга барырга җыенган идек.

Иркә. Мин аңа бармаска кушкан идем!

Азат. Хатыннарны тыңлый башласаң, диде дә... Урамга чыккан идек, бер хатын тап булды.

Иркә. Нинди хатын?

Азат. Яшь, сылу. Даян шуны күрде дә... Юк, мәрхүмне яманлый алмыйм.

Иркә. Әйт.

Азат. Тик үзеңне кулга ал.

Иркә. Алдым.

Азат. Утыр. Була бит шундый кешеләр. Оят юк, ни юк. Хәзер әйтәм. Кыен булыр. Әмма түз. Теге хатынны күрде дә Даян: «Аны үземә кияүгә чыгарга күндерәм»,— ди. Биш минутта.

Иркә. Ничек? Ул бит өйләнгән...

Азат. Шаяра, янәсе. Бөтен хатыннар да бер калыптан, ди. Теләсә кайсысын биш минутта үгетләргә була, ди.

Иркә. Нахал!

Азат. Дөрес!

Иркә. Уйнаш... А-а! Ул бит үлгән! Ул инде юк! Даян!..

Азат. Бетте, бетте. Карама ул якка. Мин әйтәм: «Нигә бөтен хатыннар алай булсын. Менә, мәсәлән, синең Иркәң алай түгел»,— дим. Ә ул әйтә: «Иркә дә шулай».

Иркә. Хайван.

Азат. Мин дә шулай дидем. Бәхәсләштек. Булмый, мин әйтәм. Ул синең белән сөйләшеп тә тормаячак.

Иркә. Шуннан?

Азат. Китте Даян тегенең янына һәм... көтмәгәндә... Сөйли алмыйм...

Иркә. Нәрсә? Ни булды?

Азат. Мин күрмичәрәк калдым. Хатын нидер әйтте дә китеп барды. Янына барсам... Даян ап-ак... Хатын моның битенә түкергән дә...

Иркә. Дөрес эшләгән!

Азат. Шунда ук Даян йөрәген тотты... Үзең аңлыйсың, футбол кайгысы китте... Чак өйгә керттем. Ул ятты. Шуннан: «Чәй эчәсем килә»,— диде. Мәрхүмнең соңгы сүзләре... Кем уйлаган... Чәй куйдым да керсәм... Идәндә ята... Йоклый икән дидем... Шулай да йөрәген тыңлап карасам... Ул минем иң якын дустым иде... Ансыз миңа якты дөнья караңгы. Бәхил бул, дускай...

Иркә. Даянкаем!..

Азат. Инфаркт миокарда.

Иркә. Хәзер ни эшләргә?

Азат. Аның инде кирәге юк. Күмәргә.

Иркә. Нәрсә?

Азат. Шушылай ятмас бит. Гомер буе.

Иркә. Бүген үкме?

Азат. Бүген хушлашабыз. Иртәгә. Әй шәп кеше иде. Ничек җырлый иде! *(Күңелле җыр суза.)*

Иркә. Нинди тыңлаучан иде бит ул. Хәзер кайдан табармын андый ирне?

Азат. Нәрсә-нәрсә, ирләр эт тубыгыннан.

Иркә. Түгел шул... Кабер казырга кирәк бит?

Азат. Казылыр, мин эшенә шалтыраттым.

Иркә. Туганнарына әйтергә.

Азат. Хәзер килеп җитәрләр.

Иркә. Рәхмәт инде. Син булмасаң...

Азат. Ярый, утыр. Сөйләшеп алыйк. Үлгән артыннан үлеп булмый...

Иркә. Юк, мин болай утыра алмыйм. Ни дә булса эшләргә кирәк.

Азат. Бернәрсә дә кирәкми. Кабер казыла, гроб ясала. Тиздән туганнары килә. Утыр. Без аны сакларга тиеш.

Иркә. Нигә?

Азат. Шундый йола бар. Мәетне ялгыз калдырырга ярамый.

Ишектә звонок.

Тукта! Кем бу?

Иркә. Туганнары килгәндер.

Азат. Булмас. Иртә әле. Ачма!

Иркә. Нигә?

Азат. Әллә кемдер. Куркуы бар.

Иркә. Барыбер ишетәчәк бит.

Азат. Ишетү – бер, ә кереп мәеткә төртелү...

Ишектә янә звонок.

Иркә. Кем?

Азат. Нигә кычкырасың?

Иркә. Күрше апа килергә тиеш.

Тавыш. Иркә, ач әле!

Иркә. Бикә апа!

Азат. Тукта!.. Сора: нәрсә кирәк аңа?

Иркә. Бикә апа! Нәрсә кирәк?

Тавыш. Шырпы!

Азат. Тукта!.. Ярый, бар. Тик Даян хакында әлегә әйтмә.

Иркә. Нигә?

Азат. Соңыннан аңлатырмын. Бар, тизрәк котыл.

Иркә китә. Даян сикереп тора.

Даян. Син, сволочь, нәрсә эшлисең? Нинди хатынга өйләнәм, дидем мин?

Азат. Үлемеңне аңлатырга кирәк бит инде.

Даян. Син безнең араны бозарга телисең!

Азат. Икенчерәк хәл уйлап өлгермәдем. Ярый, ят, хәзер керә.

Даян. Юк инде. Сине тыңлаган мин җүләр! Терелэм!

Азат. Ничек тереләсең? Ә Иркәгә хәзер нәрсә дип аңлатырбыз?

Даян. Аңлатма, керер дә күрер.

Азат. Ул синең үлемеңә ышанды. Хәзер килеп керә...

Даян. Керсен!.. Синең дурак сүзләреңне тыңлап ятарга...

Азат. Иркәне әзерләргә кирәк. Югыйсә берьюлы ике удар. Йөрәге шартлавы бар.

Даян. Курыкма, аның йөрәге нык. Мин үлгәнгә тамчы да яше чыкмады.

Азат. Чыкты, мин күрдем. Ә бәхәс?

Даян. Кирәге юк! Син монда миннән көл, мыскыл ит...

Азат. Мин бит әле экспериментны башламадым да. Ә син шүрләп тә төштең. Кερә! Ят!

Азат Даянны аяк чалып ега.

Даян. Кара әле, ни эшлисең?

Бикә керә.

Азат. Тукта, кая керәсез?

Бикә. Керергә ярамыймыни?

Азат. Нәрсә кирәк?

Бикә. Тукта әле, син кем? Нигә сорау аласың?

Азат. Даянның дусты. Ярый, бар, чыгыгыз.

Бикә. Даян өйдә юк. Ә син ни эшлисең биредә?

Азат. Шырпы кирәкме? Алыгыз да таегыз.

Бикә. Абау! Кем ята анда?

Азат. Югал дим!

Бикә. Даян бит... Сез әллә... Разбой!

Азат. Нигә кычкырасыз?

Бикә. Үтерәләр!

Азат. Акырма әле!

Бикә. Якын килмә! Килмә, дим! А-а!

Азат. Үкермә, дим! Беркем дә сиңа тими!

Бикә. Коткарыгыз!

Азат. Җитәр!

Иркә керә.

Иркә. Ни булды?

Азат. Әнә мәет күрмәгән.

Бикә. Иркә, тимәгез миңа. Мин хәзер китәм. Китәм. Беркемгә дә әйтмәм.

Иркә. Нигә тиик сиңа? Мин үзем... Даянсыз калдым бит, Бикә апа!..

Бикә. Әй Алла... Нәрсә эшләттегез соң аны?

Азат. Приступ. Инфаркт миокарда.

Бикә. Соң, бүген генә...

Азат. Безгә Алла хуҗа.

Бикә. Әй Ходаем... Япь-яшь көенә...

Азат. Ярый, барыгыз. Кайгырырга комачаулыйсыз.

Бикә. Күршеләргә әйтергә кирәк. Өчәр генә сумнан җыелсалар да...

Азат. Кирәкми. Сез әлегә ул хәтле шауламагыз.

Бикә. Йоласы шулай аның.

Азат. Сау булып торыгыз.

Бикә. Иркә, шырпы юкмыни?

Иркә. Тапмадым. Шкаф башында булырга тиеш. Азат, алып бир әле.

Азат чыгып китә.

Иркә. Ялгыз калдым бит, Бикә апа.

Бикә. Ә теге соң?

Иркә. Иплэп...

Бикә. Курыкма, ул фәрештәләр янында. Киңәшем: шуны кулыңнан ычкындырма.

Иркә. Аның хатыны бар.

Бикә. Булса ни. Аерт.

Иркә. Ярый, җитәр!..

Азат тавышы. Юк монда шырпы!

Иркә. Юшкәсендә генә иде!

Иркә китә.

Бикә. Ә-ә, ятасыңмы? Иркәгә нәрсә дигәнсең әле? Бикә белән аралашма. Бикә хәйләкәр, имеш. Мин сиңа шулхәтле ни эшләдем? Ух, хайван! *(Тибеп ала.)* Әнә шуның үче ул үлемең! *(Өйдәге төрле нәрсәләрне кесәсенә яшерә. Даянның өстенә басып югарыдан нәрсәләрдер ала, кесәсенә сала.)* Нәрсә акаясың? Хәзер болар сиңа кирәкми. Бер көннән әйберләрең дә, хатының да икенче кешегә кала.

Азат белән Иркә керә.

Иркә. Мә.

Бикә. Рәхмәт, рәхмәт. Ул-бу булса, хәбәр ит. Ярдәм итәрмен.

Бикә китә.

Азат. Ул ярый үлде дә котылды. Ә сиңа киләчәгең турында уйларга кирәк.

Иркә. Нәрсәсен уйлыйсың? Менә кояш сүнде...

Азат. Тормышың башлана гына әле.

Иркә. Юк инде, юк. Мин Даянны беркайчан да оныта алмам. Ул шундый изге күңелле иде. Командировкага китсә, көн дә шалтырата, хәлемне белешә иде...

Азат. Үлгән сыер сөтле була. Тик син аны оныт, үзеңне уйла... Шушындый чакта ялгызың... Шуңа кайгырам.

Иркә. Мин тере... Ә менә ул...

Азат. Телисеңме, көн саен яныңа килеп йөрермен. Беренче вакытта.

Иркә. Кирәкми, җәфаланма.

Азат. Нигә җәфалану булсын? Сине күрү миңа куаныч.

Иркә. Әллә нәрсәләр сөйлисең.

Азат. Сиңа хәзер шуны аңларга кирәк. Нык итеп аңларга. Даян үлде. Ул башка беркайчан да кайтмаячак. Кайгырудан файда юк. Димәк...

Иркә. Нәрсә?

Азат. Иң элек тынычланырга. Шуннан... Аны тизрәк онытырга. Стресс хәлендә озак яшәргә ярамый. Врачлар шулай ди.

Иркә. Әйтүе ансат.

Азат. Әйтүемчә, иң әйбәт чара – сиңа тизрәк кияүгә чыгарга кирәк.

Иркә. Юк-юк.

Азат. Авыр уйлардан шулай гына котыласың.

Иркә. Мин гомергә чыкмам. Даян кебек кеше...

Даян. Ишет!

Иркә. Нәрсә? Син эндәштеңме?

Азат. Әйе, мин... Тукта, ашыкма.

Иркә. Ә миңа тоелды...

Азат. Түгел, мин. Мин болай дим. Даяннан да ун тапкыр артыграк кешеләр бар.

Иркә. Кайда алар?

Азат. Менә, мәсәлән, мин.

Иркә. Син? Син бит ул...

Азат. Ә нигә? Даяннан киммени?

Иркә. Юк ла.

Азат. Ул мастер гына иде. Ә мин – начальник. Ул 150 сум ала иде, ә мин – 200. Синең кайгыңны уртаклашу өчен мин бөтенесенә дә әзер. Тот та чык миңа!

Иркә. Ни сөйлисең? Юк-юк.

Азат. Нигә? Ни өчен?

Иркә. Белмим, тик – юк.

Азат. Мин бит сине күптән... Студент чакларымнан... Аның үлеменә мин куанам хәтта. Гафу ит, әлбәттә, яшерә алмыйм. Шунда ук Иркә минеке булачак дип уйладым. Бәлки, моны әйтергә ярамыйдыр...

Иркә. Әйе, ярамый. Ул монда.

Азат. Булсын. Ишетсен. Белсен. Шушындый чәчәк кебек хатынны ташлап... Җансыз! Нахал! Чык миңа. Шушыңа үч итеп.

Иркә. Тукта, Азат. Башым әйләнә. Берни аңламыйм. Тукта, зинһар.

Азат. Юк, туктамыйм. Йә хәзер әйтәсең риза икәнлегеңне, йә... Иркә, мин бит сине яратам. Үлеп яратам. Хатыным бул. Үтенәм.

Иркә. Нәрсә эшлисең син?

Азат. Берни эшләмим. Риза бул!

Иркә. Авыртмаган башка... Бөтенесенә дә син гаепле!.. Юк-юк! Мин каршы.

Азат. Иркә, үтермә мине! Риза бул! Бул! Ул бит үлде. Китте. Мәңгегә. Башка ул юк. Иртәгә күмәбез. Җир астына. Ризамы? Әйт инде! Әйт!

Иркә. Бөтенләй аптырадым. Ни дияргә дә белмим.

Азат. Күңелеңне тыңла, Иркә. Күңел ялгышмый ул. Ул риза. Риза! Риза!

Иркә. Ә менә үзем...

Азат. Үзең дә... ризасың! Мин күрәм! Күрәм! Риза! Риза! Шулай бит, Иркә?

Иркә. Уф... Әлбәттә, мин гомер буе ялгыз кала алмам...

Азат. О-о! Иркә! Кадерлем! Рәхмәт! Зур рәхмәт! Ә кайчан?

Иркә. Тик ашыкмыйк, Азат. Башта кырыгын укытыйк...

Азат. Юк, мин ул хәтле көтә алмыйм.

Иркә. Азат, аннан алда... мөмкин түгел!

Азат. Мөмкин.

Иркә. Кеше алдында уңайсыз. Уйлап кара.

Азат. Аларның ни эшләре бар? Без бер-беребезне яратабыз.

Иркә. Юк-юк. Сорама да. Кырыгыннан соң риза булуыма рәхмәт әйт.

Азат. Әйтәм, әйтәм. Тик кырык көн! Түземлегем җитмәс – мин үләрмен. Иркә... Утыз көн.

Иркә. Утыз көн?

Азат. Әй, о-о-озын бер ай.

Иркә. Бер, ике, өч... егерме тугыз, утыз. Утызмы?

Азат. Әйе, утыз.

Иркә. Утыз... Ярый инде, синеңчә булсын.

Азат. Рәхмәт. Мин синең акыллы икәнлегеңне белә идем. Тик бу хәтле! Утыз көннән без бергә! Барлыгы утыз! Мин бәхетле! Ә син?

Иркә. Мин...

Азат. Рәхмәт. Утыз көннән! Юк, уйласаң, бу бит озак! Бер ай! Коточкыч!

Иркә. Юк, шуннан бер көн дә алга риза түгел.

Азат. Иркә, Иркә, Иркә...

Иркә. Юк, юк, юк...

Азат. Егерме тугыз. Уйлап кара, бернинди аерма юк.

Иркә. Сөйләмә, сөйләмә!

Азат. Егерме тугыз, утыз. Алар янәшә, алар бергә. Егерме тугыз, Иркә. Егерме тугыз.

Иркә. Утыз яки егерме тугыз – барыбер түгелмени?

Азат. Мин дә шулай дим бит!

Иркә. Шулай булгач, утыз калсын.

Азат. Иркә, син аңла. Үлгәненә ничә көн үткәнен бөтенесе дә онытачак. Аларга егерме тугыз ни дә утыз ни. Аны без генә беләчәкбез. Карышма инде. Минем хакыма. Булачак ирең хакына.

Иркә. Ну нахал! Ну нахал!

Азат. Мин күрәм: син риза, риза!

Иркә. Нәрсә эшләргә дә белмим... Бик ялынасың бит...

Азат. Әйе, әйе.

Иркә. Ярый инде.

Азат. Ах, шайтан! Хаталандым! Ялгыштым!

Иркә. Ни булды?

Азат. Җүләр! Шулхәтле аңгыра булырга кирәк бит! Үземне гомергә гафу итмәячәкмен!

Иркә. Аңлат, нәрсә эшләдең?

Азат. Мин сүземне кире алам.

Иркә. Нинди сүзеңне?

Азат. «Егерме тугыз» дигәнне.

Иркә. Нигә?

Азат. Егерме сигез диярга иде. Их!

Иркә. Ни булыр иде?

Азат. Бер көн алдан кавышыр идек.

Иркә. Алай ди башласаң, бүгенге көнгә килеп җитәргә була.

Азат. Юк. Беркайчан да. Ә менә егермегә хәтле... Син тыңла: егерме сигез, егерме җиде, егерме алты... Көйләренең аермасы юк, сизәсеңме? Ә менә унтугыз... Ул инде, гафу ит, бөтенләй икенче страна. Егерме көннән. Һәм бетте.

Иркә. Азат!

Азат. Син ныклап уйла һәм аңларга тырыш. Әгәр аңлый алмасаң... Мин йә үләм...

Иркә. Миңа бер мәет тә җиткән...

Азат. Алайса чыгып китәм. Бөтенләйгә. Сочига.

Иркә. Китмә!

Азат. Ризамы?

Иркә. Сиңа каршы торып буламыни?

Азат. Булды, сөйләштек. Иртәгә күмәбез. Тантаналы рәвештә. Музыка чакырылган. Та-ра-ра! Бум! Та-ра-ра! Бум! Веноклар була. Та-ра-ра! Бум! Котылабыз. Шуннан... Егерме көн буе... Егерме көн буе ни эшләрбез? Икебез ике якта. Очрашырбызмы, ичмасам?

Иркә. Син ничек телисең?

Азат. Без очрашачакбыз. Көн саен. Тик кайда очрашырбыз?

Иркә. Белмим.

Азат. Минем яшеренеп очрашасым килми. Ә ниндидер йола аркасында синсез интегергә... Уйлап кара, егерме көн буе син монда кайгырасың. Ялгызлыкта. Ә мин сине кайгыра дип...

Иркә. Бәлки...

Азат. Дөрес! Дөрес! Аңа җиде көн дә җиткән.

Иркә. Азат!

Азат. Уйлап кара: кем ул шулхәтле? Генералмы? Юлбашчымы? Брежнев үлгәндә дә өч көн генә кайгырдык. Ә бу шундый хатынны калдырып, чалт аяз көнне!.. Җансыз! Эгоист! Тик үзен кайгырта! Үләсе килгәч, тоткан да үлгән! Нахал! Җиде көн җиткән. Бу соңгы сүзем!

Иркә. Мин куркам: кешеләр әллә нәрсә сөйләрләр...

Азат. Син шулардан куркасыңмы? Шушы тараканнарданмы? Алар безнең өчен чүп! Буш урын! Нуль! Без юри эшлибез. Шаккатырабыз. Бөтенесен дә. Әйе, менә тотабыз да... юк, хәтта җиде көннән дә түгел, ә өч! Өч көннән өйләнешәбез! Үч итеп!

Иркә. Юк-юк!

Азат. Син аңла! Безгә кешеләрнең сүзе дә, күзе дә кирәкми. Без бар йолаларга, капитализм калдыкларына төкерәбез! Үзебезнең төрле гадәтләрдән, кеше сүзеннән, иске йолалардан өстен икәнлегебезне күрсәтәбез. Без хәтта бүген үк өйләнә алабыз. Тик өйләнешмибез. Шуларның сүзләрен аста калдыру өчен. Ә менә өч

көннән... Сез безне гафу итегез! Өч көннән сез безгә хуҗа түгел! Өч көннән! Менә шулай. Өч көннән! Наданнарга үч итеп! Өч көннән! Өч көннән никах! Өч көннән!

Иркә. Өч көннән?

Азат. Өч көннән! Ур-ра, өч көннән! Төкерәм мин бөтенесенә дә! Иртәгә! Әйе, күмеп кайтабыз да — иртәгә!

Иркә. Азат! Син бигрәк...

Азат. Юк! Һич тә алай түгел. Болар барысы да буржуй муллалар уйлап чыгарган буш закон. Капиталистлар! Ризамы син, әйт! Ризамы син, әйт?! Өйләнгәч, барысы да синеңчә булыр! Тик бүген мине тыңлыйсың! Иртәгә! Ризамы син, әйт! Иркәкәем, матурым! Ризамы син, әйт?! Әйт! Үтенәм!..

Иркә. Риза, риза!

Азат. Молодец! Кил әле, бер үбим! Син бит акыллы! Синең кебек хатын дөньясында юк! Синме... син ул!.. Мин беләм: син хәтта бүгенгә дә риза. Чәйнәүләреннән дә курыкмыйсың! Чәйнәсеннәр! Ияклəре кыйшайганчы! Син батыр хатын! Син матур хатын! Шуңа да яратам мин сине! Бүген, ә?

Иркә. Үтерәсең мине!

Азат. Мин сиңа кайгырырга чирек сәгать тә калдырмыйм! Бүген! Бүген! Әгәр мөмкин икән, нигә кайгысыз яшәмәскә? Бүген!

Иркә. Уф Алла!

Азат. Бүген! Бүген! *(Бии, җырлый. Иркәне дә бөтерелдерә.)*

> Бүген белде: бөлдергән!
> Бөлдергәнне көлдергән.
> Бүгеннәргә риза булмый,
> Иркә мине үтергән!

Иркә. Нинди җыр бу?

Азат. Үзем чыгардым, шатлыгымнан, Иркә! Бүген! Бүген! Бүген! Кушыл! Бүген!

Иркә. Бүген! Бүген!

Бергә *(җырлап биилəр).*

> Бүгеннәргә риза булмый,
> Иркә мине үтергән!

Азат. Бүгенме?

Иркә. Бүген.

Азат. О! Иркә!..

Иркә. Кочаклаган идең, студент чаклар искә төште.

Азат. Ул хакта кирәкми.

Иркә. Нигә?

Азат. Бүгенге көн матуррак!

Иркә. Беләсеңме, синең белән йөрүемне мин Даянга әйтмәдем.

Азат. Тукта!

Иркә. Ә минем искә аласым килә.

Азат. Нәрсәгә кирәк ул?

Иркә. Ә нигә? Синең соңгы тапкыр үбүең һаман да исемдә. Син бит шундый итеп... Ә бу... түмәр! Яратмадым мин аны. Һәрчак сине уйладым. Әгәр теге чакта үпкәләшмәсәк...

Азат. Җитәр! Җитәр, дим!

Ишектә звонок.

Азат. Кем бу?

Иркә. Белмим.

Тавыш. Иркә, ач әле!

Иркә. Бикә апа!

Азат. Атаң башы! Тагын нәрсә кирәк аңа?

Иркә чыгып китә, Даян сикереп тора.

Даян. Эт!

Азат. Тукта, ни өчен?

Даян. Бөтенесе өчен дә!

Азат. Без бит бәхәсләштек!

Даян. Нигә Иркә белән йөргәнеңне яшердең?

Азат. Син әллә нәрсә уйлар дип.

Даян. Уйларлыгы калмаган: үпкәнсең!

Азат. Ну, булды инде...

Даян. Бәлки...

Азат. Юк-юк! Анысы булмады. Валлаһи!

Даян. Берегезгә дә ышанмыйм!

Азат. Нигә кызасың әле? Бу бит уен!

Даян. Уен!.. Күзем ачылды! Мин хәзерме...

Азат. Даян, тукта әле...

Даян. Кит моннан, сатлыкҗан! Алдакчылар! Фахишәләр! Үтерәм бөтенегезне дә! Тукта, мин хәзер яңадан үләм...

Азат. Бәхәс бит чишелде...

Даян. Юк! Алар кергәч, Иркәгә болай диген... синең теге сөяркәңне беләм, диген дә, икесен калдырып, алгы якка чыгып тор.

Азат. Нигә?

Даян. Су эчәргә. Биш минуттан кире керерсең.

Азат. Нигә диванга ятасың? Урыныңа ят.

Даян. Өйрәтмә, үзем беләм.

Азат. Соң бит...

Даян. Аркам авыртып бетте!

Иркә керә.

Иркә. Бикә апа күршеләрне җыйган.

Азат. Нәрсә кирәк аларга?

Иркә. Хушлашырга, диләр.

Азат. Кем белән?

Иркә. Мәет белән.

Азат. Әйттем бит иртәгә, иртәгә!

Иркә. Ә нигә бүген түгел?

Азат. Мәрхүмнең үтенече...

Иркә. Нинди үтенече?!

Азат. Үлгән көнне мине чит кешеләргә күрсәтмәгез, дигән иде.

Иркә. Кайчан... әйтте?

Азат. Үлгәч... түгел.

Иркә. Ә-ә... Менә подъезддан акча җыйганнар.

Азат. Чәчрәп кенә китсеннәр! Кирәк булганда бер тиен бирмиләр!

Иркә. Нигә ачуланасың?

Азат. Әйт, кире таратсын. Активистка!

Иркә. А-а!

Азат. Ни булды?

Иркә. Ул... юк!..

Азат. Юк? Ничек юк? Кайда ул? Ә-ә, менә ята бит.

Иркә. А-а!

Азат. Нигә кычкырасың?

Иркә. Ул ничек?.. Монда... менгән?

Азат. Ничек-ничек? Атлап. Әй, юк. Мин салдым. Мәет авыр була, диләр. Дөрес икән. Уф, хәл бетте.

Иркә. Ә нигә аны анда салдың?

Азат. Идәндә каты!.. Ярый, бар, әйт күршеләреңә. Таралсыннар, хушлашу иртәгә. Ә Бикә керсен. Әйтәсе сүзем бар.

Иркә китә.

Даян. Бетте! Аерылам!

Азат. Даян, куй әле!

Даян. Ничек күрмәгәнмен?

Азат. Син нәрсә, чынлапмы?

Даян. Якын килмә! Күрәсем килми! Үзем өчен җавап бирә алмыйм.

Азат. Бу бит эксперимент!

Даян. Эксперимент!.. Андый хатынның булганыннан...

Азат. Нигә тузынасың? Иркә әйбәт тә түгел, начар да түгел. Башка хатыннар кебек.

Даян. Алайса өйлән. Риза булды бит.

Азат. Җүләрләнмә әле!

Даян ята. Иркә белән Бикә керә.

Бикә. Күршеләр бик аптырый.

Азат. Түзәрләр.

Бикә. Нигә чакырдың?

Азат. Теге ни... Нәрсә әле?

Иркә. Азат, ни булды?

Азат. Ә-ә, менә нәрсә! Мин синең хакта шуны беләм. Синең сөяркәң бар. Син аның белән очрашасың икән. Мин хәзер. Су гына эчеп керәм.

Азат чыга.

Иркә. Нәрсә сөйли ул?

Бикә. Тегене әйтә микән?

Иркә. Кайдан белсен ул аны?

Бикә. Белсә, ул синең иреңме?

Иркә. Мин бит хәзер тол.

Бикә. Кара әле, ире үлеп өлгермәгән! Сез әллә монда бикләнеп...

Иркә. Кит әле!.. Кайдан белә ул? Бикә апа, син Альберт хакында берәүгә дә...

Бикә. Ак тәүбә, кара тәүбә! Беркайчан, беркемгә!

Иркә. Аптыраганнан сорыйм.

Бикә. Төпченсә баш тарт!

Азат керә.

Иркә. Азат, синең ул сүзләрең...

Азат. Нинди сүзләрем?

Иркә. Сөяркәң бар, диюең...

Азат. Ә-ә... Юкмыни?

Иркә. Юк, әлбәттә. Ә кем әйтте сиңа аны?

Азат. Бер кеше... белешергә кушкан иде.

Иркә. Кем?

Азат. Кемме?

Даян тора. Иркә белән Бикә аны күрми.

Азат. Кызлар! Кадерлеләрем! Батыр йөрәклеләрем! Кыбырдамагыз! Мине игътибар белән тыңлагыз! Сез әзерләнегез. Дөньяда төрле хәлләр була. Искиткеч хәлләр була.

Иркә. Ни булды?

Азат. Хәзер белерсең. Сез Аллага ышанасызмы?

Иркә
Бикә } *(бергә)*. Юк.

Азат. Ә менә могҗизага ышаныгыз. Файдасы тиюе бар. Хәзер күз алдыгызда коточкыч хәл туса да курыкмагыз. Йөрәгегезне тотыгыз – шартламасын.

Иркә
Бикә } *(бергә)*. Нигә? Ни сөйлисең?

Азат. Бөтенесе дә әйбәт. Барысы да табигый. Тормыш ал да гөл. Әйе. Әмма... артыгызга борылмагыз!

Иркә
Бикә } *(бергә)*. А-а!..

Икесе дә һушсыз егыла.

Азат. Эх! Әзерли алмадым!

Даян. Аларга шул кирәк.
Азат. Су китер!
Даян. Үлмәсләр!
Азат. Үлүләре дә бар.
Даян. Күмәрбез. Күршеләр акча җыйды.

Азат су китереп Иркәгә бөрки.

Иркә. Даян!
Даян. Нәрсә үкерәсең?
Иркә. Син... тереме?
Даян. Юк, үлек!
Иркә. Менә бит торасың!
Даян. Күзеңә күренәм!
Иркә. А-а!.. *(Кире егыла.)*
Азат. Нәрсә эшлисең?
Даян. Аңа шул кирәк!

Азат Бикәгә су бөрки. Бикә торып утыра.

Бикә. Күршекәем, дускаем!
Даян. Сиңа ишәк дус!
Бикә. Бу синме?
Даян. Түгел. Бу минем җаным.
Бикә. Мин куркам.
Даян. Курыкма. Мин бит юк. Менә тотып кара. Бушлык.
Бикә. Якын килмә. Килмә!
Даян. Юк, киләм әле, киләм!
Бикә. А-а... *(Егыла.)*
Азат. Йөрәкләрен ярасың бит!
Даян. Курыкма. Андыйларның йөрәге нык була.
Азат. Читкәрәк китеп тор.

Азат Иркә белән Бикәгә су бөрки. Алар һушларына килә.

Иркә. Кайда ул?
Даян. Монда, монда.
Азат. Курыкмагыз, ул тере. Үлмәде.
Иркә. Ә нигә үлмәде?
Азат. Ну... без шаярдык.
Иркә. Ничек инде?..

Бикә. Мин кайтыйм...

Даян. Ашыкма, кадерлем!

Бикә. Килмә, килмә якын!

Даян. Бая бик батыр идең. Минем мәеткә басып йөри идең. Күрсәт әле, шифоньер башыннан нәрсә урладың?

Бикә. Мин аны...

Даян. Китер.

Бикә. Мә, мә!.. Шуны алганчы...

Даян. Менә ул синең шәп апаң! Шкафтан алганнарны да китер... Ә сиңа килгәндә, Иркә... Аерылышабыз!

Иркә. Даян!

Даян. Кыланма! Альбертыңа чыгарсың. Хатынын аертып. Хуш!

Азат. Даян, тукта әле!

Даян. Кит юлдан!

Иркә. Даян, китмә!..

Даян. Күземнән югал!

Даян китә.

Иркә. Син гаепле барысына да! Син!

Азат. Без шаярган гына идек! Ә ул... Җүләр!

Иркә. Ни эшләргә миңа хәзер? Мин кемгә кирәк?

Азат. Кайгырма. Тынычланыр да кайтыр.

Иркә. Юк, ул кайтмаячак – мин беләм. Нигә эндәшмисең? Бик үгетли идең бит!

Азат. Даян бит тере!

Иркә. Минем өчен мәет! Мин сине беркая да җибәрмим. Мин риза.

Азат. Юкны сөйләмә!

Бикә. Мин шаһит. Баш тартсаң, без сине судка бирәбез!

Азат. Кызлар! Туктагыз әле...

Иркә. Кил яныма.

Азат. Юк, килә алмыйм.

Иркә. Нигә?

Азат. Миңа кайтырга кирәк.

Иркә. Юк инде! Бикә апа, тот, җибәрмә!
Бикә. Тукта, кабахәт!..
Азат. Коткарыгыз! Каптым!

Ут сүнә.

Икенче күренеш

Шул ук урын. Сәхнәдә Азат белән Иркә.

Иркә. Курткамны алып бир!
Азат. Яныңда бит. Үзең ал.
Иркә *(елый)*. Нигә чыктым шушыңа? Кайдан барып эләктем. Ухаживать итә белми, сөйләшә белми. Деревня! Алып бир!
Азат. Уф...
Иркә. Кара туфлиемне китер!
Азат. Кайда ул?
Иркә. Шифоньерда.
Азат. Мә.
Иркә. Кидер!
Азат. Нәрсә?.. Ярый. Ычкындыр тапочкаларыңны.
Иркә. Син ычкындырсаң кулың корырмы? Туң йөрәк!
Азат. Колга әйләндерергә уйлыйсыңмы?
Иркә. Ир хатынның колы булырга тиеш. Аңладыңмы, ахмак? Даян минем өчен йөгереп кенә йөри иде. Их, нигә аерылдым аңардан?!
Азат. Аның хәлләре шәптән түгел икән.
Иркә. Ой! Ни булган?
Азат. Милициягә эләккән. Бүген эшкә кәгазе килде.
Иркә. Мескен, әллә эчә башлаганмы?
Азат. Урамда ике хатынны тукмап ташлаган.
Иркә. Абау! Ни өчен?
Азат. Ул хәзер хатын-кызларны күралмый. Синең аркада.
Иркә. Ә бәлки, синең аркададыр? Кем монда эксперимент үткәрде? Эндәшмисеңме? Әнә шулай ул. Мин Бикәгә кереп чыгам. Шуннан соң йомыш белән барасы җир бар. Син идәннәрне юа тор.

Азат. Синең чират.

Иркә. Кем әйтә?

Азат. Конституция. Анда ир белән хатынның хокук...

Иркә. Син башта минем кебек акча тап. Көн дә эшләгән урыныңнан колбаса белән май алып кайт. Бесплатно! Шуннан әйтерсең – конституция!

Азат. Гомумән, идәнне аена бер тапкыр юарга кирәк. Бу музей түгел.

Иркә. Дурак син!

Азат. Кабатла әле.

Иркә. Ду-рак.

Азат. Бетте! Минме! Мин... идәнне юмыйм!

Иркә. Юарсың. Җырлый-җырлый юарсың.

Азат. Хәлем юк. Ачыктым.

Иркә. Ачыксаң аша.

Азат. Нәрсә?

Иркә. Пешер.

Азат. Хатын пешерергә тиеш.

Иркә. Бәлки, авызыңа да чәйнәп каптырырмын?

Азат. Мин пешерә белмим.

Иркә. Белмәгәч, нигә өйләндең?

Азат. Тукта! Мин сиңа ирме, түгелме? Аш пешереп ашатканың юк, идәнне, керне үзем юам...

Иркә. Әниең өйрәттеме? Әйт әбиюшкәңә: күзен акайтып килеп йөрмәсен монда. Үзең дә ике аягыңның берсен дә басмыйсың.

Азат. Тукта әле, ничек «аягыңның берсен»...

Иркә. Менә шулай.

Азат. Эштән туры кайт... Калып шахмат уйнама... Дуслар белән очрашма... Хәзер инде әниләргә дә бармаскамы? Юк, мин кайда соң? Тигез гаиләме бу, әллә гади совет төрмәсеме?

Иркә. Күрәсең килә икән – өйлән дә яшә янында.

Азат. Ни сөйлисең син?

Иркә. Миңа өйләнгәнсең икән, будь добр, өйдә утыр. Көне-төне гулять итәргә теләсәң, башта аерыл, алимент түлә.

Азат. Нинди алимент? Яшәвебезгә ике ай, балабыз юк.

Ирк ә. Дәүләт кушса, бик түләрсең. Мин Бикә апага барып киләм.

Азат. Нәрсә эшлисез анда?

Ирк ә. Төпченә! Хатын булган!

Азат. Көн дә барасың, шуңа сорыйм. Төпченмим...

Ирк ә. Эшебез бар. Кайтуыма идән ялт итеп торсын, ишеттеңме?!

Иркә китә.

Азат. Менә эләктем! Шашканнан-шаша бара бу. Акыра, гулять итә... И-их! *(Елый.)* Ир – ир ектә, хатын – өйдә, дигәннәр борынгылар. Хәзер хатыннар чабып йөри, ирләр идән юа!

Әй хатыннар, хатыннар,
Ну ирләрен тиргиләр.
Кесә ягы сай булса,
Кирәкләрен бирәләр.

Үзе йөри, мине тыя,
Акчаны бит күп ала.
Әгәр эшләр шулай барса,
Без ирләрдән ни кала?

Әй хатыннар, хатыннар,
Ну ирләрен тиргиләр.
Кесә ягы сай булса,
Кирәкләрен бирәләр.

Идән юарга әзерләнә. Ишектә звонок. Азат чыга һәм Даян белән кире керә.

Даян. Идән юасыңмы?

Азат. Көләсеңме әллә? Иркә юарга йөри иде әле...

Даян. Ә нигә балакларыңны сызгандың?

Азат. Эссе. Кара әле, син ниндидер хатыннарны тукмап ташлагансың икән. Дөресме шул?

Даян. Дөрес.

Азат. Чынлап тукмадыңмыни?

Даян. Чигәләренә чәпәдем.

Азат. Хәзер бит сине иптәшләр судына куеп тикшерергә туры киләчәк.

Даян. Тикшерегез. Кышкы киемнәремне алырга килдем.

Азат. Аларны Иркә сумкага тутырып куйган. Менә.

Даян. Ярый. Пока.

Азат. Тукта әле, ни өчен чәпәдең аларның чигәсенә?

Даян. Рестораннан егетләр белән чыгып киләләр иде. Кочаклашып.

Азат. Син кочаклашуга да каршымыни?

Даян. Бу хатыннарның икесенең дә ире бар. Алар кичке сменада эшлиләр, акча табалар. Ә болар... Фахишәләр!

Азат. Ярый, тынычлан... Мин сиңа әйттем бит: аларның бөтенесе дә бер калыптан...

Даян. Ә менә «Кичке Уфа»дагы белдерүләрне укысаң, андагы хатыннарның күбесе гаделлек таләп итә. Димәк, бар ул кызларның әйбәтләре, бар!

Азат. Алдашалар. Беркатлыларның ышануына өметләнәләр. Тугрылык та кирәкми аларга, мәхәббәт тә. Ир дигән кол кирәк хәзерге хатыннарга!..

Даян. Шулай да бүген белдерү бирүчеләрнең берсе белән очрашып сөйләшәм әле. Менә бит, тыңла, нәрсә яза: «Бер-береңне ихтирам итү кирәк, тугрылык кирәк».

Азат. Хәйлә кора. Менә укы: барысына да эчмәгән, тартмаган, юмарт ир кирәк. Каймак өстендәге май тормышы турында хыяллана, эгоисткалар. Ә мәхәббәткә төкерә алар. Бар, бар, очраш. Ул, күрү белән, сиңа чат ябышачак.

Даян. Нигә?

Азат. Чөнки эчмәвең, тартмавың, беркатлылыгың күренеп тора. Ә кызларга шундыйлар кирәк тә. Аларга ир эт тә, ат та, акча табучы да булсын.

Даян. Алайса, беләсеңме, мин ни эшлим! *(Азатның колагына пышылдый.)*

Азат. Шәп! Кирәкләрен бирәсең!

Даян. Әгәр шунда да миңа чыгарга риза булса... учымда гына күтәреп йөртер идем.

Азат. Молодец! Күрмәгәннәрен күрсәт! Ха-ха-ха!

Даян. Нигә көләсең?

Азат. Күз алдына китерәм! Ну шәп булачак бу! Шунда ук кем икәннәрен беләчәксең!

Даян. Эчәргә юкмы?

Азат. Син бит эчмисең.

Даян. Бүген эчәм... У-у, бу бит агу! Ничек эчәсез моны?

Азат. Күңел елаганда ярдәм итә. Сал әле миңа да.

Даян. Мә, ал... Әгәр юлым уңмаса... гомергә буйдак булып калам. Мәктәпкә укытучы булып барам. Һәм таза, саф, тугры кешеләр тәрбияләргә тотынам! Киттем!

Азат. Кайчан очрашасыз?

Даян. Җидедә, парктагы эскәмиядә. Үзең ничек яшисең?

Азат. Иркәнең сөяркәсе бар.

Даян. Икенчегә өйлән.

Азат. Ул да шул булачак. Мин дә тик йөрмим. Ике айда сөяркәләрнең санын йөзгә тутырдым.

Даян. Их, Азат! Син бит үзеңнән көләсең! Бербереңне яратып, тугры яшәүдән дә олы бәхет юк. Аңла шуны.

Азат. Ярый, бар. Уңыш телим.

Даян китә. Азат идән юа башлый.

Азат. Эх, дөнья, кәкре морҗа! Нинди хәлгә төшердең син ирләрне, Салават токымнарын... Без бит идәннән чүп чүпләргә түгел, күктән бөркет эзләргә яратылганбыз. Барып чыкмады бу. Эх!

Иркә керә.

Иркә. Йә?

Азат. Булды, күп юдым. Хәзер үзең ю.

Иркә. Кем акчаны күбрәк ала, ул өйдә азрак эшли.

Азат. Шул законың белән яшә. Мин китәм.

Иркә. Кая?

Азат. Үзеңнән күбрәк акча эшләгән кеше тап. Ә мин үземнән ким акча алган кеше эзләп карыйм.

Иркә. Беркая да китмисең. Син минем законлы ирем.

Азат. Без язылышмадык.

Иркә. Загска гариза бирелгән.

Азат. Өч ай көтәргә куштылар. Мин сине ике айда аңладым.

Иркә. Син алдадың мине!

Азат. Алдамадым. Аңладым: яши алмыйбыз бергә. Китәм.

Иркә. Ярый, мин риза: идәнне алмашлап юарбыз.

Азат. Столовай ашыннан ялыктым.

Иркә. Пешерермен.

Азат. Акчаны да аз алам. Колбаса урламыйм.

Иркә. Ярый, урлама, түзәрмен. Тик китмә.

Азат. Тыштан гына шулай дисең, ә эчтән... Булмый. Җибәр.

Иркә. Җансыз! Судка бирәм мин сине!

Азат. Әрмәнең белән яшә!

Иркә. Кем белән?

Азат. Бикә таныштырган бит.

Иркә. Бернинди дә әрмәнне белмим.

Азат. Мин аның белән базарда очрашып сөйләштем. Исеме Сурен. Сине бик мактый.

Иркә. Азат!.. Гафу ит!

Азат. Булмый. Юлымнан кит!

Иркә. Тукта! Башта Даянны кайтар. Ул синең аркада чыгып китте.

Азат. Соңладың. Ул өйләнергә йөри.

Иркә. Кемгә?

Азат. Бер кызга. Бүген сәгать җидедә очрашалар да сөйләшәләр, вәгъдә куешалар.

Иркә. Кайда?

Азат. Парктагы эскәмиядә. Хуш! *(Китә)*

Иркә. Азат!.. Хайван! Эт!.. Нәрсә эшләргә миңа хәзер?

Ишектә звонок. Иркә чыгып, Бикә белән кире керә.

Бикә. Иркә, Вартан кайтып китте бит! *(Елый.)*

Иркә. Бикә апа!..

Бикә. Тагын ялгыз калды башым!.. Кемгә ташладың мине, Вартан? Кемгә калдырдың? Монда бит синең кебек ирләр юк! Барысы да хәерче!.. Әле генә ике черкес белән таныштым. Иртәгә икебезне кунакка чакыралар.

Иркә. Теге ташлап китте бит мине, Бикә апа!

Бикә. Кем? Азатмы?

Иркә. Шул эт!

Бикә. Берсенә дә ышанып булмый. Ә син тугры булырга маташасың. Сволочь!

Иркә. Хәзер ни эшләргә миңа? Бикә апа, әйт, өйрәт!

Бикә. Даяныңны кире кайтар. Аннан да әйбәт ир тапмассың. Юаш, эчми, тартмый, хатын-кыз артыннан чапмый.

Иркә. Ул өйләнергә йөри.

Бикә. Кемгә?

Иркә. Бүген бер кыз белән очраша. Шуңа.

Бикә. Өйләндермә.

Иркә. Ничек?

Бикә. Ничек-ничек... белмим. Тик күзең акайтып утырма болай. Очрашасы урыннарын беләсең. Вакытын беләсең. Бар да ояларын туздыр.

Иркә. Ничек туздырыйм? Ул инде өч ай минем ирем түгел.

Бикә. Элекке ирең. Хатын-кызның тәүге иренә һәрчак хокукы кала.

Иркә. Ә ничегрәк эшләргә соң аны?

Бикә. Барасың да яннарына утырасың. Шуннан теге кызга Даян турында сөйләп ташлыйсың: «Эчә, тарта, айныткычтан чыкмый, эшеннән куылды. Җитмәсә, мине тукмый торган иде. Шуңа кияүгә чыкмакчы буласыңмы, җүләр?»

Иркә. Аннан соң Даян миңа борылып та карамаячак.

Бикә. Алайса... Белмим.

Иркə. Идея!

Бикə. Йə-йə, нəрсə?

Иркə. Икəүлəшеп барабыз.

Бикə. Нигə икəүлəшеп?

Иркə. «Джазда кызлар гына» фильмын карадыңмы? Анда ике егет кызлар булып киенə. Ə без егетлəр булып киенəбез!

Бикə. Шуннан?

Иркə. Даянның кызына бəйлəнəбез. Янəсе, аның белəн бергə төн үткəрəбез. Ə Даян, җүлəр, шуңа өйлəнергə йөри! Хи-хи-хи!

Бикə. Кыз «алдыйлар» дисə?

Иркə. Əйтсен. Сиңа кияүгə чыгарга тырыша, шуңа безне белмəмешкə салыша, диярбез.

Бикə. Даян безне танымасмы?

Иркə. Мин сөйлəшмəм. Ə ул сине бер тапкыр гына күрде. Җитмəсə, грим салабыз, мыек ябыштырабыз. Аңа калса, безгə охшаган егетлəр юкмыни?

Бикə. Əйе шул!

Иркə. Ашыгыйк! Аларның очрашуына ярты сəгать калды!

Йөгереп чыгалар.

Пəрдə.

ИКЕНЧЕ ПƏРДƏ

Өченче күренеш

Эскəмия. Анда кемдер ята.
Ирлəрчə киенгəн Иркə белəн Бикə керə.

Иркə. Монда беркем дə юк, Бикə апа.

Бикə. Иркə, тс-с-с!

Иркə. Абау! Кем ята анда?

Эскəмиядəге кеше торып утыра. Бу – Даян. Ул бик килбəтсез, пычрак киенгəн, костюм эчендə күлмəге дə юк. Яланаягына шнурсыз иске ботинка кигəн. Чалбары кыска. Чəчлəре укмашып оешкан.

Бикә. Даян түгелме?

Иркә. Нишләп Даян булсын? Ниндидер алкаш!

Бикә. Танымый да башладыңмы?

Иркә. Абау! Шул бит, бахыр. Эчәргә сабышты микәнни?

Бикә. Хатыннарны тукмаган дигән идең. Дөрес икән.

Иркә. Юк, ышанмыйм. Даян эчә торган кеше түгел.

Бикә. Кара! Эчмәгән кеше шушылай киенәме? Адәм страмы!

Иркә. Юк. Монда ниндидер хикмәт бар.

Бикә. Кит, мондый ирең булганчы... Бик килештереп киенгән идек. Әрәмгә булды. Әйдә, киттек.

Иркә. Юк-юк. Ашыкмыйк, Бикә апа. Теге кызының килгәнен көтик әле.

Бикә. Алайса йөреп килик. Йә танып калыр.

Иркә белән Бикә чыга. Шәмсия керә.
Ул 65 яшьләр тирәсендә. Кулында зур сумка.

Шәмсия. Абау, монысы кем?

Даян. Әби, юлыңда бул.

Шәмсия. Акырма, яме! Сәгать ничә?

Даян. Җиде.

Шәмсия. Соңга калам дип курыккан идем. Нигә җәелеп ятасың? Ал әле аягыңны! *(Сумкасыннан кирәк нәрсәләрен чыгарып, иренен, кашларын буярга тотына.)* Бу сиңа йокы бүлмәсе түгел.

Даян. Әби, син миңа комачаулыйсың.

Шәмсия. Комачауласам тор да кит. Шәмсия апаның шушында свиданьесы!

Даян. Нинди свиданье?

Шәмсия. Егет белән.

Даян. Бабай белән, диген.

Шәмсия. Бабайның ни хаҗәте? Алла боерса, егет белән очрашам.

Даян. Сиңа нинди егет карасын?

Шәмсия. Синнән ун тапкыр матуры, йөз тапкыр акыллысы. Ярый, бар, әнә теге эскәмиягә күчеп ят. Комачаулама.

Даян. Минем дә монда свиданье. Шушы эскәмиядә.

Шәмсия. Хи-хи-хи!.. Хи-хи-хи!

Даян. Нигә көләсең?

Шәмсия. Син өтәчкегә кем карасын? Хәтта миннән карт әбиләр дә сиңа карамый. Хи-хи-хи!.. Свиданье!..

Даян. Борчылма, яме. Эскәмияне ничек бүлешәбез?

Шәмсия. Бәй, бүлешмибез. Эскәмия апаңныкы.

Даян. Ярый. Без эскәмиянең теге башында үбешербез, сез – бу башында.

Шәмсия. Тфү, имансыз!

Иркә белән Бикә керә.

Бикә. Әй, син!

Шәмсия. Хулиганнар!

Даян. Нәрсә кирәк?

Бикә. Тартырга бир.

Даян. Мин тартмыйм.

Бикә. Эчәргә белә, тартмый. Ир аламасы.

Даян. Юлыңда бул. Аңладыңмы?

Бикә. Син ипләп! Югыйсә – ха! Каратэ!

Шәмсия. Эндәшмә. Үзләре китәр.

Бикә. Ишеттеңме, сөйгәнең ни ди?

Иркә. Ярый, үбешергә комачауламыйк.

Читкәрәк китәләр.

Иркә. Аңламыйм, шушы әби белән очраша микәнни?

Бикә. Әби белән тынычрак инде.

Иркә. Юк, очраклы гына очрашканнардыр.

Бикә. Кара, кара, бик ихлас сөйләшәләр. Үбешәләр, үләм!

Иркә. Берни аңламыйм.

Бикә. Ярый. Әби синең өчен куркыныч түгел. Китик әле.

Китәләр.

Шәмсия. Жуликлар!.. Сәгать ничә?

Даян. Сигезенче. Онытты егетең.

Шәмсия. Озаклый шул. Син ничәдә очрашасың?
Даян. Үзем беләм.
Шәмсия. Ул да сине онытты. Кыяфәтең исенә төшсә...
Даян. Карама кыяфәткә, кара йөрәккә.
Шәмсия. И-и, ни сөйләгән була, бахыр. Алкашмы син?
Даян. Талант бар, әби. Бер көндә биш йөз сумны юк итәм.
Шәмсия. Әстәгъфирулла! Яшь кенә үзең. Нигә эчүгә сабыштың?
Даян. Ирне кеше иткән дә, хур иткән дә хатын.
Шәмсия. Әйтмә. Шашты хәзерге хатыннар. Ирләрен чүпкә дә санамыйлар. Менә минем кызым андый түгел. Әй, әттәгенәсе, юк бит бу.
Даян. Минеке дә юк. Әллә шуларга үч итеп...
Шәмсия. Оятсыз!
Даян. Алайса көт, көт. Ә егетең килмәячәк. Бер яшь кенә, матур гына кызны очраткан да... выжт!
Шәмсия. Ә синеке?
Даян. Киләчәк.

Иркә белән Бикә керә.

Бикә. Һаман утыралар.
Иркә. Ә кыз юк.
Шәмсия. Тик торганда гына йөрми болар.
Даян. Сиңа күзләре төшкән.
Шәмсия. Болар безне таларга җыена. Ун сум акчамны алып чыккан идем. Алла сакласын...
Даян. Минем кесәдә бер тиен дә юк. Кием дә шәптән түгел. Ә менә сине чишендерсәләр, мантый болар.
Шәмсия. Алла сакласын.
Даян. Яулыгың йөз сум торамы?
Шәмсия. Кычкырма инде шулхәтле!

Иркә белән Бикә аларның арасына килеп утыралар. Тәмәке тартып җибәрәләр.

Бикә. Гашыйкларга сәлам!
Шәмсия. Йа Алла!
Даян. Нәрсә кирәк?

Бикә. Эскәмия.

Даян. Алар парк тулы.

Бикә. Безгә шушысы, үзебезгә ошаганы кирәк, әйеме, Вася?

Иркә. Әйе шул, Федя.

Шәмсия. Башкорт түгелмени сез?

Бикә. Әбиюшкә, сиңа нәрсә ошамый?

Шәмсия. Ошый, ошый, бөтенесе дә ошый.

Бикә. Ошагач, яп бияләеңне. Югыйсә бабаеңа әйтербез. Яшь ирләрне аздырасың монда...

Шәмсия. Бәй, аздырып мин ни эшләгән?

Бикә. Сиңа тол бабайлар беткәнме? Ә моның хатыны бар.

Даян. Карагыз әле, шылыгыз моннан!

Бикә. Куркытты!

Даян. Мин бит сезне!

Шәмсия. Куй, улым, кызма!

Бикә. Ишеттеңме, сөяркәң нәрсә ди?

Даян. Җитте!

Бикә. Без тик утырабыз. Сез башладыгыз.

Утырышалар. Иркә белән Бикә суыра-суыра тәмәке тарта. Аларның төтененә Даян белән Шәмсия ютәлли башлый.

Даян. Карагыз әле, китәсезме сез моннан?

Бикә. Нишләп китик ди? Эскәмия дәүләтнеке.

Даян. Читтәрәк тартыгыз.

Шәмсия. Әй, балалар, тын алып булмый бит.

Бикә. Әнә куак төбендә... тын ал! Хи-хи!

Даян. Түземлегем бетте!

Бикә. Җибәр! А-а!

Иркә. Нәрсә эшлисез?

Шәмсия. Куй, улым, куй!

Даян. Таегыз моннан!

Бикә. Кулыңа хуҗа булмасаң...

Иркә. Хулиган!

Даян. Нәрсә, аз булдымы?

Бикә. Ярый, ярый, курыктылар дип уйлама. Эшебез бар. Без килүгә эзегез булмасын. Ишеттегезме? Әйдә, Стёпа.

Шәмсия. Бая Федя иде, хәзер – Стёпа. Әллә өчәү инде болар.

Даян. Күрсәтермен мин аларга Стёпаны.

Шәмсия. Батыр икәнсең. Икәү дип тормадың.

Даян. Алардан да курка башласаң...

Шәмсия. Әбиюшкә диләр бит әле ишшу. «Әби»е әби инде, ә «юшкә» дигәне нәрсәне аңлата икән?

Даян. Мич юшкәсен.

Шәмсия. Ничек мыскыл иткәннәр, юньсезләр... Юк, килмәс, ахры, бу. Син көтәсеңме әле?

Даян. Минеке киләчәк.

Шәмсия. Хәзерге хатын-кызга ышансаң...

Даян. Ул язган хатларны укысагыз...

Шәмсия. Хатлар?

Даян. Әйе. «Минем бер көчле егеткә кияүгә чыгып, аңа буйсынып, киемнәрен юып, ашарына пешереп, балаларын үстереп яшисем килә». Нинди сүзләр! Мондый кызга ышанырга була.

Шәмсия. Тукта... Ә синең фамилияң ничек?

Даян. Котлыбаев.

Шәмсия. Син!.. Ничек син... син бит... Шундый сүзләр язып... Нахал!

Даян. Аңламадым.

Шәмсия. Ә мин, җүләр, ышандым! Эзләгән кешемне таптым дип уйладым!

Даян. Тукта, ни булды?

Шәмсия. Сиңа берәрсе карар дисеңме? Кияүгә чыгар дисеңме? Карачкы! Алкаш!

Даян. Кем кияүгә чыга? Кемгә чыга?

Шәмсия. Сиңа түгел!

Даян. Әби, әби! Ипләбрәк, ярыймы?

Шәмсия. Кәләш кирәк булган! Сине башта ун ел дәваларга кирәк!

Даян. Җитәр дим!

Шәмсия. Нинди хатлар язган булды, оятсыз!.. Тигез булырга, бер-береңне кыерсытмаска... Синең кыяфәтең генә дә кешене мыскыл итә!

Даян. Тукта! Ә синең фамилияң ничек?

Шәмсия. Айчуакова!

Даян. Миңа хатларны...

Шәмсия. Мин яздым!

Даян. Ха-ха-ха! Матур буйлы, чибәр кыз!.. Ха-ха-ха! Үләм!

Шәмсия. Хи-хи-хи! Дурак!

Даян. Мин бит сиңа яшемне яздым. Егерме биш дип. Хәтерлисеңме?

Шәмсия. Мием черемәгән!

Даян. Ә нигә килдең? Миңа чыгарга җыенасыңмы?

Шәмсия. Синдәй алкаш белән сөйләшеп тә тормыйм!

Даян. Шушыңа хатлар язганмын! Страм! Позор!

Шәмсия. Башка белән очрашсам... Кем белгән!

Даян. Башкалар белән дә хат алышасыңмы?

Шәмсия. Белдерүемә илле алты җавап килде! Белеп тор! Бөтенесе белән дә хат алышам. Сигезе белән очраштым. Берсе дә ошамаган иде. Хәзер аңладым: алтын булганнар икән.

Даян. Хатыңда яшеңне күрсәтә торган бул, карга!

Шәмсия. Ә синме? Син... Сиңа чыгардай хатын юк дөньяда!

Даян. Бар, кайт! Кайт та үзеңә кәфен әзерлә! Свиданье!

Шәмсия. Иптәш Котлыбаев! Авызыгызны үлчәп ачыгыз! Югыйсә...

Даян. Югал дим! Чәүкә!

Шәмсия. Сине карачкы итеп бакчага куярга кирәк. Гөрбиян!

Ләлә керә.

Ләлә. Исәнмесез!

Даян. Исән без, исән без.

Шәмсия. Нәрсә кирәк?

Ләлә. Үтеп бара идем дә... Ә бу кем? Тегеләрнең берсеме?

Шәмсия. Түгел. Алкаш. Әйдә.

Даян. Ихтирам итүегезне сорыйм, иптәш Айчуакова. Алкоголик та кеше.

Шәмсия. Хөрмәтле алкоголик галиҗәнаплары! Гафу итегез, зинһар. Башыгыз авыртмыймы? Кичәге төшерүләрдән соң?

Даян. Әнә шулайрак.

Ләлә. Киеме юк микәнни?

Шәмсия. Сатып эчкән. Ярый, киттек.

Даян. Беләсезме, мин сездән бәхетлерәк!

Шәмсия. Кем? Синме?

Даян. Син – чүпрәк колы. Ә мин – ирекле.

Шәмсия. Кол булмыйм дип, синең кебек йөрисем юк.

Даян. Син чүпрәк аша кешене күрә алмыйсың. Шунда синең трагедияң. Ә акыллы кешегә чүпрәк ул чүп!

Ләлә. Ә нигә эчә башладыгыз?

Даян. Сез гаепле!

Ләлә. Ничек?

Даян. Менә матур киенеп, елмаеп карап торган буласың, ә эчеңдә елан ята.

Шәмсия. Син! Минем кызыма!..

Ләлә. Сез бит мине белмисез.

Даян. Барыгыз бер калыптан. Акча, ир!

Шәмсия. Кызым, тыңлама шуны. Әйдә.

Ләлә. Тукта әле, әни. Аның күзләренә кара...

Шәмсия. Күп эчүдән кызарган.

Ләлә. Сезне кемдер нык кимсеткән. Шулаймы?

Даян. Эшең булмасын!

Ләлә. Аның аркасында башкаларга ачуланырга ярамый.

Даян. Барыгыз да шулай!

Ләлә. Бөтен кеше дә начар булалмый.

Шәмсия. Ләлә, җитәр, әйдә киттек.

Даян. Әйе, барыгыз. Үзегезгә бер бай ир табыгыз, аны учыгызга йомарлап тотыгыз, ара-тирә хыянәт итегез. Менә ул сезнең хыялыгыз! Ә минем хатларны... ертып ташлагыз.

Шәмсия. Ә минекен саклый аласыз. Истәлек итеп.

Ләлә. Әни! Ул бит тегеләрнең берсе.

Шәмсия. Киләчәккә сабак. Матур хат язучыларның барысына да ышанырга ярамый.

Даян. Соңгы киңәшем: үзеңне кайгыртканчы, кызыңа кияү эзлә, шүрәле. Ул, бәлки, матурлыгы белән берәрсен алдар.

Ләлә. Ә ул миңа эзли.

Даян. Ничек?

Ләлә. Кияүсез калырмын дип курка.

Шәмсия. Нигә аңлатасың шуңа?

Ләлә. Белсен, әни. Югыйсә әллә нәрсә уйлар. Егерме бишкә җитеп тә үз тиңемне тапмагач, әнием, танышу бюросына яз, дип бәйләнә башлады. Мин баш тарттым. Шуннан ул минем исемнән белдерү биргән. Бервакыт алтмышка якын хат килеп төште. Мин кайсыларын укыдым, тик берсенә дә әле җавап язмадым. Бервакыт әнием үзе шулар белән хат алыша башлады. Мин булып, әлбәттә. Пенсиядә, вакыты күп. Кабаланмый утырып, озын-озын хатлар яза. Җавапларын миңа укый. Көлке. Менә хәзер әкренләп шуларның һәрберсе белән очраша. Янәсе, миңа пар булырдаймы, түгелме. Миңа читтән генә карап китәргә куша. Моңарчы барганым юк иде. Бүген...

Шәмсия. Иң аламасына килдең.

Даян. Менә ничек...

Шәмсия. Тегеләре, бәлки, ошар иде. Кәнфит кебекләре булды! Бу түгел инде, йолкыш.

Ләлә. Ә миңа... бу егет ошады.

Шәмсия. Шушымы? Моңа мин дә карамыйм.

Ләлә. Күптән берәр алкоголик белән танышырга тели идем...

Шәмсия. Ахмак!

Ләлә. Беләсем килә: чынлап та куркыныч кешеләрме икән? Сез – Даян, әйе бит?

Даян. Әйе.

Шәмсия. Җирәнмичә карарлык түгел. Шуннан?

Ләлә. Алкоголикны эчүеннән туктатып булмый диләр. Шул дөресме?

Шәмсия. Дөрес. Ике ел дәүләт җилкәсендә дәваланып кайталар да янә эчә башлыйлар.

Ләлә. Мин сездән сорыйм.

Даян. Дөрес.

Ләлә. Әни, ул котылырга тели бу бәладән. Тик ярдәмче кирәк.

Шәмсия. Каян беләсең?

Ләлә. Күзләреннән.

Шәмсия. Похмельдән тонган. Әнә психбольница ярдәм итсен. Син врач түгел, укытучы. Киттек.

Ләлә. Тукта, әни. Аны шушы хәлендә калдырыйкмы?

Шәмсия. Өеңә алып кайтыр идеңме?

Ләлә. Сезнең фатирыгыз бармы?

Даян. Юк.

Ләлә. Ә кайда яшисез?

Даян. Кайда туры килә, шунда.

Шәмсия. Алла сакласын.

Ләлә. Берәр җирдә эшлисезме?

Даян. Эшләп кем баеган?

Ләлә. Сезгә иң элек өйләнергә кирәк...

Шәмсия. Йа Хода, үзең сакла...

Даян. Өйләнеп карадым. Барыбер эчә башлыйм, исереп хатынымны тукмыйм, күршеләр белән сугышам. Хәзер, хәзер урамга куып чыгардылар.

Ләлә. Мескен...

Шәмсия. Ләлә! Кайтыйк!

Ләлә. Әни, тукта... Мин жәлләдем аны...

Шәмсия. Нәрсә? Үзен жәлләмәгән кешене! Кайтыйк, дим!

Ләлә. Мин хатларыгызны хәтерлим. «Кешеләр бер-берсенә ярдәм итеп, бер-берсен хөрмәтләп, аңлап яшәргә тиеш. Шунсыз бәхет юк».

Шәмсия. Ул бит алдап язган.

Ләлә. Андый сүзләрне алдап язып булмый, әни.

Шәмсия. Беркатлы! Киттек моннан!

Ләлә. Менә үзе әйтсен. Чын күңелдән язганмы ул, әллә юкмы?

Шәмсия. Күзгә туры карап алдаячак!

Ләлә. Әйтегез, мин көтәм.

Даян. Ләлә... Чык миңа кияүгә.

Шәмсия. Нәрсә? Оятсыз! Бандит! Менә сиңа Ләлә! Менә! *(Кукиш күрсәтә.)*

Даян. Сезнең белән сөйләшмим.

Шәмсия. Башта үзеңә кара! Мондый чүпрәк белән идән дә юмыйм. Ә син шуны киеп, кәләш сорамакчы! Бәлки, шулай загска барырсың? Җирбит!

Даян. Мин җавап көтәм.

Шәмсия. Ләлә! Ләлә!!! Эндәшмә! Ул синнән көлә! Мыскыл итә! Киттек, кайтыйк тизрәк!

Ләлә. Әни, тукта әле...

Шәмсия. Юк, туктамыйм, бер секундка да туктамыйм! Әйдә, әйдә дим!

Ләлә. Әни, син мине кияүгә бирә алмый аптырый идең...

Шәмсия. Ләлә! Кызым! Үтермә әниеңне! Тереләй кабергә тыкма!

Ләлә. Әни, миңа инде егерме биш яшь. Үземә үзем хуҗа. Мин...

Шәмсия. Әйтмә! Әйтмә!!!

Ләлә. Мин риза!

Шәмсия. Нәрсә? Нәрсә дидең?

Ләлә. Мин Даянга кияүгә чыгам, әни. Минем исемнән хат алышкан Даяныңа.

Шәмсия. Үтердең. Тереләй суйдың... Йөрәгем...

Ләлә. Әни! Даян! Су! Фонтаннан!

Даян чыга да учына салып су китерә, Шәмсиянең битенә бөрки.

Ләлә. Әни, әнием...

Шәмсия. Кызым!.. Ләлә...

Даян. Мин хәзер!

Даян йөгереп чыга.

Шәмсия. Кайда ул? Киттеме?

Ләлә. Хәзер килә.

Шәмсия. Әй, кызым, кызым... Мин бит сине төннәр буе йокламый үстердем... Бар тапканымны да сиңа бирергә тырыштым. Укытырга, кеше итәргә бар

кəчемне, исəнлегемне бирдем. Əйбəт, акыллы кешегə кияүгə биреп, карт көнемдə оныкларымны сөеп яшəрмен дип хыяллана идем... Булмады.

Лəлə. Əни, ул начар кеше түгел. Мин ышанам аңа.

Шəмсия. Ишетмəдеңмени: эчəм, исерəм, хатынымны тукмыйм, диде. Хəзер икебезне...

Лəлə. Начар кеше үзе хакында алай дип əйтми.

Шəмсия. Яшəргə урыны юк, беркайда да эшлəми...

Лəлə. Ул үзгəрергə тели, əни.

Шəмсия. Телəми! Эчə-эчə оятын югалткан. Менə шул. Юк! Аңа чыкмыйсың! Үлсəм үлəм, аңа бирмим! Киттек моннан тизрəк.

Даян керə. Ул бик шəп киенгəн. Чəче таралган.

Даян. Лəлə! Бу мин!

Шəмсия. Кем син? Даян?!

Даян. Шəмсия апа, спектаклем өчен гафу итегез.

Шəмсия. Менə сиңа кирəк булса!

Даян. Хəзер каршы булмассыз бит?

Шəмсия. Син... алкоголик түгелме?

Даян. Түгел. Торакта аерым бүлмəм бар. Инженер булып эшлим. Дөрес, кайчандыр өйлəнгəн идем. Əмма хəзер аерылган кеше.

Шəмсия. Уф! Шулай шаярырга ярыймыни? Үтерə яздың бит!

Даян. Димəк, сез риза?

Шəмсия. Ə нигə алай киенеп килдең монда?

Даян. Пычрак киемле эчкечене изге күңелле кеше генə ярата ала, Шəмсия апа.

Шəмсия. Лəлəнең баш тартуы бар иде бит.

Даян. Ə андый кыз миңа кирəкми. Берсе белəн яшəп карадым. Җитəр.

Шəмсия. Акыллы булырга охшаган... киявем.

Даян. Рəхмəт!

Лəлə. Ə нигə минем ризалыгымны сорамыйсың?

Шəмсия. Син ризалыгыңны бирдең бит.

Лəлə. Моңа түгел.

Шəмсия. Ə кемгə?

Ләлә. Аңа.
Шәмсия. Теге... алкоголиккамы?
Ләлә. Әйе.
Шәмсия. Хи-хи-хи... Соң шушы үзе бит инде.
Ләлә. Түгел.
Шәмсия. Ничек «түгел»?
Ләлә. Ул кызганыч иде. Аңа карагач, минем җаным сызлап китте. Ә бу... Каймак өстендә йөзгән карьерист!
Шәмсия. Нәрсә?
Ләлә. Мин мондый кеше белән яшәргә теләмим.
Шәмсия. Акылдан шаштыңмы әллә?
Ләлә. Мин бит укытучы. Аны тәрбияли, кеше итә алыр идем... *(Елый.)*
Шәмсия. Нәрсә эшлисең, җүләр?
Ләлә. Алкоголик җәл...
Шәмсия. Нәрсә? Нәрсә дисең?
Ләлә. Ул кеше төсле иде... Яңа гына күз алдымда тора иде... Ул китте, үлде... Аны башка беркайчан да күрмәячәкмен...
Шәмсия. Тынычлан хәзер үк! Ни сөйләгәнеңне колагың ишетми...
Даян. Ләлә...
Ләлә. Китегез! Сез үтердегез аны! Комачауламасын дип!
Даян. Шул эчкече, сәрхуш...
Ләлә. Ул гаделсезлекләргә чыдый алмыйча эчә башлаган. Ул сездән йөз тапкыр артык!
Даян. Минем эчмәвем...
Ләлә. Сез дөньяның кире якларына төкереп карыйсыз! Карьерагызны бозмас өчен!
Даян. Мин кайгырам, әмма...
Ләлә. Кайгырам... Көрәшергә кирәк.
Даян. Бәлки, көрәшәмдер дә...
Ләлә. Көрәшкән кеше болай булмый: канәгать төскыяфәт, ялтырап торган костюм! Ул көрәшкән! Әйе. Көче җитмәгән. Һәм шундый хәлгә төшкән.
Даян. Кара әле, син дә көрәшкәнгә охшамыйсың!
Ләлә. Мин – хатын-кыз. Мин иремә балалар табам,

тәрбиялим. Аңа көрәшергә илһам бирәм. Иремнең тылы булам мин. Ә ул гаиләбезне саклар. Безгә суык яңгырны да, ачы җилне дә үткәрмәс. Һәм тормышны үзгәртү, матурлау өчен көрәшер. Бәлки, ул җиңелер, максатына ирешә алмас, хәтта кайгысыннан эчеп тә китәр. Тик тырышканы өчен генә мин аны хөрмәт итәр, яратыр идем. Теге эчкече шундый иде. Янында аңлардай кешесе генә булмаган, шуңа бирешкән.

Шәмсия. Ләлә! Ул сәрхуш юк, юк!

Ләлә. Әйе, юк. Аны үтерделәр. Әмма мин аны яратырга өлгердем. Кияүгә чыгарга ризалыгымны бирдем. Мин аны мәңге онытмам, аңа гомергә тугры булып калырмын... Әйдә.

Шәмсия. Ләлә кызым... Әллә авырыйсыңмы? Кайсы җирең авырта?

Ләлә. Күңелем... Киттек.

Даян. Ләлә, тукта... Мин... Бүгеннән эчә башлыйм!

Шәмсия. Даян, шуның җүләр сүзләренә карап...

Даян. Эчәм! Сугышам! Икейөзлеләрне, бюрократларны тукмыйм! Алдакчылар, караклар, күз буяучылар шундый күп! Урыннарына ничек утыртырга белми идем. Җаен таптым. Эчәм дә кабыргаларын саныйм.

Шәмсия. Алла сакласын, Даян, куй. Юк белән булышма.

Даян. Бер айдан шушы урында очрашырбыз. Кечке җидедә. Шәһәрнең беренче алкашын күрерсең.

Ләлә. Бар.

Даян. Киттем.

Ләлә. Нигә туктадың? Куркак!

Шәмсия. Ләлә! Ни кылануың?

Даян. Аңа эксперимент кирәк. Эчсәм, тәрбияли аламы, юкмы? Куан, эчә башлыйм. Эчәм һәм көрәшәм. Ишетерсең. Тик көтмә. Бер айдан монда килмим... Йөрәксез син!

Шәмсия. Даян! Улым!

Даян. Сез мине башка күрмәссез! Хушыгыз!

Бикә белән Иркә керә.

Бикә. Привет!

Иркә. Ә без сине эзлибез!

Ләләне кочаклап читкә алып китәләр.

Ләлә. Туктагыз әле!

Шәмсия. Коткарыгыз! Хулиганнар! Даян!

Бикә. Апа, тавышланма! Без кызыңның танышлары.

Иркә. Сөйгән егетләре.

Ләлә. Мин сезне танымыйм.

Бикә. Ярый, кыланма.

Иркә. Киттек танцыга. Шуннан төне буе! Үткәндәге кебек, ә?

Ләлә. Нәрсә?

Бикә. Кара, тартынган була. Әнә теге карачкыга чыгарга җыенмыйсыңдыр бит?

Шәмсия. Китегез кызым яныннан. Ләлә, кил монда!

Бикә. Апа, курыкма! Без Ләләнең иң яраткан егетләре.

Шәмсия. Алдашмагыз! Берегезне дә күргәнем юк.

Бикә. Алайса, исемен кайдан беләбез?

Иркә. Әйе. Ләлә. Икебез дә белә.

Шәмсия. Китегез, дим яныннан! Югыйсә хәзер... Милиция! Прокурор!

Бикә. Син, апа, менә шушыны ку. Ул кызларны алдый да кача.

Даян. Нәрсә?

Бикә. Юк диярга телисеңме? Бар кызларың да шулай сөйли.

Иркә. Елап сөйли.

Бикә. Шулай, апа. Кызың исән чакта качыгыз моннан. Без соңыннан килеп чыгарбыз.

Бикә. Ләләдән көлгәне өчен акылга утыртабыз да.

Даян. Ну-ка, килегез әле монда! Кем сез? Нәрсә кирәк?

Бикә. Ипләбрәк, ярыймы?

Даян. Тукта, тукта! *(Кинәт кенә Бикәнең эшләпәсен, шуннан мыегын йолкып ала.)* Ха-ха-ха!

Шәмсия. Хатын-кыз түгелме соң бу?

Даян. Ә монысы кем? Иркә, син бит?

Иркә. Түгел, түгел!

Иркә качмакчы була. Даян тотып аның кепкасы белән мыегын йолкып ала.

Даян. Иркә! Сәлам!

Шәмсия. Әстәгъфирулла!

Даян. Таныш булыгыз: Иркә – минем беренче хатыным. Бикә – аның ахирәте.

Шәмсия. Нигә алай итеп йөрисез, оятсызлар?

Азат керә.

Иркә. Эшегез булмасын! Ләләне шушыңа бирергә телисезме? Ә мин аның беренче хатыны! Белеп торыгыз: ул – алкаш! Гел мине тукмый торган иде. Күршеләр белән сугышты, киемнәребезне сатып эчте.

Бикә. Бүген киенгән булган. Дусларыныкын урлаган ул.

Азат. Әйе. Минекен! Тотылдыңмы, карак?

Даян. Кит әле!

Шәмсия. Әй Алла!

Ләлә. Дөресме бу, Даян?

Иркә. Дөрес, Ләлә, дөрес. Алдашсам, җир йотсын. Урамда хатыннарны тукмады, башы айныткычтан чыкмады.

Даян. Сез нәрсә, акылдан шаштыгызмы?

Ләлә. Җаным... Ничек җәл ул... Әни, әнием! Аңа авыр. Ташламыйк аны!..

Шәмсия. Әй, кызым...

Даян. Ләлә, тукта әле!..

Ләлә. Даян, акланма. Мин аңлыйм сине. Әни, аңа ярдәм кирәк. Харап була бит кеше!

Шәмсия. Шулай дисеңме?

Ләлә. Әйе... Мин сине беркайчан да җибәрмим, Даян. Мин... риза.

Даян. Нәрсә? Миңа чыгаргамы?

Ләлә. Әйе.

Даян. Ләлә! Мин... Ярый.

Шәмсия. Әй-й!.. Чыксаң чык та куй, кызым!

Иркә. Ул бит алкаш, сугыш чукмары.

Шәмсия. Булсын! Кеше итәрбез әле!

Ләлә. Бөтенесе дә әйбәт булачак, Даян.

Даян. Мин беләм, Ләлә.

Иркә. Оятсызлар! Нахаллар!.. Ялгыз калдым!..

Бикә. Бәхетебез юк, Иркә!..

Иркә. Кит!..

Азат. Кызларның да акыллысы бар икән. Их!.. Әйдә, тагын эксперимент эшлик! Миңа да шундый хатын кирәк!

Даян. Димәк, мин хаклы булганмын. Дөньяның гадел булуына куанам мин. Менә хәзер мин күккә аштым!

Шәмсия. Бәхетле булыгыз, балалар!

Даян, Ләлә *(бергә)*. Рәхмәт! ***(Җырлыйлар.)***

Каршылыклар аша бер-беребезгә...

Ләлә. Мин сиңа...

Даян. Мин сиңа...

Ләлә. Озак еллар килдек без.

Даян. Сөюдән дә олырак тойгының...

Ләлә. Юклыгын...

Даян. Булмасын...

Ләлә, Даян *(бергә)*. Очрашкач кына белдек без.

Бөтенесе бергә. Рәхим итегез туебызга,
Авыз итегез сыебыздан.
Безгә бетмәс бәхет теләгез,
Ә без сезгә аннан бүләрбез.

Пәрдә.

1988

СТУДЕНТЛАР, ЯКИ КЫЗЛАР, ИШЕК АЧЫГЫЗ!

Комедия, ике пәрдәдә

Катнашалар:

Госман.
Алмас.
Морат.
Хәкимә.
Рәмзия.
Әсма.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Җәй башы. Кич. Студентлар тулай торагы.
Хәкимә өстәл әзерли. Әсма караватта ята.

Әсма. Хәкимә апам! Нишләргә миңа? Иртәгә бит әтиебез килә! Аның күзенә ничек күренербез? Бәлки, миңа больниска ятаргадыр?

Хәкимә. Нигә?

Әсма. Үтерәчәк бит икебезне дә! Ичмасам, аңа: «Әсма авырып китте, больниска ятты. Шуңа анатомияне тапшыра алмады»,— диярсең.

Хәкимә. Син бит башка фәннәрне «бишле»гә тапшырасың. Ә нигә анатомияне өч тапкыр «ике»гә?

Әсма. Минем хәлем юк! Инде ничәмә көн чәй дә чәй! Башым әйләнә, хәтерем югала.

Хәкимә. Мин дә ач, ә имтиханнарымны бирәм бит.

Әсма. Өч ел буена син өйрәнеп беткәнсең.

Хәкимә. Ачлыкка өйрәнеп булмый. Тукта, кухняга барып киләм.

Әсма. Анда ни эшлисең?

Хәкимә. Аш куйдым пешерергә. *(Китә.)*

Әсма. Аш! Минем бит ике ай итле аш күргәнем юк!

Хәкимә керә.

Хәкимә. Егерме минуттан пешә.

Әсма. Тукта! Ә каян акча алдың?

Хәкимә. Кешедән!

Әсма. Уф, апам! Үләм бит ачлыктан! Ашап алсам, бәлки, иртәгә анатомияне биреп ташлармын. Әти килгәнче...

Хәкимә. Сиңа эләкми әле ул аш.

Әсма. Ничек «эләкми»? Үзең генә ашап утырасыңмы бертуган сеңлеңнән яшереп? Тукта! Ә бу нинди табын?

Хәкимә. Тимә! Миңа кунак килә. Калдырырмын.

Әсма. Чак кына! *(Ашап карый.)* Уф, тәмле!

Хәкимә. Җитте! Җитте, дим! Табынны бозасың!

Әсма. Ә нинди кунак? Шулхәтле важныймыни?

Хәкимә. Хәзер егылып китәчәксең! Республикада иң яшь фән кандидаты, иртәгә безгә декан булачак кеше!

Әсма. Кем?! Әллә Госман Сабировичмы?

Хәкимә. Нәкъ үзе! Синең анатомия буенча укытучың!

Әсма. Нигә? Нигә чакырдың аны?! Ул бит мине шушы көнгә төшерде! Юри «икеле» куя, кабахәт! Институттан кудырырга тели! Ә син аны — кунакка!

Хәкимә. Аңламадыңмыни әле? Мин бит аны хәйлә белән кунакка чакырдым. Әгәр син институттан куылсаң, әти иң беренче минем кирәкне бирәчәк. Ул бит миңа әйтте, сеңлең куылсын гына, сине...

Әсма. Ай, куркам мин әтидән! Исеңдәме, авылда чакта «икеле» алсак, келәткә бикләп куя иде.

Хәкимә. Икенчедән, әти-әни алдында... җаваплылык бар бит әле. Алар безне үстерде, тәрбияләде, кеше итәбез дип тырыша. Ә без... оят! Хәзер Госман Сабирович килсә сыйлыйм... Вино эчәбез, биибез!

Әсма. Шуннан?

Хәкимә. Шуннан ул сиңа иртәгә анатомиядән «бишле» куя! Син институттан куылмыйсың! Әти безне мактаячак!
Әсма. Ура! Тукта! Ышанмыйм! Ул бит туң йөрәк! Боз күз! Хайван! Ул килмәячәк!
Хәкимә. Киләчәк. Мин аны туган көнемә чакырдым. Икәүдән-икәү генә утырабыз, дидем.
Әсма. Ничек туган көнеңә? Синең бит...
Хәкимә. Тс-с! Киләчәк!
Әсма. Тулай торакта аны бөтенесе дә белә. Ул бит куркак!
Хәкимә. Бөтенесе дә уйланган, туганкай. Ул бүген тулай торакта дежурить итә. Бүлмәләр буйлап йөри. Минем янда озаграк булачак. Беркем дә сизмәячәк.
Әсма. Ул шулай һәр чакырган студентка янына йөри микән?
Хәкимә. Ул җүләр түгел. Иң ошаганы янына гына.
Әсма. Нәрсә, син аңа ошыйсыңмы?
Хәкимә. Ә нигә ошамаска? Чибәрмен, фигурам матур.
Әсма. Ә ул сиңа?
Хәкимә. Ул да миңа ошый.
Әсма. Ә Алмасың? Ул белеп алса?
Хәкимә. Мин аның белән араны өздем! Бетте мәхәббәт!
Әсма. Ничек? Үткән атнада гына...
Хәкимә. Ул миннән яшереп башка кызлар белән йөргән. Дурак. Ярый, бар, кит! Госман Сабирович килә хәзер. Сине күрсә, хәйләне аңлар да чыгар да китәр. Пока!
Әсма. Юк! Апам, кирәкми. Очрашма аның белән!
Хәкимә. Нәрсә? Институттан куылырга телисеңме? Бар, бар! Курсташ кызларыңда утырып тор.
Әсма. Кайчан... кайтырга?
Хәкимә. Ике сәгатьтән.
Әсма. Бик эреп китмә! Аның кызы бар. Өйләнергә йөри.
Хәкимә. Аңладым. Бар, кит! Хәзер килә!

Ишек шакыйлар.

Әнә килде! Их син!

Әсма. Ул микәнни?

Хәкимә. Тс-с! Кем бар?

Тавыш ишетелә: «Обход! Тикшерү! Ачыгыз!»

Хәкимә. Ул! Йа Ходаем! Сине күрсә, ул бөтенесен дә аңлаячак!.. Госман Сабирович! Бер генә минут! Әйттем мин сиңа кит дип!

Әсма. Миңа күренергә ярамый!

Хәкимә. Кычкырма! Кач!

Әсма. Кая?

Хәкимә. Туалетка! Юк, шкафка!

Әсма. Монда караңгы!

Хәкимә. Түзәрсең! Кара аны! Тыныңны да чыгарма!

Әсма шкафка кача. Хәкимә ишекне ача, Госман керә.

Госман. Хәерле кич, Салихова!

Хәкимә. Исәнмесез, Госман Сабирович! Әйдә, үтегез!

Госман. Туган көнең белән!

Хәкимә. О! Рәхмәт!

Госман. Менә шәраб алып килдем.

Хәкимә. Кирәкмәс иде. Үзем дә алган идем.

Госман. Анысын дусларың белән эчәрсең. Хәкимә! Нинди чибәр син! Көмеш калакка салып йотарлык!

Хәкимә. Госман Сабирович, сез бигрәк! Ничек кенә рәхмәт әйтеп бетерим икән? Иң олы рәхмәтем – килүегез өчен!

Госман. Шундый матур кыз чакырсын да, ничек килмисең? Берүзең яшисеңме?

Хәкимә. Иптәш кызым белән. Ул авылына кайтып китте.

Госман. Әйбәт. О, нинди табын! Студентлар ярлы яши, дигән булалар.

Хәкимә. Сезнең өчен тырыштым инде, Госман Сабирович.

Госман. Әйткәнемчә, минем вакыт бик тар. Унбергә хәтле тулай торакны әйләнеп чыгарга кирәк.

Хәкимә. Нигә унбергә? Сезгә тулай торакта күпме теләсәгез, шулкадәр йөрергә ярый бит.

Госман. Ярамый шул. Вахтёрша күреп искәртте. Унбердә китәргә.

Хәкимә. Ай, ул әби! Аны төрмәдә надзиратель булган диләр. Дөрес микән?

Госман. Дөрес.

Хәкимә. Шулайдыр. Ул тулай торактан әллә никадәр кешене кудырды инде.

Госман. Ярый. Утырыйк.

Хәкимә. Мин ашны гына карап керим.

Хәкимә чыгып китә.

Госман. Кирәк бит! *(Утыра.)* Сак булырга кирәк! Ә кыз... шәп! Их! Бигрәк вакыт тар!..

Ишек шакыйлар.

Вахтёрша!..

Рәмзия керә.

Рәмзия. Госман Сабирович, бу сезме? Исәнмесез!

Госман. Сез монда ни эшлисез? Мин бүген тулай торакта дежурда. Бүлмәләрне карап йөрим. Кара, тәрәзә төпләре тузанлы икән.

Рәмзия. Ә Хәкимә кайда?

Госман. Нинди Хәкимә?

Рәмзия. Салихова.

Госман. Ул каядыр чыккан иде.

Рәмзия. О, табын! Нинди бәйрәм?

Госман. Белмим. Туган көн үткәрергә җыеналар шикелле. Син Наушربановның кызы бит әле?

Рәмзия. Әллә охшамаганмынмы?

Госман. Бик охшаган. Әтиеңне бик хөрмәт итәм. Үтә акыллы кеше.

Рәмзия. Начальниклар акылсыз булмый инде. Госман Сабирович, сезне шушында очратуым яхшы булды әле. Сезгә бер йомышым бар.

Госман. Мондый матур кызның йомышын үтәү минем өчен бәхет. Тыңлыйм.

Хәкимә керә.

Рәмзия. Хәкимә, исәнме!

Хәкимә. Рәмзия? Син монда ни эшлисең?

Рәмзия. Мин... Мине эзләп килмәделәрме монда?

Хәкимә. Син бит кала кызы. Ни эшләп эзләсеннәр? Ярый, бар, кит! Мин имтиханнарга әзерләнәм.

Госман. Салихова, менә монда тузан бар. Сөртеп куегыз.

Хәкимә. Хәзер сөртәм, Госман Сабирович. Рәмзия, сау бул!

Рәмзия. Мин Госман Сабировичны көтәм. Аңа йомышым бар.

Хәкимә. Госман Сабирович әлегә китми. Минем дә аңа әйтәсе сүзем бар. Бар, кит!

Рәмзия. Әйт соң сүзеңне. Мин көтеп торам.

Хәкимә. Бик тә кызык кеше син! Синең алда әйтә алмыйм. Сер.

Рәмзия. Алайса чыгып торам. Өч минуттан кире керәм.

Хәкимә. Кара әле, Рәмзия! Ул бит сиңа түгел, минем бүлмәгә килгән. Госман Сабирович кирәк булса, иртәгә институтта күрерсең. Хәзер аның вакыты юк! Бар, бар!

Рәмзия. Кара әле! Нигә этешәсең?

Госман. Кызлар, талашмагыз әле! Икегез белән дә шушында сөйләшәм. Кайчан миңа шушындый ике матур кыз белән утырырга туры килә әле. Салихова, рюмкалар! Бүген бит синең туган көнең!

Хәкимә. Бездә каян рюмка булсын? Чынаяклар. Ашка төшкән таракан кебек...

Рәмзия. Ай Аллам! Хәзер китәм, китәм! Госман Сабирович туктатканга гына...

Госман. Хәкимә! Елмай әле! Әнә шулай! Елмаю сиңа шундый килешә! Их, кызлар! Шундый матур сез! Тост! Матурлыгыгызның кадерен белегез, файдаланыгыз! Кияүгә чыккач үкенерлек булмасын! Һәм, Хәкимә, туган көнең белән! Һәрчак шушылай матур һәм бәхетле бул! *(Жырлый.)*

Эх, кызлар, кызлар!
Сез шундый матур!
Сезне күргәч тә
Таш чәчкә атыр!

Берне үбәем,
Килче яныма!
Бирче тынгылык
Янган җаныма!
Яшьлек кешегә
Бер генә килә.
Аның кадерен
Бик азлар белә.

Яшәп калыгыз
Сөеп, яратып,
Үкенмәс өчен
Соңыннан «аһ» итеп!

Хәкимә. Рәхмәт, Госман Сабирович!

Рәмзия. Бәхетле бул, Хәкимә!

Хәкимә. Рәхмәт!

Госман. Беренче курста да бер Салихова укый. Исеме ничек әле?

Хәкимә. Әсмамы?

Госман. Әйе, Әсма. Синең туганың түгелме?

Хәкимә. Юк-юк!

Рәмзия. Ул бит...

Хәкимә. Түгел! Фамилияләребез генә бертөсле. Ә ни булган?

Рәмзия. Ә-ә...

Госман. Шул кыз миңа өч тапкыр имтихан бирде. Матур гына кыз! Керә дә минем күзләргә шундый итеп текәлә! Әллә ничек булып китә. Үзе бер сүз эндәшми. Шулай утыра-утыра да капыл йөгереп чыга да китә. Өчесендә дә «икеле» куйдым.

Рәмзия. Коточкыч!

Хәкимә. Сезгә ул кыз... жәл түгелме?

Госман. Бер сүз дә эндәшми бит! Минемчә, ул кыз акылга чамалырак.

Хәкимә. Һич тә чамалы түгел, нормальный кыз. Ә сез беләсезме, аны институттан куалар. Сез куйган «икеле»ләр өчен.

Госман. Хәзер ни эшлисең инде? Шыр надан бит. Әйдә кайтсын авылына, бәлки, әйбәт кенә сыер савучы чыгар үзеннән. Болай матур кыз. Ярый, төп темадан читкә киттек. Тагын берне күтәрик әле Хәкимәне туган көне белән котлап! Әйдәгез!

Шкаф эчендә нидер ава.

Нәрсә ул?

Рәмзия. Нәрсәдер ауды. Шкафта.

Хәкимә. Һич тә шкафта түгел.

Госман. Миңа да шушында, якында гына кебек тоелды.

Хәкимә. Юк-юк, Госман Сабирович. Өстә. Бишенче катта. Анда хулиган егетләр яши. Һәрвакыт нәрсә дә булса аударалар. Госман Сабирович, мин әле генә шул Әсманы урамда күрдем. Күзләре сүнгән. Бау сатып алган.

Рәмзия. Бау?

Хәкимә. Әйе, бау. Яшәвемнең мәгънәсе калмады, асылынып үләм, ди.

Рәмзия. Кит, чынмы?

Хәкимә. Валлаһи! Бавын тартып алдым. Менә. Яңасын сатып алам, барыбер асылынам, дип, киредән магазинга китте.

Рәмзия. Коточкыч! Нәрсә булса да эшләргә кирәк бит!

Госман. Алдаша бит ул! Студентларның хәйләсен беләбез инде! Яңарак кына миңа бер студент килде дә: «Өчле» куймасаң, тәрәзәдән сикерәм!» – ди. Ә минем кабинет, үзегез беләсез, өченче катта. Тәрәзәне ачтым да: «Сикер, рәхим ит!» – дидем. Сикермәде. Асылынмаячак, куркыта гына! Куегыз, юк нәрсә турында сөйләшмик! Рәмзия, нинди йомышың бар иде миңа?

Рәмзия. Миңа эшкә урнашырга кирәк. Сезнең кафедрада лаборант урыны буш дип ишеткән идем.

Госман. Сиңа нәрсәгә эш, Рәмзия? Әтиең зур начальник.

Рәмзия. Әти куша да инде эшләргә. Ялкау булып үсәрмен дип курка.

Госман. Мәриядә юкмыни берәр эш?

Рәмзия. Үзең тап, ди. Янәсе, яшәргә өйрәтә.

Госман. Ярый, Рәмзиякәй, иртәгә килеп чык.

Рәмзия. Рәхмәт сезгә, Госман Сабирович!

Хәкимә. Рәмзия, син – эгоистка! Тегендә Әсма асылынырга йөри! Ә син үз мәнфәгатеңне кайгыртасың! Госман Сабирович! Бәлки, мин аны монда чакырыйм да тагын бер тапкыр имтихан алып карарсыз. Соңгы тапкыр!

Госман. Юк! Өч тапкыр алдым бит инде. Җитте!

Хәкимә. Институттан куалар бит кызны!

Госман. Кусыннар! Ул берни эндәшмәгәч, минем ни гаебем бар?

Рәмзия. Хәкимә, нигә катышасың? Госман Сабирович әйтеп тора бит...

Хәкимә. Тик тор, ярыймы?

Госман. Хәкимә, аңла, мин ялыктым алардан! Имтихан ал дип, өйгә киләләр, театрга барсам, театрда тоталар. Тулай торакка килеп ял итеп кайтыйммы дисәм... Юк, монда да! Аны чакырсаң чыгам да китәм.

Рәмзия. Госман Сабирович, тынычланыгыз. Янә кәефегезне күтәрү өчен күңелле генә бер тост әйтим әле. Кичә ишеткән идем.

Шул мәлдә Әсма шкафтан чыга да бүлмәнең ишеген эчтән бикли һәм ачкычны үзе белән алып кире шкафка кереп китә. Бүлмәдәгеләр аны күрми.

Хәкимә. Юк, кирәкми! Хәзер кунакларым килә. Синең тостыңны тыңлап торырга вакытым юк. Сау бул!

Рәмзия. Ярый инде алай булгач. Гафу итегез. Көткән кешеләрем дә күренми. Коридорда йөрмиләрме икән?

Госман. Хәкимә, миңа да вакыт. Унбер тула. Тулай торакны әйләнеп чыгарга кирәк.

Хәкимә. Госман Сабирович! Бер генә минутка туктагыз әле.

Рәмзия. Ачкыч кая?

Хәкимә. Ишектә.

Рәмзия. Ишектә юк.

Хәкимә. Яхшылап кара.

Рәмзия. Юк монда бернинди дә ачкыч!

Хәкимә. Идәнгә төшкәндер.

Рәмзия. Идәндә дә юк.

Хәкимә. Ай Аллам! Яхшылап кара! Әле генә шунда торган ачкыч очып китмәгәндер инде!

Рәмзия. Юк, беркайда да юк! Ә ишек бикле!

Госман. Ничек «юк»?

Хәкимә. Чынлап та юк. Менә сиңа кирәк булса! Ишектә тора иде бит! Кая китте икән?

Госман. Юкмы? Кызлар, шаяртмагыз! Мин — дежурда! Унбергә кадәр тулай торакны урап чыгарга тиешмен!

Хәкимә. Госман Сабирович, нинди шаяру?! Әле генә ишектә тора иде. Рәмзия, син ялгыш кесәңә салмадыңмы?

Рәмзия. Юк! Аның белән ни эшлим?

Госман. Кызлар! Әгәр уйныйсыз икән, хәзер үк туктатыгыз!

Хәкимә. Ай Алла!.. Кесәләребезне яхшылап карыйк!

Госман. Минем бүлмәләр буйлап йөргәнемне бөтен институт белә! Вахта белә! Миңа бер минутка да бикләнеп утырырга ярамый!

Хәкимә. Аңлыйм, Госман Сабирович, аңлыйм!

Госман. Аңлагач, нәрсә карап торасыз? Китерегез ачкычны!

Хәкимә. Госман Сабирович, хәзер табабыз, хәзер! Чак кына сабыр итегез.

Госман. Йә? Йә? Юкмы?

Хәкимә. Әлегә юк. Хәзер була.

Госман. Эзләгез, эзләгез!.. Тукта! Запас ачкычыгыз бардыр бит?!

Хәкимә. Бар... иде.

Госман. Кайда?

Хәкимә. Вахтада.

Госман. Шакы стенаны, күршеңне чакыр. Барып алсын да безне ачсын.

Хәкимә. Хәзер ул ачкыч юк.

Госман. Ничек «юк»? Кая киткән?

Хәкимә. Бер ай элек үзебезнекен югалткан идек. Запас ачкычны алдык.

Госман. Тфү! Шуннан, хәзер нишлибез? Моның өчен минем башны ашаячаклар, аңлыйсызмы шуны?

Хәкимә. Әй, ашым! Әй, ашым!

Рәмзия. Нинди ашың?

Хәкимә. Кухняда ашым кайный иде. Кайнап бетә.

Госман. Шайтаныма кирәкме ул аш? Монда баш яна, баш!

Рәмзия. Мин бик ашыга идем... Ничек ачарга соң бу ишекне?

Ишек шакыйлар.

Тавыш. Хәкимә! Хәкимә!

Хәкимә. Нәрсә кирәк?

Тавыш. Рәмзия монда түгелме?

Госман. Кем ул?

Рәмзия. Алмас! Мин монда!

Тавыш. Рәмзия, бу синме?

Рәмзия. Мин, мин! Алмас!

Госман. Нинди Алмас?

Хәкимә. Безнең группадан. Ишбулдин.

Госман. Шул гына җитмәгән иде. Минем монда икәнне сиздертмәгез.

Рәмзия. Алмас! Алмас!

Хәкимә. Тукта, ә нигә шулкадәр куанасың әле?

Рәмзия. Ул хәзер ишекне ача.

Хәкимә. Дура! Ачкычсыз ничек ачсын?

Тавыш. Рәмзия, Хәкимә, ачыгыз тизрәк!

Рәмзия. Ачкычны югалттык! Алмас! Ул яктан ачып булмыймы?

Тавыш. Ачкычсыз ничек ачыйм? Хәзер бүлмәдән ничек чыгасыз?

Рәмзия. Белмибез!

Тавыш. Ай, җүләр башлар! Яхшылап карагыз, ятадыр шунда!

Рәмзия. Бөтен җирне карадык! Беркайда да юк! Алмас! Кара әле! Кухняда Хәкимәнең ашы пешкән! Шуны безгә алып кил! Без ачыктык.

Тавыш. Нинди аш?

Рәмзия. Кухняда! Кухняда!

Тавыш. Нинди кәстрүлдә? Төсе нинди?

Хәкимә. Чәчәкле! Сары кәстрүл!

Тавыш. Алып килермен, ә ничек сезгә бирермен?

Госман. Нинди аш?! Ачкычны табыгыз, дим мин сезгә!

Хәкимә. Госман Сабирович, хәзер!.. Өстән төшер! Бишенче каттан! Тәрәзә аша! Простыняга бәйләп! Ишетәсеңме? Без моннан алырбыз!

Тавыш. Ишеттем! Хәзер эшлибез!

Госман. Сез ишекне ачарга уйлыйсызмы-юкмы?

Хәкимә. Хәзер ачабыз!..

Рәмзия. Ачмаса аптырамагыз, Госман Сабирович, ичмасам, бер туйганчы аш ашарбыз!

Госман. Тфү! Ачтан үлмисездер бит. Сәгать унбер! Хәзер вахтёр мине эзли башлаячак!..

Хәкимә. Әй Аллам!.. Үзең сакла!

Госман. Иртәгә учёный совет! Аңлыйсызмы шуны?! Ә мин – монда! Кызлар белән бикләнеп ятам! Кайдан килдем мин монда?!

Хәкимә. Госман Сабирович, минем гаебем юк!

Госман. Гаебең булмагач, кайда соң ачкыч? Кайда? Ишектә торган ачкыч ничек юкка чыкты? Монда өч кеше! Димәк, өчебезнең берсе алган!

Хәкимә. Алмаган. Кайсыбыздыр аңламастан берәр урынга куйган да оныткан.

Ачкычны эзләп йөргән Рәмзия шкафны ача.

Рәмзия. А-а!

Госман. Нәрсә булды?

Рәмзия. Анда! Анда!

Госман. Нәрсә? Ачкычмы?

Хәкимә. Нигә акырасың? Ишәк кебек!..

Рәмзия. Анда... Әсма!

Госман. Әсма? Нинди Әсма?.. Кем син? Салихова?! Нәрсә карап утырасың анда? Ну-ка, чык!

Әсма шкафтан чыга.

Тәк!.. Димәк... Өч тапкыр анатомиядән «икеле» алган, ә бүген асылынырга тиеш Салихова Әсма! Шкаф эчендә... Бау ишә!

Рәмзия. Без монда сәгать буе!.. Ә ул... Коточкыч!

Госман. Салихова! Хәкимә!

Хәкимә. Тыңлыйм, Госман Сабирович!

Госман. Моны ничек аңларга?

Хәкимә. Нәрсәне?

Госман. Нигә җүләр булып кыланасың? Аның шкафта утыруын!

Хәкимә. Ул... Ул...

Госман. Аңлашылды! Нигә утырттың?

Хәкимә. Эш шунда, Госман Сабирович... Әсма анатомия буенча өч тапкыр...

Госман. Мин синнән, нигә аны шкафка утыртып куйдың, дип сорыйм!

Хәкимә. Иртәгә... авылдан әтием... аның әтисе килә...

Госман. Кемнең атасы?

Хәкимә. Безнең, юк, аның!

Госман. Сез бертуганмы?

Хәкимә. Әйе, юк!..

Госман. Аңлашылды!

Хәкимә. Госман Сабирович, сез аңлагыз! Безнең әти бик усал! Ул әйтте... Әгәр институттан куылып, аны авыл алдында көлкегә калдырсак... Ул икебезне дә үтерә!

Госман. Димәк, син мине туган көнгә дип чакырып, сеңелкәшеңнән имтихан алдырырга уйлагансың!

Хәкимә. Госман Сабирович, аңлагыз. Әгәр бүген Әсма анатомиядән имтихан тапшырмаса...

Госман. Ул беркайчан да тапшыралмаячак! Беркайчан да! Аңладыңмы?! Алдау юлына басканыгыз өчен, ничек кенә әзерләнсә дә, мин аңа «икеле» куячакмын! Аңладыңмы?

Хәкимә. Госман Сабирович, әтиебез безне...

Госман. Бетте! Бу хакта башка сөйләшмибез!.. Бу ничәнче кат?

Рәмзия. Дүртенче.

Госман. Ишекне җимерәбез. Китерегез чүкеч яки балта! Балта, дим!

Хәкимә. Ишекне җимереп булмый. Ул – тимер.

Госман. Нәрсә юкны сөйлисең? Тулай торакта нинди тимер ишек булсын?!

Хәкимә. Әтием куйды.

Госман. Бу нинди дурдом? Нәрсәгә сезгә тимер ишек?! Алтын-көмешегез тулып ятамы? Яки доллар-маркалар? Нәрсәгә сезгә тимер ишек?!

Хәкимә. Егетләр җимереп кермәсен өчен...

Госман. Тфү! Юк, мин ышанмыйм! Ачкычны син югалтмадың! Син юри яшереп куйдың! Имтихан алмыйча мине моннан чыгармаска телисең! Тик син нык ялгышасың! Бу минем тормыш принципларыма каршы килә! Аңлыйсыңмы шуны?! Китер ачкычны!

Хәкимә. Юк!

Госман. Әһә! Димәк, мин хаклы! Ачкыч югалмаган! Яшергәнсең!

Хәкимә. Әйе.

Госман. Нинди мәкерлек! Нинди явызлык! Менә ул бүгенге яшьләр! Намус юк! Оят юк! Бир, дим?!

Хәкимә. Бирмим.

Госман. Бирмисеңме?

Хәкимә. Юк. Башта имтихан.

Рәмзия. Ничек оят түгел сиңа?!

Хәкимә. Тик тор! Синнән сорамыйлар!

Госман. Шуннан ачачаксыңмы ишекне?

Хәкимә. Ачам!

Госман. Нинди оятсызлык! Мин бит моны болай гына калдырмаячакмын! Институттан кудырам! Икегезне дә!

Хәкимә. Аңа оценка куегыз. Шуннан соң теләсә нәрсә эшләгез.

Госман. Син бит тормышыңны әле генә башлыйсың. Әгәр һәрвакыт шушылай гаделсезлек юлы белән уңышка ирешәм дип уйласаң...

Хәкимә. Кирәкми! Алдашмагыз! Без бит сезне беләбез!

Госман. Нәрсә беләсез?

Хәкимә. Ректорның кызына өйләнергә йөргәнегезне! Кылый күзле кызына! Декан булыр өчен! Бу гадел юлмы?

Госман. Сез! Сез! Анда ни эшегез бар?! Мине өйрәтергә башыгыз яшь!

Хәкимә. Сез бит аны яратмыйсыз! Карьера өчен өйләнәсез! Байлык өчен! Шушы принципмы?!

Госман. Җитте! Бир ачкычны!

Хәкимә. Башта имтихан! Зинһар өчен! Үтермәгез Әсманы, Госман Сабирович!

Госман. Үлсен! Әйттем – бетте! Алмыйм имтихан!

Хәкимә. Үлсенме? Димәк, сезгә кеше гомере бер тиен дә тормый! Ярый, сезнеңчә булсын! Әсма, кил! Кил, дим! Менә бау! Асылын! Хәзер үк асылын! Әти иртәгә барыбер үтерәчәк!.. Нәрсә карап торасың?!

Әсма. Апам?!

Хәкимә. Тиз бул!

Рәмзия. Ни эшлисез?! Әсма!

Хәкимә. Кит моннан! Урындыкка бас!

Рәмзия. Госман Сабирович! Туктатыгыз! Асылына бит!

Госман. Рәмзия, курыкма! Алдаша алар! Миннән имтихан алдыртмакчылар. Барып чыкмас! Асылын! Асылын!

Хәкимә. Хәзер күрерсез алдашканны! Димәк, аңа гадел яшәмәсә дә ярый. Ә безгә гел гадел яшәргә! Институттан куылырга! Сыер савучы булырга! Нәрсә ташбака кебек мыштырдыйсың?

Рәмзия. Хәкимә!.. Госман Сабирович!

Госман. Сез нәрсә?! Сез нәрсә? Чынлапмы?! Тукта хәзер үк! Тукта!

Хәкимә. Китегез!

Госман. Син нәрсә? Акылдан шаштыңмы әллә?! Тукта, дим!

Әсма. Юк! Үләм! Барыбер үләм!

Госман. Төш! Төш хәзер үк! Дура! Шулай шаяраларммы?!

Әсма. Иртәгә барыбер әти үтерәчәк!

Госман. Вәт җүләрләр!.. «Икеле» алдым дип!.. Ярый! Күндердегез! Димәк, болай... Хәзер бер генә сорау бирәм. Бер генә сорау!

Хәкимә. Госман Сабирович! Кадерлем!

Госман. Комачаулама! Әзерләнергә унбиш секунд!

Хәкимә. Унбиш секунд? Рәхмәт, Госман Сабирович! Әсма?

Госман. Тик бер шарт.

Хәкимә. Тыңлыйм!

Госман. Дөрес җавап бирәме-юкмы, мине чыгарып җибәрәсез. Килештекме?

Хәкимә. Килештек! Булды! Әсма! Фикереңне тупла! Син бит бөтенесен дә беләсең! Чәчләреңне рәтлә! Әзерме?.. Йә!

Госман. Нәрсә ул... йөрәк?

Хәкимә. Йөрәк?!

Госман. Әйе, йөрәк?

Хәкимә. Әсма!

Госман. Биш секунд! Карама!

Хәкимә. Уйла! Уйла! Син бит беләсең!

Госман. Ун секунд! Карама миңа, карама!

Хәкимә. Ичмасам, әйт берәр нәрсә!

Госман. Карама, карама, дим! Унбиш секунд! Бетте!

Хәкимә. Дура! Нигә эндәшмисең?!

Госман. Менә күрәсеңме? Әнә шулай эндәшми тик утыра. Шуннан «икеле»дән башка нәрсә куйыйм?

Хәкимә. Бер сүз әйтсәң, телең корыр идеме?! Тинтәк, аңгыра, туңбаш! Дөрес куалар! Дөрес!

Госман. Мин дә әйтәм бит – кусыннар. Кайтсын авылына. Сыер савучы булсын!

Әсма. Кусыннармы? Сыер савучы булсынмы? Ә син?Мине кудырып бәхетле булачаксыңмы? Менә сиңа бәхет! Син бит тиле! Аңгыра! Акыллы булсаң, шушында бикләнеп калмас идең! Хәзер сине тотачаклар! Эштән куачаклар! Менә хәзер бул инде декан! Өйлән ректор кызына!

Хәкимә. Дура! Акылдан шаштыңмы? Тукта хәзер үк!

Әсма. Чәчрәп китегез! *(Ваннага кереп китә.)*

Госман. Кара, ничек этләшә! Ә мин аны телсез дигән булам!

Хәкимә. Ахмак! Нәрсә сөйләгәнен белми. Гафу итегез инде аны, Госман Сабирович! Кайгысыннан ул...

Госман. Мондый тел белән!.. Имтиханда эндәшми утыруына аптырыйм. Башка фәннәре ничегрәк соң аның?

Хәкимә. «Бишле».

Госман. «Бишле»?! Ә ни өчен миңа килсә... Гаҗәп! Гаҗәп бу!.. Ярый, булды. Хәкимә, шартыңны үтәдем. Хәзер минем чират.

Хәкимә. Гафу итегез, Госман Сабирович, ача алмыйм.

Госман. Бу бит гадел түгел! Без бит сөйләштек! Килештек! Мин имтихан алам, Әсма җавап бирәмеюкмы...

Хәкимә. Юк миндә ачкыч!

Госман. Ничек «юк»! Син бит әйттең! Имтихан гына ал, ишекне ачам, дидең! Ач давай!

Хәкимә. Мин алдаштым.

Госман. Ничек? Алдаштың?

Хәкимә. Миңа бернәрсәгә карамый Әсмадан имтихан алдыртырга кирәк иде. Ә ачкыч... Ул чынлап та югалды...

Госман. Нинди куркыныч кеше син! Йөрәксез! Йа Алла! Каян килеп каптым мин?!

Хәкимә. Госман Сабирович, тынычланыгыз!.. Мә, су эчегез.

Госман. Хәкимә, зинһар, аңларга тырыш! Иртәгә учёный совет. Әгәр шушы хәл билгеле булса... Әгәр ачкыч синдә икән, зинһар, ач! Куям мин синең Әсмаңа «өчле»не! Куям! Ач!

Хәкимә. Чынмы?! Госман Сабирович! Зур рәхмәт сезгә! Сез шундый изге кеше! Рәхмәт! Менә зачётка. Туктагыз!

Госман. Нәрсә?

Хәкимә. Миндә бит... ачкыч юк...

Госман. Бетте!.. Хәзер бу ишекне милиция генә ача ала... Бу хәл бөтен институтка билгеле булачак... Син мине үтердең!..

Рәмзия. Кая киткән соң ул каһәр суккан ачкыч?!

Тәрәзә шакыйлар.

Рәмзия. Шакыйлар!

Госман. Бу – вахтёрша!

Хәкимә. Ишекне түгел, тәрәзәне!

Госман. Тәрәзәне?! Дүртенче катта?!

Рәмзия. Ура! Алмас! Аш китерделәр!

Госман. Кем ул? Ишбулдинмы?

Хәкимә. Әйе. Анда алар икәү!

Рәмзия. Алмас! Мин монда! Керегез!

Госман. Тукта! Алар мине күрергә тиеш түгел!

Алмас. Ачыгыз тәрәзәне!

Хәкимә. Аш кайда?

Алмас. Ач тизрәк! Егылып төшәбез бит!

Хәкимә. Мин бит сиңа ашны төшер, дидем. Нигә үзең төштең?

Алмас. Аш! Аш хәзер була!

Рәмзия. Ашны түгәләр! Ач тизрәк!

Госман. Ашны бирсен дә, китсеннәр!

Рәмзия. Егылып төшәләр бит!

Хәкимә. Ашны бирәсез дә китәсез!

Алмас. Китәбез, китәбез! Ач, тиз бул!

Госман чаршау артына яшеренә. Хәкимә тәрәзәне ача. Алмас, аның артыннан Морат керәләр.

Алмас. Сәлам, тутый кошлар!

Морат. Исәнмесез!

Рәмзия. Исән әле.

Хәкимә. Аш кайда?

Алмас. Нинди аш?

Хәкимә. Мин бит сиңа әйттем! Кухняда аш пешеп утыра! Чәчәкле кәстрүлдә. Шуны төшер, дидем. Кайда ул?

Алмас. Кухняда?

Хәкимә. Әйе.

Алмас. Чәчәкле кәстрүлдә?

Хәкимә. Кыланма! Алып кердеңме-юкмы?

Алмас. Ул әле... пешеп җитмәгән!

Хәкимә. Ул бер сәгать элек әзер иде!

Алмас. О, Рәмзия! Син дә мондамыни? Сагындым!

Рәмзия. Мин дә!

Хәкимә. Җитте сезгә! Бу мәхәббәт аңлашу урыны түгел! Нигә алып кермәдең?

Алмас. Пешмәгән, дидем бит мин сиңа! Морат, кара әле! Без бит монда парлы икән! Рәмзия – миңа, Хәкимә – сиңа! Погуляем!

Хәкимә. Гулять итмичә тор, прогульщик! Кая куйдың ашны?

Алмас. Кара әле, син нәрсә, попугай кебек, бер сүзне кабатлыйсың? Кайда аш, кайда аш? Әйттем бит, пешмәгән.

Хәкимә. Бар, чыгып кит!

Алмас. Кычкырма, яме. Старостамын дигәч тә... Үзең чакырдың бит!

Хәкимә. Кем чакырды сине?

Алмас. Син! Бишенче каттан төш, дидең. Простыня белән.

Хәкимә. Мин бит ашны төшер, дидем. Дурак!

Алмас. Шулаймыни? Ә мин уйладым...

Хәкимә. Булды, аңлаштык! Хәзер чыгып китегез!

Алмас. Ничек? Ишек бит бикле!

Хәкимә. Кайдан кердегез – шуннан!

Алмас. Простыняларыгыз җитмәс!

Хәкимә. Чыгып китегез, дим! Бар! Бар!

Алмас. Тынычлан! Без әле беркая да китмибез. Менә вино алып килдек. Башта шуны эчәбез. Танышу хөрмәтенә. Шуннан карарбыз.

Хәкимә. Ал виноңны! Хәзер бәреп ватам!

Алмас. Ватсаң, хакын түләргә туры килә, дамочка! Үзенә ярты стипендия китте! Ә синең аркада минем стипендиясез калганны исәпләгәндә...

Хәкимә. Менә сиңа... стипендия! *(Кукиш күрсәтә.)*

Морат. Алмас, бәлки, китәргәдер. Уйламыйчарак килеп кердек шикелле.

Алмас. Ишекне ачсыннар, китәрбез. Без каскадёр түгел көненә ун тапкыр стена буйлап йөрергә! Ач виноны!

Рәмзия. Хәкимә, ярый, ачуланма инде. Кертмәскә иде, керткәч, аларны ничек чыгарып җибәрәсең?

Хәкимә. Тик кенә тор, яме!

Алмас. Тукта! Бу нинди табын? Вино эчкәннәр! Өч чынаяк! Ә кем өченче?

Хәкимә. Анда синең ни эшең бар?

Алмас. Ничек булмасын? Парлы-парлыбыз, дисәм... Кем?

Рәмзия. Алмас! Өченчебез – Әсма. Ваннада елап утыра.

Алмас. Тагын имтихан бирә алмаганмыни?

Рәмзия. Әйе.

Алмас. Ну бу Госман Сабирович, ишәк, ә? Ну ишәк! Шундый матур кызны елатып...

Хәкимә. Җитте сиңа!

Алмас. Нигә «җитте»! Ул бит декан булам дип ректорның кылый күзле кызына өйләнергә йөри. Вәт дурак, ә?!

Рәмзия. Алмас, тукта! Ярамый кеше үзе юкта аның хакында начар сөйләргә!

Алмас. Ай, акыллы да соң син, Рәмзиякәем! Аптырап әйтәм. Миллион доллар бирсәләр дә, мин ул кызга өйләнмәс идем.

Рәмзия. Ә миңа?

Алмас. Ә сиңа үзем миллион доллар биреп өйләнер идем. Әй, онытып торам. Хәкимә, таныш бул: Морат – минем авылдаш...

Хәкимә. Ташла кылануыңны! Ялкытты!

Алмас. Ә нигә? Икегез дә отличник. Сездән менә дигән пар чыгачак. Әйдәгез, танышу хөрмәтенә күтәрик берне!

Хәкимә. Без эчмибез!

Рәмзия. Хәкимә, ачуланма инде! Хәзер безгә озак кына бергә... кайгырырга туры киләчәк. Ачкыч табылганчы. Чак кына эчсәк, бәлки... җиңелрәк булыр.

Морат. Эчәргә түгел, ишекне ачарга кирәк!

Рәмзия. Алмас! Дустыңны телсез генә димәкче идем, өстәвенә җүләр дә икән!

Морат. Кызларга тупаслык килешми.

Рәмзия. Кызларны егетләр тупасландыра!

Алмас. Морат, Рәмзиягә бәйләнмә, ул – минем любовь! Сиңа әнә Хәкимә! Рәмзия, кил әле монда! Күрсеннәр безнең мәхәббәтне!

Хәкимә. Җитте сезгә!

Алмас. Синнән сорамыйлар, тик тор! Рәмзия!

Морат. Алмас, Хәкимә дөрес әйтә. Ярамый алай.

Алмас. Кара, мин аны дус дип алып килдем, ә ул... Рәмзия! Кил, тагын берне!

Рәмзия. Арттырып җибәрәсең!

Алмас. Ах, шулаймы?! Рәмзия, кирәк...

Алмас Рәмзияне тотмакчы була, ул кача, Алмас чаршау артында торган Госманга барып бәрелә.

Бәй, кем монда? Госман Сабирович?! Менә сиңа кирәк булса!

Госман. Кхым!.. Исәнмесез, егетләр!

Алмас. Исән әле.

Морат. Сез? Монда? Ха-ха-ха!

Рәмзия. Нигә көләсең?

Морат. Бу бит комедия!

Алмас. Тукта! Кем чакырды монда Госман Сабировичны?

Хәкимә. Мин! Шуннан?

Госман. Юк. Мин дежурда идем... Шушы бүлмәне тикшерергә кергән идем... Ачкычны таба алмыйбыз...

Алмас. Анда бит сезне эзлиләр. Бездән ике тапкыр сорадылар.

Госман. Кем эзли?

Алмас. Вахтёр әби!

Морат. Ректорның әбисе!

Хәкимә. Нәрсә?

Рәмзия. Ул әби ректор хатынының әнисемени?

Морат. Әйе. Ректорның тёщасы!

Алмас. Менә сиңа мә! Безнең бикләнеп ятканны ректор бүген үк беләчәк! Исән чакта моннан качарга кирәк, егетләр!

Морат. Менә сезгә бер капкын!

Госман. Ишбулдин!

Алмас. Тыңлыйм, Госман Сабирович!

Госман. Ишекне ничек тә ачарга кирәк. Башкача юл юк.

Алмас. Аны ничек ачасың, Госман Сабирович?! Ишек бит тимер! Да, Хәкимә! Бикләнеп бүлмәдә бардак оештырганың өчен...

Хәкимә. Нигә шатланасың?

Алмас. Сине институттан кусалар, икенче староста сайлар идек. Ул миңа стипендия юллар иде...

Хәкимә. Синдәй прогульщикка Алланың кашка тәкәсе дә стипендия юлламаячак! Элек яшереп йөргәннәремә рәхмәт әйт!

Алмас. Эш бит прогулда түгел!

Хәкимә. Син үзеңне бик кыйммәт бәялисең, дускай!

Алмас. Миңа стипендия юлла давай!

Хәкимә. Акча кирәк булса, эшкә урнаш!

Алмас. Ә институт?

Хәкимә. Институтта синең кебек аморальный бәндәләр булырга тиеш түгел!

Алмас. Ух! Нигә кызлар шулай бәгырьсез була икән?

Госман. Ишбулдин! Тукта әле! Кил монда!

Алмас. Тыңлыйм, Госман Сабирович!

Госман. Син бик үткен егет. Миңа моннан ничек булса да чыгарга кирәк. Киңәш бир.

Морат. Песи дә агачка менгәндә кире төшәрен уйлый.

Алмас. Минемчә, моннан чыгу өчен бердәнбер юл тәрәзә аша, Госман Сабирович!

Госман. Тәрәзә аша? Бу мөмкинме?

Алмас. Бик мөмкин. Парашют!

Госман. Нинди парашют?

Алмас. Студентларның иң яраткан транспорты! Простыняга бәйлибез дә төшерәбез дә җибәрәбез. Бер секунд!

Морат. Тик моның өчен бәләкәй генә булса да йөрәк кирәк!

Рәмзия. Госман Сабирович, тыңламагыз шуның сүзләрен.

Госман. Мин ахмак сүзләрне ишетмим.

Морат. Нигә аның яклы булдың әле? Берәр нәрсә вәгъдә иттеме?

Рәмзия. Итте шул! Шуннан?

Алмас. Госман Сабирович, уйлый торыгыз. Хәл итсәгез, хәзер төшереп җибәрәбез. Ә әлегә! Егетләр! Кызлар! Вино ачык торса айный ул! Тост әйтик!

Рәмзия. Чынлап та! Бүген бит Хәкимәнең туган көне!

Алмас. Туган көне? Ничек?

Хәкимә. Әйе, туган көнем!

Алмас. Бик... Сәер бу. Шуңа чакырдыңмы Госман Сабировичны?

Хәкимә. Анда ни эшең бар?

Алмас. Ярар, безгә ни, арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит! Тост! Госман Сабирович, кайгырмагыз шулай! Безнең кәефне бетерәсез! Хәзер тәрәзәдән төшереп җибәрербез. Ә лутчы калыгыз монда. Вино бар, кызлар бар. Күп булса, эштән куарлар. Иң мөһиме – баш исән булсын! Әйдә, эчик!

Госман. Юк! Эштән куа алмый алар мине! Монда бикләнеп калуым ул – чүп! Ул бернәрсә дә аңлатмый!

Морат. Өйләнергә йөргән кеше тулай торакта кызлар белән бикләнеп ята. Төнлә! Шушы чүпме?

Госман. Бу очраклы хәл! Очраклы! Андый хәлгә һәркемнең эләгүе бар!

Морат. Тик иртәгә декан булам дигән кеше түгел!

Алмас. Ай Алла! Эчәбезме бүген, юкмы? Госман Сабирович, тотыгыз! Эчкәч, берәр юлы табыла аның! Хәкимә әйтмешли, Госман Сабирович качмас борын нигә Әсмадан имтихан алдыртмаска!

Госман. Миннән – ишәктән?

Алмас. Госман Сабирович, беләсегез килсә, безнең институтта сездән дә әйбәт укытучы юк!

Госман. Син бит әйттең, Госман Сабирович – ишәк, дип.

Алмас. Госман Сабирович, кайгырмагыз! Үзләре ишетмәгәндә без барлык укытучыларны да ишәк дип атыйбыз.

Госман. Юк, мин – ишәк! Мин кызларның матурлыгына түгел, белеменә карыйм. Шуның өчен мине шушында китереп бикләдегез! Алдан сөйләшеп! Дошманнарым белән кушылып! Бик иртә шатланасыз! Моның өчен җавап бирәчәксез! Бөтенегез дә!

Алмас. Юк, егетләр! Мөмкин хәтле тизрәк эчәргә кирәк! Югыйсә хәзер сугыша башлыйбыз!

Госман. Чыгыйм гына! Я с вами разберусь!

Морат. Бөтен бәла дә шунда – чыгып булмый. Вахтёр милиция чакырмаса.

Госман. Хәбиров, җитте сиңа! Эндәшмәгән саен! Син институттан куылган! Нәрсә кирәк сиңа безнең тулай торакта?

Морат. Мин медицина институты студенты!

Алмас. Җитте! Тост!

Хәкимә. Нинди тост? Эчсәк эчик тә... Югыйсә шундый кыен...

Алмас. Тостсыз пьянка була. Тост! Иптәшләр! Шундый тормыш китте: кеше хәлен кеше белми. Һәркем үзен генә уйлый. Әйдә, бер-беребезнең хәлен аңлау өчен эчик!

Хәкимә. Мәгънәсез тост! Кеше гаепле икән, аның хәлен аңлау кирәкми!

Алмас. Кирәк! Чөнки бер яктан караганда, кеше гаепле кебек, ә икенче яктан...

Хәкимә. Гаеп – һәрчак гаеп! Ул кешенең бәйсезлегеннән килә. Андый кешене беркайчан да гафу итәргә ярамый.

Рәмзия. Минемчә, тормышта иң мөһиме – һәркем мәхәббәттә тугры булырга тиеш. Әгәр кемдер байлыкка алданып, мәхәббәтенә хыянәт итсә... Дөньяда шундый кешеләр булмасын. Шуның өчен!

Морат. Мин бу тост өчен эчмим!

Алмас. Нигә? Бик матур тост!

Морат. Әгәр тормыш үзе хыянәт ясарга мәҗбүр итсә?

Рәмзия. Тормыш беркайчан да хыянәт ясарга мәҗбүр итми!

Госман. Туктагыз!

Алмас. Нигә?

Госман. Ачкыч Әсмада түгелме икән? Әсма!

Хәкимә. Эчәбезме бүген минем туган көн өчен, юкмы?

Алмас. Эчәбез! Туган көнең белән, Хәкимәү! *(Җырлый.)*

Яшьлек көннәре томанлы,
Парыңны табуы авыр.
Алтын диеп бакыр сайлап,
Күпләрнең өзелә бавыр.
Ашыкма, юллар чатында
Син кат-кат уйла.
Ялгышып соңыннан терсәгең
Тешләрдәй булма!
Тормыш юллары бормалы,
Ялгышып китүе җиңел.
Күп юлларның иң дөресен
Сайлый тик таза күңел.

Хәкимә. Кит! Ялагай!

Алмас. Үтерә бу староста бүген мине!

Госман. Әсманы чакырыгыз! Әсма!

Алмас. Госман Сабирович, эчик! Эчсәң җиңеләйтеп җибәрә, кайгылар онытыла! Эчегез!

Госман. Хәкимә, чакыр әле Әсманы. Йә, ярый! Әйдә!

Алмас. Вәт, афәрин! Күптән кирәк иде!

Хәкимә ваннага кереп китә.

Госман. Ох! Әйбәт вино икән!

Алмас. Күптән эчәсе иде. Югыйсә юк нәрсәгә кайгырып тик йөрисез!

Госман. Бигрәк тәмле! Сал әле тагын берне. Күбрәк сал!

Алмас. Безгә калмый бит!

Госман. Анда тагын бер шешә бар! Ох! Җиңелрәк булып китте... Рәмзия, кил әле минем янга. Утыр. Иртәгә үк миңа синең әтиең белән очрашырга кирәк.

Морат. Әтисе белән? Очрашыгыз, очрашыгыз. Аның әтисе сезгә нык ярдәм итәчәк.

Рәмзия. Тик тор! Ә мине эшкә алырсызмы соң?

Госман. Әлбәттә, Рәмзия!

Алмас. Әй, әй, Госман Сабирович! Бәйләнмәгез минем кызга! Чүтеки безнең арада любовь!

Рәмзия. Алмас, кысылма!

Алмас. Хыянәт! Нәрсә эшләргә миңа, Морат?

Морат. Беләсеңме, син кем? Хамелеон!

Рәмзия. Нәрсә? Хәзер маңгаеңа чәпим бит!

Алмас. Әй, әй! Иптәшләр! Кызмагыз! Винонны түгәсез!

Хәкимә керә.

Хәкимә. Әсма алмаган.

Алмас. Нәрсәне?

Хәкимә. Ачкычны.

Госман. Шуннан? Нәрсә тәкъдим итәсез? Ничек моннан чыгабыз?

Алмас. Ә нигә чыгарга? Вино бар, закуска бар! Һәркемгә берәр кыз. Утырыйк әле!

Хәкимә. Кемгә берәр кыз?

Алмас. Борчылма, син миңа түгел. Минем Рәмзиям бар. Рәмзия!

Хәкимә. Закуска бетте! Бар, кит!

Алмас. Беткән икән шул! Их, теге ашыгыз булса! Эчне тишмәс иде!

Хәкимә. Нигә алып кермәдең соң. Дурак! Алып төшсәң, кулың корыр идеме? Хәзер аны берәрсе урлаячак.

Алмас. Их, Хәкимә! Ашыңны күптән урлаганнар шул!

Хәкимә. Ничек «урлаганнар»?

Алмас. Кухняда бер генә кәстрүл утыра иде. Ул да булса буш.

Хәкимә. Чәчәкле сары кәстрүлме?

Алмас. Нәкъ үзе!

Хәкимә. Нинди тулай торак бу? Кемнәр яши монда? Булачак врачлар түгел бит болар! Караклар!

Госман. Нәрсә шул аш дип өзгәләнәсез? Аш күргәнегез юкмы? Ачтан үләргә җыенмыйсыздыр бит. Ашаудан да мөһимрәк нәрсәләр бар!

Хәкимә. Ач хәлен тук аңлыймыни? Сез бит доцент! Көн дә туйганчы ашыйсыз! Ә безнең ярты ел ит күргәнебез юк! Юк акчаны бар итеп бер кило ит алган идем. Аны да... Караклар! Тамакларына аркылы килсен шул аш! Ашыйм дисәң, ашы юк, укыйм дисәң... Нигә шулкадәр гаделсез бу тормыш?

Алмас. Хәкимә, тынычлан. Аш та булдымы кайгы...

Хәкимә. Кит моннан! Морат, әйдә, тот! Эчәбез!

Госман. Әйе, эчик! Бу тормыш, чынлап та, шундый гаделсез!

Морат. Мин тост әйтим әле.

Алмас. Тизрәк әйт. Эчәсе килә!

Морат. Тормыш барыбер гадел ул! Берәрсе хәйлә белән уңышка ирешергә маташса, тормыш аны һәрвакыт урынына утырта. Тормыш гаделлеге өчен!

Госман. Аңламадым. Кем хәйлә белән уңышка ирешә әле? Кемне тормыш үз урынына утырта?

Рәмзия. Госман Сабирович! Болар барысы да буш сүзләр! Игътибар итмәгез!

Алмас. Кұтәрдек!

Госман. Юк, аңлатсын! Кемгә төрттерә ул?

Морат. Мин бик аңлаешлы итеп әйттем шикелле.

Госман. Тәк, Хәбиров. Мин түздем. Бик озак түздем. Тик син чаманы югалттың. Минем кемлегемне оныттың, ахры! Бездән куылуың җитмәде, эшеңнән дә куыласың киләмени?

Морат. Син хатын-кыз булма! Ир була бел!

Госман. Ах, селәгәй! Мин бит сине!

Морат. Мә, ал! *(Суга.)*

Хәкимә. Ни эшлисез?!

Рәмзия. Оятсыз! Деканга кул күтәрде!

Алмас. Егетләр! Виноны түгәсез! Туктагыз!

Госман. Эшсез калдырам! Уфадан кудырам!

Морат. Тешең үтмәс!

Ишек шакыйлар.

Хәкимә. Тукта! Тавышланмагыз! Ишек шакыйлар!

Тавыш. Ачыгыз! Ачыгыз, дим!

Госман. Вахтёрша!

Тавыш. Госман Сабирович, мин беләм, сез биредә! Ачыгыз хәзер үк! Ишекне җимерәбез! Үкенергә туры киләчәк! Ачыгыз ишекне!

Ишеккә тибәләр.

Рәмзия. Коточкыч! Ни эшлибез?

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук вакыйгалар дәвам итә.

Хәкимә. Тукта! Тавышланмагыз! Ишек шакыйлар!

Тавыш. Ачыгыз! Ачыгыз, дим!

Хәкимә. Вахтёрша!

Тавыш. Госман Сабирович, мин беләм, сез биредә! Ачыгыз хәзер үк! Ишекне җимерәбез! Үкенергә туры киләчәк! Ачыгыз ишекне!

Рәмзия. Коточкыч! Ни эшлибез?

Хәкимә. Эндәшмәгез!

Тавыш. Мин ишеттем, сез бүлмәдә! Госман Сабирович, ишетәсеңме? Бу – мин, вахтёрша! Кызлар белән бикләнеп нәрсә эшлисез? Оят түгелме! Ишекне җимерәбез! Ачыгыз!

Хәкимә. Тс-с-с!

Рәмзия. Китте!..

Хәкимә. Уф Алла!.. Ничек белде икән?

Алмас. Бөтен бүлмәләрне урап, карап чыккан да белгән.

Рәмзия. Ә милиция тимер ишекне ача аламы?

Морат. Аларның махсус кораллы бар. «Ә» дигәнче ачалар.

Госман. Каян килеп эләктем мин монда? Каян?

Хәкимә. Алмас! Морат! Нигә карап торасыз? Әйтегез! Ни эшлибез?

Алмас. Госман Сабировичка моннан таярга кирәк!

Хәкимә. Ничек? Ничек?

Алмас. Әйттем бит инде, тәрәзә аша!

Госман. Тәрәзә аша?!

Алмас. Әйе. Парашют! Берничә простыняны берберсенә бәйлибез дә, төшәсез дә китәсез!

Госман. Простыня? Ә ул... өзелмиме?

Алмас. Юк! Сыналган ысул!

Хәкимә. Госман Сабирович! Тәвәккәлләргә кирәк! Хәзер тегеләр килеп җитә! Югыйсә янабыз! Сез дә, без дә!

Госман. Ярый! Ни булса, шул булыр! Бәйләгез простыняларны!

Хәкимә. Алмас, Морат! Мә!

Госман. Юк! Алмас кына бәйләсен! Алмас, ныграк бәйлә!

Алмас. Морской узел, Госман Сабирович! Беркайчан да чишелми!

Госман. Йа Ходаем! Укытучы! Фән кандидаты! Иртәгә – декан! Студентлар тулай торагының тәрәзәсе аша!

Рәмзия. Госман Сабирович, барысы да әйбәт булачак.

Морат. Узган атнада безнең завод тулай торагының өченче этажыннан бер егет простыня белән аска төшмәкче булган.

Рәмзия. Шуннан?

Морат. Шундый акыллы егет иде.

Рәмзия. Нигә «иде»?..

Морат. Врачлар килгәндә тере булган әле. Больниста үлгән.

Рәмзия. Нигә юкны сөйлисең? Алдый ул, алдый! Ышанмагыз, Госман Сабирович!

Хәкимә. Бездә егетләр гел тәрәзә аша йөри. Беркемнең дә үлгәне юк.

Морат. Бездә дә йөриләр. Беркемнең дә үлгәне юк иде. Менә берәү үлде. Туксан тугызы үлми, берсе үлә.

Госман. Мөмкин, бик мөмкин. Монда ничә метр бар икән?

Алмас. Ун.

Морат. Ун гына булмас, егермене тартыр!

Рәмзия. Госман Сабирович, тыңламагыз шуны! Хәзер төшәсез дә котыласыз!

Госман. Әйе. Башкача юл юк. Тәвәккәлләдек!

Алмас. Парашют әзер! Тәрәзә төбенә менеп басыгыз!

Госман. Тукта!

Хәкимә. Ни булды?

Госман. Күңел тыныч түгел. Вино салыгыз әле!

Алмас. Рәхим итегез!

Госман. Эх! Невезучий мин! Моңарчы йөз укытучы шушы тулай торакка килеп кунак булган, берсе дә тотылмаган. Мин беренче тапкыр килүемдә үк тотылдым! Моңарчы йөз студент дүртенче каттан простыня белән төшкән, берсенең дә простынясы өзелмәгән. Минеке өзеләчәк! Декан тулай торакның тәрәзәсеннән төшкән чакта үлгән, дип сөйләячәкләр! Үлеме куркыныч түгел, әнә шулай сөйләүләре оят! Ярый, хәл иттек. Беткән баш беткән!

Кызлар тавышы *(астан)*. Госман Сабирович! Сезме бу?

Госман. Йа Ходаем!

Тавыш. Госман Сабирович! Сәлам! Нишләп тәрәзә төбендә торасыз? Әллә сикерергә уйлыйсызмы?

Хәкимә. Төшегез! Төшегез монда тизрәк!

Госман. Кем ул?

Хәкимә. Күршедәге кызлар!..

Госман. Харап булдым! Таныдылар!

Хәкимә. Сания, сәлам! Нинди Госман Сабирович турында сөйлисез?

Тавыш. Әле генә тәрәзә төбендә күргән. Госман Сабировичны дөнья бетереп вахтёрша эзли. Ул сездәмени?

Хәкимә. Җүләрләндегезме әллә? Ул монда ни эшләсен? Алмас бит ул. Алмас! Кил әле, күрен!

Алмас. Кызлар, сәлам! Мине танымый башладыгызмы әллә?

Тавыш. Бәй, Алмас! Ә безгә Госман Сабирович кебек тоелды.

Алмас. Юк! Мин бу, мин! Ә Госман Сабировичны тапмадылармы әле?

Тавыш. Юк. Ә нигә тәрәзә төбенә менгән идең?

Алмас. Менә Хәкимәләрнең ишеген ача алмыйбыз. Тәрәзәдән төшәргә туры килер, ахры!

Госман. Бетте! Соңгы юл да ябылды!

Хәкимә. Юк! Ябылмады!

Госман. Ничек ябылмасын! Бөтен тулай торак күз алдында төшимме?

Хәкимә. Алмас белән киемнәрегезне алыштырыгыз!

Госман. Шуннан?

Хәкимә. Кара күзлеген киясез!

Госман. Шуннан?

Хәкимә. Кара мыегын ябыштырасыз!

Госман. Мыегын?!

Хәкимә. Ә, юк! Мыек ябыштырабыз! Һәм барысы да сезне Алмас дип уйлаячак! Төшендегез! Алмас, чишен!

Алмас. Әй шушы кызларның чишен дип әйтүләре! Хәкимә, бер минут!

Госман. Туктагыз! Чишенмә! Без бит әле хәл итмәдек!

Хәкимә. Госман Сабирович! Вакыт юк. Хәзер килеп ишекне җимерәчәкләр! Котылу юлы – тәрәзә! Чишенегез!

Алмас. Тукта! Син нигә аңа «чишен» дисең?

Хәкимә. Нәрсә булган?

Алмас. Син миннән башкага «чишен» дип әйтергә тиеш түгелсең!

Хәкимә. Кит әле, дурак! Госман Сабирович, тизрәк!

Госман. Шушында чишениммени?

Хәкимә. Ваннада.

Госман. Анда Әсма!

Хәкимә. Ай Алла! Менә монда, чаршау артында! *(Алмаска.)* Ә син нигә монда чишенәсең?

Алмас. Ә мин оялмыйм! Стриптиз!

Хәкимә. Без оялабыз! Бар, син дә чаршау артына!

Алмас. Аяк киемнәрен алмаштырыргамы?

Хәкимә. Алмаштырырга!

Алмас. Ә трусикларны?

Хәкимә. Дурак! Тизрәк булыгыз!

Морат. Алмас, алмаштыр! Деканныкы кыйммәтрәктер, соңыннан алмаштырыйк дип синең артыңнан йөрмәс. Сиңа калыр!

Алмас. Госман Сабирович, сезнең чалбар ничәнче размер?

Госман. Кырык сигез.

Алмас. Миңа сыймый!

Хәкимә. Үлмәссең. Госман Сабировичка яраса булган.

Алмас. Йә, ничек?

Морат. Ха-ха-ха! Ике клоун!

Хәкимә. Нормально! Менә күзлек! Хәзер мыек ябыштырабыз! Менә булды! Коеп куйган Алмас!

Рәмзия. Чынлап та охшаган!

Морат. Арыслан тиресе ябынган куян!

Алмас. Ә мин ничек?

Хәкимә. Бройлер әтәче! Госман Сабирович, тәрәзәгә!

Госман. Йа Ходаем!

Тавыш. Алмас, төшәргә булдыңмы? Курыкмыйсыңмы?

Хәкимә. Алмас! Эндәш! Җавап бир!

Алмас. Әйе, төшәм! Ишекне ачып булмый бит!

Тавыш. Алмас, синең белән ни булды? Күшеккән тавыкка охшагансың!

Госман. Монда ничә метр дисез әле?

Алмас. Ун, Госман Сабирович! Туктагыз! Әсманың зачёткасы кая?

Хәкимә. Нигә?

Алмас. Әсмага «бишле» куеп китсен! Ичмасам, яхшы хатирә калыр!

Морат. Әйе, барыбер иртәгә җирлибез бит.

Рәмзия. Нигә юкны сөйлисез?

Алмас. Тиз бул, китер!

Хәкимә. Кирәкми. Хәйләгә корылган җиңел юл фәкать казалар гына китерә. Шуны аңламадыгызмыни? Үзе тапшырсын!.. Алга!

Госман. И-их! Хушыгыз!

Әсма йөгереп чыга.

Әсма. Госман Сабирович!.. Алмас?.. Госман Сабирович! Туктагыз! Бу простынялар черек! Алар өзелә! Төшмәгез!

Хәкимә. Нигә алдашасың? Яңа простынялар! Төшегез! Тоталар бит!

Әсма. Син аны түгел, үзеңне кайгыртасың! Госман Сабирович, төшмәгез! Һәлак буласыз!

Хәкимә. Ай, тинтәк! Аны бередә тотсалар, безне институттан куалар!

Әсма. Кусыннар! Ә ул бит... Госман Сабирович! Тотсыннар! Күп булса, эшеннән куарлар! Ә монда – үлем!

Госман. Соң, бөтен студентлар шушы транспорт белән йөри, диләр бит.

Әсма. Алдыйлар! Беркем дә алай йөрми! Алар сездән котылырга телиләр!

Хәкимә. Дура!

Госман. Алайса ни эшләргә соң?

Хәкимә. Тыңламагыз шуны! Төшегез!

Рәмзия. Тизрәк! Хәзер ишекне җимерәләр!

Морат. Төшегез, төшегез! Анда – үлем! Ә монда – тормыш! Кызлар! Әйдә, бәхилләшү хөрмәтенә берне күтәреп җибәрик әле!

Алмас. Алга барырга кушкан безгә Ленин бабабыз! Алга, Госман Сабирович!

Әсма. Юк-юк! Госман Сабирович, берсен дә тыңламагыз, төшмәгез! Харап буласыз!

Госман. Булды! Күндердегез! Төшмим!

Хәкимә. Сезне институттан куалар!

Госман. Кусыннар! Алардан куркып үләсем юк! Мин үзем иртәгә институттан китәм! Әйе! Китәм! Чәчрәп китсеннәр!.. Мәгез күзлегегезне, мыегыгызны!.. Купмый, каһәр! Клейны җәлләмәгәнсез!

Әсма. Госман Сабирович, кая, үзем ярдәм итим!

Госман. Ипләп! Ипләп! Тирене ертасың! Ярый, әлегә калсын! Соңыннан куптарырбыз! Рәмзия, кил әле! Кил! Шушындый матур, чибәр кызларны калдырып үлемгә! Юк инде! Әтиең командировкада-фәләндә түгелме?

Рәмзия. Ә сезгә мыек килешә!

Госман. Чынмы? Болай булгач үстерәм!

Әсма. Барыгыз, барыгыз! Бар! Чыгып китегез!

Госман. Нәрсә булды? Нәрсә?

Әсма. Нигә җәелеп утырасың монда? Тәрәзәдән төш!

Госман. Ничек «төш»? Соң яңа гына үзең!..

Әсма. Җүләр булганмын! Бар! Ә син нигә аңа ябышып каттың? Кит яныннан!

Рәмзия. Әсма!

Хәкимә. Ни эшлисең?

Әсма. Безнең бүлмәдә нәрсә калган аңа? Ычкынсын! Китсен! Икегез дә югалыгыз!

Госман. Бу кыз, чынлап та, бераз гына авышканрак бугай!

Әсма. Син үзең авышканрак! Мин сине күралмыйм!

Госман. Йа Ходаем! Тере килеш мин моннан котыла аламмы-юкмы?!

Хәкимә. Монда калсагыз, һичшиксез харап булачаксыз! Тәрәзә...

Госман. Юк! Бетте! Тәрәзә дип авыз да ачмагыз! Төшмим! Чыксам, ишек аша, чыкмасам... Иртәгә үк Рәмзиянең әтисе белән очрашам. Китәм мин бу эштән!

Морат. Әйе, китегез, кит! Рәмзиянең әтисе ярдәм итәчәк сезгә! Бик нык ярдәм итәчәк!

Госман. Нәрсә сөйли ул?

Рәмзия. Морат!..

Морат. Юк, белсен! Рәмзиянең әтисе... Әтисе юк!

Госман. Ничек юк?.. Ничек юк? Дөресме бу?

Рәмзия. Госман Сабирович!..

Госман. Син Науширбановның кызы түгелмени?

Рәмзия. Эш шунда... Минем әнием авыру, постельдә ята... Минем стипендиягә генә яшибез... Ә эш беркайда да юк...

Госман. Син Науширбановның кызымы, түгелме?!

Рәмзия. Түгел! Түгел!

Госман. Нигә алдаштың син? Нигә?

Рәмзия. Мин алдашмадым. Тоталар да барысы да мине Науширбановның кызы диләр. Ярдәм итәргә тырышалар. Юк, дим, ышанмыйлар. Фамилиябез охшаш булганга мин гаеплемени?

Госман. Коточкыч! Коточкыч! Сез дә шулай!.. Кемгә ышанырга? Моннан соң кемгә ышанырга соң? Кемгә?

Рәмзия. Госман Сабирович! Гафу итегез мине!.. Әнием авырый, миңа эш кирәк.

Госман. Кит!.. Күрәсем килми!..

Морат. Хәзер синең аңа кирәгең юк!

Рәмзия. Җибәр! Җибәр мине! Әнә Мәрьямең янына бар!

Морат. Миңа аның кирәге юк!

Рәмзия. Нигә? Син бит аңа өйләнергә йөри идең!

Морат. Рәмзия!.. Син бит беләсең, минем әти белән әни ике ел эшсез утырды... Шуннан әтиемнең кайчандыр армиядә бергә хезмәт иткән дусты икесен дә эшкә алды... Һәм әтиемнең шул дусты мине үзенең кызы белән таныштырды...

Рәмзия. Таныштырса, өйләнергә кушмагандыр бит!..

Морат. Кушты шул. Өйләнмәсәм, әти-әнинең эшсез калачагын сиздерде. Һәм мин каршы килә алмадым.

Рәмзия. Каршы килә алмагач, нигә килдең монда? Бар, яшә шуның белән!.. Ә минме? Мин, барыгызга да үч итеп, Алмаска кияүгә чыгам! Бүген үк! Алмас! Кил монда!

Алмас. Рәмзиякәй!

Морат. Шаштыңмы әллә?! Кит аның яныннан!

Алмас. Нигә аңа төртәсең? Ул бит кыз бала!

Рәмзия. Мин сине күралмыйм! Югал моннан!

Морат. Беләсеңме син кем? Фахишә!

Алмас. Нәрсә? Хәзер үк гафу үтен!

Морат. Кем син шулхәтле! Эләктерәм бит!

Алмас. Ах, шулаймы?!

Хәкимә. Алмас! Морат! Ни эшлисез?! Туктагыз!

Алмас. Икенче авызыңны үлчәп ач!

Морат. Сөйләшербез әле! Кара син аны!

Хәкимә. Чигәң сыдырылган, авыртамы?.. Авыртамы?..

Алмас. Хәкимә! Кулың шундый йомшак...

Хәкимә. Җибәр...

Рәмзия. Морат, менә төймәң өзелде...

Морат. Рәхмәт, Рәмзия... Мин монда... сине күрер өчен килдем бит, Рәмзия.

Рәмзия. Ә кәләшеңне кая куясың?

Морат. Әтиемнең дустының кызына Госман Сабирович өйләнергә дип кулын сорап китте.

Рәмзия. Әтиеңнең дусты безнең ректормыни?

Морат. Әйе. Аның кызын миннән тартып алу өчен Госман Сабирович мине кунакка чакырды, шуннан

исертеп айныткычка тапшырды. Һәм мине институттан да, кияүлектән дә кудылар. Әтием белән әнием дә эштән киттеләр. Госман Сабирович! Әгәр сораган булсаң, мин ул кылый күзне сезгә бушлай биргән булыр идем!

Госман. Синең чама белми эчүеңдә минем гаебем юк!

Морат. Әйе, эчтем! Рәмзия, сине югалту кайгысыннан эчтем бит мин...

Рәмзия. Морат...

Морат. Бүген менә килгән идем дә... Тик соңладым бугай... Син бит хәзер... Алмас белән...

Рәмзия. Юк-юк, Морат! Без бит юри кыландык! Аның белән алдан сөйләшеп шушы очрашуны оештырдык. Сине, Хәкимәне көнләштерер өчен! Хәкимәне – Алмаска, сине миңа кайтару өчен.

Морат. Рәмзиякәй, гафу ит мине!..

Рәмзия. Морат!

Алмас. Кара, хәйләбезнең файдасы тиде, аңлаштылар!

Хәкимә. Тик син өметләнмә! Гомергә дә гафу итәчәгем юк!

Алмас. Син бит нәрсә булганын миннән сорамадың да!.. Морат бик үтенгән иде. Озатып куй, дигәч...

Морат. Хәкимә, сезнең ара минем аркада бозылган икән. Гафу ит мине. Вакыт бик соңарды. Ә мин үзем авырып яттым...

Хәкимә. Кем иде ул?

Морат. Минем кияүдәге бертуган апам. Малайлары бар.

Алмас. Ну шул иптәш кызларыңны! Зонтигын тотып тордым! Яңгыр ява иде. Дус кызың күргән иде. Шул бишкә төрләндергән. Үземнән сорасаң ичмасам.

Хәкимә. Аһ, донжуан! Ярый, бер юлга гафу итәм. Тик бел! Әгәр минем рөхсәтсез тагын берәрсен озатып йөрсәңме!..

Алмас. Бетте, Хәкимә, бетте! Дуслыкмы?

Хәкимә. Сине ни эшләтәсең инде?

Алмас. Хәкимәкәй! Тукта! Ә менә син нигә булмәңә

Госман Сабировичны чакырдың? Аның белән нәрсә эшләргә җыена идең?

Хәкимә. Ул дежурга килде. Безнең бүлмәгә кергән иде, минем туган көн...

Алмас. Мине җүләргә санама! Синең туган көнең гыйнварда!

Госман. Нәрсә? Гыйнварда?..

Хәкимә. Әйе...

Госман. Ничек? Син бит әйттең! Бүген туган көнем, дидең! Нигә алдаштың?

Хәкимә. Иртәгә әтием килә! Безгә аның алдында оят! Оят!

Госман. Йа Ходаем! Алдау! Янә алдау! Бөтен җирдә алдау! Хәйлә! Мәкер! Шуннан соң ничек дөньяда яшәргә?

Морат. Син кемне гаеплисең? Син бит үзең ялган, мәкер белән мине институттан кудырдың!

Госман. Әйе, мин мәкерле. Чөнки... Мин бит сезнең кебек әти-әни куенында үсмәдем. Мин ятим! Мине төрттеләр, типтеләр, кыйнадылар. Мин барысына да түздем, яраклаштым, авырлыкларны урап узарга өйрәндем. Ә бүген... иң пүчтәк урында... барып тәрәлдем! Чөнки сезне саф, таза күреп, сезгә ошыйсым, яныгызда буласым килде. Хәзер күрәм: ялгышканмын! Әгәр бу дөньяда тазалык, сафлык, гаделлек юк икән, нигә яшәргә? Нигә кирәк бу тормыш? Минем рухым сынды бүген. Максатым югалды. Менә хәзер мин чынлап та беттем! Үлдем!

Әсма. Мин аңладым. Син ата-ана сөюен белмисең! Шуңа да каты бәгырьлесең. Без әти-әниебезне яратып, аларның тәрбиясендә сөелеп үскәнбез. Алар алдында олы бурычыбыз бар. Шуңа да аларның йөзләренә кызыллык китерергә куркабыз. Ә син ансат кына адәм баласына этлек эшлисең. Имтиханда эндәшми, сөйләшми, җавап бирми, имеш! Нәрсә ул йөрәк, имеш? Йөрәк кан куучы насос дип уйлыйсыңмы? Йөрәк ул – батырлык, изгелек, сөю оясы! Усал кешене – йөрәксез, батырны йөрәкле диләр. Сөйгән ярын кеше «йөрәк парәм» дип

ярата. Йөрәк хакында сорау бирер өчен, үзеңә йөрәкле булырга кирәк. Син бит йөрәксез! Туң! Теләсәм, анатомияңнең һәр битен, һәр хәрефен сөйләп бирә алам! Мин анатомияне түгел, синең күңелеңдә чак кына булса да сафлык калганмы – шуны аңларга теләдем. Белеп тор: син харап булачаксың! Юкка чыгачаксың!.. Чөнки син... ахмак! Туң йөрәк! Сукыр! Мә ачкыч! Бар, чыгып кит моннан.

Госман. Минем... яшисем килми, Әсма...

Әсма. Госман Сабирович!.. Алай димәгез... Яшәргә кирәк... Сез бик начар кеше түгел бит... Сез әйбәт... сез ошыйсыз миңа... Мин яратам сезне!

Госман. Әсма!..

Алмас. Әйттем бит монда без парлылар дип. Өченче пар да булды! Әйдә, күтәрик шуның өчен!

Барысы бергә. Әйдә! Кая чынаяк? Миңа да сал!

Алмас. Барыгызга да булдымы? Мәхәббәт өчен!

Ишек шакыйлар.

Тавыш. Ачыгыз! Мин – ректор! Милиция алып килдек! Госман Сабирович, мин беләм, сез анда! Ачыгыз яхшы чакта! Хәзер ишекне җимерәбез.

Госман. Мин бәхетемне таптым! Хәзер мин бернәрсәдән дә курыкмыйм! Ачыгыз!

Хәкимә. Алмас, мә! Ач ишекне!

Алмас ишекне ача.

Пәрдә.

2000

ҮЗ ХАТЫНЫМА ӨЙЛӘНӘМ

Комедия, ике пәрдәдә

Катнашалар:

Камил, Хәлимә, Айсылу — 40 яшьләрдә.
Хәмит
Гөлбикә
Гыйльфан
Рушания, Айнур — 20 яшьләрдә.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче күренеш

Пәрдә ачылмас борын, җыр ишетелә.

Сөюем, син кайда?
Нигә килмисең?
Өзелеп көткәнне
Әллә белмисең?
Йөрәк бит көтә,
Ә гомер үтә.
Сөю килмәгәч,
Өметләр бетә.

Түземнәрем сүнсә,
Мин бит китәрмен.
Килгәч син: «Сөюем
Кайда?» — диярсең.
Эзләргә чык мине,
Соңлап килсәң дә,
Табар юл күрсәтер
Сөю эргәңдә.

Җырлап Рушания килеп керә.

Рушания. Әни!

Айсылу. Рушания! Кызым! Саумы! Көтә-көтә көтек булдым. Нигә алай озак?

Рушания. Исәнме, әни! Тәүге рейска билет булмады. Ни булды? О! Курчак! Син сатып алдыңмы? Кемгә?

Айсылу. Камил кода бүләк итте. Миңа.

Рушания. Сиңа? Камил кода? Кем ул?

Айсылу. Хәзер аңлатырмын. Әллә нәрсә сөйләде шунда. Кечкенә балаларыңа, ди. Кырыкны узгач нинди бала?

Рушания. Ә бу нинди таблица? «Ашау-эчү графигы». Әтием кайттымы әле?

Айсылу. Әйе, ике ел әллә кайда адашып йөрде дә, тинтәк, кайтты.

Рушания. Әни, чынмы?

Айсылу. Чын инде, чын.

Рушания. Ур-ра! Әтием кайткан! Күптән кирәк иде! Югыйсә... Кара, график үзгәрмәгән икән. Әле кайда ул?

Айсылу. Кайда булсын, эштә.

Рушания. Әни, бу нинди телеграмма? «Срочно кайт. 17 июль туй. Әниең». Нинди туй? Кемнең туе?

Айсылу. Хәзер аңлатам. Утыр. Әйткәнемчә, Айнур да кайттымы?

Рушания. Нинди Айнур?

Айсылу. Курсташың.

Рушания. Бер үк рейс белән кайтырга тиеш идек. Билет булмады. Алдагы рейс белән кайта. Ул бит иртәгә Германиягә китә.

Айсылу. Беләм. Өенчекөн телевизордан ишеттем. Германиядә үткәрелгән грантта җиңгән. 300 мең доллар бирәләр. Дөресме шул?

Рушания. Дөрес. Әнә шуңа кайтып килә.

Айсылу. Рушания, утыр. Сөйләшеп алабыз.

Рушания. Ой, әллә ничек әйттең. Куркып киттем.

Айсылу. Утыр. Рушания, син үсеп җиттең, кияүгә чыгар вакыт. Син китсәң нишләрмен икән? Ялгызым... Беркемгә кирәкмим мин... Әй Аллам!..

Рушания. Әни, нигә елыйсың? Мин бит әле беркая да китмим. Җитмәсә, әтием дә кайткан...

Айсылу. Ярый, булды. Ата өендә кыз бала кунак кына. Беләсеңме шуны?

Рушания. Шуннан? Аны нигә сөйлисең?

Айсылу. Бүген кичке җидедә туй. Синең туең.
Рушания. Нәрсә?
Айсылу. Утыр.
Рушания. Юк, утырмыйм!
Айсылу. Утыр, дим! Әйе, синең туең. Туй күлмәгенә заказ бирдем.
Рушания. Әни, син чынлапмы, әллә шаярыпмы?
Айсылу. Туй белән шаярмыйлар. Синең кырык дүртенче размер, шулай бит?
Рушания. Шуннан, мин кемгә кияүгә чыгам инде? Белергә мөмкинме?
Айсылу. Айнурга.
Рушания. Нинди Айнурга?
Айсылу. Курсташың Айнурга. 300 мең доллар откан Айнурга.
Рушания. Әни, син акылдан шаштыңмы? Шушы сүзләрне әйтер алдыннан чак кына уйладыңмы? Мин ничек уйламаганда аңа кияүгә чыгыйм? Бүген! Ул берни белми! Мин берни белмим!
Айсылу. Тыныч кына чыгасың! Әти-әнисе белән сөйләшенгән, әзерләнгән, минем ашханәдә була. Кунаклар чакырылган. Бүгенгә күчерүе генә кыенрак булды. Туйны без практикадан кайткач үткәрербез дип сөйләштек. Ләкин, ситуациянең кинәт үзгәрүе сәбәпле, бүгенгә күчердек. Шул гына бераз кыенлык тудырды. Сәгать 4 тә загста язылышу.
Рушания. Әни, тукта! Син нәрсәдер бутыйсың. Мин берни дә аңламыйм. Айнур, ичмасам, беләме бу кошмарны?
Айсылу. Аңа да туйга чакыру телеграммасы сук... тылар. Кайтып төшкәч тә, әти-әнисе аңа хәлне аңлатып бирергә тиеш.
Рушания. Димәк, белми! Йа Ходаем! Кемнең идеясе бу? Нигә Айнур? Нигә башка егет түгел?
Айсылу. Башкаларга 300 мең доллар бирмиләр.
Рушания. Димәк, син шул долларлар аркасында! Юк, мин аңа чыкмыйм! Беркайчан да! Туй отменяется!
Айсылу. Утыр! Утыр, дим! Кара син аны! Анасын

узып!.. «Туй отменяется»! Беләсеңме күпме акча түктем шул туйны үткәрер өчен?

Рушания. Әни, Айнур белән безнең арада берни дә юк! Без курсташлар гына! Курсташлар!

Айсылу. Кичә курсташлар идегез, бүген ир белән хатын булырсыз!

Рушания. Син оештырдыңмы бу ботканы?

Айсылу. Айнурның әти-әнисе ризалыгы белән.

Рушания. Хәзер Айнур мин оештырган дип уйлаячак! Оят! Оят! Хәзер мин ничек аның күзенә күреним?

Айсылу. Бик тыныч күренерсең. Җыен. Без хәзер аларга барабыз.

Рушания. Юк! Юк! Мин бармыйм!

Айсылу. Ничек кенә барасың әле!

Рушания. Бу көчләп кияүгә бирү була, әни. Хәзер алай кияүгә чыкмыйлар! Мин каршы!

Айсылу. Беләсеңме, хәзер өйләнешкәннәрнең яртысыннан күбесе нигә аерылыша? Урамда дискотекада танышып өйләнешкәннәр аерылыша. Ата-анасы табып, көчләп кавыштырганнарның берсе дә аерылышмый. Чөнки без, өлкәннәр, беләбез: кем белән яшәргә була, кем белән – юк. Алмаштыр киемеңне.

Рушания. Әнием, зинһар, бармыйк аларга. Без Айнур белән дуслашып та йөрмибез бит, ичмасам! Тамчы да симпатия юк бер-беребезгә!

Айсылу. Булыр. Үткән-барганда бергә йөри идегез.

Рушания. Ара-тирә бергә йөрү берни дә аңлатмый. Хәтта үбешеп тору да!

Айсылу. Шул гына җитмәгән иде! Алла сакласын!

Рушания. Әни!

Айсылу. Җыен, дим! Җыен хәзер үк! Канымны кыздырма! Син мине беләсең!

Рушания. Анда нишлибез?

Айсылу. Нәрсә кирәк, шуны эшләрбез.

Рушания. Барсак та, мин барыбер...

Айсылу. Син барасың да тик утырасың. Матур итеп елмаеп. Калганы минем эш.

Рушания. Шундый обстановкада мин ничек елмаыйым? Җир тишеге булса...

Айсылу. Бик елмаерсың. Кияүгә көн дә чыкмыйлар.

Хәмит керә.

Хәмит. Айсылу! Срочно...

Рушания. Әти!..

Хәмит. Рушания! Үсеп киткән!..

Рушания. Әтием!..

Хәмит. Айсылу, кефир! Практика беттеме? Елыйсыңмы? Ни булды?

Айсылу. Сине сагынган.

Хәмит. Мин дә сагындым сине, кызым. Йә, җитте. Сиңа елау килешми. Син бит подполковник Хәйранов кызы!

Рушания. Подполковник?

Хәмит. Равняйсь! Смирно! Подполковник Хәйранов по вашему приказу прибыл! Вольно!

Рушания. Ә погоннарың – майор.

Хәмит. Бүген приказ алдым.

Рушания. Котлыйм, әти!

Айсылу. Котлыйм! *(Стакан белән кефир бирә.)*

Хәмит. Рәхмәт!

Рушания. Полковник, аннан генерал буламы?

Хәмит. О! Син бигрәк! Миңа зам начальника штаба гарнизона булырга тәкъдим иттеләр.

Рушания. Ул зур урынмы?

Хәмит. Гарнизонда өченче кеше.

Рушания. О! Котлыйбыз, әти!

Айсылу. Котлыйбыз. Моны юарга кирәк иде дә... вакыт юк.

Рушания. Юк, юабыз, юабыз! Юмасаң, званиеның да, вазифаның да кадере бетә.

Хәмит. Кызым, иртәгә! Иртәгә – ял. Ашыкмый, җайлап... Дусларны чакырырбыз. Бүген чынлап та вакыт юк. Кайтышлый погоннар сатып алдым. Айсылу, тегеп бир.

Рушания. Үзем тегәм! Әти, бир.

Айсылу. Тукта! Аны тегәргә вакыт юк. Бер көнгә майор булып йөреп торсын. Иртәгә тегәрсең. Хәзер кодаларга барабыз. Өчәүләшеп.

Хәмит. Мин бер минутка гына кердем. Мин – эштә! Айсылу, кичәгене онытыйк. Икебездә дә гаеп бар.

Рушания. Кичә нәрсә булды?

Хәмит. Сүзгә килештек.

Айсылу. Миндә гаеп юк. Бөтен гаеп синдә.

Хәмит. Ярый, булсын. Тик онытыйк, Айсылу. Бетте.

Рушания. Әти, бир. Сез сөйләшкәнче мин бу погоннарны парадный костюмыңа...

Айсылу. Тотынма! Хәзер китәбез!

Хәмит. Айсылу! Бер сәгатьтән гарнизон начальнигының кырык яшьлек юбилеена барабыз. Ул рәсми чакырды. Киемнәрне алмаштырабыз да юлда бүләк алабыз.

Айсылу. Без срочно кодаларга барырга тиеш! Шушы секундта!

Хәмит. Нигә бүген? Анда бит бөтенесе дә сөйләшенгән.

Айсылу. Ситуация үзгәрде.

Хәмит. Анда иртәгә барырбыз. Хәзер икәүләшеп – юбилейга! Бу – приказ! Гарнизон начальнигының приказы!

Айсылу. Кызыңның язмышына төкерәсең икән, бар шунда берүзең!

Хәмит. Ярамый, Айсылу! Начальник гарнизона искәртте. Бөтенегез дә хатыннарыгыз белән килегез, диде. Ул аерылышкан яки өйләнмәгән офицерларны яратмый, хәтта күралмый. Аларны «җилкуарлар» ди. Кем аерылыша, эштән куа да чыгара. Хатынына баш була алмаган офицер офицер түгел, ди. Мин синең белән аерылышканны яшереп йөрдем. Югыйсә күптән... Аңладыңмы, мәсьәлә нинди җитди?

Айсылу. Аңламадым, аңларга да теләмим! Безгә кодаларга барырга кирәк. Срочно!

Хәмит. Минем карьерам хәл ителә! Ул һәркемне

чакырмый юбилеена! Әгәр ялгыз барсам, ул сораячак. Аның бит сине бер тапкыр да күргәне юк. Әгәр тыңлата алмаганмын икән сине, димәк, мин офицер түгел!

Айсылу. Әйттем бит, мин бармыйм. Бу хакта бетте!

Хәмит. Айсылу! Бу – катастрофа! Үлем! Ул мине күтәрмәячәк! Эштән куачак!

Айсылу. Бүген туй!

Хәмит. Нинди туй?

Айсылу. Атаң башы! Атна буе туй дип каңгырап йөрибез. Ә ул «нинди туй»?

Хәмит. Туй бит 20 се була. Бүген 17 се!

Айсылу. Туй күчте!

Хәмит. Нигә мин белмим? Кем күчерде? Синме? Нигә миңа алдан әйтмәдең? Киңәшләшмәдең? Янә киреләнәсең!? Ялгызлык, баласызлык бәласе бу!

Айсылу. Әйтергә өлгермәдем!

Хәмит. Безнең начальник бик усал! Әгәр юбилеена бармасам яки ялгыз барсам...

Айсылу. Аңлат. Кызым кияүгә чыга, туй, диген.

Хәмит. Нигә шунда ук әйтмәгәнмен? Аның да үз принцибы бар. Кем эшләргә теләми, сәбәп эзли. Тыңлап та тормаячак. Айсылу, үтенеп сорыйм, барыйк юбилейга. Икәүләшеп барыйк. Күчерик туйны!

Айсылу. Күчереп булмый! Айнур иртәгә Германиягә китә!

Хәмит. Бәлки, туйсыз...

Айсылу. Юк! Туй була! Бүген! Әгәр начальнигың кадерле икән...

Рушания. Әни, бәлки...

Айсылу. Тик тор! Ул бит эгоист! Сине уйламый, үзен кайгырта! Бердәнбер кызы чәчрәп китсен, тик аның карьерасы күтәрелсен! Бар ялгызың! Без кодаларга киттек! Әзерме син? Нигә һаман күлмәгеңне алыштырмадың?

Рушания. Менә погоннарны тактым...

Айсылу. Атаң башына кирәкме ул погоннар? Киемеңне алмаштыр, дидем бит мин сиңа! Тиз бул!

Хәмит. Рәхмәт, кызым! Әле дә син бар, бәләкәчем!.. Тукта! Син авырлы түгелмени?

Рушания. Нәрсә?

Хәмит. Айсылу! Бу нәрсә? Син бит әйткән идең...

Айсылу. Ялгышканмын.

Хәмит. Биш айлык, дидең бит! Ничек ялгышырга мөмкин?!

Айсылу. Шулай кирәк булды! Беттеме сүзең?

Хәмит. Алдагансың! Янә алдагансың! Мине! Кодаларны! Күпме мөмкин?!

Айсылу. Ай-яй! Красная девица! Алдаганны күрмәгән! Гел гаделлек дөньясында яшәгән! Хәрбиләрне беләбез! Кругом алдакчылар!

Хәмит. Син ничек... Хәзер кодаларга ни әйтерсең?

Айсылу. Ни кирәк, шуны әйтермен! Ярый, безнең вакыт юк. Рушания! Син кайда?

Хәмит. Тукта! Рушания авырлы булмагач, кемгә кирәк булды бу? Кем биргән телеграммаларны?

Рушания. Нинди телеграмма?

Хәмит. Сездән бит «Бер атнадан туй үткәрәбез. Бөтен курс белән киләбез» дигән телеграмма алдык. Синнән – әниең. Айнурдан – аталары. Бирдегезме шундый телеграмма?

Рушания. Юк...

Айсылу. Мин бирдем! Рушания булып та, Айнур булып та. Шуннан? Син бит җүләрләнеп Гөлбикәгә өйләнергә йөри идең. Айнурның апасына. Боларга туй оештырып арагызны боздым, сине кире кайтардым!

Хәмит. Алайса, туй бөтенләй булырга тиеш түгел идеме? Бөтенесе дә синең уйдырма булдымы? Кошмар!

Айсылу. «Гөлбикә! Сиңа йә круглый дурак, йә талантлы композитор өйләнсен!» Бу кемнең сүзләре? Синекеме! Сине әнә шул круглый дурак булудан коткардым. Рәхмәт әйт!

Хәмит. Юк! Мин круглый дурак! Бүген аңладым! Синең бөтен ялганнарыңа ышанган дурак!

Рушания. Әти!

Хәмит. Синең өчен бер изге нәрсә дә юк! Булмаган туйны була дип алдау! Гөлбикәгә мин булып: «Мин бит алкоголик»,– дип алдап хат язу! Миңа Гөлбикә

булып: «Мин бит ун иргә чыктым, унысы да үлде»,— дип алдап хат язу! Шулай итеп алдап арабызны бозу! Алдау! Алдау! Алдау! Синең бар тормышың алдауга корылган! Безнең гаилә алдауга корылган! Юк! Болай яшәп булмый!

Айсылу. Ха! Яңалык ачты! Бөтен дөнья алдауга корылган!

Хәмит. Бүгенге туй чынмы, ичмасам?

Айсылу. Ышан, курыкма.

Хәмит. Рушания, син үз туеңның булуын белеп кайттыңмы? Әллә әниең янә алдап чакырдымы?

Рушания. Әти! Әтием!..

Хәмит. Аңлашылды! Эш болайга киткәч... Соңгы тапкыр сорыйм: барасыңмы юбилейга, юкмы? Әйт!

Айсылу. Юк! Миңа кызымның язмышы кадерле.

Хәмит. Рәхмәт. Иң кирәк чакта. Барма. Кирәкми. Мин бу туйның чынлыгына ышанмыйм. Мин аферистка белән яшәмим. Кызым, гафу ит, яшәрмен дип кайткан идем. Булмады... Мин китәм синнән!

Рушания. Әти! Әтием!

Айсылу. Бар, бар! Җәһәннәмгә олак!

Рушания. Әни!

Айсылу. Алдына тезләнер дигәндер. Әйе, көт, хәзер!

Хәмит. Рушания, минем киемнәрне сумкага тутырып куй. Иртәгә килеп алырмын.

Рушания. Әти!.. Китмә!..

Айсылу. Тик, туй алдыннан кодаларга барып, аерылдык дип аптыратып йөрисе булма! Ишетсен колагың!

Хәмит. Хушыгыз!

Рушания. Әти! Зинһар, китмә!

Хәмит китә.

Айсылу. Ярый. Бетте. Тынычландык. Елама, дим. Үзенеке генә проблема, безнеке шартласын! Китсен. Әлегә вакыт юк. Иртәгә разберёмся. Ярый, әйдә тор.

Рушания. Әни, нигә җибәрдең аны?

Айсылу. Җитте сиңа! Киттек!

Рушания. Әни, кайда?

Айсылу. Айнурларга!

Рушания. Әни, мин бармыйм! Бармыйм!

Айсылу. Барасың! Ничек кенә барасың! Тор! Тор, димен!

Рушания. Әни! Әнием!

Айсылу. Егерме ел мин сиңа әни! Сөрт күз яшьләреңне! Шым! Әнә шулай. Әй кызым, кызым! Миңа шушылай чабып йөрү кызыкмы? Син бәхетле булсын дип тырышам бит. Ә син...

Рушания. Әни!..

Айсылу. Тукта! Күлмәк кимә! Сарафаныңны ки.

Рушания. Нигә?

Айсылу. Аңлатырмын.

Ут сүнә.

Икенче күренеш

Камил белән Хәлимәнең фатиры. Зал. Хәлимә берүзе.

Хәлимә. Тагын нәрсәләр эшләргә тиешбез әле? Кайда исемлек? Ә, менә. Обойлар алмаштырылды. Шторлар юылды. Түшәм агартылды... Ишекләрне... алмаштырырга өлгермибез... Башны бутады бу малай! Туй – бүген! Атасы әйтмешли, ну Айнур! 20 июльдә булса да өлгермибез, дип йөри идек, ә ул телеграмма суга: туй 17 июльдә – бүген! Ну Айнур!.. Ярый әле туйны өйдә үткәрмибез, ашханәдә. Туйдан соң безгә килсәләр, тик якын туганнар гына килә. Алар аңларлар... Айнур өйләнеп башка чыкса, Камил белән икәү генә утырып калабыз инде. Ярый, Камил көне буе эштә, ә мин мәктәптән кайткач... Ялгыз... Беркемгә дә кирәкмим... Нишләрмен икән шул чакта?.. Гомернең узып китүе шушы буламы?.. Әй Ходаем!..

Ишектә звонок. Хәлимә чыга һәм Гыйльфанны ияртеп керә.

Гыйльфан. Хәлимә, саумы!

Хәлимә. Исәнме, Гыйльфан! Нигә уфылдыйсың? Артыңнан куалармы әллә?

Гыйльфан. Хәлимә, коткар!

Хәлимә. Ни булды?

Гыйльфан. Теге эт хатын үтерә мине! Тере көе йотачак, валлаһи! Йота алмаса, чәйнәп төкерәчәк!

Хәлимә. Кем ул? Гөлбикәме?

Гыйльфан. Шул инде, шул! Башка кем булсын? Сибай театры спектакленә көй язарга чакыра. Әйбәт түлиләр. Бер сәгатьтән соңгы автобус китә. Ә бу җибәрми.

Хәлимә. Нигә җибәрми?

Гыйльфан. Аның эше бетәмени? Ул черегән РДКсын шартлатып кына котылмасаң, ял да булмас, башкасы да... Хәлимә, син бик матурсың.

Хәлимә. Юк, шаярма. Ярамый... Җибәрмәсә, кушканын эшлә дә кит.

Гыйльфан. Анда эш менә моннан – муеннан. Гомергә дә бетәчәк түгел. Кичә түбә яптык. Бүген торба шартлаган, подвалны су баскан. Көн дә шул. Ә Сибайлар бүген үк килеп җитәргә куша.

Хәлимә. Мин сиңа ничек ярдәм итә алам?

Гыйльфан. Синең бертуган сеңлең бит. Апа буларак тый шуны. Аңлат. Эт куарга бармыйм бит. Музыка язарга, акча эшләргә! Пьеса ошады. Укып чыккан идем, башымда көй туды да инде. Утыр да яз! Юк! Бу подвалга төшереп бикләде дә чыгармый!

Хәлимә. «Подвалга бикләде»? Бигрәк арттырып җибәрәсең. Булмас.

Гыйльфан. Валлаһи! Анда нинди музыка тусын? Туганы үлә!

Хәлимә. Ярый! Сөйләшермен. Син тизрәк кит. Хәзер Камил кайта. Ул сине монда күрсә...

Гыйльфан. Әйдә, РДКга бергә барыйк. Әйтерсең, Гыйльфанны җибәр, музыка язсын, дип.

Хәлимә. Хәзер бара алмыйм. Айнур туйны бүгенгә күчерергә кушкан. Эш муеннан!

Гыйльфан. Хәлимә, ун минут! Ун минуттан кайтырсың. Зинһар, үтермә мине! Үтенеп сорыйм.

Хәлимә. Ярый, ярый, барырмын. Тик соңрак. Кит инде тизрәк. Камил күрсә, әллә ни уйлар.

Гыйльфан. Юк, мин берүзем бармыйм РДКга. Куркам мин аннан. Әле Сибайга китәм дигәч, чак сугып үтермәде. Кулына микрофон тотып тора иде, шуның белән җибәрде миңа! Чак иелеп өлгердем. Башка тисә, үтерә иде. Чыктым да качтым. Ай, дура! Бөтенләй сиңа охшамаган. Ялгыш өйләндем мин аңа.

Хәлимә. Алай димә. Өйләнгәч, түзәргә, яшәргә кирәк.

Гыйльфан. Йа Ходаем!

Хәлимә. Нәрсә булды?

Гыйльфан. Гөлбикә килә. Хәзер үтерә ул мине! Кайда качыйм?

Хәлимә. Бар, кит! Кит тизрәк!

Гыйльфан. Ничек китим? Чыксам, каршысына очрыйм.

Хәлимә. Качма монда, качма! Кит! Кит, дим!

Гыйльфан. Хәлимә, үтермә! Шушында утырып кына торыйм. Ул киткәч тә югалырмын!

Гыйльфан шифоньерга кача.

Хәлимә. Әй Алла! Хәзер бит Камил кайта!

Гөлбикә керә.

Гөлбикә. Исәнме, апам!

Хәлимә. Исәнме, Гөлбикә!

Гөлбикә. Сездәме теге карга?

Хәлимә. Нинди карга?

Гөлбикә. Гыйльфан, эт талагыры! Шушы якка качкан иде. Күрми калдым. Кинәт юк булды. Сезгә кермәдеме?

Хәлимә. Юк, ул монда нишләсен?

Гөлбикә. Аптыраганнан сорыйм инде. РДКда эш муеннан. Җитмәсә, торбасы шартлады, подвалны су басты. Ут сүнде. Кеше җитешми. Бер взвод солдатлар китерсәң дә артык булмас. Ә бу! Мине Сибайга җибәр, бер сәгатьтән автобусым китә! Башын төйсәң дә үз сүзеннән кайтмас! Эт ялкавы! Кайда качты икән, эт каешы?

Хәлимә. Җибәр син аны Сибайга. Язсын көен.

Гөлбикә. Менә аңа көй! Кушканны эшләсен! Монда унга ярылырдай булып йөрисең. Ә ул – көй! Җизни кайда? Эштәме?

Хәлимә. Юк, бүген өйдә. Туйга кирәк-ярак алырга чыккан иде. Хәзер кайтырга тиеш. Йә, йомышыңны әйт тә, минем эшем күп.

Гөлбикә. Мин җизнине көтәм. Теге хакта аңа әйттеңме?

Хәлимә. Юк, әйтмәдем. Ул мине тыңламас. Тыңласа, сине тыңлар. Син Камилне көтмә. Эшеңә бар, эшең күп дисең бит. Камил кайткач та мин сиңа шалтыратырмын.

Гөлбикә. Анда бөтенесенә дә эш кушылган. Миңа срочно җизни кирәк. Теге бичура кияүгә чыккан. Иртәгә китәм, дип куркыта. Ул китсә – бетте! О! Бу нинди курчак?

Хәлимә. Җизнәң алып кайтты. Сиңа да бүләк иткән түгелме?

Гөлбикә. Ә-ә, әйе. Кайдадыр ята шунда. Мин җизнине аңламадым. Җүләр кеше кебек. Әллә нинди балалар турында сөйли. Тизрәк бала табыгыз, ди. Кырыкка җиткәч, нинди бала? Кая аңа вакыт?

Хәлимә. Син китсәң кит, комачаулап торма, минем дә эшем күп.

Гөлбикә. Син миңа карама, эшеңне эшлә. Ә бу нинди уенчыклар? Сез әллә бала табарга җыенасызмы?

Хәлимә. Көләсеңме? Айнур өйләнәм дигәч, үзгәрде Камил. Өч, биш яшьлек балалар тәрбияләү турында китап алып кайткан. Нигә алып кайттың, дисәм, кирәк булуы бар, ди. Айнурга дисәң, аларга бит яңа туган баланы карау турында китап кирәк. Сеңлем, торма әле комачаулап.

Гөлбикә. Ярый, мин киттем. Соңрак тагын килеп чыгармын әле. Җизни кайту белән миңа шалтырат.

Хәлимә. Әйе, әйе, бар. Шалтыратырмын.

Камил керә.

Гөлбикә. Әнә кайтты! Исәнме, җизни!

Камил. Исәнме, Гөлбикә!

Гөлбикә. Нәрсәләр алып кайттың шулкадәр?

Камил. Туйга кирәк-ярак.

Гөлбикә. Уенчыклар! Алар кемгә?

Камил. Оныкка.

Гөлбикә. Бу бит машиналар. Болар бит дүрт-биш яшьлек балалар өчен.

Камил. Башкаларга да кирәк булыр. Менә син бала тапсаң, синең балаңа.

Гөлбикә. Җизни, көлдермә! Нинди бала? Илдә кризис!

Камил. Гыйльфан белән сиңа бала кирәк. Баласыз ир белән хатын аерылыша.

Гөлбикә. Әкият сөйләмә!

Камил. Статистика шулай ди. Нигә аерылыша? Чөнки баласыз яки бер балалы хатыннар, өйдә бала, эш булмагач, азып-тузып йөри. Төрле семинарлар, түгәрәк, фитнес дип чаба. Ә менә күп балалы гаиләләр таркалмый. Чөнки аларның юк-бар белән булышырга вакыты калмый. Моны мин түгел, статистика әйтә.

Гөлбикә. Җизни, куй әле шул статистикаңны! Минем РДКда потоп, авария, катастрофа! Ярдәм ит!

Камил. Кешенең яшәү мәгънәсе – бала! Кешелекнең! Тагын нәрсә булды?

Гөлбикә. Су торбасы шартлады. Бөтен подвалны су басты. Кул насосы белән качать итәбез. Өлгерә алмыйбыз. Кеше җитешми. Зинһар, ярдәмгә слесарьлар бир.

Камил. Балалар тәрбиялисе урынга без акча, байлык, карьера дип чабабыз. Ничә кеше кирәк?

Гөлбикә. Өчәү. Юк, дүртәү!

Камил. Алло! Петровны чакырыгыз әле. Әйе, ашыгыч... Ташла син ул РДКаңны, төкер! Көн дә авария! Хатыннар эшемени ул? Бер-ике бала тап. Кешечә яши башла.

Гөлбикә. Әйе, Гыйльфанга ышанып бала тапсаң, ыштансыз калырсың. Ташлап чыгар да китәр. Менә

әле подвалга куйган идем, белеп тора бит, кешеләр җитми – качты!

Камил. Алло! Петровмы? Миңа Петров кирәк, дидем бит сезгә! Чакырыгыз, тизрәк!.. Син ул Гыйльфанны ку! Мәхлук! Ку да рәтлерәк иргә чык. Карт көнеңдә бала табарсың, ичмасам.

Гөлбикә. Хәзер соң инде, җизни, соң!

Хәлимә. Кеше үзе юкта нигә чәйнисез аны?

Камил. Нигә аны яклыйсың? Петров? Бу мин... РДКда тагын авария! Хәзер үк ярдәмгә дүрт слесарьны җибәр. Авария, дим. Подвалларын су баскан! Утлары сүнгән.

Гөлбикә. Компьютерлар эшләми.

Камил. Компьютерлар эшләми. Әйе, хәзер үк!

Гөлбикә. Рәхмәт, җизни! Әй шәп кеше дә соң үзең! Менә синең белән мин ун бала да табар идем, валлаһи!

Камил. Үтенечең беттеме? Югыйсә апаң белән безнең эш муеннан!

Гөлбикә. Тагын берәү бар. Соңгысы. Җизни, минем бер актриса кияүгә чыкты. Бүген Уфага күчеп китте. Ә иртәгә премьера! Апам шуны алмаштырып торсын иде, зинһар. Башка кеше тапканчы. Янабыз бит. Дөрләп янабыз! Зинһар...

Камил. Юк!

Гөлбикә. Җизни!..

Камил. Юк, дим, бетте бу темага сөйләшү! Хәлимә, кайда минем эш киемнәрем?

Камил шифоньерны ача, анда Гыйльфан.

Тәк.

Гыйльфан. Исәнме, Камил!

Камил. Хәлимә, бу нәрсә?

Гөлбикә. Гыйльфан, сволочь! Нәрсә карап утырасың анда? А ну-ка, марш подвалга!

Гыйльфан. Туктале! Нигә сугышасың?

Камил. Хәлимә!

Хәлимә. Гөлбикәдән качкан иде шунда.

Гыйльфан. Син әллә нәрсә уйлама. Мин Гөлбикәдән качып утырам. Тукта! Тукта, дим!

Гөлбикә. Хәзер үк йөгер подвалга! Анда кеше житешми, ә ул шифоньерда йоклап ята!

Камил. Хәлимә, нишләп чит ир безнең шифоньерда утыра? Аңлат.

Гыйльфан. Үзем аңлатам! Гөлбикә мине Сибайга җибәрмәгәч...

Камил. Синнән сорамыйлар! Хәлимә!

Хәлимә. Гыйльфан Гөлбикәдән качып килеп керде. Ул Сибай театрына барып көй язарга тиеш булган. Гөлбикә җибәрмәгән.

Гөлбикә. Эштән качып утыра бит ул монда!

Камил. Нигә ул безнең шифоньерда утыра, дим мин сиңа!

Хәлимә. Ярдәм сорап килгән. Гөлбикәгә әйт, мине җибәрсен, ди.

Гыйльфан. Әйе, Хәлимә әйтсә, Гөлбикә җибәрер иде...

Гөлбикә. Әйе, җибәрермен! Ишектән арт саныңа тибеп чыгарырмын! Дезертир! Ялкау!

Гыйльфан. Гөлбикә, мин синең белән яши алмам, ахры...

Гөлбикә. Яшәрсең, бик яшәрсең. Яшәргә өйрәтәм мин сине!

Камил. Туктап торыгыз әле! Нигә сиңа килгән ул аны сорарга? Нигә башкага бармаган?

Хәлимә. Мин Гөлбикәнең апасы булганга, Камил.

Гөлбикә. Әйе, мин, сине тыңлап, җибәрәм ди аны! Менә!

Камил. Сорарга килгәч, нигә шифоньерда утыра? Сорасын да шайтаныма олаксын!

Хәлимә. Ул бит Гөлбикәдән качып килеп керде. Гөлбикә аны тукмаган...

Гыйльфан. Микрофон белән башта миңа... Бердәнбер микрофон! Шуны ватсаң...

Гөлбикә. Ватылса, тимә нервыма!

Хәлимә. Тәрәзә аша Гөлбикәнең килгәнен күрде дә...

Гөлбикә. Җизни, әллә көнләшәсең инде? Гыйльфанның РДКдан чыгып качканына биш минут...

Камил. Гөлбикә! Дүрт слесарь килдеме? Бар, ремонтла РДКаңны!

Гөлбикә. Киттем, киттем! Так что, ул монда берни кылырга да өлгермәде.

Камил. Син киттеңме-юкмы?

Гөлбикә. Әйдә, бездельник, әйдә!

Гыйльфан. Гөлбикә! Икебез ике якка китик тә барыйк. Ике аккош кебек!

Гөлбикә. Күрсәтәм мин сиңа хәзер ике аккошны! Башта подвалдагы суны качать итеп бетер! Алга! Нәрсә карап торасың?

Гыйльфан белән Гөлбикә чыгып китә.

Камил. Хәзер яшерми сөйлә барысын да. Нигә Гыйльфан шифоньерда утыра иде?

Хәлимә. Камил, син миңа ышанмыйсыңмы?

Камил. Нигә чит ир минем шифоньерда утыра? Аңлат шуны!

Хәлимә. Соң, аңлаттым бит. Гөлбикә Гыйльфанга микрофон белән суккан. Шуннан ул качып килеп...

Камил. Нигә ул безнең шифоньерга качкан? Аңа РДКда шифоньер беткәнме?

Хәлимә. Ул бит миннән ярдәм сорап килгән!

Камил. Ярдәм кирәк икән, милициягә чапсын! Нигә сиңа килә?

Хәлимә. Камилем, Гөлбикә әйтте бит...

Камил. Хәлимә, җитте! Мине ахмакка санама! Әйт дөресен! Нигә Гыйльфанны чакырдың?

Хәлимә. Нинди тискәре син! Әйтеп торам...

Камил. Мин тискәреме? Шифоньерга чит ирне яшереп утыртып куйган син тискәре түгел! Шуны аңлатуны таләп иткән мин тискәре! Әйдә, алайса очраш шул кулыннан бер эш килмәгән баянист белән безнең өйдә! Мин эштә чакта! Яки бөтенләй безгә күчсен. Хатынынннан куркып качып йөргәнче, яшәсен бездә! Ә мин дәшмәм. Давай!

Хәлимә. Камил, без болай яши алмыйбыз.

Камил. Хәлимә, хәзер ашыкмый гына сөйлә барысын да. Алдашмыйча. Ничек булган – шулай. Мин шуны белергә тиеш. Югыйсә мин үземнең ни эшләячәгемә җавап бирә алмыйм!

Хәлимә. Сөйләдем бит, инде ун кат сөйләдем. Тагын нәрсә сөйлим? Камил, бүген бит туй! Минем эшем күп!

Камил. Туең чәчрәп китсен! Монда дөнья асты өстенә килә! Җир шары! Минем бөтен тәнем яна! Гарьлектән! Ачудан! Аңлыйсыңмы шуны?!

Хәлимә. Камил, болай булмый! Син миңа ышанмагач, безгә аерым яшәп карарга кирәк.

Камил. Димәк, монда очрашып булмый башкача! Шуңамы?

Хәлимә. Уф Алла! Җитте! Минем дә түземлегемнең чиге бар!

Камил. Ярый, җитте. Китәм мин бу өйдән. Әйдә, шул Гыйльфаның белән...

Хәлимә. Сөйләмә миңа шул Гыйльфан турында! Зинһар...

Камил. Бик телисең икән, аерылышабыз.

Хәлимә. Мин аерылышырга теләмим.

Камил. Син бит беренче әйттең. Аерым яшик, дидең.

Хәлимә. Аптыраганнан әйттем.

Камил. Ярый, бүген үк икенче фатирга күчәм.

Хәлимә. Камил, китмә. Туй үткәнче булса да кал. Кунакларга сиздермик. Оят бит. Балалар алдында оят. Алар өйләнешә, ә без аерылышабыз...

Камил. Алдан уйларга кирәк иде. Алдан! Аерылышабыз!

Хәлимә. Ярый! Аерылышырга икән аерылышырга!

Айнур керә.

Айнур. Әти, әни! Исәнмесез!

Хәлимә. Айнур! Улым! Сагындык сине! Исәнме, исәнме!

Камил. Исәнме! Нигә туйны бүгенгә күчердең? Безнең рөхсәтсез!

Айнур. Нинди туйны?

Камил. «Нинди туйны»?! Күчерер булгач, ике-өч көн алдан әйтергә кирәк. Бер көндә туйны әзерләп буламы?

Айнур. Нинди туй, әти?

Камил. Аңгырая башладыңмы әллә? Үз туең!

Айнур. Минем туй? Мине өйләндерәсезмени? Юк! Мин өйләнә алмыйм, әти. Мин иртәгә Германиягә китәм.

Камил. Нигә безнең нервыда уйныйсың, малай актыгы?

Хәлимә. Камил!..

Айнур. Әти! Гыйльми проектлар буенча узган елда Германиядә конкурс игълан ителгән иде бит. Мин шунда эшемне җибәргән идем. Хәтерлисезме? 324 эш арасыннан минеке җиңеп чыгып, грант алды. 300 мең доллар!

Хәлимә. Чынмы? Котлыйм, улым! Син нинди башлы!

Камил. Атасына охшаган. Котлыйм!

Айнур. Мин иртәгә Мәскәүгә китәм. Анда виза эшлиләр, эшемне тагын бер тапкыр тикшерәләр. Шуннан Германиягә укырга, эшләргә җибәрәләр.

Хәлимә. Син анда бер китсәң кайтмассың да инде...

Айнур. Әни, кайгырма. Отпускыга кайтып йөриячәкмен. Менә хатлары. Бу хакта телевизордан күрсәткәннәр бит. Карамадыгызмыни?

Камил. Безнең телевизор карарга вакыт бармы? Йә бер атнадан туй! Йә иртәгә! Синең башың эшлиме азрак? Туйга әзерләнүне ансат дип уйлыйсыңмы?

Айнур. Әти, нигә мине әрлисең? Мин берни дә аңламыйм.

Камил. Син бит телеграммалар сугып ятасың. Туй да туй!

Айнур. Мин бернинди дә телеграмма сукмадым.

Камил. Ничек сукмадың? Кая әле телеграммалар?

Хәлимә. Менә.

Камил. Менә беренче телеграммаң. Бер атна элек алдык. Укы.

Айнур. «Әти, әни! Мин Рушания исемле кызга өйләнәм. Шушы шимбә аның туганнары танышырга-сөйләшергә дип безгә киләчәк. Киләсе шимбә – туй! Бөтен курс белән кайтабыз. Айнур».

Камил. Шуннан нәрсә диярсең?

Айнур. Кемдер ялгышкан, йә булмаса, саташкан! Мин сукмадым моны!

Камил. Ничек сукмадың? Яхшылап кара! Аста кем исеме тора? Бәлки, оныткансыңдыр?

Хәлимә. Ничек онытсын мондый телеграмманы?!

Камил. Эчеп, похмельдән суккан да оныткан!

Айнур. Әти, мин бөтенләй эчмим.

Камил. Ярый, беренче телеграмма белән кемдер саташкан, монда бит тагын берәү бар. Монысын син җибәргәнсеңдер бит?

Айнур. «Әти, әни! Туйны срочно 17 июльгә күчерегез. Айнур». Кемдер акылдан шашканмы әллә?! Монысын да мин сукмадым!

Камил. Яхшылап кара, яхшылап! «Айнур» дип язылган бит астына!

Айнур. Юк, мин сукмадым бу телеграмманы, әти!

Камил. Шайтан алгыры! Күпме акча түгелде! Күпме көч!

Хәлимә. Йа Ходаем! Нишлибез инде хәзер?

Айнур. Мин дә сездән телеграмма алдым бит кичә. Менә, берни дә аңлашылмый. Әллә нинди туй. Кемнеке?

Камил. «Айнур! Туй 17 июльдә. Тиз кайтып җит. Әтиең белән әниең». Бу нинди телеграмма?

Хәлимә. Кемдер бутый безне.

Айнур. Мин дә аптырадым. Шалтыратам дисәң, безнең практика үткән җирдә сотовый тотмый.

Камил. Кемгә кирәк булган бу? Тукта, сез Рушания белән өйләнешергә йөрисезме, ичмасам?

Айнур. Нинди Рушания белән?

Камил. Син туксан тугыз Рушанияне белмисеңдер бит? Курсташың Рушания!

Айнур. Бездә алар икәү!

Камил. Тфү икән лә! Теге... Әнисе Айсылу. Ну?

Айнур. Мин аларның әниләренең исемен белмим.

Камил. Ну, абыйсы Гыйльфан. Өйләнәсеңме шуңа?

Айнур. Гыйльфан агайга? Өйләнәмме?

Камил. Әнисенә! Тфү! Әнисе Айсылуга! Башны тәмам бутадың! Әнисе Айсылу, абыйсы Гыйльфан булган Рушаниягә өйләнәсеңме-юкмы?

Айнур. Юк, әти, юк! Рушанияләргә дә, башка исемле кызларга да өйләнергә җыенмыйм, мин Германиягә китәм.

Камил. Тукта, тукта! Ә Рушания авырлымы?.. Әнисе – Айсылу.

Айнур. Белмим. Мин бит гинеколог түгел, әти, кызларның авырлымы-түгелме икәнлеген тикшерергә.

Камил. Сиңа беркем дә тикшер дими. Эче сизеләме?

Айнур. Бүген автовокзалда күрдем. Тик эченә игътибар итмәдем.

Камил. Биш айлык корсакны! Аңа игътибар итү кирәкми, үзеннән-үзе күренә. Менә шулай булып. Күрдеңме?

Айнур. Әйттем бит. Игътибар итмәдем, әти.

Камил. Тфү икән! Мин болай уйлыйм. Бу катавасия юктан килеп чыкмаган. Ни өчен Айнур Рушаниянең эченә игътибар итми? Нигә күрмәмешкә салыша? Чөнки Айнур белән Рушания очрашып йөргән. Шуннан кыз авырлы калган. Айнур баш тартмакчы була. Шулаймы?

Хәлимә. Йа Ходаем!

Айнур. Кем әйтә?

Камил. Мин әйтәм! Яшермә. Эш туйга килеп җитте! Булган икән, булды, дип әйт. Туй оештырганыгыз өчен рәхмәт, диген.

Айнур. Бернинди дә эш булмады, әти.

Камил. Беркайчан да булмадымы? Моннан биш ай элек тәме? Бәлки, оныткансыңдыр? Егет халкында була торган хәл.

Хәлимә. Камил, «булмады» дип тора бит.

Айнур. Әти, юк. Онытмадым. Булмады андый хәл.

Камил. Алайса!.. Рушания кемнәндер авырлы калган! Аны безгә тагарга уйлыйлар! Айсылу кодагыйның эше бу! Туй да туй дип, көне-төне йөгерә. Тиз генә ашханәсен әзерләп куйды. Телеграммаларны да ул суккандыр. Аның гына эше бу!

Хәлимә. Белмичә әйтеп гөнаһланма.

Камил. Башка кемгә кирәк бу кәмит? Вәт шайтан хатын! Кайда әле телефоны? Хәзер әйтәсен әйтәм! Кара, күпме расхутка салып, туй әзерләтте, әйттем мин сиңа, сотовый тотмый икән, Айнур яшәгән тулай торакка шалтыратыйк, дип. Ә син «телефонын белмим», «телефонын белмим»! Менә хәзер бел инде – нишлибез сый белән? Чакырган кунаклар белән? Нишлибез?

Хәлимә. Белмим, Камил. Нәрсә әйтергә дә белмим!..

Ишектә звонок. Хәлимә ишекне ача. Айсылу белән Рушания килеп керәләр. Рушаниянең эче сизелеп тора.

Айсылу. Исәнмесез, кода, кодагый! Исәнме, Айнур!

Рушания. Исәнмесез!

Хәлимә. Исән әле.

Камил. Исәнме!

Айнур. Исәнмесез! Исәнме, Рушания! Ни булды сиңа? Бу нәрсәне аңлата?

Айсылу. Вәт шаян егет, ә? Эшен эшләгән дә «ни булды сиңа, бу нәрсәне аңлата»? Бу шуны аңлата, тәти егет, бүген туй!

Камил. Ашыкма, кода... Айсылу ханым! Гафу итегез, отчествогызны белмим.

Айсылу. Кызны шушындый хәлгә җиткергәч, отчествоны сорамыйлар. Мин – төп кодагый!

Камил. Тукта! Кодагый булмый тор! Туй булмый!

Айсылу. Йә-йә? Шуннан?

Камил. Бу телеграммаларны Айнур безгә сукмаган, без дә аңа сукмадык!

Айсылу. Мин сuктым аларны. Шуннан? Менә күрәсезме – телеграмма сугарлыгы калмаган! Болар бөтенесе дә ялган!

Камил. Юк, Айсылу ханым! Син безне ярык тагаракка утырта алмассың! Айнур синең кызың белән йөрмәгән, яратышмаган! Син әллә кемнән авырлы кызыңны безгә алдап такмакчы! Килеп чыкмас!

Айсылу. Тәк, гражданин кода! Димәк, сугыш игълан итәсең! Өченче бөтендөнья сугышы. Пакт о ненападениины юкка чыгарабыз! Ярый! Башлыйбыз гражданнар сугышын! Алло! Гыйльфан! Хәзер үк Хәлимәләргә кил! Нәрсә-нәрсә – пожар! Срочно!

Камил. Чакырма! Күземә күренмәсен!

Айсылу. Мине бутамакчымы?! Килеп чыкмас! Айнур, кил әле монда! Кил, дим! Утыр шушында!

Рушания. Сезнең инәгез белән җебегез бармы?

Хәлимә. Нәрсә дисең?

Рушания. Инә белән җеп бирегез әле.

Хәлимә. Нәрсәгә ул сиңа?

Рушания. Хәзер күрсәтәм.

Хәлимә Рушаниягә инә белән җеп бирә.

Рушания *(Камилгә)*. Җиңегез ялтырап тора бит. Төймәсе төшкән. Карыйк әле, запас төймә бармы? Бар.

Айнур. Нигә утырырга?

Айсылу. Допрос! Утыр!

Камил. Сеңлем, тукта!

Рушания. Тыныч кына утырыгыз.

Хәлимә. Сезнең ни хакыгыз бар?

Айсылу. Кодагый, тавыш! Хәзер аңларсың! Айнур! Биш ай элек сез курсыгыз белән «Карагай» турбазасына бардыгызмы?

Айнур. Турбаза? Бардык. Тик биш ай элек түгел, дүрт ай элек.

Айсылу. Анда бер өйдә ярты курс – идәндә, яртысы сәкедә йокладыгызмы? Бергәләп? Ачык кына җавап бир. Бер сүз белән. Йокладыгызмы, әллә юкмы?

Айнур. Ну, йокладык.

Айсылу. Рушания белән сез икегез дә сәкедә яттыгызмы? Бер сүз белән – яттык, йә булмаса, юк!

Айнур. Яттык. Шуннан?

Айсылу. Шул, энем, теорема исбатланды. Ишеттегезме, алар турбазада бергәләп йоклаганнар!

Айнур. Анда сәкедә безнең белән ярты курс йоклады!

Айсылу. Анысы мөһим түгел.

Камил. Рәхмәт, сеңлем. Менә уңган кыз! Шушы җиң ике көн ялтырап йөри, беркем күрми, ә ул...

Хәлимә. Камил, минем вакытым булдымы?

Камил. Аның хәле синекеннән дә хәтәррәк, әмма күрде!.. Ярый, Айсылу ханым!

Гыйльфан килеп керә. Кулында огнетушитель.

Гыйльфан. Нәрсә яна? Кайда пожар?

Айсылу. Туй яна! Рушаниянең язмышы яна!

Гыйльфан. Шул гынамы? Уф, куркыттыгыз! Монда бит Айнурның... Исәнме, Айнур! Практикаң беттеме?

Айнур. Исәнме, Гыйльфан абый!

Гыйльфан. Хәлимә, рәхмәт. Гөлбикә тыңлады синең сүзләреңне. Сибайга җибәр, дигән идем, бар, чыгып кит, күземә күренмә, диде.

Камил. Ә мин, безнең өйгә аягыңны да басма, димен! Ишеттеңме? Хәзер үк чыгып кит!

Айсылу. Кода, тукта! Гыйльфан – свидетель, шаһит! Гыйльфан! Кил, утыр шушында!

Гыйльфан. Нигә?

Айсылу. Утыр, дим! Допрос! Алдашмыйча, дөрес җавап бир! Моны судта исәпкә алырбыз. Син хәзер шушы егетне коткарасың яки батырасың!

Камил. Бу нинди комедия?

Айсылу. Кода, тавыш! Тыңлап бетер!

Гыйльфан. Мин Айнурны коткарырга тиешме?

Айсылу. Әйе, Айнурны. Ул еш кына, якынча атнасына өч тапкыр, РДКга килеп, синең кабинетыңда!..

Гыйльфан. Юк-юк! Дөрес түгел! Ул килмәде беркайчан да!

Айсылу. Отставить! Бүлдерми генә тыңла! Мин бит беләм, шалтыратыйммы вахтёрга? Йә булмаса, монда чакырыйммы? Ул бөтенесен дә сөйләп бирер! Чакырыйммы?

Гыйльфан. Юк! Кирәкми!

Айсылу. Туктап тор! Мин бит, музыка белән шөгыльләндегез, дип әйтмим!

Камил. Шул гына җитмәгән иде!

Айсылу. Рушания белән очрашты Айнур! Йә! Расла шушы сүзләрне! Килдеме Айнур синең кабинетыңа? Рушания белән очрашу өчен?.. Эндәшмисеңме? Ярый, вахтёрга шалтыратам хәзер.

Гыйльфан. Шалтыратма. Килде...

Айнур. Гыйльфан абый!

Айсылу. Тавыш! Рушания белән очрашты. Шулаймы? Мин синнән сорыйм, шулаймы?

Гыйльфан. Шулай...

Айсылу. Ә хәзер, егеткәй, син утыр шушында һәм җавап бир! Җай чыккан саен бардыңмы РДКга, Гыйльфанның кабинетына?.. Онытма, вахтёр бөтенесен дә күргән. Рушания белән очрашырга?

Рушания. Әни! Нигә алай борасың?

Айсылу. Тик тор! Йә? Ишетмим!

Камил. Нигә эндәшмисең? Әллә телеңне йоттыңмы? Бардыңмы-юкмы? Нәрсә эшләдең анда?

Айнур. Әйе... Бардым... Очрашырга...

Айсылу. Менә, бу теорияне икенче тапкыр исбатлау була, кода белән кодагый. Ә яшь кыз белән яшь егет еш кына бергә-бер очрашса нәрсә була? Менә шушы була. Йә, хәзер нишлибез? Нигә эндәшмисез?.. Туй үткәрәбез!

Хәлимә. Сез... ничек ... шулай...

Камил. Ну Айнур! Ну Айнур! Нигә юкны сөйлисең, алай булгач? Ух! Ну Айнур!

Айсылу. Вот именно «ну Айнур»! Ә сез, булмый туй, дисез. Ишшу как була!

Айнур. Барыбер Рушания миннән авырлы түгел.

Айсылу. Ха-ха! Ышандык! Кайсы егетнең, кыз миннән авырлы, дип әйткәнен ишеткәнегез бар? Бөтенесе дә сволочьлар, эшне эшләп, койрыкларын сыртка салырга маташа. Аларны менә шушылай җилкәсеннән тотып өйләнергә мәҗбүр итәргә кирәк. Өйләнми икән, төрмәгә!

Камил. Ну Айнур! Ну Айнур!

Айсылу. Хәзер бөтенегез дә минем команданы тыңлагыз! Утырышыгыз!

Гыйльфан. Апа, мин...

Айсылу. Утыр!

Ишектә звонок. Хәлимә чыга да Хәмитне ияртеп керә.

Хәмит. Равняйсь! Смирно! Подполковник Сайранов прибыл! Вольно! Исәнмесез!

Бөтенесе бергә. Исәнмесез! Исәнме, исәнме, җизни!

Хәмит. Гөлбикә кайда?

Айсылу. Әнә ире утыра. Шуннан сора.

Хәмит. РДКда, монда китте, диделәр. Кайда ул?

Гыйльфан. Апай, мин йөгердем! Автобуска соңга калам!

Айсылу. Утыр! Беркая да китмисең! Син туйда төп кода буласың!

Гыйльфан. Нигә мин? Аның әтисе бар.

Айсылу. Әтисе төкерә кызының туена.

Хәмит. Чүтеки туй буламы?

Айсылу. Юк, булмый! Бар, йөгер эчәргә!

Хәмит *(телефоннан шалтырата)*. Алло! Гөлбикә! Син кайда? Мин монда, Камил... кодаларда. Кем? Гыйльфан?

Гыйльфан. Мин юк! Мин юк!

Хәмит. Ул «мин юк» ди. Көтәм. Хәзер килә.

Гыйльфан. Апа!..

Айсылу. Нәрсә «апа»? Синең әнә хатыныңны урларга йөриләр!

Гыйльфан. Бөтенләйгә түгел бит.

Хәмит. Бер кичкә.

Рушания. Әти, график! Кефир!

Хәмит. О! Онытып торам! Рәхмәт, кызым! Миндә ашказаны язвасы. Ун минут саен ашарга кирәк. Врачлар шулай кушты.

Айсылу. Үтерә инде шул графигың!

Гөлбикә керә.

Гөлбикә. Җизни, коткар! Сварочный аппарат кирәк. Торбаларны алмаштырырга! Срочно!

Камил. Бәйләнмәгез миңа! Берегезне дә күрәсем килми!

Гөлбикә. Җизни, үтермә, зинһар, ярдәм ит! Йә яшим, йә үләм! Үзем шалтыратам. Алло! Беренче цехмы? Сезнең белән цех начальнигы сөйләшә. Җизнәй, мә!

Камил. Ну сине!.. *(Телефонга.)* Петровны чакырыгыз!

Хәмит. Гөлбикә, вакыт! Соңга калабыз.

Гөлбикә. Күрмисеңмени, РДК шартлый!

Айсылу. Вәт оятсыз! Тере ире алдында! Нәрсә карап торасың? Бар, тәгәрәтә тор!

Гөлбикә. Гыйльфан мондамы? Кайда ул?

Рушания. Әти, график! Массаң!

Хәмит. Рәхмәт, кызым! Әле дә син бар. Бу әниең... Үзе дә хәтерләми, мине дә...

Айсылу. Синең миең сыегайганга мин гаеплеме?

Гөлбикә. Гыйльфан! Сволочь, тагын качкан! Син кайда? Син нигә монда?

Гыйльфан. Син бит әйттең, бар, күземнән югал, дидең.

Гөлбикә. Мин бит сиңа, подвалга бар, дидем! Анда кеше житешми! Бар, йөгер! Суны качать итеш!

Гыйльфан. Юк! Җитте! Бармыйм! Мин сиңа сантехник түгел. Кичә – канализация, бүген – подвал! Мин – композитор! Мин хәзер Сибайга китәм.

Гөлбикә. Күрсәтәм мин сиңа хәзер Сибайны.

Камил *(телефонга)*. Петровмы? Хәзер үк РДКга бер сварочный аппарат җибәр! Җибәр, диләр бит сиңа! Срочно! Әйе, сварщигы белән!

Гөлбикә. Җизни, зур рәхмәт! Син мине үлемнән коткардың!

Хәмит. Тукта, Рушания. Тукта, бу нәрсә? Айсылу, бу нәрсә, дим!

Айсылу. Нәрсә-нәрсә! Күзең чыкканмыни? Биш айлык!

Хәмит. Ничек? Ничек? Соң бая өйдә...

Айсылу. Тавыш!.. Утыр! Эшең булмасын! Аңладыңмы? Әнә Гөлбикәңне ал да юбилееңа тай!

Хәмит. Син бит кодаларны...

Айсылу. Молчать! Сесть! Авызыңны да ачма! Понял?

Хәмит. Әй, чәчрәп кит!

Гөлбикә. Җизни, соңгы үтенеч! Сварочный аппараттан да мөһим! Катастрофа! Үлем!

Камил. Йә, нәрсә? Нәрсә?

Айсылу. Синең катастрофаң бетмәс!

Гөлбикә. Халык театрында иртәгә премьера! Мәдәният министрлыгыннан комиссия килә. Әгәр спектакльне комиссиягә күрсәтә алмасак, бетте! Звание яна, театр яна, аны ябалар!

Камил. Ябылсын. Нәрсәгә кирәк ул театр?

Айсылу. Дөрес, кода! Кешеләрне эштән аерып йөриләр шунда, арт сан сикертеп!

Камил. Нигә хатын-кыз өйдә утырмый, азып-тузып теләсә кайда йөри? Чөнки балалары юк! Тапмаганнар вакытында! Тапсалар, бер-икене тапканнар да, алары үсеп җитеп, читкә киткән. Хәзер хатыннар нишләргә белми, йә ирләрен көне-төне әрли, йә...

Гөлбикә. Тапмаганнар инде вакытында, тапмаганнар! Хәзер нишләргә аларга? Халык театрына йөрсеннәр!

Камил. Хәзер таба алмагач, балалар йортыннан бала алсыннар. Әнә Америкадагы кебек. Аларда һәр гаилә үзләренең ике-өч баласына өстәп өч-дүрт ятимне алып тәрбияли! Җәмгыятькә файда, үзләренә куаныч. Ә без?

Рушания. Әти, бетте.

Хәмит. Рәхмәт, кызым! Кода! Шәп идея бу! Хәрбиләрчә – прямая наводка! Раз, два – детдомнан бала! Азапланырга да кирәкми.

Гөлбикә. Җизни, туктале шул балаларың хакында! Болай да проблемалар баштан ашкан. Актрисам күчеп китте. Алмаштырыр кеше юк! Шул рольне башкарырга... Зинһар! Зинһар! Хәлимә апама уйнарга рөхсәт ит! Үтенеп сорыйм! Менә аягыңа егылам!

Камил. Уйнасын.

Гөлбикә. Нәрсә дидең? Мин ялгыш ишетмәдемме? Уйнасынмы?

Камил. Теләсә нишләсен! Анда минем эшем юк!

Гөлбикә. Апам, ишетәсеңме? Уйнасын, диде җизни! Мин үз колагыма үзем ышанмыйм!

Хәлимә. Нигә аптырыйсың? Камилгә хәзер барыбер.

Гөлбикә. Тукта, ни булды сезгә?

Айнур. Әти, афәрин! Күптән кирәк иде. Син – демократ, әти, акыл иясе! Бәлки, музыкага да...

Камил. Юк! Музыка – ялкаулар, кулыннан эш килмәгәннәр, уңмаганнар эше! Ул каһәрләнгән сүзне әйтмәгез миңа!

Хәлимә. Демократ! Акыл иясе, имеш! Без аерылыштык, менә шуңа акыл иясе ул!

Камил. Хәлимә! Без бит сөйләштек!..

Хәлимә. Бөтен нервыларымны ашап бетердең! Синеке генә дөрес! Син генә хаклы! Сиңа мин кеше түгел!

Айнур. Әни!..

Гөлбикә. Апам!.. Тынычлан...

Айсылу. Менә, ирләр, хатыннарыгызны нинди хәлгә төшерәсез! Бер тамчы нервының хакы тормыйсыз бит сез! Менә утыра! Аерылышып өлгермәде, икенче хатын артыннан чабып килеп җиткән!.. Нигә аптырыйсыз? Без дә аерылыштык!.. Әйе. Әй Ходаем!..

Хәмит. Елаган булып кыланма, барыбер ышанмыйм! Гөлбикә, вакыт! Киттек!

Гөлбикә. РДКга кереп чыгыйк.

Айсылу. Отставить! Гыйльфан! Нәрсә карап торасың? Хатыныңны урлыйлар!

Гыйльфан. Апа, кайгырма! Кайта ул!

Рушания. Әти! График, чәй.

Айсылу. Нигә син шул графигың белән киләсең дә кысыласың?!

Хәмит. Точно, чәй! Гөлбикә!

Рушания. Менә! Термоста!

Хәмит. Кызым, акыллым! Ай, афәрин! Рәхмәт!

Камил. Менә, балалары, ире өчен, гаиләсе өчен яши хатын-кыз! Аңа халык театры кирәкмәячәк!

Айсылу. Бир әле термосны!

Хәмит. Айсылу, минем график! Язва желудка!

Айсылу. График бетте! Ачтык! Түктек!

Хәмит. Дошман! Син мине үтерергә телисең! Гөлбикә, әйдә! РДКаңа кереп чәй эчәбез дә юбилейга!

Гөлбикә. Әйдә!

Айсылу. Юк! Беркая да бармыйсың! Гыйльфан, ал хатыныңны! Ал, дим!

Гыйльфан. Гөлбикә, җибәр аны!

Камил. Туктагыз хәзер үк!

Хәмит. Җибәр, чукынган хатын!

Хәлимә. Нишлисез?

Рушания. Әни! Әти!

Айнур. Рушания, кысылма! Сиңа ярамый!

Тартыш-этеш, Рушаниянең эчендәге мендәре төшеп китә.

Барысы бергә. Аһ! Бу нәрсә? Мендәр! Алдаганнар!

Гөлбикә. Менә сиңа биш айлык корсак!

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Өченче күренеш

Икенче күренештәге шул ук декорация. Бөтенесе дә сәхнәдә.

Гөлбикә *(телефоннан сөйләшә)*. Нигә кирәк мин анда сезгә? Срочно суны качать итеп бетерегез! Сварочный аппарат килдеме? Торбаларны ябыштырыгыз! Ул-бу булса, миңа шалтыратыгыз! Аңлашылдымы? Эшләгез!.. Ха-ха-ха! Нигә аптырап калдыгыз? Мине артистка дип мыскыл итә идең. Менә кем ул артистка! Мин сине халык театрына алам әле. Менә дигән артистка чыгачак синнән! Яучы Җиһанны уйнарсың!

Айсылу. Ичмасам, син нервыга тимә!

Хәлимә. Оятыгыз юк икән! Шулай ярыймы? Эчегезгә мендәр бәйләп... Ярый, сау булыгыз! Хәзер бар туганнарга да хәбәр итәргә кирәк. Туй булмый.

Хәмит. Әйттем мин сиңа! Алдашып бәхет корып булмый. Сау булыгыз! Гөлбикә!

Айсылу. Кая киттең? Утыр!

Хәлимә. Беркем дә утырмый. Таралышабыз. Сау булыгыз!

Камил. Туктагыз! Мин сүз әйтәм... Эш менә нәрсәдә. Ошады бу кыз миңа. Әй ошады! Менә шушы җиңем атна буе җилфердәп йөрде. Шуны хатыным да, балдызым да күрми. Чөнки аларның башында икенче нәрсә! Тик ире, гаиләсе түгел.

Хәлимә. Мин бит туйга әзерләндем.

Гөлбикә. Ә мин нәрсә, синең ирең не карарга тиешме әллә?

Камил. Слесарь, сварочный аппарат кирәк булса, йөгереп килеп җитәсең. Ә мин нигә аларны сиңа бирергә тиеш? Ә Рушания... Кай арада кайтып җиткән дә әтисенең графигын ятлап алган! Менә син, Айсылу туган, шушында ярты сәгать бөтенесе белән дә тавыш чыгарып йөрисең, ә ирең нең графигын бер тапкыр да исенә төшермәдең. Ә аның язва желудка!

Айсылу. Язва булса аерылмасын!

Камил. Табигать могҗизасы! Шушындый хатыннан шундый әйбәт, акыллы кыз туган!

Хәмит. Миңа охшаган!

Айсылу. Үз хатыныңны тикшер, яме!

Хәлимә. Мин нишләгән?

Айсылу. «Туй булмый!..» Халык театры! Ә баласының язмышына төкерә! Лачт итеп! Әйдә, Айнуры китсен Германиягә! Ялгыз! Өйләнсен шунда берәр немкага! Шуннан утырыр оныкларыгыз: «Хайль Гитлер!» – дип. Шуны телисезме?

Хәлимә. Алла сакласын!

Камил. Туктагыз! Мин әйтеп бетермәдем. Мин болай уйлыйм! Рушания ирен хөрмәт иткән, гаиләсе турында уйлаган әйбәт хатын булачак. Ким дигәндә биш бала анасы! Айнурга именно шундый кәләш кирәк. Шуңа мин Айнур белән Рушаниянең өйләнүенә риза. Үткәрәбез туйны!

Айсылу. Кода! Кадерлем! Афәрин! Кил, үбим берне!

Гөлбикә. Җизни! Айнурга егерме генә яшь. Аңа өйләнергә иртә. Җитмәсә, Германиягә китәргә йөри.

Хәмит. Әйе, иртәрәк! Иртәрәк!

Айсылу. Тик утыр!

Гыйльфан. Өйләнешсеннәр! Менә дигән пар! Рушания бит искиткеч! Пианистка! Ә Айнур... Яптым авызны...

Хәлимә. Камил! Айнур әле бала гына! Җитмәсә, алар бер-берсен бөтенләй белми. Йөрмәгән, яратышмаган...

Гөлбикә. Җизни, әйе, ә мәхәббәт кайда?

Камил. Мәхәббәтме? Мәхәббәт болай була. Айнур! Рушания! Безнең талашканны тыңлап утырмагыз монда. Икенче бүлмәгә керегез, сөйләшегез, килешегез! Айнур, мин шушында әйткәннәрне исеңдә тот! Сезгә унбиш минут! Чыккач, өйләнешәбез, дип әйтерлек булсын. Ишеттеңме? Барыгыз!

Айнур белән Рушания чыгып китә.

Гөлбикә. Җизни, бу бит элеккечә, көчләп өйләндерү була.

Айсылу. Әти-әнисе көчләп өйләндергән гаиләләр таркалмый, чөнки әти-әни гаилә кору өчен нинди егет белән кыз кирәк икәнен белә.

Гөлбикә. Мин барыбер каршы болай итеп өйләндерүгә! Күренеп тора: алар бер-берсен яратмый. Ә мәхәббәтсез тормыш тормыш түгел!

Камил. Гаиләдә хөрмәт кирәк. Хөрмәт! Ул мәхәббәт дигәнегез берзаман бетә. Акыллы парларда ул әнә шул хөрмәткә әверелә, ә акылсызлар – хөрмәткә әйләндерә алмаганнар – аерылыша. Җүләрләр генә янәшәсендәге кешесен хөрмәт итәсе урынга, картайгач мәхәббәт эзләп йөри.

Хәмит. Дөрес! Иң беренче хөрмәт кирәк. Боларда әлегә хөрмәт тә, мәхәббәт тә юк! Мин туйга каршы!

Айсылу. Тукта хәзер үк! Утыр!

Хәмит. Отставить! Нәрсә уйлыйм, шуны әйтәм. Мин туйга каршы! И всё. Алар – бала! Ни акчалары, ни бакчалары юк! Безнең җилкәгә утырачаклар. Айнур аякка бассын, фатир сатып алсын! Яратсын! Әйе, мәхәббәт кирәк. Ансыз булмый. Шуннан өйләнер. Всё!

Айсылу. Айнурның бит акчасы була. 300 мең доллар!

Хәмит. Андый акча кирәкми! Аны һич тә алырга ярамый. Немецлар юкка бирми ул акчаны. Айнурның башын, мозгасын сатып алырга телиләр. Йөрмәсен Германиягә сатылып. Алар безнең потенциаль дошман!

Айсылу. Мондый ахмак сүз әйткәнче, эндәшмә, ичмасам!

Камил. Кешегә яшьтән җаваплылык салырга кирәк. Балалары, хатыны, гаиләсе өчен җаваплылыкны. Өйләнсеннәр егерме яшьтә. Иреклерәк эштә эшләсен. Мәсәлән, галим булып, һәм гаилә өчен яшәсен. Күп итеп бала тапсыннар. Ким дигәндә бишне! Шуларны тәрбияләсеннәр, үстерсеннәр. Күп бала караган ир белән хатынның юк-бар уйларга, кирәкмәгән нәрсәләр артыннан чабарга вакыты калмый. Бала карау – менә шул ул кеше бәхете!

Хәмит. Кода, бишәү артык! Иң әйбәте – дүрт! Ике кыз, ике малай!

Гөлбикә. Ике герой-ата! Сөйләнгән булалар: биш бала! Дүрт бала! Ә нигә балаларыгыз берәр?

Хәмит. Ул гаепле! Күпме әйттем, тапмады!

Айсылу. Уянды!

Гөлбикә. Эх син, ир! Ишшу полковник! Бала кирәк булгач, хатынны тыңлап тораламмы? Тәгәрәтеп суктың да... эшеңне эшлә!

Хәмит. Ул чакта мин лейтенант кына идем шул!

Камил. Мин гаепле! Гомер буе эш дип чаптым, акча дип, карьера дип. Хәлимә дә шул. Баланы күрмәдек. Дөнья артыннан кумаска, күп итеп балалар үстерергә кирәк булган. Ул чакта бүген Германиягә Айнур китсә, башкалары янибызда калыр иде. Без иң бәхетле кешеләр булыр идек! Хәзер бөтенесе дә бар – фатир, машина, гараж, дача! Ә балалар – юк! Хәзер Айнур чыгып китсә, утырып калачакбыз ике кәккүк кебек. Ни өчен яшәдек? Ул хәзер театр дип чабар, мин эштән кайтмамын. Шул да булдымы гаилә? Шул да булдымы тормыш?

Хәлимә. Камил... Айнурлар әнә шулай үкенмәс өчен, күп итеп бала тапсыннар. Гаиләсе, балалары өчен яшәсеннәр. Шушы – тормышның мәгънәсе. Кешелекнең.

Гөлбикә. Күп баланы карарга акча кирәк, җизни. Ә илдә кризис.

Камил. Әнә безнең күрше Хәдичәнең ун баласы бар. Ул нәрсә ди? Һәр бала үз ризыгы белән туа, ди. Бала туугa, Аллаһы Тәгалә уйламаган җирдән байлык бирә, ди. Гаҗәп сүзләр бит! Бала туугa, Аллаһы Тәгалә уйламаган җирдән байлык бирә!

Айсылу. Ярый, җитте! Ничә бала табарга үзләре белер. Өйләнешүне хәл итик. Балаларны чакырып әйтәбез дә – туйга!

Хәлимә. Ничек «хәл иттек»?

Гөлбикә. Һич тә хәл итмәдек әле! Тавышка куябыз! Бу бик җитди мәсьәлә!

Айсылу. «Тавышка куябыз» дияргә син кем?

Гөлбикә. Айнурның апасы. Әти-әнисе эштә чакта мин аны менә шушындый чагыннан карап үстердем!

Хәмит. Дөрес! Хәзер демократия! Тавышка!

Айсылу. Ух, шушыны! Ашка төшкән таракан!

Хәлимә. Әйе, Камил, тавышка куйыйк! Баланың язмышын хәл итәбез бит.

Камил. Тавышка икән тавышка! Кем дә кем...

Айсылу. Тукта, кода! Хәмит белән Гөлбикәнең тавыш бирергә хакы юк! Әйе, юк!

Хәмит. Ни өчен? Мин чүтеки Рушаниянең атасы!

Айсылу. Туйга бармый, үз рәхәтенә киткән өчен! Вәт! Кем дә кем Айнур белән Рушания өйләнешсен ди, кулларыгызны күтәрегез. Камил кода, Гыйльфан, мин – өч тавыш. Кем каршы? Сез күтәрмәгез! Сезгә тавыш бирелмәгән, Хәлимә кодагый – бер тавыш. Ярый, воздержаться итәргә хокук бирәм. Кем воздержался? Күтәрегез кулларыгызны! Икәү. Өчкә бер, өйләндерергә теләүчеләр җиңде! Процедура бетте!

Гөлбикә. Ә Германия? Анысын хәл итмәдек бит! Алар китәме?

Айсылу. Бу нинди ахмак сорау? Әлбәттә, китә!

Хәмит. Юк, монда да тавышка куярга кирәк!

Айсылу. Нәрсәгә ул сиңа? Барыбер тавыш бирергә хакың юк.

Хәмит. Алайса, фикеремне әйтәм!

Айсылу. Синең фикерең безгә нуль! Тик утыр!

Камил. Кодагый, тукта! Кода, әйт!

Хәмит. Немецлар хәйләкәрләр! Акыллы башларны үзләренә җыялар. Шуннан немкага өйләндерерләр дә гомерлеккә бәйләп куярлар. Акыл, ми үзебезгә кирәк! Китмәсен! Армиягә барсын! Менә дигән офицер булачак!

Айсылу. Армия дип, үз баласын күрмәгән кишер майор кешегә акыл өйрәткән була! Акылың булса, карьера ясыйм дип, начальнигың оештырган пьянкага чапмас идең, бердәнбер кызыңның туена барыр идең! Әнә Камил кода, акылы булгач, соңлап булса да үкенә, карьера дип, акча дип, баламны күрмәдем, ди. Ә бу кырыкны үткән, сакалы биленә җиткән, һаман карьера дип саташа, дурак! Нәрсәгә сиңа карьера ил-

легә җиткәч? Бер елдан арт саныңа тибеп пенсиягә җибәрәчәкләр! Шуннан кызыңа туйда булмавыңны ничек аңлатырсың? Китмәсеннәр, имеш! Шуннан кызың студентка булып, бала табып, синең биш тиенлек пенсияңә карап утырырмы? Шуны телисеңме? Китәләр Германиягә! Менә шул!

Гөлбикә. Әйе, китсен Айнур Германиягә. Тик ялгыз китсен. Әйе! Нигә аңа җүләр кеше кебек Германиягә хатын ияртеп барырга? Урманга утын төяп бармыйлар.

Айсылу. Айнур белән Рушаниянең язмышына кысылма! Монда аларның әти-әниләре бар. Ә син кем?

Гөлбикә. Апасы! Әти-әнисе эштә чакта мин карап үстердем ул баланы. Дәресләрен әзерләп бетерә иде дә минем кабинетта ятып йоклый торган иде. Китсен! Шунда эшләсен, яшәсен! Немецлар сатып ала диген. Алсыннар! Безгә кирәкмени ул ум, голова, мозг? Немецларга кирәк булгач алсыннар. Бушка түгел бит. Монда безнең кебек хәерче яшәгәнче, немецларга сатылып бай яшәр. Без дә кунакка барып, немецларның ничек яшәгәнлеген күреп кайтырбыз. Немкага өйләнсә ни, өйләнсен! Аларча туй күреп кайтырбыз. Хинде хох, дип биешербез туйда.

Айсылу. Артистка ни – ихахай да, туй да бию! Кеше язмышына төкерә ул! Шул фашистлар сугышта синең, минем бабайны үтерде. Шулар белән гарьләнмичә туганлашасызмы?

Гөлбикә. Ул сугыш күптән беткән, онытылган. Без хәзер немецлар белән дуслар!

Айсылу. Горурлык кирәк, милли горурлык! Патриотлык!

Гыйльфан. Апа, гафу ит, мин дә Айнурның Германиягә китүенә каршы. Башкорт көе белән немецның җырын чагыштырганыгыз бармы? Җир белән күк бит алар! Безнең моң... күңелгә үтеп керә. Безнең халык моңнары медитация бит ул, үзе бер дога. Галимнәр исбат иткән: башкорт халык җырларын гел җырлап йөргән авырулар терелә икән.

Айсылу. Причём монда башкорт халык җырлары?

Гыйльфан. Апа, тыңлаганың юкмыни? Сугыш турындагы фильмнарда күрсәтәләр. Немецларның җыры эт улавы кебек. Лаф-лаф-лаф!

Айсылу. Шуннан?

Гыйльфан. Китмәсен Айнур Германиягә, апа. Ул анда рухын югалтачак, талантын. Айнур бит шундый талантлы ком... галим. Талант туган җирдә генә үсә, чит җирдә ул үлә. Айнур немецка өйләнәчәк. Без тагын бер талантлы башкортны югалтачакбыз. Башкортлар болай да аз калды.

Гөлбикә. Карале! Бу ирләргә сүз бирсәң, бигрәк акыллылар икән. Әллә үзебез шуларның башына сугып миңгерәү итеп бетердек инде? Афәрин, Гыйльфан, шәп әйттең. Тик китсен Айнур Германиягә. Анда бер җыр өчен мең доллар түлиләр, бездәге кебек тиеннәр түгел.

Гыйльфан. Әй, теләсә ни эшләгез. Егет кенә жәл. Апа, монда бөтенесе дә ачыкланды. Мин китим инде Сибайга!

Айсылу. Үтерә инде шул Сибае белән! Җитте сиңа! Иртәгә барырсың!.. Бүген туй! Аңлыйсыңмы шуны, юкмы? Ярый, булды. Күп сүз китапка яхшы. Чит кешеләрнең сүзе кирәкми безгә. Әти-әниләр, хәл иттек! Өйләнешәләр һәм китәләр Германиягә! Бетте! Вакыт аз калды! Таралышабыз!

Камил. Тукта, кодагый, Германия хәл ителмәгән әле.

Хәлимә. Камил, алай димә. Китсен Айнур Германиягә. Китсен. Ул талантлы! Гөлбикә дөрес әйтә, монда аның таланты әрәм була, юкка чыгачак. Аны көнләшеп бетерәчәкләр. Ә Германиядә чәчәк атачак, немецлар талантны таба да, күтәрә дә белә. Үтенеп сорыйм, җибәр аны Германиягә. Зинһар өчен!

Айсылу. Кодагый, тукта әле. Кода, җибәрмим, дип әйтмәде бит. Нигә шулай бетеренәсең?

Хәлимә. Мин күрәм, Камил җибәрмәскә тели. Ә ул, җибәрмим, дисә – бетте! Без шушында үлик, шартлыйк – берни дә эшли алмаячакбыз!

Айсылу. Кода җүләр түгел. Улының язмышын сындырмас, зур, бай кеше булып китүенә каршы килмәс, монда кадерсез ятарга юл куймас. Кода, әйт сүзеңне!

Камил урыныннан тора.

Гөлбикә *(телефоннан сөйләшә)*. Алло, тыңлыйм... Аңладым! Гыйльфан, йөгер подвалга! Бер кеше кирәк ярдәмгә. Срочно! Бар!

Гыйльфан. Юк! Бармыйм!

Гөлбикә. Нигә? Мин бит сине!.. Эштән куам!

Гыйльфан. Ку! Куып кына калма, аер! Башка РДКаңа аяк басмыйм!

Гөлбикә. Ах, шулаймы? Аерырмын менә! Ныклап бәйләп куям! Беркая да китә алмассың!

Гыйльфан. Гөлбикә, алай итмә. Үтенеп сорыйм, җибәр мине!

Айсылу. Җитте сезгә! Сөйләшергә бирмисез!

Ут сүнә.

Дүртенче күренеш

Бүлмә. Айнур белән Рушания керә.

Айнур. Оят түгелме сиңа?

Рушания. Оят.

Айнур. Шулай булгач, нигә килдең монда?

Рушания. Сиңа кияүгә чыгарга.

Айнур. Мин шаярмыйм, чынлап сорыйм.

Рушания. Мин дә чынын әйтәм.

Айнур. Димәк, боларның барысын да син оештыргансың?!

Рушания. Мин оештырдым. Шуннан?

Айнур. Белеп тор: без беркайчан да өйләнешмәячәкбез!

Рушания. Беләм. Тик ничек?

Айнур. Нәрсә «ничек»?

Рушания. Ничек итеп син миңа өйләнмәссең?

Айнур. Баш тартам! Һәм бетте!

Рушания. Бик батыр кыланасың. Ә нигә тегендә телеңне йоттың?

Айнур. Синең әниең!.. Каян белә ул минем РДКага, Гыйльфан абзыйның кабинетына барып йөргәнне?

Рушания. Әйтте ич: вахтёр күргән. Икенчедән, онытма, Гыйльфан абый әниемнең бертуган энесе.

Айнур. Ничек китереп куйды! Югыйсә утырта идем икегезне дә урыныгызга! Нигә син, Гыйльфан аганың кабинетына йөрмәдем, дип әйтмәдең?

Рушания. Ә нигә син әйтмәдең?

Айнур. Чөнки... Ничек котылырга соң бу хәлдән?

Рушания. Менә чыккач та әйт: «Мин Рушанияне яратмыйм! Яратмаган кызга өйләндерергә хакыгыз юк!» – диген.

Айнур. Эх! Син минем әтине белмисең! Ул әйтсә, трактор белән дә кузгатып булмый!

Рушания. Трактор да ярдәм итмәгәч, яратмаган кызга өйләнергә туры килер.

Айнур. Юк-юк! Бу гадел түгел! Мин сиңа боерам! Мин бит сине яратмыйм! Баш тарт миннән! «Чыкмыйм аңа!» – диген.

Рушания. Синең атаң трактор булса, минем әнием – танк! Әйтте – өзә!

Айнур. Нәрсә, ул сине миңа көчләп бирә димәкче буласыңмы?

Рушания. Алай ук димим. Чөнки моны бит мин оештырдым. Әмма хәзер инициативаны әнием үз кулына алды. Ул син дип үләргә әзер.

Айнур. Мине шулкадәр ошаттымы?

Рушания. Юк, куралмый. Эшсез, пешмәгән, ди һәм башкалар.

Айнур. Алай булгач, нигә?

Рушания. Гашыйк булган.

Айнур. Аңламадым. Миңамы?

Рушания. Юк. 300 мең долларга.

Айнур. Бу бит!.. Акча, байлык дип кияүгә чыгу! Андый гаиләләр, син бит беләсең, бәхетсез була.

Рушания. Кем әйтә?

Айнур. Кайдадыр укыдым.

Рушания. Дөрес түгел. Акчалы гаиләләр... әйбәт яши. Бу яктан мин әнием белән килешәм.

Айнур. Димәк, син дә шул акча аркасында миңа ябыштыңмы?

Рушания. Юк.

Айнур. Мин сиңа... ошыйммы?

Рушания. Миңа хәзерге вакытта курсыбыздагы өч егет ошый. Алар арасында син юк.

Айнур. Алай булгач, нигә оештырдың бу комедияне?

Рушания. Синең белән Германиягә китү өчен.

Айнур. Коточкыч! Хәзерге кызлар шундый дип ишеткәнем бар иде. Тик бу кадәр!.. Һәм син! Рушания, алай ярамый. Син бит әле яшь, матур! Яраткан кешеңне очратырсың. Аңа кияүгә чыгарсың һәм бәхетле булырсың. Германия ул – буш нәрсә! Пшик! Шуның аркасында үзеңне бәхетсез итмә!

Рушания. О! Германия! Мин һәрвакыт чит илдә яшәргә хыялландым! Юк! Германиягә киткән кеше бәхетсез булмый.

Айнур. Син бит яратмаган кеше белән яшәргә җыенмыйсың!

Рушания. Булсын. Бөтен хатын-кызлар да яратмаган кеше белән яши.

Айнур. Ничек?

Рушания. Хатын-кызга нәрсә кирәк? Егетнең өе, акчасы булсын, эчмәсен, сугышмасын...

Айнур. ...Озын буйлы, мыеклы, бөдрә чәчле...

Рушания. Юк! Андыйларга гашыйк кына булалар. Тик кияүгә чыкмыйлар. Чөнки аларның акчасы булмый.

Айнур. Алдашасың! Бар кызлар да матурларга кияүгә чыгарга хыяллана!

Рушания. Син кызларны җүләргә санйысың. Алар матурларны ташлыйлар, шуннан төне буе елап чыгалар һәм яратмаганнарга, әмма акчалы, бай егетләргә чыгалар.

Айнур. Синең дә гашыйк булган егетең бар идеме?

Рушания. Әлбәттә. Кичә аны ташладым. Бүген төне буе еладым. Ә хәзер сиңа кияүгә чыгам.

Айнур. Юк! Миңа мондый кәләш кирәкми.

Рушания. Аны миңа әйтмә, әтиең белән минем әнигә әйт.

Айнур. Алар бит... Нәрсә эшләргә соң? Нәрсә эшләргә?

Рушания. Ярый, тынычлан. Өйләнешәбез дә Германиягә китәбез.

Айнур. Бармыйм мин бернинди дә Германиягә! Точно! Мин баш тартам Германиядән! 300 мең доллардан! Мин баш тартам! Ишетәсеңме?

Рушания. Ишеттем. Шуннан?

Айнур. Бармыйм Германиягә! Юк 300 мең доллар! Так что мин хәерче кияү!

Рушания. Ә бәлки, син алдыйсыңдыр. Мин синнән баш тартырмын. Шуннан син Германиягә китәрсең дә барырсың.

Айнур. Юк! Ант итәм, китмим. Мин бу хакта чакыру кәгазе алгач та уйлый башладым. Чөнки... Анда җырсыз мин ничек яшәрмен?.. Германия бүген мине музыкадан аерырга теләүче бер кара көч кебек. Мине бит болай да әтием бәләкәйдән музыка белән шөгыльләнүдән тыйды. «Музыка» сүзен ишетергә дә теләми. Әйтсәң ярсый да китә, тик торганда ачуланып ташлый. Ә мин музыканы яратам, ансыз яши алмыйм. Әти каршы булгач, музыка мәктәбен дә — читтән торып, сәнгать училищесын да аннан яшереп тәмамладым. Хәер, яшермәдем дә. Ул иртә таңнан караңгы төшкәнгә кадәр эштә. Минем нәрсә белән шөгыльләнгәнемне күрмәде дә, белмәде дә. Әнием дә көне буе эштә. Бәләкәй чакта мәктәптән кайткач, Гөлбикә апа янында РДКада була идем. Үсә төшкәч, көне буе өйдә ялгызым. Әй күңелсез була торган иде. Нигә минем энем яки сеңлем юк микән дип уйлый идем. Хәтта үз-үземә, зурайгач, биш балам булачак дип сүз биргәнем хәтеремдә. Аннары, улым яки кызым берәр әйбер сораса, шунда ук алып

бирәчәкмен дип хыяллана идем. Чөнки музыка белән мавыга башлагач, әтиемә, гитара сатып алып бир миңа, дигән идем. Ул мине ачуланып ташлады. Әнә шунда ул тәүге тапкыр «музыка» сүзен әйтүдән тыйды.

Рушания. Өегездә чынлап та бер музыкаль әйбер дә күренми. Ә музыка белән кайда шөгыльләнәсең соң?

Айнур. РДКада, Гыйльфан абыйның кабинетында. Кечкенәдән аңа йөрдем. Ул бик талантлы музыкант. Холкы гына бигрәк йомшак...

Рушания. Аның урынына апасының, минем әниемнең холкы начар. Ул икесенә тиешле усаллыкны берүзенә алгандыр. Син әтиең турында сөйләгән чакта, минем күз алдымда әнием торды. Ул да шундый бит. Мин бәләкәй чакта, миңа сеңел кирәк, дигән идем, шундый итеп сүкте, башка ул хакта уйларга да курыктым. Аннан әтием дә, мин дә куркабыз. Чын. Әнием кычкырса, әллә нәрсә эшлим дә куям. Башым бөтенләй эшләми башлый. Әллә гипнозлый шунда. Менә бүген практикадан кайтып төшкән идем, әйдә киттек, Айнурга кияүгә чыгасың, ди. И всё! Бармаска тырышам, ә ул, ачуланып, куркытып, алып килде барыбер. Җитмәсә, авырлы булып кылан дип, эчемә мендәр бәйләп куйды. Коточкыч бит.

Айнур. Ха-ха-ха! Авырлы булганда син бик мәзәк идең. Мин ышандым хәтта.

Рушания. Ничек ышандың? Бүген иртән вокзалда күргәндә мин авырлы түгел идем бит.

Айнур. Мин каян белим? Бәлки, авырлы хатыннарның эче кинәт шулай зураядыр.

Рушания. Бигрәк беркатлы инде син... Ә әтиең синең көйләр язуыңны, вокаль-инструменталь төркемең барлыгын, концертлар куеп йөрүеңне беләме соң?

Айнур. Каян белсен? Ул хәтта минем музыкаль инструментта уйнавымны да белми. Өйдә бернәрсә дә юк бит. Кайвакыт өйдә булганда күңелдә бер көй туа. Шул вакытта, беләсеңме, нәрсәдә уйныйм? Менә кара!

Рушания. Нәрсә болар?

Айнур. Бокаллар, фужерлар, рюмкалар! Мин кечкенә чакта ук аларда уйнарга өйрәндем. Менә шулай тезеп куям, һәркайсының үз нотасы бар. Шушы таяклар белән сугам... Һәм көй туа. Ишетәсеңме?

Рушания. Таныш көй.

Айнур. Син бу җырны беләсеңме?

Рушания. Мин хәтта сүзләрен дә беләм. Без кызлар белән аны еш кына җырлыйбыз. *(Җырлый.)*

Әллә нигә кайчак мине
Һич беркем дә аңламый.
Туганнар да, дусларым да
Мин әйткәнне тыңламый.

Икесе бергә *(җырлыйлар).*

Аңламасалар сине,
Тыңламасалар сине,
Балконга чык та сызгыр,
Бар кайгыларың узар!

Айнур. Ишетмәсләрме икән дип,
Мин кычкырып карадым!
Ишеттерәм барыбер дип,
Әйберләрен урладым!

Икесе бергә *(җырлыйлар).*

Аңламасалар сине,
Тыңламасалар сине,
Балконга чык та сызгыр,
Бар кайгыларың узар!

Рушания. Аңлаучылар булмаганга,
Качып киттем урманга!
Анда ялангач йөримен,
Мин ялгызым булганда.

Икесе бергә *(җырлыйлар).*

Аңламасалар сине,
Тыңламасалар сине,
Балконга чык та сызгыр,
Бар кайгыларың узар!

Рушания. Әйбәт җыр! Шуны җырласаң, күңелдәге бар әрнү беткәндәй була.

Айнур. Гыйльфан абый да мактады, шушы җырны язгач. «Сиңа чынлап та композитор булырга кирәк»,— диде. Мин аңа бик рәхмәтлемен. Музыкада ирешкән уңышларым барысы да аның аркасында. Тик нигәдер әтием шуны күралмый.

Рушания. Мин беләм. Әйтимме? Гыйльфан абый әниеңнең тәүге мәхәббәте булган. Әтиең шуны гафу итә алмый. Әниең һаман да аны уйлап йөри икән дип ачулана. Көнләшә. Гыйльфан абый музыкант, композитор булгач, музыканы күралмый.

Айнур. Аңлашыла...

Рушания. Мәхәббәт чынлап та бар микән?

Айнур. Белмим. Минем беркемне дә яратканым юк.

Рушания. Минем дә юк. Шуңа «мәхәббәт» дигән тойгы да юктыр кебек. Аны шагыйрьләр, композиторлар, җырчылар уйлап кына чыгаргандыр сыман. Матурлык өчен.

Айнур. Син бит яңа гына, бер егетне ярата идем, кичә ташладым, бүген төне буе елап чыктым, дигән идең.

Рушания. Шулай булса, матур бит инде. Кызганыч хәтта. Кинодагы кебек. Тик юк шул. Эләкмәде миңа андый бәхет.

Айнур. Уф! Кинәт кенә җиңел булып китте.

Рушания. Мине беркем дә яратмагангамы?

Айнур. Әйе.

Рушания. Эх, эгоист! Безне онытуылар шикелле. Ничә минут үтте?

Айнур. Ярты сәгать.

Рушания. Унбиш минут бирәбез, дигәннәр иде... Хәзер, чыккач, нәрсә дибез?

Айнур. Белмим.

Рушания. Әгәр ирек бирсәләр, теләсәң бар, теләмәсәң барма Германиягә дисәләр, син нишләр идең?

Айнур. Минме?.. Ул чактамы? Юк, бу мөмкин түгел.

Рушания. Нигә мөмкин түгел? Нәрсә эшләр идең? Әйт.

Айнур. Юк-юк! Әйтеп тә тормыйм, алай булмый.

Рушания. Аңладым мин сине. Үз иркеңә куйсалар, китмәс идең Германиягә. Музыка белән шөгыльләнер идең, көйләр язар идең. Шулаймы?

Айнур. Әйе, Рушания, дөрес! Хәтта мин, беләсеңме, бу институтны ташлар идем дә сәнгать институтының композиция бүлегенә укырга керер идем. Тс-с! Тик берәүгә дә әйтмә. Бу хыял гына. Тормышка ашмас хыял.

Рушания. Айнур! Син боларны чын күңелдән әйтәсеңме?

Айнур. Иң яшерен хыялым. Хәтта Гыйльфан абыйга да әйткәнем юк. Ул үзе кайчак әйтеп куя, сиңа композиторлыкка укырга кирәк, дип. Тик кайда укырга икәнен әйтми.

Рушания. Ә фән? Безнең институт? Сине бик талантлы, зур галим булачак диләр.

Айнур. Әйе, миңа бөтен җирдә шулай диләр. Кечкенә чакта футболга йөргән идем, анда, зур спортсмен буласың, дигәннәр иде. Йөзүгә йөрдем — анда да шул. Рәссамнар түгәрәгенә йөрдем — шул ук сүзләр. Ташлыйм дисәм, җибәрми аптыраталар. Мин бит бөтен җиргә дә чәчелә алмыйм. Музыканы гына яратам. Көйләр язасым килә. Күңелемдә көненә йөз көй туа. Язып кына өлгер. Башка бернәрсә дә эшлисем килми. Ә фән эшен бөтенләй яратмыйм. Кушкач йөрим инде. Бигрәк тә әтием мәҗбүр итә. Минем кебек цехта черемәссең, галим булырсың, ди.

Рушания. Айнур! Син бит үзеңне гомерлеккә бәхетсез итәргә йөрисең! Сиңа бу институтны ташларга кирәк.

Айнур. Әтием рөхсәт итмәячәк.

Рушания. Синең бит язмышың, бәхетең хәл ителә! Әгәр гел әти-әниләрдән куркып яшәсәк, бездән кем чыгар? Әйдә, без икәүләп аларга... сугыш игълан итәбез!

Айнур. Ничек?

Рушания. Икәүләшеп өйләнешү турында бер фи-

кергә килик тә шуны алга сөрик. Юк, башта син әтиеңә, мин Германиягә бармыйм, дип әйтергә тиеш. Бу институтны ташлыйм. Сәнгать институтына укырга керәм. Композитор булам.

Айнур. Ул мине үтерәчәк.

Рушания. Үтермәс. Ачуланыр. Ә син каршы тор. Аңлат. Исбат ит. Нык бул.

Айнур. Юк-юк! Аңлатмыйм да, каршы да тормыйм. Ул барыбер аңламаячак. Бу хакта бетте.

Рушания. Эх син!.. Мин сине егет дип уйлаган идем.

Айнур. Син минем әтине белмисең.

Рушания. Алайса, ичмасам, өйләнешүгә каршы чыгыйк. Теләсә нәрсә эшләгез, өйләнешмибез, диик. Чөнки без бер-беребезне яратмыйбыз. Яратышмаган кешеләрне өйләндерергә хакыгыз юк! Безне бәхетсез итәргә хакыгыз юк! Әйдә шулай дип әйтәбез.

Айнур. Син әйт. Ә мин: «Рушаниягә кушылам»,— дип кенә әйтермен.

Рушания. Ярый! Мин әйтермен. Тик әни бер кычкырса, каушап төшүем бар. Туктап калсам, син дәвам итәрсең, ярыймы?

Айнур. Әтием кычкырса, мин дә туктап калам.

Рушания. Ул чакта яңадан мин дәвам итәрмен. Шулай итеп алмашлап әйтеп бетерербез. Ярыймы?

Айнур. Ярый.

Рушания. Шуннан алар безне аңларлар да: «Ярый алайса, өйләнешмәгез! Ничек телисез, шулай яшәгез!» — диярләр. Бүген булачак туйны туктатырлар. Шуннан иртәгә без кире практикага китәрбез. Һәм элекке кебек курсташлар гына булып калырбыз. Ничек әйбәт булачак, әйеме?

Айнур. Әйе.

Рушания. Кинәт кенә күңелсез булып китте. Синең берәр сагышлы җырың бармы?

Айнур. Бар. Күп алар.

Рушания. Җырла әле берәрсен. Нигәдер елыйсы килә.

Айнур (*җырлый*).

Мәхәббәтне күптән көтәсеңдер,
Ул килми дә килми нигәдер.
Ашыкмачы, йөрәк, мәхәббәт бит
Килер вакытларын беләдер.

Килер, килер ул мәхәббәт,
Көтә генә аны бел.
Ярың күптән юлга чыккан,
Сине эзләп килә ул.

Көткән чакта елыйсылар килер,
Бөтен дөнья булыр караңгы.
Йөрәк әйтер, әллә көтеп тормый
Йөгереп лә каршы барасыңмы?

Көтә белгәннәргә түзем кирәк,
Түземлегә килер сөюе.
Килгәч сагышларны оныттырыр
«Мин сагындым сине» дию.

Рушания. Айнур, син... шундый талантлы!

Айнур. Рәхмәт! Ә син... шундый матур!..

Ут сүнә.

Бишенче күренеш

Зал. Сәхнәдә Айсылу, Камил, Хәлимә, Хәмит, Гөлбикә, Гыйльфан.

Айсылу. Кода, әйтсәң әйт тә. Вакыт тар. Озакка сузма.

Камил. Монда озакка сузасы юк. Айнур Германиягә... китми!

Айсылу. Кода! Ни сөйлисең?! Ничек «китми»?

Хәлимә. Камил, яхшылап уйладыңмы? Мондый тәкъдим гомергә бер була.

Хәмит. Дөрес, кода! Германия – безнең потенциаль дошман!

Камил. Германиягә китсә, алар безнең язмышны кабатламаячак. 300 мең долларны бушка бирмиләр. Алар Айнурның соңгы тамчы канына кадәр суыра-

чаклар! Баласыз яки бер балалы гаилә, көне-төне эш! Балаларын рәтләп күрмәячәкләр. Бервакыт ни өчен яшәгәннәрен аңламый башлаячаклар һәм бәхетсез кешегә әвереләчәкләр. Беркая да китмиләр!

Айсылу. Тукта, кода! Бу ни дигән сүз? Син безнең башны бутама. Без монда, Айнур Германиягә китә дип, кызыбызны җитәкләп килдек. Туйны бүгенгә күчердек. Германия юк икән, нигә бу базар? Кирәкми безгә Германиясез кияү! Юк, кода, нык итеп уйла! 300 мең доллар! Ул бит безнеңчә 6 миллион сум дигән сүз! Китсеннәр, кода, китсеннәр Германиягә. Туктатасы булма!

Камил. Кеше үз җирендә яшәргә тиеш. Яшәсен шушында. Гаиләсе өчен, итәк тулы балалары өчен, үз җире өчен. Кешегә шушыннан да олы бәхет юк. Бу – кешелекнең төп мәгънәсе. Төп миссиясе!

Айсылу. Кода! Син үзең ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы? Бу бит әкият! Балалар әкияте! Яшәү өчен акча кирәк! Өй! Моны һәркемгә дә бирмиләр. Айнурларга бирәләр. Мә, дип торалар немецлар! Шуны сузылып кына алырга кирәк! Шуңа акылыбыз җитмәс микәнни? Кодагый, нигә эндәшмисең? Әйт берәр сүз!

Хәлимә. Ул мине тыңламый.

Айсылу. Юк, кода, мин бу җүләрлеккә каршы. Айнур белән Рушания Германиягә китә. Үлсәм үләм, аларны җибәрәм. Бу – гомергә бер була торган шанс. Кулдан ычкындырсак, без – ахмак, дурак, дундук! Соңыннан гомер буе үкенәчәкбез. Бетте. Германиягә китәләр.

Камил. Мин әйттем. Китмиләр!

Айсылу. Син аларны ничек туктатасың? Ничек? Мин үзем барам ректорга. Атасы җүләрләнгән, дим. Тыңламагыз аны, дим.

Камил. Мин Айнурга, Германиягә бармыйсың, дип әйтәм. Һәм ул бармый.

Айсылу. Бу нинди сумасшедший дом?! Хәмит! Гөлбикә! Әйтегез шуңа! Аңлатыгыз! Ярамый алай. Бу бит балаларның бәхете. Аларның язмышы белән уйнарга ярамый.

Гөлбикә. Чәбәләнмә. Файдасыз. Җизни әйтте икән, бетте. Айнур Германиягә бармый.

Айсылу. Ышанмыйм! Юк! Хәзер балаларны чакырып, үзләреннән сорыйбыз. Алар, китәбез, ди икән, синең хакың юк туктатырга! Мин милициягә барам. Нарушение прав человека, дим. Шуның представителенә барам. Барыбер җибәрәм Германиягә! Айнур! Рушания! Чыгыгыз! Нигә ябыштыгыз шул бүлмәгә?! Чыгыгыз, дим!

Рушания белән Айнур керә.

Йә, нәрсә сөйләштегез анда? Без хәл иттек. Сез өйләнешәсез. Иртәгә – Мәскәүгә, шуннан Германиягә китәсез. Сез дә шулай уйладыгыз, әйеме? «Әйе» булырга тиеш! Йә?

Камил. Кодагый, тукта!

Айсылу. Тик тор! Әйтегез сүзегезне! Тик монда мин әйткәнгә каршы икән... карагыз аны! Йә? Ни сөйләштегез анда? Сәгать буе? Кода, тавыш!

Рушания. Айнур, син әйт. Хәзер сиңа әйтергә кирәк. Соңыннан соң була.

Айнур. Әти, әни...

Айсылу. Йә, йә? Шуннан?

Камил. Тыңлыйбыз сине.

Рушания. Айнур! Егет бул! Курыкмый әйт сүзеңне.

Айнур. Әти, әни! Мин быел сәнгать институтына укырга керәм. Композиция бүлегенә.

Гыйльфан. Айнур! Молодец!

Хәлимә. Улым!..

Айсылу. Нәрсә дидең? Аңламадым.

Хәмит. Германиягә китми!

Камил. Причём монда сәнгать институты?

Гөлбикә. Ну коендырды! Хәзер ураган булачак!

Айнур. Әти, син белмисең... Монда синең гаебең юк. Эшең бик авыр, вакытны күп ала, иртә белән китәсең, соңлап кайтасың. Ял көннәрендә дә эшлисең. Цех начальнигы, планны үтәргә кирәк...

Камил. Нәрсә юкны такылдыйсың? Причём монда сәнгать институты, дип сорыйм мин синнән.

Айнур. Әти!.. Мин...

Рушания. Айнур, курыкма, әйт! Аңлат!

Айнур. Әти!.. Син белмисең... Мин – музыка мәктәбен, соңыннан, читтән торып, сәнгать училищесын тәмамладым. Мин... музыка белән шөгыльләнәм...

Рушания. Камил абый, Айнур шундый матур җырлар яза! Җырлап күрсәтимме? *(Җырлый.)*

Капкалардан чыгу белән
Китә юлның чатлары.
Бар юлларның ялгышлысы,
Бар юлларның хаклысы.

Юллар чаты, юллар чаты,
Кайсы юлдан китәргә?
Ничек итеп тормыш юлын
Адашмыйча үтәргә?

Кайсы юллар түбән илтә,
Икенчесе үрләргә.
Әти-әни әйткәннәре
Дөрес юлны күрсәтә.

Камил. Бу җырны син яздыңмы?

Айнур. Әйе. Минем йөздән артык җырым бар, әти!

Камил. Нигә мин моны белмим? Хәлимә, синнән сорыйм. Син беләсеңме боларны?

Хәлимә. Камил, без сиңа кат-кат әйтергә маташтык. Тик син «музыка» сүзен ишетергә дә теләмәдең. Әйтү белән безне сүгә башлый идең.

Айсылу. Кода, кодагый! Без читкә киттек.

Камил. Тукта әле! Бу сәнгать институты да синең идеяме?

Хәлимә. Юк. Бу хакта мин үзем дә беренче тапкыр ишетәм. Мин моңа каршы. Айнур, музыка мавыгу гына булырга тиеш. Яшәү өчен җитди профессия кирәк.

Камил. Ул хакта музыка мәктәбенә йөргәндә уйларга кирәк иде. Бу институт белән нишләргә җыенасың?

Айнур. Читтән торып тәмамлыйм.

Камил. Ташлыйм дисәң, маңгаеңа берне тарта идем. Музыка... Тфү!

Айсылу. Дөрес, кода, дөрес! Кирәкми музыка!

Камил. Ул сиңа шулкадәр кирәкме?

Айнур. Әти, кирәк, бик кирәк! Кеше күңеле, йөрәге яраткан һөнәрне сайларга тиеш. Шул чакта гына ул бәхетле! Ә мин музыканы яратам, әти! Минем төркемем бар. Каршы булма, зинһар. Мин ике институтта да укыйм.

Хәмит. Була бу егеттән, барысы да була. Айнур, ташла ул музыканы, давай армиягә! Менә дигән офицер чыгачак синнән!

Айсылу. Ташлап тор әле шул армияңне!

Камил. Композитор! Әнә тора бер талантлы композитор! Ни өе юк, ни акчасы, ни баласы. Айнурга шуны телисеңме?

Хәлимә. Гыйльфан... ир түгел инде ул. Айнур – икенче, сиңа охшаган. Максатына ирешә белә.

Гыйльфан. Мин сәнгать өчен яшим!

Айсылу. Кода!

Камил. Ну Айнур! Ярый, бүген мин юмарт – туй көне! Бу институтны тәмамлап, диплом аласың, галим буласың. Кара аны! Вакытында тәмамламасаң, галимлеккә бармасаң, сәнгать институтын мәңге күрә алмаячаксың! Ишеттеңме?

Айнур. Ишеттем, әти. Мин сүземдә торачакмын!

Хәлимә. Мин шундый курыккан идем. Рәхмәт, Камил.

Айсылу. Шуннан? Ә Германия нишли? Барасызмы?

Айнур. Юк, Айсылу апа, бармыйбыз!

Рушания. Әни, кирәкми безгә ул Германия.

Айсылу. Яп авызыңны! Германиягә бармасагыз, туй булмый! Мин кызымны кулыннан эш килмәгән малаегызга бирмим. Рушания, киттек! Менә дигән кияү табам мин сиңа! Әйдә!

Рушания. Әни! Мин китмим!

Айсылу. Нәрсә? Әниеңә каршы эндәшәсең? Хәзер бит мин сине!.. А ну-ка киттек!

Рушания. Әни! Мин Айнурга кияүгә чыгам! Безнең дүрт балабыз була!

Хәмит. Вәт молодчина!

Айсылу. Җүләр! Сиңа мин хуҗа әле! Кил монда!

Айнур. Тимәгез минем кәләшкә! Мин Рушанияне сезгә бирмим!

Айсылу. Кызым, бәләкәчем! Мин хәзер сиңа кирәкмиммени? Миңа хәзер нишләргә соң?.. Ялгызым...

Хәмит. Матурым, тынычлан.

Хәлимә. Хәзерге яшьләр нинди акыллы! Үзләренең пар килгәннәрен шунда ук аңладылар. Ә без күпме ел яшәп...

Хәмит. Хәлне үзгәртәбез хәзер! Яшьләрдән үрнәк алырга! Кире өйләнешергә!

Камил. Кода, стоять! Монда дәртләндерүче стимул җитешми. Тыңлагыз! Хәлимә! Мин нигә уенчыклар, тәрбия хакында китаплар алган дисең? Мин детдом белән сөйләштем, ике бала алабыз тәрбияләргә. Өч һәм биш яшьлек! Синең ризалыгың кирәк.

Хәлимә. Риза! Кил, үзеңне бер үбим.

Хәмит. Айсылу?!

Айсылу. Хәмиткәем! Без дә алабыз!

Хәмит. Кил, үбим! Төкердем гарнизонына! Иртәгә үк гариза язам, пенсиягә китәм. Икәүләшеп бала карыйбыз.

Гөлбикә *(телефоннан)*. Алло! Тыңлыйм! Подвалдагы эшне бетергәннәр. Рәхмәт сиңа, җизни!

Камил. Балдыз, уенчыклар бүләк иттем, сез дә бала алыгыз!

Гөлбикә. Юк инде. Кеше баласын түгел, үземне дә, иремне дә карарга вакыт юк. Бездән гаилә чыкмас. Гыйльфан, куан! Бирәм мин сиңа ирек!

Гыйльфан. Ура! Рәхмәт, Гөлбикә! Мин Сибайга китәм.

Камил. Ә хәзер барыбыз да туйга!

Барысы бергә. Туйга! Туйга!

Күмәк җыр.

Пәрдә. *2002*

АТЫ БАРНЫҢ ДӘРТЕ БАР

Комедия, ике пәрдәдә

Катнашалар:

Котлыбай – 80 яшьтә.
Сатыбал – 80 яшьтә.
Закирҗан – 60 яшьтә.
Балбикә – 80 яшьтә.
Шәмсебикә – 80 яшьтә.
Октябрина – 58 яшьтә.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ике якта ике авыл өе. Уртада ике ишегалдын бүлгән койма. Өеннән атылып Котлыбай килеп чыга. Аңа карчыгы Балбикә ияргән.

Котлыбай. Мин моңа ышанмыйм! Син алдыйсың! Кайда ул? Кайда?

Балбикә. Котлыбай, тынычлан...

Котлыбай. Мин санаторийдан кайтып киләм. Хәзер Акбүз атымны күрәм дип... Ә ул юк!.. Юк! Акбүз атым юк! Син бит минем канатымны сындырдың! Җанымны йолкып алдың!

Балбикә. Тукта әле, тукта...

Котлыбай. Дошман! Син мине үтерер өчен эшләгәнсең моны! Акбүз ат! Районда икенче ат. Кемгә саттың?..

Балбикә. Мин бит сине уйлап...

Котлыбай. Кемгә саттың, дим! Кемгә? Ичмасам, ат күргән кешеме? Кемгә?

Балбикә. Белмим.

Котлыбай. Ничек белмисең? Кемгә сатканыңны белмисеңме?

Балбикә. Әйе.

Котлыбай. Юк, син беләсең! Алдашасың! Бар! Теләсәң кайдан алып кайт атны! Бар! Бар, дим! Акчасын илт тә алып кайт!

Балбикә. Аның акчасы... бетте.

Котлыбай. Нәрсә? Ничек «бетте»? Кайда куйдың?

Балбикә. Бер атна элек Октябринаның улына, оныгыбызга, кырык яшь тулды...

Котлыбай. Миңа димәгәе, йөз тулсын! Ат, ат кайда?

Балбикә. Юбилеена матай бүләк иттем.

Котлыбай. Матай? Ат акчасынамы?

Балбикә. Әйе. Икебезнең исемнән.

Котлыбай. Җүләр! Ахмак! Юк! Мин берни дә белмим. Белергә дә теләмим. Бар, матайны кире ал да сат! Акчасын илт тә Акбүз атымны алып кайт! Бар! Бар, дим!

Балбикә. Котлыбай!

Котлыбай. Дәшмә миңа. Тиз бул!

Балбикә. Аны алып кайтып булмый.

Котлыбай. Ничек? Ни өчен?

Балбикә. Ул кеше атны...

Котлыбай. Нәрсә? Нәрсә дидең? Әйтеп бетер!

Балбикә. Суяр өчен...

Котлыбай. А-а! А-а! Дәшмә! Ни өчен? Тавышыңны чыгарма! Мәхлук! Йа Ходаем! Ни ишетәм мин? Акбүз атны! Өлгернең токымын! Ит өчен!.. Әй Аллам! Нигә миңа мондый җәза бирдең? Нинди гөнаһым бар синең алдыңда? Ходаем, бу сүзләрне ишеттергәнче үтер мине!

Балбикә. Котлыбай!..

Котлыбай. Кит! Кит, дим! Син моны юри эшләгәнсең! Мине үтерер өчен! Куан! Максатыңа ирештең! Мин үләм.

Балбикә. Котлыбай, нәрсә сөйлисең?.. Тукта, кая киттең?

Котлыбай. Син бит гомер буе шул ат өчен миңа кырын карадың. Янәсе, ат диеп, сине, балаларны

күрмәдем. Җүләр! Сезне ат ашатты, эчерде, шуны аңлыйсыңмы? Иң авыр елларда ат аркасында исән калдыгыз бит сез! Ә хәзер... син үтердең аны! Аттан котылдың, шуңа Котлыбайсыз да калачаксың! Япаялгыз! Шул кирәк сиңа! Явызлыгыңа күрә таман!

Балбикә. Котлыбай, алай димә, зинһар!..

Котлыбай. Якын килмә! Бар, рәискә әйт: кабер казысыннар. Кайтышлый мулланы чакыр. Ясин укырга. Иярмә! Тыныч үләргә бир!

Котлыбай өйгә кереп китә.

Балбикә. Йа Алла! Чынлап сөйлиме бу? Бәлки, куркытырга гына телидер? Юк, ул гомер буе сүзендә торды, ни дисә, шуны җиренә җиткерде, әй Ходаем! Үлә инде болай булгач, үлә! Ни эшләргә соң хәзер? Мулла чакырыйммы икән?

Октябрина керә.

Октябрина. Исәнме, әни!

Балбикә. Исәнме, Октябрина! Исәнме, кызым! Бик яхшы булды килүең...

Октябрина. Әти кайттымы?

Балбикә. Кайтты, кайтты, кайтмый кая барсын?

Октябрина. Шуннан? Нәрсә ди?

Балбикә. Әй Ходаем! Күрәселәрем бар икән!..

Октябрина. Нәрсә, нык ачуланамы?

Балбикә. Менә дигән бия иде бит! Кымызы каймак кебек иде! Әйттем мин сиңа: «Сатма! Сатма! Әтиең гафу итмәс!» – дип. Юк, тыңламадың!..

Октябрина. Бөтен кирелеге өчен үч алдым. Мине пенсиясез калдырган өчен яшәсен атсыз!.. Тик син, әни, әлегә әйтми тор, Октябрина сатты дип... Бәлки, акылга утырыр да...

Балбикә. Үзем саттым, дидем инде болай да. Тик ул шушы хәлләрдән соң берәрсенә изгелек эшләр дисеңме?

Октябрина. Нигә эшләмәсен? Ул бит минем нинди хәлгә калганымны күрә!

Балбикә. Изгелекне бары тик игелек кенә тудыра ул, кызым. Ә явызлыкны фәкать явызлык кына. Әнә, үләм дип, өйгә кереп китте.

Октябрина. Үлсен! Аңа шул кирәк!

Балбикә. Кызым! Ул бит синең әтиең!

Октябрина. Әти, имеш... Әти булса... Миңа тиздән алтмыш яшь! Һаман пенсия алмыйм! Шуны җайлар иде.

Балбикә. Кулыннан килсә.

Октябрина. Килә! Райсобес рәисе – аның фронташының улы. Әгәр җайлап кына сөйләсә: «Менә шулай, шулай, энем, кызым гомер буе артельдә эшләде. Тик андагы документлары янды. Бергә эшләгән кешеләрнең кайберләре үлгән, кайсылары әллә кая күчеп киткән, азаплама инде шуны, эшлә пенсия»,– дисә...

Балбикә. Үзең дә бит һич тә кешечә сөйләшмисең, киләсең дә эт кебек талаша башлыйсың...

Октябрина. Талашам! Чөнки җаным сызлый. Ул бит гомер буе сиңа да, безгә дә кешечә яшәргә бирмәде. Ул бит ат алкоголигы! Алкаш та бер айный. Бер генә ай булса да кешечә яши. Ә бу... Көн дә ат, төн дә ат! Кыз баланың атка атланып Сабантуйда чапканын кайда күргәнең бар? Ул бит безне шушындый вакыттан әрләптукмап атта йөрергә өйрәтте! Ә егетләр бездән көлә иде! «Атлы казак!» Гарьлегеңнән үләрсең, валлаһи! Саттым! Яшәсен атсыз! Ичмасам, карт көнеңдә сиңа тынгылык бирсен.

Өйдән Котлыбай чыга.

Котлыбай. Акбүз атым!.. Былтыр колхоз көтүенә кушканга да үпкәләгән булган иде бит, бахыркаем!.. Янына барып, кулымдагы икмәкне сузуга, башын читкә борды. Ә бит элек, бәләкәй генә сынык өчен, куанычыннан кулымны ялый-ялый, рәхмәт яудыра иде. Йортыннан аерганы өчен бик тә рәнҗегән иде... Ә монда... ит өчен. Мин хыянәт итте дип уйлагандыр инде аткаем...

Октябрина. Әти, исәнме!

Котлыбай. Өйдә ямь бетте! Кояш сүнде!..

Октябрина. Әнием сине үләргә кереп китте, дигән була.

Котлыбай. Ә-ә, үлемемне теләгән идегезме? Юк инде, ансат кына котыла алмассыз! Мин үлмим, сезгә үч итеп үлмим!

Октябрина. Бик әйбәт.

Котлыбай. Мин өйләнәм! Ишеттегезме? Өйләнәм!

Балбикә. Нәрсә?

Октябрина. Кемгә?

Котлыбай. Өйләнәм! Шәмсебикәгә! Мәрхүм Галинур дустымның хатынына! Аның аты бар! Ә синеке юк!

Балбикә. Котлыбай, ни сөйлисең? Ипләп! Кеше ишетеп калмасын!

Котлыбай. Ишетсеннәр! Барысы да белсен! Әй, кешеләр! Мин Шәмсебикәгә өйләнәм!

Тавыш. Котлыбай, ни булды?

Котлыбай. Омырзак! Мин Шәмсебикәгә өйләнәм!

Октябрина. Әти, ни эшлисең?

Котлыбай. Кит! Омырзак, әйт барысына да! Өйләнәм! Иртәгә туй!

Октябрина. Ул акылдан шашкан!

Котлыбай. Юк! Менә ул акылдан шашкан! Районда икенче атны! Өлгернең токымын! Иткә! Котылдыңмы аттан? Хәзер миннән дә котылырсың! Миңа атсыз әби кирәкми! Өйләнәм Шәмсебикәгә!

Октябрина. Әти, тукта әле! Әнием синең законлы карчыгың...

Котлыбай. Юк! Атсыз хатын законный булалмый! Шәмсебикә!

Октябрина. Әни, нәрсә карап торасың?

Балбикә. Котлыбай, куй. Карт көнеңдә кеше көлдермә. Әйдә сөйләшик...

Котлыбай. Элек атны китер! Акбүз атны! Шунсыз сөйләшү юк! Шәмсебикә, дим, Шәмсебикә! Колакка катыландыңмы әллә?

Октябрина. Оятсыз!

Балбикә. Әй Ходаем! Күрәселәрем бар икән!..

Балбикә өенә кереп китә. Күрше өйдән Шәмсебикә чыга.

Шәмсебикә. Ни булды? Кем акыра шулхәтле?

Котлыбай. Мин! Нигә озак чыкмыйсың?

Шәмсебикә. Әйрәнбикә ясап ятам бит. Аны өзәргә ярамый.

Октябрина. Нәрсә ясыйсың?

Шәмсебикә. Әйрәнбикә. Борынгыча әйтсәң, фискүлтүрә! Фигурам бозылып бара югыйсә.

Октябрина. Тфү! Фигура! «Аэробика» диген, карт тиле!

Шәмсебикә. Бәй, Котлыбай кайткан лабаса! Кайчан кайттың? Саулыгың ничек? Әйбәт дәваладылармы санаторийда?

Котлыбай. Тфү! Анда барган мин ахмак!

Шәмсебикә. Атак! Файдасы тимәдеме әллә?

Котлыбай. Дөлдөл ни хәлдә?

Шәмсебикә. Кем?

Котлыбай. Колак! Дөлдөл! Атың ни хәлдә, дим.

Шәмсебикә. Аңа ни булсын, үләт кыргырына. Галинур үлгәннән бирле нервыларымны бетерде, каһәр суккыры!

Котлыбай. Авырып киттеме әллә?

Шәмсебикә. Авырмый шул, чәчрәгере, ичмасам, авырса...

Котлыбай. Шәмсебикә! Син Дөлдөлгә сүз тидермә! Ишеттеңме?

Шәмсебикә. Атак! Нигә сүз тидерим мин аңа? Галинурымның төсе, истәлеге бит ул миңа. Иркәләп кенә әйтәм инде шунда. Атак, нигә сорашасың әле Дөлдөлне?

Котлыбай. Эш шунда, Шәмсебикә күрше, мин сиңа өйләнәм.

Шәмсебикә. Нәрсә эшлисең?

Котлыбай. Хатынлыкка алам!

Шәмсебикә. Куй, Котлыбай күрше, көлмә тол

хатыннан. Болай да ялгызым шундый дөнья белән ни эшләргә белми азапланам. Әнә Закирҗан каладан күчеп кайтырга риза түгел. Шул кош-кортны карашырга бирәр бабай табылсачы дип, көне-төне Ходайдан сорыйм...

Котлыбай. Мин бит сиңа әйтеп торам: өйләнәм! Дөньяңны да, малыңны да, үзеңне дә карыйм.

Шәмсебикә. Бик шәп булыр иде ул!

Октябрина. Җирбит! Син шуңа чыгарга ризамы?

Шәмсебикә. Атак, нишләп чыкмыйм ди? Алам дип торган кеше барда...

Октябрина. Аның бит законный хатыны бар!

Котлыбай. Бар, кайт! Бар...

Шәмсебикә. Хәзер икәү булыр. Югыйсә мондый дөнья белән эт күрмәгәнне күреләә бит.

Октябрина. Анда безнең эшебез юк! Икенче бабай тап!

Шәмсебикә. Әйе, урамга чыгарып атканнар ди. Табарсың. Кем, дөньясын ташлап, миңа күчеп килсен?

Котлыбай. Син китәсеңме моннан, юкмы?

Шәмсебикә. Әйе, бар, кит, кызым! Без үзебез какнибудь!

Октябрина. Дивана! Әтием бит сиңа түгел, атыңа өйләнә!

Шәмсебикә. Атак! Ничек атыма?

Котлыбай. Дөрес. Мин атсыз яши алмыйм. Миңа әбиле ат кирәк. Әйе, атлы әби.

Шәмсебикә. Ә-ә, шулай диген. Югыйсә котны алдыгыз. Болай булгач, Дөлдөл синеке, Котлыбай!

Котлыбай. Шәмсебикә! Рәхмәт!..

Октябрина. Оятсызлар! Әни! Әни, дим!

Өйдән Балбикә чыга.

Октябрина. Нәрсә карап утырасың анда? Бир кирәкләрен! Өйләнешәләр бит!

Балбикә. Әй, кызым, нәрсә генә эшлим соң?..

Котлыбай. Атны саткан өчен килде сиңа җәза.

Шәмсебикә. Котлыбай, тукта! Балбикә, ахирәт!.. Күреп торасың бит хәлемне. Галинурыма нигезне, дөньяны сакларга сүз бирдем, ә көчем җитми. Дөлдөлне карарга гына да дастуен ир кирәк. Ул бит гади генә ат түгел, районда берәү! Ә Котлыбай ат кадерен белә...

Октябрина. Кем куша сиңа ат тотарга? Сат та котыл!

Котлыбай. Молчайть! Бер атымның башына җиттегез, монысына кулыгыз җитмәс! Хатын! Шәмсебикә! Бер баш малыңны да сатмыйбыз! Барысы да үзебезнеке!

Шәмсебикә. Ай, рәхмәт төшкере! Сатаммы соң? Әнә Закирҗаным да шәһәрдән хат язып җибәргән: «Тиз генә Дөлдөлне сат, миңа акча кирәк!» — дигән. Дөлдөл бит ат кына түгел, алтын! Галинурымның төсе! Сатмыйм!

Котлыбай. Ай, афәрин! Шәмсебикә булсын да сатсын, имеш! Син бит җүләр түгел моның кебек!

Балбикә. Нигә күрә торып мине мыскыл итәсез? Ичмасам, үлүемне көтәр идегез. Болай да күп калмаган. Берәр айдан үләрмен. Шуннан рәхәтләнешеп...

Октябрина. Әни!.. Җансыз сез!..

Шәмсебикә. Балбикә, ахирәткәем! Син каршымыни аның өйләнүенә?

Октябрина. Юк, шатлана!

Шәмсебикә. Соң, мин бит Котлыбай хәлемне аңлагандыр да сине күндергән икән дип уйлаган идем. Алайса, ничек була инде?

Котлыбай. Берничек тә булмый! Аны аерам, сиңа өйләнәм! Менә граница! Ике аягымның берсен дә басмыйм бу якка!

Шәмсебикә. Юк! Мин моңа каршы! Йә син икебез белән дә яшә, ике дөньяны да кара, йә мин риза түгел!

Котлыбай. Тукта! Болай булгач, минем ике хатыным буламы?

Шәмсебикә. Әйе!

Котлыбай. Ярар! Аның белән бер көн дә яшәмәм дигән сүзем бар иде. Икегез белән дә яшәрмен!

Октябрина. Ай, карт уйнаш! Әни, ничек шуңа түзәсең? Ул бит синнән көлә!

Балбикә. Әй, кызым! Ул бит гомер буе шул булды...

Шәмсебикә. Куй, куй, Балбикә, мин белгәннән шулай сарансың! Сиксән яшьлек картыңны җәлләп, оялмыйча елап торган буласың! Көнаралаш кереп, төнен аркамны җылытып ятса, кай җире кимер дисең?

Балбикә. Соң, ул бит минем бабай, Шәмсебикә!..

Котлыбай. Җитте... Атны сатканда уйларга иде! Әнә ул ялгыз калса да сатмаган атын! Ә син!.. Ташлап китмәвемә рәхмәт әйт!.. Шәмсебикә, Дөлдөл кайда?

Шәмсебикә. Кайда булсын, яланда. Күктау янында.

Котлыбай. Тышаулымы?

Шәмсебикә. Тышаусыз бит ул ярты сәгатьтән районнан чыгып югала.

Котлыбай. Солың бармы?

Шәмсебикә. Юк.

Котлыбай. Ничек «юк»? Син әллә, кич алып кайткач, Дөлдөлгә солы бирмисеңме?

Шәмсебикә. Ничек бирим, колхозда булмаганны.

Котлыбай. Вәт җүләр! Шуннан ышан инде шушы хатыннарга!

Шәмсебикә. Атак, нигә шулай тузынасың? Ул бит яланда туенып кайта.

Котлыбай. Туя, атаң башы! Атка солы кирәк! Солы ашамаган ат ат түгел, сыер! Сезгә сөйләгән мин җүләр. Ярый, мин капчыкларны карт хатынымның сараеннан яшь хатынымның сараена күчерим. Атка якынрак булыр.

Шәмсебикә. Котлыбай, тукта! Хәзер бит ике дөнья да синеке. Дөлдөлне капчыкларың янында тотарсың.

Котлыбай. Чынлап та! Ну баш үзеңдә! Кил, үбим әле үзеңне шуның өчен!

Шәмсебикә. Нишләвең инде, дивана?

Октябрина. Оятсызлар! Атка алданып, шуңа өйләнәсеңме? Ул ат барыбер синеке булмаячак!

Шәмсебикә. Атак, нигә булмасын? Өйләнә икән, ат та, мин дә аныкы инде! Вәт!

Октябрина. Сезнең өйләнешкәнегезгә документыгыз, загс кәгазегез юк. Бүген үк улыңа хәбәр итәм: «Өеңә, атыңа этием хуҗа булырга йөри!» – дим. Закирҗан кайтып төшәчәк тә аның артына тибеп чыгарачак!

Котлыбай. Бик әйбәт киңәш бирдең, кызым, рәхмәт. Шәмсебикә, миңа синең дөньяңа законный хуҗа булырга кирәк. Бүген үк загска барабыз!

Октябрина. Ничек барасыз? Син әниемнең законный ире! Хи-хи!

Котлыбай. Ха-ха! Без әниең белән загста тормыйбыз!

Октябрина. Ничек? Әни, чынмы бу?

Балбикә. Чын инде, чын.

Октябрина. Алтмыш ел буена нәрсә карадың шуны тышаулап куймый?

Балбикә. Әй, кызым! Кем уйласын аны? Безнең заманда загс дигән нәрсә юк иде шикелле ул.

Октябрина. Менә ул ирләр! Барысы да алдакчы! Сволочь!

Котлыбай. Декабрина!

Октябрина. Декабрина!.. Менә, менә! Син бит минем исемемне дә хәтерли алмыйсың! Тавык мие, аңгыра! Чак кына акылың булса, йөзгә җиткәндә кеше көлдермәс идең!

Котлыбай. Җитте! Бар, чыгып кит минем иске ишегалдымнан!

Октябрина. Бу безнең өй! Әниемнеке! Кирәк булса, үзеңнең артыңа тибәрбез!

Котлыбай. Ах, чүпрәк! Күрсәтермен мин сиңа өйне! Югал! Эзең дә булмасын монда!

Октябрина. Кит әле!

Котлыбай. Бар! Бар!

Балбикә. Котлыбай! Кызым! Ни эшлисез?

Октябрина, Котлыбай, Балбикә урам ягына чыгалар.

Шәмсебикә. Әй, саранннар! Бер аягы белән кабердә торган картны җәлләп чак үлешмиләр!..

Урамнан Котлыбай, артыннан Балбикә керә.

Котлыбай. Шәмсебикә! Ярты сәгатьтән керәм. Әзер бул!

Шәмсебикә. Атак, анысы ничек?

Котлыбай. Соң, буян, бизән, үзеңне рәткә китер! Адәмчә киенеп ал.

Балбикә. Котлыбай!..

Котлыбай өйгә кереп китә.

Оятың юк икән синең!

Балбикә Котлыбай артыннан керә.

Шәмсебикә. Һай-һай, оятлы бәндә! Бөтенләй тартып алмаганга рәхмәт әйт!

Урамнан Сатыбал керә.

Сатыбал. Шәмсебикә!

Шәмсебикә. Атак! Нигә акырасың шулхәтле?

Сатыбал. Чынмы бу?

Шәмсебикә. Нәрсә?

Сатыбал. Сине Котлыбайга чыга диләр. Дөресме?

Шәмсебикә. Дөрес! Чыгам, Алла боерса. Башкалар бит синең кебек йоклап йөрми. Тоткан җирдән сындыралар. Ир дисәң ир!

Сатыбал. Ничек инде? Без бит сөйләштек: Галинурның кырыгын укыту белән өйләнешәбез, дип. Кичә аның кырыгы тулды, бүген мин менә сиңа килеп ятам.

Шәмсебикә. Бигрәк озак килдең. Соңладың.

Сатыбал. Тукта, Шәмсебикә, ничек соңладым? Без бит сөйләштек...

Шәмсебикә. Сөйләштек, хәзер үк күчеп кил! Сиңа чыгам! Күчәсеңме?

Сатыбал. Үз дөньямны ташлапмы?

Шәмсебикә. Әйе.

Сатыбал. Бу бит нәселдә булмаган хәл! Миннән бөтен район көләчәк, хатын өенә күчкән дип. Бу — позор, мәсхәрә,үлем!

Шәмсебикә. Мин дә сиңа күчә алмыйм. Чөнки Галинурым үләр алдыннан әйтте: «Шәмсебикәм,— ди-

де,— бу безнең нәсел нигезе, аны корытмый гына балаларыбызга калдырырга тиешбез,— диде. — Син, Шәмсебикәм,— диде ул,— бу нигезне ташлама, мал-туарны туздырма, улыбыз яки оныгыбыз кайтканчы шушы көе сакла. Шуннан гына, теләсәң, икенче кешегә чыгып, аның өенә күчәрсең»,— диде.

Сатыбал. Оятсыз ул синең Галинурың!

Шәмсебикә. Сатыбал! Син мәрхүм хакында...

Сатыбал. Әйтәм. Яшь чагымда нахаллашып танау төбемнән сине йолкып алып китте! Инде үлгәч комачауламас дисәм, юк, һаман аяк чалып маташа! Ә шушы ферма кебек дөньяны ялгызың ничек карарсың? Шуны уйладыңмы? Юк, хәзер үк бөтенесен ташлыйсың да миңа күченәсең! Нигез саклатам дип, аягыңны суздырасым юк! Җыен!

Шәмсебикә. Рәхмәт! Мәрхүмнең васыятенә хыянәт иттереп, үлгәч тәмугта яндырырга уйлыйсыңмы? Мин моннан беркая да китмим! Котлыбайга чыгам!

Сатыбал. Кемгә?

Шәмсебикә. Күршемә! Ул минем өемә күчәргә риза! Ул өемне дә, малымны да, үземне дә караячак!

Сатыбал. Үзеңне дә?

Шәмсебикә. Әйе, үземне дә! Нигә аптырыйсың? Әллә мин карамаслык хатынмы?

Сатыбал. Ә миңа ни эшләргә?

Шәмсебикә. Син, бар, кайт. Үзеңә икенче әби эзлә. Хәзер тол әбиләр авыл тулы.

Сатыбал. Шәмсебикә! Син ничек шулай дип әйтә аласың? Мин бит сиңа егерме яшемнән гашыйкмын. Син дип гомер буе өйләнмәдем. Алтмыш ел буе бабаеңның үлгәнен көттем. Шундый өйдән Шәмсебикәгә минем тавык кетәклеге кебек йортыма күчү авыр булыр дип, карт көнемдә яңа өй салдым. Аллага шөкер, ниһаять, Галинурың үлде. Инде сиңа өйләнәм дисәм, янә!..

Шәмсебикә. Бахыркаем! Әллә нигә мине шулай нык яраттың шул...

Сатыбал. Миңа синнән башка беркем дә кирәкми, аңлыйсыңмы?

Шәмсебикә. Аңлыйм, аңлыйм, аңламаган кайда ул! Үземнең дә синең белән яшәп карыйсым килә дә бит. Ни дисәң дә, алтмыш ел буе мине яратып йөргән, өйләнмәгән кеше бит әле син. Тик Галинурымның васыяте...

Сатыбал. Ух! Ул юри эшләгән моны! Безне өйләндермәс өчен! Үлдең бит инде, ят тыныч кына! Юк, һаман ашка таракан булып төшә, тискәре!

Шәмсебикә. Сатыбал! Әгәр тагын бер тапкыр Галинурым хакында шулай сөйләнсәң... Кыскасы, әйттем — бетте: йә монда күчеп киләсең, йә әнә барыр юлың!..

Сатыбал. Шәмсебикә!..

Шәмсебикә. Бар, кит! Минем вакытым юк! Хәзер Котлыбай килә. Миңа азрак бизәнеп, төзәнергә кирәк.

Сатыбал. Алтмыш ел буе — Галинур, ә хәзер — Котлыбаймы?.. Юк! Үлсәм үләм, Котлыбайга бирмим!

Шәмсебикә. Атак! Ничек бирмисең?

Сатыбал. Менә шулай! Шушында торам да аны сиңа үткәрмим!

Шәмсебикә. Җүләр, бар, кайтып кит! Бар.

Сатыбал. Юк инде! Алтмыш ел көттем! Йә минеке буласың, йә тол калдырам!

Шәмсебикә. Әй, мескен! Синме инде Котлыбайга каршы торырдай ир? Ул бит сине менә — басты, изде! Әйдә, яшәүдән туйсаң тор! Ә миңа кияүне каршыларга әзерләнергә кирәк! Хуш!

Шәмсебикә өенә кереп китә.

Сатыбал. Тукта! Тукта, дим! Нигә бикләндең? Ач! Вәт эт хатын!.. Ни эшләргә? Ычкына бит кулдан, ычкына! Алтмыш ел буе ире үлгәнен көт тә, кулга килеп эләккәч ычкындыр инде, ә?.. Әллә чынлап та үзенә күченеп килергәме? Оят бит, оят! Күзне дә ачтырмаслар. Сатыбал хатын булган, әбигә күчеп килгән, диярләр. Юк, булмый! Ничек тә Котлыбайга бирмәскә, үземә алып кайтырга кирәк!

Өеннән Котлыбай чыга.

Котлыбай. Кем бу? Сатыбал, синме?

Сатыбал. Мин. Шуннан? Исәнләшмисең?

Котлыбай. Исәнме, исәнме! Ни эшләп йөрисең монда адашкан бозау кебек?

Сатыбал. Син – кигәвен чаккан бозау – өйләнәсең икән дип ишетеп килдем. Дөресме шул?

Котлыбай. Дөрес, кордаш, өйләнәм. Алтмыш ел буе бер хатын белән бит! Ялыктырды. Яңа хатын алам, яшь хатын.

Сатыбал. Ә Балбикәне кая куясың?

Котлыбай. Куып чыгарсаң җәл. Үтереп тә булмый. Яшәр әле шунда. Иске йортта.

Сатыбал. Син нәрсә, ике хатын белән яшәргә уйлыйсыңмы?

Котлыбай. Алла боерса! Бер төн берсендә, икенче төн...

Сатыбал. Тукта әле! Ә менә минем бер хатын да юк! Ә синең – ике! Бу бит гаделсезлек!

Котлыбай. Мин гаеплемени, кулыңнан килмәгәч?

Сатыбал. Безнең илдә ике хатын алу тыелган!

Котлыбай. Хәзер хет ун хатын ал – демократия!

Сатыбал. Котлыбай, кордаш! Үтенәм! Өйләнмә Шәмсебикәгә!

Котлыбай. Үтенәсеңме?

Сатыбал. Бик-бик! Менә аягыңа егылам!

Котлыбай. Ха-ха-ха! Исеңдәме, мин бит сиңа әйткән идем: көне җитәр әле бер, дигән идем, каршыма килеп тезләнерсең, дигән идем! Тыңламадың, сиңа тезләнеп бармам, дидең. Менә бит, килдең!

Сатыбал. Кайчан әйттем?

Котлыбай. Төп-төгәл илле өч ел элек.

Сатыбал. Кайчан-кайчан?

Котлыбай. Кыланма! Син бик яхшы хәтерлисең! Илле өч ел элек! Сезнең авыл белән безнең авыл бер колхозга кушылган чакта. Син амбар хуҗасы. Мин синнән атыма бер чиләк солы сорап бардым! Республикада дан казанган атка! Бер чиләк солы! Син бирмәдең!

Сатыбал. Соң, ул заманда...

Котлыбай. Акланма! Юри эшләдең! Көнләшеп! Ә бүген... Шуның өчен җәза – сиңа әби юк!

Сатыбал. Котлыбай, мин гомер буе Шәмсебикә дип...

Котлыбай. Бер генә чиләк бит!

Сатыбал. Алтмыш ел Галинурның үлгәнен көттем!

Котлыбай. Мәскәүгә барган атка! Юк, бирмәдең!

Сатыбал. Ул атың күптән дөмеккән! Бир Шәмсебикәне!

Котлыбай. Юк!

Сатыбал. Юкмы?

Котлыбай. Юк, юк, юк!

Сатыбал. Син беләсеңме кем? Фашист!

Котлыбай. Нәрсә?

Сатыбал. Үзсүзле деспот! Шушы холкың белән гомер буе Балбикәне азапладың! Икетуган сеңлемне! Хәзер килеп минем тормышымны бутарга җыенасыңмы? Килеп чыкмас!

Котлыбай. Кит моннан! Миңа керергә кирәк!

Сатыбал. Юк, кертмим!

Котлыбай. Ничек кертмисең?

Сатыбал. Бар, Балбикәңә кайт! Шәмсебикә минеке!

Котлыбай. Хәзер! Кем белән яшәргә синнән сорармын! Үткәр!

Сатыбал. Үлсәм үләм, үткәрмим!

Котлыбай. Шулаймы? Ярый! Башкортлар китте сугышка! Ятып калды күк Урал!

Сатыбал. Дошманга бирешми безнең горур «Варяг»!

Котлыбай. Үткәр! Җибәр! Ах! Ух!

Сатыбал. Юк! Тукта! Ух! Ух!

Котлыбай. Ай, бил!

Сатыбал. Ай, аяк!

Котлыбай. Паразит! Нигә радикулиттан тотасың?

Сатыбал. Ревматизмны сындырды, алаша!.. Тукта! Кайда барасың?

Котлыбай. Кит әле!

Сатыбал. Тукта, дим! Тукта! Югыйсә үтерәм, атам! Дуэльгә чакырам!

Котлыбай. Нәрсәгә чакырасың?

Сатыбал. Дуэльгә! Гомер буе шул булды! Котлыбай – беренче! Котлыбай – җиңүче! Җитте! Урыныңа утыртыр көн килде! Атышабыз!

Котлыбай. Нәрсә белән?

Сатыбал. Мылтык белән. Җир шарындагы бер паразитны киметәм!

Котлыбай. Синең үз гомереңдә мылтык тотканың бармы соң?

Сатыбал. Тотмасам тотармын! Сиңа төзәп курокка басарга акылым җитәр! Аучы Аллаярның келәтендә егерме мылтык тора. Шуның икесен алып киләм дә атышабыз!

Котлыбай. Мин атышмыйм!

Сатыбал. Ә-ә, куркасыңмы? Үтерер дип шүрлисеңме! Син куркак! Дезертир! Шпион!

Котлыбай. Җитте, ахмак! Мин атышмыйм! Шәмсебикә үзе мине сайлады!

Сатыбал. Бар, кер! Кер! Тик бел: мин хәзер барыбер ике мылтык алып киләм! Әгәр атышмасаң, мин сине атып үтерәм!

Сатыбал чыгып китә.

Котлыбай. Әй, җүләр! Шәмсебикә! Әзерләнәсеңме? Мин әзер!.. Тукта! Хатын качмас. Элек ат сараен карыйм әле. Хатын-кыз атка ни кирәген беләмени ул?

Котлыбай кире борылып сарай ягына китә. Урамнан Октябрина керә.

Октябрина. Әни! Әни, дим!

Өйдән Балбикә чыга.

Балбикә. Ни булды?

Октябрина. Бар, әтием белән икегезнең паспортларын алып чык!

Балбикә. Тагын нәрсә уйлап чыгардың?

Октябрина. Мин икегезне дә загслы итәм. Менә аңа Шәмсебикә! *(Йодрык күрсәтә.)* Бар, тиз бул! Әтием өйдәме? Аңа сиздермә!

Балбикә. Хатын алам дигән кеше өйдә торамы? Анда ул.

Балбикә өйгә керә.

Октябрина. Кара, ишекләре бикле. Тәрәзәне корганнар. Вәт уйнашлар!

Балбикә өйдән чыга.

Балбикә. Кызым, бәлки, кирәкмәс?

Октябрина. Ничек «кирәкмәс»? Ул синнән көлсен, мыскыл итсен, ә без карап торыйкмы? Хәзер сельсоветка барып, паспортларыгызга пичәт суктырам! Һәм сез – закунный ир белән хатын!

Балбикә. Акбүз атын сатмаска кирәк иде! Үзең дә яшәмәдең кешечә, хәзер килеп минем тормышны да чәлпәрәмә иттең.

Октябрина. Әни, минмени? Ул бит!.. Бер аягы җирдә, икенчесе гүрдә. Син борчылма, без аны беркая да җибәрмибез.

Балбикә. Ярый да бит пичәт юк дип Шәмсебикәне ташласа...

Октябрина. Ташлар! Мин яңа гына Закирҗан белән сөйләштем.

Балбикә. Ирең беләнме?

Октябрина. Нинди ирем булсын? Аның белән аерылышканга бишбылтыр! Шәмсебикәнең улы белән. Күрше авылга килгән иделәр. Телефон аша таптырдым да аңлаттым хәлне. Минем әти синең әниеңнең Дөлдөлен тартып алырга йөри, дигән идем!.. Коты очты. Ул, атны үзем сатам, миңа акча кирәк, ди. Хәзер монда килә.

Балбикә. Болгаткансың икән дөньяны.

Октябрина. Ну кызык булачак! Закирҗан киләчәк тә әтиемнең арт санына тибеп чыгарачак бу өйдән!

Балбикә. Ай-һай, әтиеңне беләсең. Ул Закирҗанны гына тыңлармы икән?

Октябрина. Тыңлар! Паспортында – сиңа өйләнгән дигән пичәт! Димәк, бу хуҗалыкка бернинди дә хакы юк! Барысы да Закирҗанныкы!

Балбикә. Йа Ходаем! Олы җәнҗал кубачак икән! Ә әтиең хәзер үк паспортын таптыра башласа ни эшләрмен?

Октябрина. Син берни дә белмисең, барысына да мине гаеплә!

Балбикә. Йөрәгем һич тә тыныч түгел. Берәр афәт кенә килеп чыкмаса ярар иде. Бар, куйдырсаң куйдыр да шул пичәтне, тизрәк кире кайт. Синсез куркам мин монда!

Октябрина. Әни, курыкма. Монда минем хәзер кирәгем дә юк. Бер ун минуттан Закирҗан кайтачак та барысын да үз урынына утыртачак.

Балбикә. Син әллә, дөнья бутап, мине ялгыз калдырып китәргә уйлыйсыңмы? Юк-юк! Пичәт суктырырга сиңа ярты сәгать вакыт җитә. Сәгать биштә монда бул!

Октябрина. Әни, минем үз эшләрем дә бар.

Балбикә. Нинди эш ди ул шундый чакта? Монда әтиең мине ташларга йөри. Инде син дә китәсең...

Октябрина. Мин бит бөтенләйгә китмим. Бер-ике сәгатьтән килермен.

Балбикә. Ярый. Ул чагында инде миңа кабер казыйсы гына калыр.

Октябрина. Әни, шулхәтле эгоистка булма әле! Бәлки, шушы минутта минем дә язмышым хәл ителер. Әтием сине берни дә эшләтмәячәк!

Балбикә. Эшләтәчәк! Паспортларның юклыгын белгәч тә мине үтерәчәк! Нигә хәзер үк кире килмисең? Ике сәгать буе сельсоветта нәрсә карап йөрергә җыенасың? Пичәт суктырырга бер минут вакыт җитә.

Октябрина. Мин кияүгә чыгам.

Балбикә. Атаң башы!.. Кит, кызым, кеше көлдермә. Картайгач нинди кияү ул тагын?

Октябрина. Сиксән яшьлек Шәмсебикә «кияү» дип йөргәндә, мин кемнән ким? Миңа әле илле сигез генә яшь!

Балбикә. Соң, өч ир белән яшәп карадың бит инде. Һаман туймадыңмыни?

Октябрина. Алар ир идемени? Өчесе дә алкаш. Ә бу эчми.

Балбикә. Эчмәгәч, юньле адәм түгелдер ул.

Октябрина. Син эчкән ир белән яшәмәгәч белмисең шул. Ичмасам, карт көнемдә эчмәгән ир белән яшәп карыйсым килә, әни. Хатыны ике ел элек үлгән. Балалары үсеп таралган. Хәзер ялгыз яши, тәмәке тартмый.

Балбикә. Кем соң ул? Мин беләмме?

Октябрина. Күрше авылдан. Котдус.

Балбикә. Әллә теге Бүре Котдусмы?

Октябрина. Бернинди дә бүре түгел. Просто Котдус.

Балбикә. Әй Алла! Шул Бүре Котдус инде алайса. Бу тирәдә аннан башка Котдус юк. Тик аны бик саран, кеше сөймәс адәм диләр бит.

Октябрина. Алар юри сөйли, байлыгыннан көнләшеп.

Балбикә. Соң, сине – безгә, безне сиңа җибәрми тормасын, дим. Синең белән дә күрешмәгәч, ничек яшәрбез? Башка балалар Себергә китеп беттеләр...

Октябрина. Әни!.. Без көн дә күрешәчәкбез. Әгәр әтием кыерсытса, мин сине яныма алачакмын. Менә күрерсең.

Балбикә. Ярый, балам, ярый... Бәхетле генә була күр инде...

Октябрина. Сельсоветка алдан баруымның сәбәбе шул Котдус белән очрашыр өчен. Ярты сәгатьтән ул минем өемә килә.

Балбикә. Алай булгач, күпме кирәк, шулкадәр йөр, кызым. Мин монда ничек тә... Бар, бар...

Балбикә өйгә кереп китә. Октябрина урамга юнәлә. Аңа каршы Закирҗан керә.

Закирҗан. Сәлам, хатынкай!

Октябрина. Мин нишләп сиңа хатынкай булыйм?

Закирҗан. Ну, элекке хатыным.

Октябрина. Бурычыңны алып килдеңме?

Закирҗан. Нинди бурыч?

Октябрина. Тавык мие! Әтиеңне җирләргә кайтканда, иртәгә үк кертеп бирәм дип, кем ярты алган иде?

Закирҗан. Әй, куй әле! Шулхәтле вакланмасаң! Көнең бер яртыга калмагандыр бит!

Октябрина. Нахал! Аракы хәзер ике йөз сум тора! Ә мин пенсия дә алмыйм. Син бит гомер буе малаеңа бер тиен алимент та түләмәдең, алкаш! Хәзер килеп... «Похмель, үләм!..» Мин шуңа ышанып биреп тордым бит әле, җүләр... Акчасын китер давай!

Закирҗан. Тукта әле! Кеше юлдан тын алырга өлгермәгән. Ул яртың миңа кылган этлекләрең өчен булыр.

Октябрина. Нинди этлекләрем?

Закирҗан. Кыланма! Син үзең, без аерылганнан соң, тагын ике иргә чыгып аерылдың. Ә миңа менә утыз биш ел инде өйләнергә ирек бирмисең! Шул этлек түгелме?

Октябрина. Өйлән! Сине кем тота?

Закирҗан. Син! Хәкимәгә өйләнәм дигәндә, барып мине эттән алып, эткә салып, сүгеп, хурлап киттең – бер. Сәкинәгә өйләнгән җирдән, син мине юри эчереп, исертеп, аның ишегалдына ташлап киттең – ике. Оксанага йортка кергән идем, коточкыч хат язып җибәрдең – өч. Мәдинәгә...

Октябрина. Җитәр! Мин ул хатыннарны синнән коткардым, белдеңме? Син гаилә кора ала торган кеше түгел. Яшә ялгыз!

Закирҗан. Ух, деспот! Икенче Котлыбай!.. Кайда әле шул картлачың? Дөресме теге хәбәрең? Әллә син алдап...

Октябрина. Башта бурычыңны бир!

Закирҗан. Минем бер тиенем дә юк. Мә, тенте!

Октябрина. Хәерче! Гомер буе шул булдың! Әгәр чын ир булсаң, улыңның туган көненә бирәр бүләк алыр идең!..

Закирҗан. Кырыкка җиткән ир картайган атасыннан бүләк сорамас.

Октябрина. Хәчтерүш син! Мескен!

Закирҗан. Син онытма: без инде утыз биш ел ир белән хатын түгел. Бу сүзләрең өчен мин сине судка бирә алам.

Октябрина. Хайван! Эт! Бар, бар! Хәерче! Чучка!

Закирҗан. Беләсең килсә, мин хәзер районда иң бай ир! Әни кияүгә китә, ә бу өй миңа кала. Аның хакы миллион ярым! Шәһәрдә кооператив фатир алам, машина. Тагын...

Октябрина. Тукта, тукта, саташмый тор! Ул миллион ярымның бер тиене дә сиңа эләкмәячәк!

Закирҗан. Нигә эләкмәсен? Минем әниемнең өенә Котлыбайның бернинди дә хакы юк.

Октябрина. Ул синең әниеңә өйләнә.

Закирҗан. Нәрсә эшли?

Октябрина. Хатынлыкка ала. Колак!

Закирҗан. Нәрсә, әллә Балбикә апа үлдеме?

Октябрина. Әтием ике хатын белән яшәмәкче.

Закирҗан. Вәт картлач! Нахал! Монда кешегә бер хатын да юк. Төрмәгә утыртырга кирәк ул уйнашчыны!

Октябрина. Тынычлан. Әтиемнең уе – синең дөньяңа хуҗа булу. Иң мөһиме – атка, Дөлдөлгә!

Закирҗан. Нәрсә? Менә аңа Дөлдөл! *(Кукиш күрсәтә.)* Бандит! Мин бит аны!..

Октябрина. Тукта, тыңлап бетер. Әти санаторийда чакта мин аның атын сатып, уртак улыбызга мотоцикл алган идем. Атсыз калгач, әтием бик ачуланды. Шуннан, Дөлдөлне үзенеке итү өчен, әниеңә өйләнергә булды.

Закирҗан. Дөньяны син бутагансың икән.

Октябрина. Син тыныч кына тыңлый аласыңмы? Әтием хәзер син куганга гына чыкмаячак.

Закирҗан. Ничек чыкмасын? Җилкәсеннән тотам да...

Октябрина. Әтәчләнмә. Ул бер өрсә, син бит... син хәзер иң элек атны сат. Әтигә аттан башка бернәрсә дә кирәкми монда.

Закирҗан. Мин үзем дә шундый уй белән кайттым бит. Сатам! Атсыз калдырам әтиеңне! Ух! Ул бит мине менә шундый чактан кыерсыта иде. Бер тапкыр кечкенә чагында кыярыгызны урларга бакчагызга кергән идем. Тотып алды да чак-чак колакны өзеп чыгармады, кабахәт! Һаман сызлый.

Октябрина. Дөрес эшләгән. Урлашмаска кирәк иде.

Закирҗан. Безнең тормышны да ул гына бутады.

Октябрина. Синең эт кебек эчүеңә ул гаеплемени?

Закирҗан. Мин бит элек чак кына эчә идем. Авылдагы һәркем кебек. Беркөнне исереп кайткан идем... эләктерде, малай!.. Тагын колакка, фашист ул! Шуннан ачуымнан ныграк эчә башладым.

Октябрина. Ә синең әниең соң!.. Миңа ялкау, тупас, дип...

Закирҗан. Октябрина! Әйдә шуларга үч итеп киредән кавышабыз.

Октябрина. Соңладың, кадерлем. Мин кияүгә чыгам.

Закирҗан. Нәрсә? Кияүгә? Ха-ха! Сине кем алсын?

Октябрина. Ала шул. Искиткеч шәп кеше. Эчми, тартмый. Син түгел инде, алкаш! Өе бар, ике аты.

Закирҗан. Кем ул?

Октябрина. Өч сыеры, машинасы.

Закирҗан. Кем, дим?

Октябрина. Утыз умартасы.

Закирҗан. Ә-ә, белдем. Бүре Котдус!

Октябрина. Бүре түгел, Котдус Ибраевич!

Закирҗан. Анда шул бүредән башка Ибраич юк. Ике ел хатын таба алмый интегә инде. Аңа бит беркем дә барырга теләми. Сине тапкан икән.

Октябрина. Аңа чыгарга теләүчеләр – менә! Ул апаңны сайлады шул!

Закирҗан. Ахмак! Алтмышка җиткәнсең, һаман акылга утырмагансың. Ул бит саран, карун! Ул чәшкеңә салган шикәреңә кадәр санап утырачак!

Октябрина. Үзеңә хәзер беркем дә калмагач, көнчелегеңнән шартлыйсыңмы?

Закирҗан. Миңа чыгарга теләүчеләр миллион! Әле күрше авылга нигә барган дисең?

Октябрина. Нигә?

Закирҗан. Ярый, ул сиңа кирәкми. Әтиең кайда?

Октябрина. Юк, тукта! Әйтеп бетер! Ни эшләдең ул авылда?

Закирҗан. Берни дә эшләмәдем! Отчёт сорарга син хәзер минем хатыным түгел!

Октябрина. Элекке хатының. Йә? Әйтмисеңме?

Закирҗан. Юк.

Октябрина. Мин бит беләм сине, уйнашчы! Син янә өйләнергә йөрисең! Әйт, шулаймы? Әйт, дим! *(Колагын бора.)*

Закирҗан. Җибәр! Өзәсең бит колакны! Әйе, әйе, өйләнәм!

Октябрина. Кем ул?

Закирҗан. Әйтмим. Хәзер син аңа барып, мине хурлап сөйләп кайтыр идең бугай.

Октябрина. Кем? *(Якасына ябыша.)*

Закирҗан. Әләй, әләй! Саҗидә, Саҗидә!

Октябрина. Ашханәдә эшләгәнме?

Закирҗан. Әйе, әйе!.. Нигә тотасыз да колакка ябышасыз әле? Өзеп аласың бит!

Октябрина. Өзсә, яшермә! Саҗидә. Ул бит чалыш күз!

Закирҗан. Һич тә чалыш түгел, нормальный.

Октябрина. Җитмәсә, камыт аяк.

Закирҗан. Һәрхәлдә, синекеннән төзрәк.

Октябрина. Бөкре! Хи-хи-хи!

Закирҗан. Җитәр!

Октябрина. Җүләр! Ул бит алты иргә чыкты! Алты ире дә бер-бер артлы үлде.

Закирҗан. Үлде? Син алдыйсың! Көнләшүеңнән!

Октябрина. Кирәгең бар иде! Бар, өйлән! Тик башта кәфенлек әзерлә, якты дөнья белән хушлаш. Алла боерса, ярты елдан күмәрбез! Хи-хи-хи!

Закирҗан. Җитте сиңа! Әтиең кайда?

Октябрина. Анаңның кочагында!

Закирҗан. Нәрсә?

Октябрина. Ул сездә яши хәзер. Әнә тәрәзәне корганнар, ишекне эчтән бикләгәннәр! Медовый месяц!

Закирҗан. Үтерәм! Ачыгыз! Ачыгыз, дим!

Ишек ачыла. Өйдән Шәмсебикә чыга.

Шәмсебикә. Бәй, улым кайткан икән!..

Закирҗан. Әни, сиңа оят түгелме? Көпә-көндез!..

Шәмсебикә. Атак, ни булган?

Закирҗан. Кем белән бикләнеп ятасың?

Шәмсебикә. Авызыңнан җил алсын!

Октябрина. Кыланма! Әтием анда бит!

Закирҗан өйгә кереп китә.

Шәмсебикә. Кит, Октябрина. Ни сөйләгәнеңне белмисең!

Закирҗан өйдән чыга.

Закирҗан. Анда беркем дә юк!

Октябрина. Димәк, яшергән!

Закирҗан. Син минем әнине уйнашчы атаңа бәйләмә, ярыймы!

Октябрина. Ышан! Өйсез калгач аңларсың әле әниеңне!

Октябрина чыгып китә.

Шәмсебикә. Атак, мин аңа ни эшләгән? Әй, куй әле шуны! Йә, улым, ничек кайтып җиттең?

Закирҗан. Син нәрсә, кияүгә чыгасыңмы?

Шәмсебикә. Чыгам инде, аптырагач. Сиңа күпме әйтәм: «Өйлән дә кайт, яшә шунда!» – дим. Ә син...

Закирҗан. Бер тапкыр яшәп карадым. Җитте! Хатыным да, үзем дә ошамадым. Башка гомердә дә кайтасым юк!

Шәмсебикә. Әнә шул шул! Ә шундый дөньяны ялгызыма ничек карарга? Нигезне ничек сакларга?

Закирҗан. Пычагымамы сиңа нигез? Өйне дә, малны да сатабыз!

Шәмсебикә. Улым, ни сөйлисең? Бу нигезне моннан бик күп еллар элек синең ата-бабаң салган, үз улларына аны беркайчан да корытмаска кушкан. Ә син «сатабыз»! Сату юк! Бу минем теләк түгел, әтиеңнең васыяте. Ә мәрхүмнең сүзен бозарга ярамый.

Закирҗан. Әкият сөйләмә! Мин гомер буе фатирсыз җәфаланам, тулай торакта яшим! Хәзер кооператив фатирга чиратым җитте. Миңа акча кирәк!

Шәмсебикә. Миндә акча юк! Өйне дә саттырмыйм! Вәт!

Закирҗан. Миңа беренче взносны түләргә кирәк! Иң элек атны сатабыз!

Шәмсебикә. Улым!

Закирҗан. Өйгә хәзер мин хуҗа! Сатабыз атны! Әйттем – бетте!

Ат сараеннан Котлыбай чыга. Ул сәхнәдәгеләрне күрми.

Котлыбай. Юк, Дөлдөлне үземнең сарайга күчерәм! Бу бит келәт! Шунда тотарга ярыймы Дөлдөлне! Районның беренче атын!.. Дөлдөл минеке! Ышанып булмый! Бәй, кунаклар бар икән.

Закирҗан. Димәк, Дөлдөл синеке?

Шәмсебикә. Закирҗан!

Закирҗан. Тик тор! Бәлки, бөтен бу дөнья да синекедер?

Котлыбай. Закирҗан, энем, әниеңә ялгыз дөнья көтүе бик авыр... печән чабарга кирәк, кышка әзерләнергә.

Закирҗан. Син, карт шайтан, боргалама, турысын әйт!

Котлыбай. Турысынмы? Без өйләнешергә булдык! Менә шул!

Закирҗан. Ә син беләсеңме, совет власе ике хатынлы кешене ни эшләтә?

Котлыбай. Хәзер совет власе юк!

Закирҗан. Ат кирәк булдымы? Менә сиңа ат! *(Кукиш күрсәтә.)* Өйләнешмисез!

Котлыбай. Синнән сорап торырбыз шул!

Закирҗан. Сорамыйсыңмы? Мин бүген атны сатам! Хәзер! Егерме биш мең! Кешесе сөйләшенгән!

Шәмсебикә. Закирҗан! Улым!

Закирҗан. Әни, монда мин хуҗа! Сатам! Менә хәзер әйтсен ул: өйләнәме, юкмы?

Котлыбай. Тукта, энем, ашыкма! Бүгеннән бу дөньяга мин хуҗа! Ат та минеке! Ул сатылмый!

Закирҗан. Хуҗа?.. Әниемә өйләндем дигән документың бармы?

Котлыбай. Булачак! Шәмсебикә, китер паспортыңны! Загска барабыз!

Закирҗан. Әни, тукта!

Шәмсебикә. Миңа бабай кирәк!

Шәмсебикә өйгә кереп китә. Урамнан Сатыбал керә. Кулында ике мылтык.

Сатыбал. Котлыбай! Мә!

Котлыбай. Нәрсә кирәк?

Сатыбал. Дуэль!

Котлыбай. Кит әле!

Котлыбай өенә кереп китә.

Сатыбал. Дезертир! Куркак! Закирҗан улым, исәнме!

Закирҗан. Нигә әниемне үзеңә алып кайтып китмисең?

Сатыбал. Котлыбайны үтерәм дә алып кайтам!

Бер өйдән — Шәмсебикә, икенчесеннән Котлыбай белән Балбикә чыга.

Котлыбай. Кая алып китте ул паспортны? Кая?

Балбикә. Сельсоветка.

Котлыбай. Ух, чүпрәк баш! Хәзер бит барсам!.. Шәмсебикә, паспорт! Тиз бул!

Закирҗан. Әни, бирмә!

Шәмсебикә. Улым!

Сатыбал. Котлыбай, тот мылтыкны. Атышабыз!

Котлыбай. Кит моннан! Шәмсебикә!

Балбикә. Йа Ходай! Ни эшлисез сез, ә? Туктагыз!

Талаш, тарткалаш, шау-шу.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук күренеш. Сәхнәдә, ике мылтыгын кочаклап, Сатыбал йоклап утыра. Урамнан Котлыбай керә дә өенә юнәлә.

Сатыбал *(йокы аралаш)*. Дуэль! Атышабыз!

Котлыбай. Тфү, мәхлук!..

Өйдән Балбикә чыга.

Балбикә. Кайткансың икән. Алдыңмы паспортыңны?

Котлыбай. Оялмый сорап торган була, бичура!

Балбикә. Минмени? Кызың. Ул да синең бердәнберең бит.

Котлыбай. Торма янымда. *(Сарайга кереп, йөгән алып чыга.)*

Балбикә. Алай көралмагач, чынлап та аерылышыйк та куйыйк.

Котлыбай. Тик бел: өй минеке. Теләсә кая чыгып кит!

Балбикә. Ярый... Син һәрчак атларыңны миннән кадерлерәк күрдең. Мин дә ат яратам. Шуңа аңлый идем сине. Тик бу юлы... Ярый, киттем. *(Өйгә керә.)*

Котлыбай. Атны сатмасаң, шушы көнгә төшмәс идең, җүләр!.. Хәзер иң мөһиме: Дөлдөлне яшерергә! Загс качмас. Югыйсә Шәмсебикәнең көчеге сатты-җибәрде! Дөлдөл артыннан йөгерүчеләр районда буа буарлык! *(Китә.)*

Өйдән Закирҗан белән Шәмсебикә чыга. Закирҗанның кулында йөгән.

Закирҗан. Кайсы тирәдә йөри Дөлдөл?

Шәмсебикә. Улым, Дөлдөл бит әтиеңнең истәлеге! Ничек кулың бара?

Закирҗан. Әни, җитте! Сатам дигәч сатам!

Сатыбал *(йокы аралаш)*. Атма! Атма!

Шәмсебикә. Әй Алла! Йөрәкне яралады. Әнә Сатыбал абыең да «сатма» ди бит.

Закирҗан. Ул «атма» ди, төш күрә. Дөлдөл кайда? Анда кеше көтеп утыра!

Шәмсебикә. Күктау яланында. Китүең шул булдымы инде?

Закирҗан. Хәзер Дөлдөлне сатам. Шуннан күрше авылга барып киләм... Аш әзерләп тор. Бер сәгатьтән хатын алып кайтам.

Шәмсебикә. Атак, кемне?

Закирҗан. Саҗидәне.

Шәмсебикә. Нинди Саҗидә?

Закирҗан. Ашханәдә эшләгән.

Шәмсебикә. Әй Алла! Аның әнисе усал бит!

Закирҗан. Мин әнисенә түгел, үзенә өйләнәм.

Шәмсебикә. Әнисе нинди, кызы да шундый инде. Әй Ходаем! Алай булгач, сиңа бу нигезгә кайту бетте!

Закирҗан. Мин патша кызына өйләнсәм дә монда кайтмыйм!

Шәмсебикә. Улым, зинһар, аңа өйләнмә!

Закирҗан. Ялгыз яшимме?

Шәмсебикә. Яшә. Тик аңа өйләнмә. Яки әнә Октябринабызны ал. Шундый һәйбәт, юмарт...

Закирҗан. Әйе, аждаһа!

Шәмсебикә. Икәүләшеп шушы өйгә кайтыгыз яшәргә. Ә мин...

Закирҗан. Әни, җитте! Кемгә телим, шуңа өйләнәм! Бер сәгатьтән без монда булырбыз! *(Китә.)*

Шәмсебикә. Әй җүләрләр! Октябринасы Котдуска чыгам дип йөргән була, монысы... Иманым камил: Закирҗан Октябринасына яңадан өйләнсә генә монда кайтачак. Димәк, ничек тә Котдуска Октябринаны бирмәскә, Закирҗанын Саҗидәгә өйләндермәскә кирәк! Хәер, Октябрина минсез дә Закирҗанын башкага өйләндермәс, ни булса да эшләр. Ә менә Октябринаның үзен ничек итеп Котдуска чыгармаска? Тукта! Хәзер Котдуска барам да Октябринаны үтергәнче яманлыйм?! Ул ялкау! Ул усал! Ул... Тагын нинди начарлыклар бар әле дөньяда? Эчкече! Уйнашчы! Хи-хи! Шуларны ишетсә, Котдус Октябринаны тупсасына да бастырмаячак! Киттем! Тукта! Атны ни эшләтергә?

Сата бит аны Закирҗан, сата! Котлыбай нәрсә карап йоклап ята соң? Котлыбай! Балбикә, бабаебыз өйдәме? Кайда китте? Белмисеңме? Ярый, башта Котдуска барам, шуннан Котлыбайны эзләрмен.

Шәмсебикә китә. Октябрина керә.

Октябрина. Хәзер ничек тә Закирҗанны Саҗидәгә өйләндермәскә. Әллә өйдә юк инде? Саҗидәсенә киттеме икәнни?

Сатыбал. А-а!

Октябрина. Ай Алла! Котны алды. Нигә акырасың ишәк кебек? Бәй, әллә йоклый инде? Әни!

Өйдән Балбикә чыга.

Балбикә. Ни булды?

Октябрина. Болар кайда?

Балбикә. Мин кайдан белим. Тукта, кайда йөрдең? Сөйләштеңме Котдус белән?

Октябрина. Сөйләштек, килештек. Өйләнешәбез. Ярый. Соңыннан сөйләрмен.

Балбикә. Октябрина! Мине әтиең өйдән куа. Күземә күренмә, теләсә кая чыгып кит, ди. Хәзер әйберләремне алам да сиңа күчәм.

Октябрина. Тукта әле, әни. Аның куарга хакы юк. Шәмсебикәгә өйләнә икән, күчсен аңа. Ә бу өй синеке.

Балбикә. Әтиеңне җиңеп буламыни? Китәм. Өеңдә мин генә ятарлык почмак табылыр әле.

Октябрина. Әни, эш шунда... Котдус миңа күчеп килә. Үзенең өендә шәһәрдән кайткан кызы белән киявен калдыра.

Балбикә. Килсен. Әнием юаш кына, сиңа беркайчан да каршы сүз әйтмәс, дисәң...

Октябрина. Әйттем. Ул ни диде... Өйдә чит кешеләрнең булуын яратмыйм, минекеләр дә килмәс, синекеләр дә килмәсен, кирәк булса, үзебез барып күрербез, диде.

Балбикә. Ярый.

Октябрина. Әни! Ачуланма миңа. Ул әйбәт кеше.

Тик чак кына... Менә күрерсең, мин аңа аңлатачакмын, ул сиңа безгә килергә рөхсәт итәр. Әни!

Балбикә. Ни булса да бер-берегезне тыңлап, тату гына яшәгез инде, балам.

Октябрина. Рәхмәт, әни!

Балбикә. Ә мин... һич тә булмаса, Ташкенттагы сеңлемә китәрмен. Аның балалары күбрәк тә... Миңа гына почмак табарлар әле.

Октябрина. Әни, беркая да китмисең! Үзен куабыз! Кайда әле ул?

Балбикә. Белмим.

Октябрина. Кайда китеп олакканнардыр бөтенесе дә. Закирҗан!.. Өйләнеп йөридер әле, уйнашчы! Юк! Ярый, әни, минем ашыгыч эшем бар.

Балбикә. Кызым, киявең кайчан күчеп килә соң? Бәлки, бүгенгә генә...

Октябрина. Әни, вакытым юк, соңыннан! Килгәч сөйләшербез.

Сатыбал. Тукта! Атам!

Октябрина. Әй Алла! Уят әле шуны. Югыйсә берәрсенә инфаркт ясый бит. *(Китә.)*

Балбикә. Иртәгә Ташкентка киткәнче генә синдә яшәп торыр идем... Китте, ишетмәде... Әй язмыш!.. Алтмыш ел әлек шушында килен булып төшкән идем. Карт көнемдә куылып китәрмен дип кем уйлаган... Үзем гаепле, Октябринаны ничек тә туктаткан, атны саттырмаган булсам... Тимә... әтиең ачуланыр, дип карадым да бит, тыңламады шул...

Сатыбал *(йокы аралаш елый)*. Бәхетсез булдык!..

Балбикә. Әй, мескенем! Өнендә дә бәхет күрмәде, ичмасам, төшендә кайгырмасын әле. *(Уята.)* Сатыбал, тор! Гомереңне йоклап үткәрәсең бит. Сатыбал!

Сатыбал. Кайда? Кайда ул? Котлыбай! Дуэль! Атышабыз!

Балбикә. Кит, төзәмә мылтыгыңны! Юк монда Котлыбай!

Сатыбал. Кайда ул?

Балбикә. Белмим. Атышасы кеше шулай йоклап ятмый инде.

Сатыбал. Әй! Утырып кына торган идем, йоклаганмын да киткәнмен. Кайтмадымыни Котлыбаең?

Балбикә. Без аның белән аерылышабыз.

Сатыбал. Дөрес эшлисең. Күптән кирәк иде. Ташлап кит син аны, Балбикә. Эт көненә калсын! Ачыксын, кергә батсын. Кортлап бетсен. Кит. Барыбер сиңа тормыш күрсәтмәде. Их, яшь чакта бер-беребезгә өйләнешкән булсак!..

Балбикә. Ни сөйлисең син? Безнең бит әтиләр бертуган иде.

Сатыбал. Әнә шул туган булганга якын бара алмадым бит сиңа, ә бик ошый идең... Шуннан юлыма шушы каһәр суккыры килеп очрады.

Балбикә. Кем?

Сатыбал. Кем булсын – Шәмсебикә!.. Аңа ничек якынаерга белми йөргәндә, әнә шул Галинур нахал өйләнеп тә куйды. Шуннан соң беркемне дә якын күрә алмадым, шул дип ялгыз картайдым. Әй гомер!.. Төш кебек үтте дә китте. Кичә генә егерме яшьтә идек, кичке уеннарга чыга торган идек... Исеңдәме, синең белән минем әтиләр печәнне гел янәшә чабалар иде...

Балбикә. Исемдә.

Сатыбал. Җәй, печәнлек... Ул чакта көннәр дә хәзерге кебек караңгы, салкын түгел иде. Якты, җылы иде. Ничек әйбәт булган! Ә якында гына, исеңдәме, Күктау!.. Актау!.. *(Яшь аралаш.)* Имчәктау!..

Балбикә. Әйе шул... Сатыбал, куй, елама...

Сатыбал. Елыйм, Балбикә, елыйм! Кайда шул чактагы таулар?

Балбикә. Кайда булсын, әнә утыралар элеккеге урынында.

Сатыбал. Әй Балбикә! Без яшь чактагы таулар түгел бит алар! Тегеләр бит бөтенләй икенче иде! Биек! Мәгърур! Ә болар таумыни. Тфү! Үтте, барысы да үтте! Берни калмады. Ярый синең, ичмасам, балаларың бар,

ишәк сыман булса да бабаең бар. Ә мин... Гомер буе ялгыз!.. Тормыш заяга үтте, Балбикә, заяга!.. Шул үкендерә!

Балбикә. Үтте шул, үтте. Шушы Котлыбай дип, балаларым дип яшәдем. Ә алар... Бер тапкыр рәхмәт әйтмәде... Әй Ходаем! Нигә шундый икән бу тормыш? Менә хәзер Котлыбай мине өйдән куа!..

Сатыбал. Ничек «куа»? Ах оятсыз, нахал!.. Эт! Иманын укытам мин аның!.. Балбикә, сеңелкәем, елама.

Котлыбай керә.

Котлыбай. Тәк! Бу нәрсә?

Балбикә. Котлыбай!

Котлыбай. Мин сездән сорыйм: бу нәрсә? Ә?

Сатыбал. Ә-ә, дезертир! Кайттыңмы? Кил әле монда!

Котлыбай. Сез нәрсә эшли идегез монда көпә-көндез?

Сатыбал. Сине көттек! Тот! Үтерәм мин сине!

Котлыбай. Син бит минем хатынны кочаклап утыра идең!

Сатыбал. Кочакладым! Ә син нигә аны өйдән куасың? Ат, имеш!.. Бу бит кеше, хатын! Ат хатыннан кадерлерәкмени сиңа?

Котлыбай. Син ни аңлыйсың? Ул Акбүз атымны үтерде! Өлгернең токымын! Сугыш алдыннан Башкортстанны шаулаткан, Мәскәү күргәзмәсендә булган Өлгернең токымын! Мине сугышта үлемнән коткарган Өлгернең! Мин аның токымын беркайчан да корытмамын дип ант иткән идем! Шул атны саткан! Ит өчен! Мин шушында каршыгызда торам, ә эчем яна, сызлый! Аңлыйсызмы шуны? Ә син, атның ни икәнлеген белмәгән адәм, монда килеп... Югал күземнән!

Сатыбал. Юк, башта атышабыз!

Котлыбай. Аңгыра! Үтерәм! Бир мылтыкны!

Балбикә. Йа Ходаем!

Сатыбал. Балбикә, читкәрәк кит. Каны чәчрәмәсен!

Котлыбай. Иманын укытам!

Сатыбал. Балбикә, бар, мулла чакыр, кабер казырга куш. Күмәбез, Алла боерса.

Котлыбай. Әйе, казысыннар. Тик мулласы кирәкми. Сиңа бер тиен дә жәл. Ясинсыз күмәбез.

Балбикә. Туктагыз хәзер үк!

Котлыбай. Кит, дим!

Сатыбал. Бар, бар, кәфен әзерлә мәрхүмгә. Әй әйбәт кеше иде!..

Балбикә. Әй, чукынып китегез! *(Өйгә кереп китә.)*

Алгы планда ике бабай дуэльгә әзерләнә: мылтыкларын коралар, атышырга урын әзерлиләр, араны адымлап үлчиләр һ. б.

Сатыбал. Ничек аталар моны?

Котлыбай. Эндәшмә!

Сатыбал. Соң, әйт: минем бит мылтык тотканым юк.

Котлыбай. Надан!

Сатыбал. Көл, көл! Иманыңны укытам хәзер синең. Тукта, ашыгып атма. Мин атарга өлгермим бит.

Котлыбай. Тагын нинди үтенечең бар?

Сатыбал. Ерактан минем күзем күрми. Өч метрдан атышабыз.

Котлыбай. Бәлки, түшкә түш терәшеп атышырбыз?

Сатыбал. Ә нигә? Бик дөрес. Пуля читкә китмәс.

Октябрина белән Закирҗан килеп керә.

Закирҗан. Тукта! Сөйлә яхшылап. Нәрсә дидең Сажидәгә? Минем хакта ни әйттең?

Октябрина. Башта әниеңнән сора: минем хакта Котдуска нәрсә чәйнәде икән?

Закирҗан. Әнием? Котдуска?

Октябрина. Барып, әллә нәрсәләр сөйләп кайткан! Оятсыз! Өендә юк икән. Кайтсын гына әле, кирәген бирәм!

Закирҗан. Котдус отбой бирдеме? Хи-хи-хи! Шәп!

Октябрина. Шәпме? Менә мин дә сине Сажидәгә якын килмәслек иттем! Шәпме?!

Закирҗан. Мин бит аңа өйләнергә йөри идем! Өйләнергә.

Октябрина. Өйләнмирәк тор! Сәҗидәгә дөнья күтәрдәй ир кирәк. Син түгел, алкаш!

Закирҗан. Нахалка! Менә күрерсең: мин барыбер аңа өйләнәм.

Октябрина. Бар, өйлән! Мин аңа бөтенесен дә әйттем: бер тиен дә акчасы юк, әйберләрен урлап сата, эчә, кыйный, дидем.

Закирҗан. Нигә юкны сөйлисең? Нәрсәне урлап саттым? Кемне кыйнадым?

Октябрина. Кыйнамасаң ни? Анда минем эшем юк!

Закирҗан. Их!.. Хәзер Сәҗидә мине тупсасына да бастырмаячак! Нигә эшләдең моны? Мин ялыктым ялгыз тормыштан! Минем дә бит әйбәт хатынга өйләнеп, дөнья корып яшисе килә!.. Нигә син миңа өйләнергә бирмисең?!

Октябрина. Кара син аны! Әйбәт хатын кирәк икән! Мине ташлап китмәскә иде вакытында! Кадеремне белмәдең, дурак! Хәзер шуның үчен алам. Кеше көлкесенә каласың алда әле!.. Ә бу ике дивана ни кылана?

Котлыбай. Кит моннан, дошман!

Закирҗан. Хәзер миңа Башкортстаннан читкә, син белмәс җиргә китеп өйләнергәме?

Октябрина. Сатыбал абый, бу ни эшләвегез?

Сатыбал. Октябрина кызым, үпкәләмә, хәзер сине ятим калдырам.

Октябрина. Закирҗан, нәрсә карап торасың? Туктат!

Закирҗан. Хәзер туктатам! Ат кайда?

Котлыбай. Кирәк урында!

Закирҗан. Кая яшердең? Ул минем ат!

Котлыбай. Менә сиңа ат! Кит моннан!

Закирҗан. Ух!.. Нәселегез белән эт сез!

Октябрина. Бирегез мылтыкны!

Котлыбай. Якын килмә!

Сатыбал. Октябрина кызым, ул корылган.

Октябрина. Төзәмә, төзәмә! Атыла бит! Закир! Үтерешәләр бит!

Закирҗан. Аларга күптән үләргә вакыт!

Шәмсебикә керә.

Әни, көрәк кайда? Кабер казырга кирәк.

Шәмсебикә. Атак, кем үлде?

Закирҗан. Котлыбай карт.

Шәмсебикә. Йа Ходаем! Яңа гына тере иде бит! Ни булды?

Котлыбай. Мин синең үзеңә ясин чыкмакчы әле!

Шәмсебикә. Ай, аты коргыры! Кешенең йөрәген алды!.. Атак! Нәрсә эшләргә йөрисез сез?

Октябрина. Кил әле монда, карт кәҗә!

Шәмсебикә. Ни булды?

Октябрина. Син нәрсә сөйләдең Котдуска минем хакта? Ә?

Шәмсебикә. Сөйләдем. Ялкау, дидем, эчә, дидем, гүләйт итә, дидем. Шуннан ни эшләтерсең?

Октябрина. Гайбәтче! Минем эчкәнне кайда күргәнең бар? Кем белән гүләйт иттем?

Шәмсебикә. Итмәсәң ни? Котдус бит аны белми.

Октябрина. Оятсыз син! Нигә кысыласың минем тормышыма? Ни хакың бар?

Шәмсебикә. Юри кысылдым. Котдуска чыкмасын дип. Вәт!

Октябрина. Нәрсә эшләдем мин сиңа шулхәтле? Нигә мине шулай күралмыйсың? Ичмасам, карт көнемдә эчмәгән ир белән яшәп карарга хакым бармы минем? Их сез!.. Нигә шулай бәхетсез соң мин?

Шәмсебикә. Октябрина, кызым! Мин бит сине уйлап эшләдем моны. Котдус белән барыбер бәхетле булмас идең. Ул кеше сөймәс бәндә, саран. Сез бит Закирҗан белән бер-берегез өчен яратылгансыз. Өйләнешегез! Яңадан икәүләшеп кайтыгыз шушы өйгә!

Октябрина. Кирәге бар иде алкашыңның!

Закирҗан. И аждаһа! Мин синең белән янәшә утырып...

Мылтык тавышы.

Сатыбал. Әй Алла!

Котлыбай. Аттыңмы?

Сатыбал. Аттым.

Котлыбай. Ах! *(Егыла.)*

Октябрина. Әти!

Шәмсебикә. Котлыбай!

Закирҗан. Нәрсә эшләдең син?

Сатыбал. Мин бит... ялгыш. Шушы җиренә баскан идем...

Октябрина. Закирҗан, врач!

Котлыбай. Кирәкми!.. Сизәм: соңгы минутларым килде...

Өйдән Балбикә чыга.

Балбикә. Кем атты? Котлыбай! Кайсы, кайсы җиренә тиде?

Сатыбал. Йа Ходаем! Менә бит...

Котлыбай. Балбикә, үләм, бәхил бул. Их, ялгыш яшәгәнмен! Сине юкка кыерсытканмын. Ә бит кешегә бөтенләй аз кирәк. Иң мөһиме, изге булырга кирәк. Шуны соң аңладым, соң. Балбикә, сиңа барысы өчен дә рәхмәт. Әгәр тере булсам, мин сиңамы... үзем чәй кайнатып эчерер идем! Их!

Балбикә. Котлыбай!

Котлыбай. Закирҗан, улым!

Закирҗан. Әү, Котлыбай абый!

Котлыбай. Сине дә кыерсыткан чакларым булгандыр... Ачуланма миңа.

Закирҗан. Юк, юк...

Котлыбай. Дөлдөл теге очта, Сәгыйтьнең сараенда. Барып ал, тик сатма. Дөлдөл бит...

Закирҗан. Юк, сатмыйм...

Котлыбай. Шәмсебикә... Сатыбал, син дә кил бирерәк.

Сатыбал. Котлыбай, мин бит...

Котлыбай. Ярый, үкенмә... Көнем беткәндер инде... Сез өйләнешегез. Октябрина...

Октябрина. Әти!..

Котлыбай. Кызым!.. Син бит минем иң яраткан кызым!.. Син бөтен ягың белән миңа охшагансың...

Бәхетле бул! Мин санаторийга китешли райсобеска кереп сиңа пенсия эшләттем. Киләсе айдан акча ала башларсың...

Октябрина. Әти, әтекәем минем!..

Котлыбай. Их! Кызым! Усал булдым! Явыз булдым! Шуңа җәфаланам. Явызлык явызлык тудыра. Изге күңелле бул. Сиңа васыятем шул. Изге эшләреңә изгелекләр килер... Ах!

Шәмсебикә. Үлде!

Балбикә. Тол калдым!

Октябрина. Әти! Әтекәем!

Сатыбал. Их, мин! Ахмак!

Закирҗан. Шундый шәп кеше иде! Әгәр йөрәгенә тимәсә, бәлки... Тукта, йөрәгенә тимәгән!.. Ә кайсы җиренә тигән соң?

Шәмсебикә. Улым, шуны тикшерер вакытмы соң? Бар, кабер казыт!

Закирҗан. Соң, пуля тигән урын юк бит!

Котлыбай. Ничек «юк»? Булырга тиеш, яхшылап кара!

Закирҗан. Тере! Үлмәгән әле! Врач кирәк, врач!

Сатыбал. Кайгырмагыз, хәзер үлә.

Котлыбай. Шунда кара, шунда! Күренмиме тишек?

Закирҗан. Юк, дим бит, юк!

Котлыбай. Соң, син ничек кордың мылтыгыңны?

Сатыбал. Син ничек, мин дә шулай.

Котлыбай. Дробь салмадыңмы әллә, булдыксыз?! Менә шушыларны!

Сатыбал. Аларны да салырга кирәк идемени?

Котлыбай. Тфү, надан! Кешечә яши белмәдең, ичмасам, адәмчә атар идең! Холостой выстрел булган бит! Холостой! Атмаган! Тимәгән!

Барысы бергә. Котлыбай!

Котлыбай. Иптәшләр! Тавыш! Бая әйткән сүзләремнән баш тартам. Алар ялгыш әйтелде. *(Балбикәгә.)* Кит моннан!.. Китер мылтыгыңны! *(Кора башлый.)*

Балбикә өйгә керә.

Октябрина. Ничек «ялгыш»? Миңа син пенсия эшләмәдеңмени?

Закирҗан. Октябрина, сельсовет председателен очраткан идем. Сиңа тәүге пенсия килгән, кереп алсын, диде.

Октябрина. Закирҗан! Чынмы?! *(Кочаклый.)*

Закирҗан. Кысып үтерәсең бит!

Октябрина. Түз! Сине утыз биш ел буе кочаклаганым юк бит.

Шәмсебикә. Балаларым! Өйләнешегез кире! Шушы өйгә кайтыгыз! Яшәгез рәхәтләнеп!

Октябрина. Синең беләнме?

Шәмсебикә. Мин Сатыбалга күчәм.

Сатыбал. Шәмсебикә!

Котлыбай. Тукта! Нигә хуҗа булып киттегез? Беркем беркая да күчми! Хәзер атышабыз! Тот!

Сатыбал. Юк. Шәмсебикә мине сайлады. Бәхәс бетте. Атышмыйбыз.

Котлыбай. Атышабыз! Тот, дим мин сиңа! Тот! Китегез моннан!

Октябрина. Закирҗан!

Закирҗан. Җитте! Утыз биш ел сине тыңладык. Хәзер мине тыңла! Без Октябрина белән... өйләнешәбез! Шушы өйдә яшибез.

Октябрина. Закирҗан! Күпме көттем шушы сүзеңне.

Шәмсебикә. Һай, улым! Әйтсә әйтә бит!

Сатыбал. Рәхмәт, Закирҗан улым!

Котлыбай. Туктагыз! Син кем монда боерык бирергә? Атышабыз – баста!

Закирҗан. Юк! Бир мылтыкны! *(Тартып ала.)* Бетте! Бу дөнья да, ат та минеке!

Котлыбай. Тукта, ничек? Ә мин? Мин...

Сатыбал. Хи-хи! Менә сиңа ат! Менә сиңа Шәмсебикә! *(Кукиш күрсәтә.)*

Өйдән Балбикә чыга. Кулында сумка.

Октябрина. Әни, кая җыендың?

Балбикә. Ташкентка, сеңлемә. Инде кайтып бу җирләрне дә, сезне дә күрә алмам. Бәхил булыгыз!

Октябрина. Әни! Ул ни дигән сүз? Ә без, әтием синсез ни эшләр?

Балбикә. Сез гомер буе минем белән исәпләшмәдегез. Мин сез дип яшәдем, ә сез үзегездән башканы күрмәдегез, кадеремне белмәдегез. Киттем. Хушыгыз!

Котлыбай. Балбикә! Ярый, китәрсең. Тик мине күмгәч. *(Закирҗаннан мылтыкны тартып ала.)* Бәхил булыгыз!

Барысы бергә. Ни эшлисең?! Ташла мылтыгыңны!

Барысы да Котлыбайга ташлана.

Атма! Атылма! Тукта!

Мылтык тавышы. Котлыбайдан башкалар егыла.

Барысы бергә. Ах!

Котлыбай. И Ходаем! Балбикә! Октябрина, кызым! Бәй, үлмәгәнсең бит, нәрсә карап ятасың?

Октябрина. Кара, бер җиремә дә тимәгән! Кешене куркытты! Закирҗан!

Закирҗан. Мин дә исән!

Шәмсебикә. Атак! Мин дә тере инде әллә? Сатыбал!

Сатыбал. А-а! Бәй, синме? Теге дөнья дип торам.

Барысы бергә. Балбикә! Балбикә! Үлгән! Әй Алла!

Октябрина. Әнекәем!

Котлыбай. Балбикә! Карчыгым! Кичер акылсыз картыңны!

Балбикә. Тс-с!

Барысы бергә. Тере! Үлмәгән!

Балбикә. Ат чапкан тавыш ишетелә! Акбүз ат тояклары!

Ат чапкан тавыш көчәя бара. Ат кешни.

Әнә килә! Әнә! Акбүз ат!

Барысы бергә. Акбүз ат бит! Акбүз ат үзе!

Котлыбай. Акбүз атым! Качып кайткан! Балбикә, карчыккаем!

Балбикә. Кит әле моннан! Хуш!

Котлыбай. Юк-юк! Мин сине җибәрмим! Китмә!

Балбикә. Китмә, дисеңме? Алайса, шартым бар.

Котлыбай. Әйт!

Балбикә. Җитәр, картайдың. Атны Закирҗан кияү караячак. Булдымы?

Котлыбай. Булды, карчык, риза. Иң мөһиме: Акбүз ат тере һәм без яңадан бергә.

Барысы бергә. Акбүз ат! Акбүз ат!

Хайванның да җаны була.
Аңа бик авыр читтә.
Ул сагына туган җирен
Һәм кайтыр көнне көтә.

Әнә, әнә ул күренде!
Куаныч чолгый күңелне!
Бөтенебезне куандырып,
Сөйгәннәрне кавыштырып,
Тоякларын тыпырдатып,
Районда беренче ат —
Акбүз ат кайтып килә!

Пәрдә.

1992

АВЫЛГА КЫЗЛАР КИЛДЕ,
ЯКИ
МОҢНАР КАЙТСЫН АВЫЛГА

Комедия, ике пәрдәдә

Катнашалар:

Раилә.
Нурания.
Кәүсәрия.
Ләйсән.
Мәстүрә.
Әмир.
Хәйбулла.
Әхтәм.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авыл өенең ишегалды. Тәрәзә төбендә, йә булмаса, постамент кебек берәр җирдә баян тора. Мәстүрә өстәл әзерли.

Мәстүрә. Кайда йөри икән бу Әмир?

Әмир керә.

Әмир. Хәерле көн, Мәстүрә апа!

Мәстүрә. Хәерле көн, Әмир! Сине генә искә төшереп тора идем.

Әмир. Ни булды?

Мәстүрә. Соң, сәгать алтынчы китте. Хәзер килеп җитәләр бит. Ә берни дә әзер түгел.

Әмир. Менә кыяр, помидор, торт. Табын әйбәт булсын! Күңелләрен эретерлек! Тегеләр күренмиме әле?

Мәстүрә. Юк. Ай Аллам, мунча да ягарга кирәк бит инде. Шәһәр кешеләре мунча ярата торган иде. Ә минем утыным да беткән.

Әмир. Ул кадәр мескенләнеп торма әле. Мунчага бер кочак утын җитә.

Мәстүрә. Ягарлыгын җәй буена ягып бетердем, урманда киселгәне ята, шуны китерергә бер тракторист табып булмый.

Әмир. Ул трактористлар белән не знай. Бөтен нервыны бетерделәр!

Мәстүрә. Барысына да берүзең шул. Өлгермисеңдер.

Әмир. Авыл хакимияте башлыгы вазифасы биргәннәренә ярты ел. Куярлык бер кеше табып булмый. Берсе эчә, икенчесе йомшак, өченчесе ялкау.

Мәстүрә. Юк шул, юк.

Әмир. Кара, һаман күренмиләр бит бу җилкуарлар, ә вакыт үтә.

Хәйбулла белән Әхтәм керә. Хәйбулла бер кочак утын күтәргән.

Әхтәм. Саумысыз!

Хәйбулла. Рита, Рита, Маргарита! Мәстүрә апага кайнар сәлам!

Мәстүрә. Исәнмесез, егетләр! Вәт афәрин, Хәйбулла энем. Утыным бетә дип уйларга да өлгермәдем, инде күтәреп тә киләсең. Бар, мунчага кертеп сал.

Хәйбулла. Мин бит күрәзәче, кешенең ни уйлаганын белеп торам. *(Китә.)*

Әмир. Күрәзәче булсаң, күптән урманнан утын китерер идең. Кайда йөрисез йоклап?

Әхтәм. Син бит бишкә чакырдың.

Әмир. Ә хәзер сәгать ничә?

Әхтәм. Как раз... Алтынчы унбиш минут.

Әмир. Унбиш минут!.. Монда һәр секунд кадерле. Йә, клуб әзерме?

Әхтәм. Анда эш күп әле. Нигә чакырдың?

Әмир. Сезне уйлап. Ятасыз бит эшегез беткән кебек. Көне-төне эчеп.

Әхтәм. Мин бит бөтенләй эчмим.

Әмир. Эчсәң, бәлки, эшләр идең! Эчмисең дә, эшең дә бармый.

Әхтәм. Тотасың да шулай дисең, Әмир абый. Менә быел гына Яңа елдан бирле унсигез мероприятие үткәрдек. Анда 176 кеше...

Әмир. Ташла шул кәгазьләреңне! Клубның тәрәзәсе ватык. Түшәме агартылмаган, эче тузанга баткан, тупсасы җимерек. Ә син җыр язып утырасың!

Әхтәм. Син бит миннән ачкычны тартып алдың!

Әмир. Булмый синнән! Тагын бер тикшерәм дә. Әгәр бүгенге концертка клубны җиренә җиткереп әзерләмәсәң хушлашабыз, энем!

Әхтәм. Синең мине куарга хакың юк. Мин районның мәдәният бүлегендә эштә торам.

Әмир. Телеңә салынма, аңладыңмы?

Әхтәм. Аңладым ла... Аларның үзләренең аппаратуралары бармы икән? Югыйсә бездә баян да юк.

Әмир. Булмас шул, өр-яңа баянны юл уртасына салып таптаткач.

Хәйбулла керә.

Әхтәм. Концертка алып барабыз дип чыгарган җирдән... Менә бу бит!..

Хәйбулла. Нәрсә «бу»?

Әхтәм. Баян турында сөйләшәбез. Син трактор белән таптамасаң...

Хәйбулла. Һаман шул бер балык башы. Ярты елда күптән баян алыр идегез!

Мәстүрә. Баян табуы кыен түгел, моң табуы авыр.

Әмир. Бигрәк телләнеп киттегез! Нәрсә, кулың рәтләндеме? Утын күтәреп йөрисең.

Хәйбулла. Мин сул кул белән бит.

Әмир. Эчеп йөрсәң, башсыз да калырсың әле, малай! Бөтен кеше печәндә, ә син... Утыр, нәрсә терәлеп каттың? Мәстүрә апа, кил әле!

Мәстүрә. Ярый-ярый, мин йөри-йөри тыңлармын. Югыйсә эшем күп, син сөйлә.

Әмир. Утырыгыз! Димәк, болай. Егетләр, житте! Өйләнәбез! Бетте-китте.

Хәйбулла. Нәрсә? Өйләнәбез?

Әхтәм. Ничек? Кемгә?

Хәйбулла. Авылда бит кызлар юк!

Әмир. Бүген безгә «Кызлар» ансамбле килә. Без өчәү аларны фатирларга бүлеп алабыз да... таңга хәтле өйләнәбез.

Хәйбулла. Тукта-тукта. Беренчедән, мин өйләнергә җыенмыйм, үземне чак карыйм. Ишшу хатын, балалар... Юк!

Әмир. Утыр, син үзеңне уйлама! Авылны уйла! Биш-алты ел авылда бала туганы юк! Әнә мәктәпне ябып куйдылар. Әгәр һәр егет шулай дип әйтә башласа, авыл бетә! Аңлыйсыңмы шуны?

Хәйбулла. Бездә өйләнмәгән утыз егет бар. Нигә мин? Башканы чакырырга иде.

Әмир. Авылда без бүген өчәү генә калганбыз. Калганнар барысы да печәндә. Концертка гына кайталар. Хәзер мин утыз чакрымга машина җибәримме? Анда-монда алтмыш чакрым. Аңа күпме бензин кирәк!

Хәйбулла. Ярый алайса. Кичкә хәтле берәрсен развлекать итеп торырмын. Ә ниндирәк кызлар алар? Ничәү, ничә яшьтә?

Әмир. Мәстүрә апа аларны калада концертта күргән. Яннарына кереп танышкан. Мәстүрә апаның Зирекледән икәнлеген белгәч, безгә килергә теләүләрен әйткәннәр.

Әхтәм. Үзләреме? Бу тиккә генә түгел!

Әмир. Бу — язмыш. Шуннан файдаланырга кирәк. Мәстүрә апа, сөйлә әле, ниндирәк кызлар?

Мәстүрә. Дүрт кыз. Яшьләре шул сезнең тирә булыр. Егерме белән утыз арасы.

Хәйбулла. Алар дүрт кыз, нигә без өчәү?

Мәстүрә. Мин дә шулай дигән идем дә...

Әмир. Әйтәм бит, егетләр концертка гына кайта. Икенчедән, табигать законы буенча, хатын-кызлар артык булырга тиеш. Сайлап алу өчен!

Хәйбулла. Монысы дөрес.

Әхтәм. Ә матурлармы икән соң?

Мәстүрә. Искиткеч матурлар! Ул буйлары, ул йөзләре!

Хәйбулла. Ярый, монысы аңлашылды. Ә ничек бүләбез?

Әхтәм. Мин яратмасам өйләнә алмыйм.

Әмир. Яратырлык булсаң, элек үк яраталар аны! Хәзер без кемне әйтәбез, шуңа өйләнәсең!

Әхтәм. Ничек? Мәхәббәтсезме?

Әмир. Нинди мәхәббәт? Мәхәббәт көтеп картайыйкмы? Бүгеннән никаких мәхәббәт!

Хәйбулла. Алдан әйтәм: иң матуры миңа!

Әхтәм. Нигә сиңа? Чүтеки мин завклуб, культура-агарту работнигы. Минем кәләш авылда иң чибәре булырга тиеш.

Хәйбулла. Синең буең кыска. Ә матур кызлар кыскаларны яратмый.

Әхтәм. Матур кызлар исерекләрне яратмый.

Хәйбулла. Рита, Рита, Маргарита! Кара, кинәт кенә Рита исемле кыз белән хат язышуым исемә төште.

Әмир. Ярый, егетләр! Матурлык буенча түгел, озынлык буенча бүләбез. Иң озын кыз – Хәйбуллага, уртанчысы – миңа, иң кыскасы – Әхтәмгә!

Хәйбулла. Менә болай гадел!

Әхтәм. Карагыз аны, әгәр иң кыскасы ямьсез булса, мин өйләнмим.

Әмир. Өйләнмәсәң, авылдан шагом марш! Иртәгә үк эзең булмасын!

Әхтәм. Син мине күптән куарга телисең! Чөнки икетуган энең Стәрле культпросвет училищесын бетерде. Шуңа эш кирәк. Мин сизми дип уйлыйсыңмы?

Әмир. Сине берәү дә кумый! Кал авылда, тик калырга теләсәң өйләнәсең! Баста! Мәстүрә апа аларны буйларына карап һәрберебезгә берәр кызны фатирга бүлгән. Хәзер сезгә исемнәрен әйтә.

Мәстүрә. Кайда куйдым әле кәгаземне? Ә, менә икән! Раилә исемлесе Әхтәмнәргә, Ләйсәне Хәйбуллаларга, Кәүсәриясе Әмирләргә!

Әхтәм. Ә дүртенчесе кайда?

Мәстүрә. Нурания исемлесе миндә йоклар.

Әхтәм. Анысының буе ничек соң?

Мәстүрә. Буе әйбәт. Тик шәһәр кызы. Әмир, өч егет булабыз, дигәч, өч кызны бүлдем инде үземчә. Алар өчесе дә авыл кызлары.

Хәйбулла. Ә алар үзләрен нәрсә көткәнлеген беләләрме соң?

Әмир. Белүләре кирәк тә түгел. Һөҗүмне көтмәгәндә ясыйбыз и баста! Чапай кебек. Кияүгә чыкканнарын сизми дә калсыннар.

Мәстүрә. Алла боерса, әйбәт итеп туй үткәрсәк... Минем сезгә матур гына туй бүләгем дә бар.

Хәйбулла. Ай-һай, егетләр, авантюра бу!

Машина тавышы.

Әхтәм. Килделәр!

Раилә, Нурания, Кәүсәрия, Ләйсән керәләр.

Кызлар. Исәнмесез!

Егетләр. Исән әле.

Мәстүрә. Әйдәгез, түрдән узыгыз. Көтеп кенә тора идек.

Әмир. Егетләр, ярдәм итегез! Рәхим итегез! Башта танышыйк. Бу – Мәстүрә апа. Шушы өйнең хуҗасы. Мин – шушы авылның председателе, исемем Әмир. Болар – безнең егетләр. Хәйбулла – тракторист, шофёр. Әхтәм – завклуб.

Раилә. Мин – Раилә.

Әмир. Бик шатбыз! Ә кызларның исемнәре ничек?

Раилә. Кәүсәрия – безнең биюче. Ләйсән – җырчыбыз. Нурания – юморескалар укый, бии дә белә. Ә мин – төркемнең җитәкчесе, конферансье.

Хәйбулла *(Әхтәмгә)*. Куан! Без уңдык! Иң ямьсезе Әмиргә!

Әмир. Концертны ничәдә башлыйбыз? Без тугызда дип уйлаган идек.

Раилә. Кунак – хуҗаның ишәге. Халыкны ничәдә җыясыз, шунда башлыйбыз. Тик юлдан соң юынып алырга иде.

Мәстүрә. Шуны уйлап, мунча ягып куйдым бит. Хәзер әзер була.

Раилә. Бик әйбәт! Концертка хәтле тиз генә юынып чыгарбыз. Тагы... безнең машинага әллә ни булды, бөтенләй тартмый. Шуны иртәгә хәтле рәтләп куймассызмы?

Әмир. Шофёрыгыз кайда?

Раилә. Юк, без дүртәү генә. Машинаны арендага алдык. Мин йөртәм.

Әмир. Хәйбулла, ишеттеңме? Машиналары кичкә сәгать кебек эшләп торсын.

Хәйбулла. Минем вакытым юк! Клубтагы утны рәтләргә кирәк.

Әмир. Тырышсаң табарсың!

Хәйбулла. Есть!

Әмир. Барысы да ал да гөл булачак!

Мәстүрә. Юлдан соң ачыккансыздыр. Юынып-киенеп алыгыз. Шуннан бергәләп чәй эчәрбез. Кул юарга — монда. Ә сез, егетләр, әйдәгез, кызлар әзер булганчы, мунчаны карагыз, чишмәдән салкын су ташып куегыз.

Мәстүрә һәм егетләр чыгып китә.

Раилә. Бу кемнең сумкасы? Нурания, синеке бит? Нигә ташлап калдырдың? Кертеп куй, яратмыйм тәртипсезлекне.

Нурания. Кызлар, егетләр ошадымы?

Раилә. Син концертны уйла! Бер сәгатьтән барыгыз да әзер булырга тиеш!

Нурания. Курыкма. Булырбыз. Без детдомда егетләр күрсәк, кайсысына кияүгә чыгар идем дип хыяллана торган идек. Кәүсәрия, син шушы егетләрнең берәрсенә чыгар идеңме?

Кәүсәрия. Мин беркайчан да кияүгә чыкмыйм.

Нурания. Нигә?

Кәүсәрия. Егетләрнең барысы да... примитив! Алар эчке матурлыкны күрә белмиләр.

Нурания. Анысы дөрес! Бер елмаеп карадыңмы, артыңнан калмыйлар, тинтәкләр!

Ләйсән. Ә мин башта — сәнгать училищесын, аннан институтны бетергәч кенә кияүгә чыгам. Республикада билгеле кеше булачак ул. Җырчы йә композитор!

Нурания. Оһо! Раилә, ә син?

Раилә. Монда ашау-яшәү хәл ителмәгән! Ничек түләрләр! Ә аларда егет кайгысы! Миңа егетнең өе булсын, мал-туары! Хуҗа булсын ул.

Нурания. Ә мин берәр зур начальникка кияүгә чыгам.

Ләйсән. Начальникларның бөтенесе дә карт яки пеләш!

Нурания. Зато фатиры, машинасы, дачасы була.

Ләйсән. Алайса чык әнә Кәүсәриянең Габдрахман Сабировичына.

Кәүсәрия. Тоталар да шул бабайны миңа тагалар.

Ләйсән. Соң, сине яучылый бит.

Кәүсәрия. Мин ризалык биргәнме?

Нурания. Аның машинасы иске, «Москвич» кына.

Раилә. Кара! Әллә Габдрахман Сабировичны тартып алырга ниятең бар идеме?

Нурания. Кит әле! Ул минем өчен бигрәк бәләкәй начальник.

Ләйсән. Кәүсәрия, әллә үпкәләдеңме?

Кәүсәрия. Тукта әле, алкам югалды.

Ләйсән. Кайсы алкаң? Теге чәчкәлеме?

Кәүсәрия. Әйе.

Раилә. Кичә генә колагыңда иде бит.

Кәүсәрия. Сумкама салган идем, ә бүген карасам – юк!

Нурания. Ярый, кайгырма шулхәтле. Яңасын алырсың!

Кәүсәрия. Ул алка миңа талисман кебек иде. Таксам – юлым уңа, такмасам...

Нурания. Бу авылда уңмаса да ярый, барыбер матур егетләр юк.

Кәүсәрия. Моннан биш ел элек мин армиядә хезмәт иткән бер егет белән хат алышкан идем. Шушы авылныкы. Роберт исемле. Мин авылдан киткән чагында аны икенче частька күчергәннәр дә, арабыз өзелде. Адресы югалды.

Ләйсән. Бәлки, очрашырсыз әле.

Кәүсәрия. Юк, юлым уңмый...

Нурания. Кибетләренә чыгып керим әле. Ислемай, кремнар юк микән?

Нурания урамга чыга, Раилә өйгә керә.

Ләйсән. Кәүсәр, беләсеңме?.. Бүген машинада Нурания синең сумкаңны актарып утыра иде.

Кәүсәрия. Кайчан?

Ләйсән. Иртән. Мине күрде дә тиз генә урынына куйды. Алкаңны шул гына алган!..

Мәстүрә, Әмир, Хәйбулла, Әхтәм керә.

Мәстүрә. Кайда башкалар? Чакыр, бергәләшеп чәй эчеп алыйк.

Ләйсән. Нурания кибеткә китте. Раилә!

Өйдән Раилә чыга.

Әмир. Әйдәгез, рәхим итегез. Егетләр, нәрсә карап торасыз багана сыман, якынрак килегез.

Нурания керә.

О, менә Нурания дә керде! Әйдә, утыр.

Утырышалар. Нурания янына Әхтәм утырырга җыена. Әмир аны куып җибәрә. Әхтәм Нурaниянең икенче ягына бара. Ләкин анда Хәйбулла утыра. Нурания үзе аның янына барып утыра.

Әхтәм. Миңа кайда утырырга?

Хәйбулла. Әнә теге якка!

Мәстүрә. Туктагыз әле! Үзем командовать итәм.

Әмир. Иптәшләр! Монда Мәстүрә апа хуҗа! Аны тыңлыйбыз.

Мәстүрә. Мәрхүм әтием кунак җыйса, һәркемне үзе утырта иде. Әмир, Хәйбулла, торыгыз! Нигә кызлардан алда утырдыгыз? Әмир, кил, син хуҗа буларак менә монда утыр. Кәүсәрия кызым, утыр янына. Әхтәм, син – монда! Раилә кызым, кил, утыр. Вәт шулай! Хәйбулла, бу урын сиңа! Кечкенә кызның исеме ничек әле?

Ләйсән. Ләйсән.

Мәстүрә. Ләйсән, син менә монда утыр, булдымы? Нурания кызым, кил монда, яныма.

Раилә. Ә нигә шулай парлаштырып утыртасыз? Һәркем үзенчә утырсын!

Мәстүрә. Юк! Табында һәрчак менә шулай аралашып утырырга кирәк: егет, кыз, егет, кыз! Ул чакта кызларга да күңелсез булмас, югыйсә кайсыбер табыннарда карыйсың, ир-ат бер якта, икенче якта кызлар утыра, нәрсә хакында сөйләшергә белмичә. Егетләр, янығыздагы кызларга ныклап карап куегыз. Сез шуларны концерттан соң үзегезгә алып кайтырсыз.

Раилә. Мәстүрә апа, сез ялгыз яшисез түгелме? Бәлки, без дүртебез дә монда калырбыз?

Мәстүрә. Миңа шәһәрдән туганнарым кайта шул.

Миндә Нурания генә йоклар, сез борчылмагыз. Бу егетләрнең барысының да әти-әниләре бик әйбәт кешеләр. Матур итеп кунак итәрләр, һәм барыгызга да аерым бүлмә булыр. Әйдәгез, булганыннан рәхим итегез.

Нурания. Миңа шикәр бирегез әле.

Әхтәм белән Әмир ашыгып торып шикәр савытын алырга сузылалар. Әмир, Әхтәмнең кулын этеп, Нуранияга шикәр савытын үзе алып бирә.

Әмир. Менә, Нураниякәй!

Нурания. Рәхмәт. Балкашыгы да бирсәгез.

Балкашыгына Әхтәм дә, Әмир дә сузыла. Әхтәм алдан өлгерә.

Әхтәм. Рәхим итегез!

Нурания. Рәхмәт! Мәстүрә апа мине читкә утыртты да, бөтен нәрсә ерак. Икмәк тә кирәк иде. Хәйбулла, бир әле?!

Хәйбулла. Миңа да ерак.

Мәстүрә. Кыз кеше сорагач, алып бир, Хәйбулла.

Хәйбулла. Әхтәм, алып бир. Сиңа якынрак!

Әхтәм савыт белән икмәк бирә.

Әхтәм. Рәхим итегез.

Раилә. Нурания, нигә егетләрне аптыратасың? Үзең ала алмыйсыңмы?

Нурания. Сиңа рәхәт, өстәл уртасына утыргансың да!..

Мәстүрә. Раилә, борчылма. Бер кыенлыгы да юк. Безнең егетләр әнә шулай итагатьле, бик культурный. Аларга кызларның үтенечен үтәү – үзе бер куаныч.

Әмир. Мәстүрә апа, дөрес! Безгә үтенеч кенә булсын, аны үтәү чүп!

Раилә. Үтенеч дигәннән, түләү мәсьәләсен сөйләшеп куйыйк әле.

Әмир. Аны соңрак.

Раилә. Ә нигә? Минем яшерер серем юк. Күпме түлисез?

Әмир. Йомырка белән түләрбез.

Раилә. Без бары тик акчалата гына алабыз.

Әмир. Йомырканы сатасыз, менә сезгә акча!

Мәстүрә. Әмир улым, алай димә инде. Акчалата түлә дә куй!

Әмир. Ух, тереләй туныйсыз! Күпме кирәк?
Раилә. Ике мең!
Әмир. Ярый, безгә ошадыгыз,түләрбез.
Раилә. Кайчан?
Әмир. Хәзер! Ике мең... Менә!
Раилә. О! Рәхмәт! Димәк, йокларга урын бар, ашау-эчү була. Ә клуб ни хәлдә?
Әмир. Әзер булачак! Хәзер чәй эчик тә, аннары барып җиренә җиткерәбез.
Раилә. Зур рәхмәт! Менә хәзер күңелем тынычланды. Кая барсак та, менә шушы бәләкәй генә проблемаларны хәл итү өчен генә дә көне буе йөрергә кирәк. Ә сезнең белән бер минутта аңлаштык та куйдык. Мәстүрә апа, председателегез бик шәп кеше икән!
Мәстүрә. Бездә бөтен егетләр дә шәп, Раилә кызым, ул өлгер, ул уңган. Эчми, тартмый. Тик менә авылда кызлар гына юк...
Әмир. Мәстүрә апа, бик мескенләнеп китмә әле! Теләсәк, кызларын да табарбыз, башкасын да. Безгә бит менә сезнең кебек матурлар кирәк. Ә матурлар бик сирәк. Шуңа күрә өйләнә алмый йөрибез. Ә менә сез безгә ошадыгыз! Сезне авылдан җибәрмәгәндә бик шәп булыр иде! Шулай бит, егетләр?
Егетләр. Шулай! Әйе!
Нурания. О! Акылыгыз алтын икән! Ә машиналарыгыз бармы?
Әмир. Минеке бар.
Нурания. Нинди марка?
Әмир. «Мерседес»! Украинский!
Нурания. Ә синеке?
Хәйбулла. Минеке Белорусский!
Нурания. Ә дачаларыгыз?
Әмир. Безнең бакчалар – во! Дачаң читтә торсын!
Раилә. Нурания, йөдәтмә егетләрне теләсә нинди сораулар белән! Миңа варенье бирегез әле?..
Нурания. Җибәрмибез, диләр бит! Тикшерергә кирәк, калырлыкмы-юкмы.
Әмир. Анысы дөрес! Безнең егетләр...
Мәстүрә. Әхтәм, Раилә варенье сорый.
Әхтәм. Кем? Сезме? Рәхим итегез!

Әмир. Син йоклап утырма!

Ләйсән. Минем дә баядан бирле әнә теге кәнфитләргә күзем төшеп утыра да ул...

Мәстүрә. Хәйбулла!

Хәйбулла. Әү!

Мәстүрә. Ишетмисеңмени?

Хәйбулла. Нәрсәне?

Әмир. Колак! Син әзрәк кенә кызлар сүзен тыңлабрак утыр!

Мәстүрә. Ләйсәнгә кәнфит кирәк!

Хәйбулла. О! Рита, Рита, Маргарита! Пожалуйста!

Кәүсәрия. Ә сезнең авылда Роберт исемле егет бармы?

Хәйбулла. Роберт?

Мәстүрә. Юк, андый исемле егет юк, югары оч Хисамның ун яшьлек малаеннан башка.

Кәүсәрия. Чәемне алып бирегез әле?

Кәүсәриянең үтенечен ишетүче юк.

Әмир. Нурания, безнең авыл ошадымы соң сезгә?

Нурания. Бик ошый!.. Миңа да кәнфит бирегез...

Әмир белән Әхтәм йөгереп торып кәнфит савытына ябышалар. Әмир кәнфитне Нураниягә бирә.

Әмир. Сез безнең елга буйларын күрсәгез! Үзегезнең дә безнең авылдан китәсегез килмәс.

Нурания. Күрсәтегез – күрермен!

Әмир. Хәзер чәемне эчеп бетерәм дә күрсәтәм!

Кәүсәрия урыныннан торып китә.

Мәстүрә. Кәүсәрия кызым, тагын эч!

Кәүсәрия. Туйдым, рәхмәт!

Мәстүрә Әмиргә ымлый: янәсе, янына бар. Әмир кул селти.

Ләйсән. Әхтәм, сез баянистмы?

Әхтәм. Әйе.

Ләйсән. Ә «Соңгы мәхәббәт» җырын беләсезме?

Әхтәм. Беләм, әлбәттә.

Хәйбулла. Аның җыры бит ул! Белеп торыгыз, ул безнең композитор!

Ләйсән. Композитор? Синең фамилияң ничек?

Әхтәм. Шәйхисламов.

Ләйсән. Менә кызык! Бәләкәй генә авылда композитор яшәп ята! Минем беркайчан да тере композитор күргәнем юк.

Әмир. Композитор! Клубның идәнен юдырттыңмы?

Әхтәм. Юдырттым.

Әмир. Көй язу ансат ул! Клубны каравы авыр... Нурания, әйдә әле. Безнең табигать моннан матур күренә.

Әмир Нуранияне читкәрәк алып китеп кулы белән күрсәтә-күрсәтә нидер сөйли.

Ләйсән. Мин бит сезнең бер җырыгызны җырлыйм: «Акчарлаклар нигә талгын оча». Шундый матур җыр, ә соңгы вакытта нинди көйләр иҗат итәсез? Берәрсен уйнап күрсәтегез әле!

Әхтәм. Баян юк. Ә Нурания җырлыймы?

Ләйсән. Мин җырлыйм.

Әхтәм. Аны аңладым. Ә Нурания җырламыймы, дим?

Ләйсән. Юк, җырламый!

Әхтәм. Ә ни эшли?

Нурания. Әхтәм, алай күп төпченмә, җырчысыз каласың бит.

Раилә. Нурания, председательне аптыратма, утыр урыныңа!

Әмир белән Нурания өстәл янына утыра. Хәйбулла өстәл артыннан торып, Кәүсәрия янына килә.

Хәйбулла. Роберт кем ул сиңа?

Кәүсәрия. Анда ни эшең бар?

Хәйбулла. Ай-һай, усалсың! Мәхәббәтме?

Кәүсәрия. Мәхәббәт юк ул!

Хәйбулла. Дөрес!

Кәүсәрия. Син дә... шулай уйлыйсыңмы?

Хәйбулла. Әйе.

Кәүсәрия. Ә нигә?

Хәйбулла. Чөнки яратырлык егетләр юк. Барысы да бушкуык, исерек. Сволочь, бер сүз белән әйткәндә.

Кәүсәрия. Кайдан беләсең аны?

Хәйбулла. Мин үзем шундый.

Кәүсәрия. Кызык икән. Син дә эчәргә яратасыңмыни?
Хәйбулла. Авылда тракторист бул да эчмә, имеш.
Кәүсәрия. Алай бит ярамый.
Хәйбулла. Аңлыйм. Ә ни эшләргә?
Кәүсәрия. Тот та ташла эчүеңне.
Хәйбулла. Ничек ташлыйсың? Бөтен авыл эчә. Печән китерсәң – ярты, утын китерсәң – ярты!
Кәүсәрия. Сиңа өйләнергә кирәк.
Хәйбулла. Хатынны тыңламаячакмын мин. Туктатса, усал хатын гына туктатыр.
Кәүсәрия. Ә бәлки, киресенчә, йомшагы туктатыр? Сине аңлый торганы.
Хәйбулла. Бәлки... Сезнең арада кем йомшак? Раилә – Наполеон сыман. Нурания – үз-үзенә гашыйк дура. Ләйсән? Аңа эчкече түгел, композитор кирәк.
Кәүсәрия. Ә мин?
Хәйбулла. Синме? Син – хыялый.
Кәүсәрия. Ничек «хыялый»?
Хәйбулла. Безнең авылда әйбәт егет табармын дип хыялланасың. Белеп тор: картлар гына әйбәт була.
Кәүсәрия. Картлар? Юк! Алкамны тапсам, бәлки, юлым уңар иде. Мин аны югалттым, беркем дә тап булмаячак.
Нурания. Әй, сез, нигә анда икәүләшеп кенә серләшәсез?
Мәстүрә. Чынлап та, Хәйбулла, утыр урыныңа. Әмир, чакыр Кәүсәрияне яныңа!
Әмир. Кәүсәр! Кил, утыр!
Раилә. Тукта, аңламадым! Сезнең бөтенләй баяныгыз юкмыни?
Әмир. Бар иде. Бер... исерек таптап китте тракторы белән! Сволочь!
Раилә. Ә монда торган баян нәрсә?
Әмир. Ярамый.
Раилә. Нигә? Һәйкәл түгелдер бит?
Мәстүрә. Аңа тияргә беркемнең хакы юк.
Раилә. Безгә бит хәзер репетиция ясарга кирәк. Аппаратура юк, баян юк!
Әмир. Борчылмагыз. Күрше авылга киттеләр. Тиздән була.

Раилә. Залда, сәхнәдә ут бармы, ичмасам?

Әмир. Булачак! Алай булгач, Нурания биюче булып чыга инде?

Нурания. Әйе.

Әмир. Фигураң биюченекенә охшап тора шул!

Раилә. Кара әле, председатель! Клубың бөтенләй әзер түгел! Син шуны кайгырту урынына кызларның фигурасын тикшереп утырасың! Чәй эчеп утырыр вакыт түгел! Булды, рәхмәт! Концертка ике сәгать кенә вакыт калды! Әйдә, мунчага барсак барыйк та киттек клубка!

Әмир. Кайгырма, Раилә. Бөтенесе дә әзер булачак! Рәхмәт, Мәстүрә апа!

Хәйбулла. Сыең тәмле, кызларың матур!

Бөтенесе дә кузгала.

Мәстүрә. Файдага булсын! Нурания, савыт-сабаны юып ал, син хәзер монда хуҗабикә. Кызлар, сез мунчага әзерләнегез! Ул инде әзердер. Мин хәзер карап кайтам да... Хәйбулла! Ибрай абыеңа барып, каен себеркесе алып кил. Ул миңа мәтрүшкәләп бәйләп бирергә тиеш иде. Шушы кунаклар өчен.

Мәстүрә бакчага чыга. Раилә, Кәүсәрия, Ләйсән өйгә кереп китә. Нурания савыт-саба юа башлый.

Әмир. Хәйбулла, син хәзер себерке китер дә клубка барып утны кара. Зал да, сәхнә дә ялт итеп торсын!

Хәйбулла китә.

Кызларның машинасын да онытма! Әхтәм, син клубка оч! Билет сатыламы, идән юылганмы, тузан сөртелгәнме, тупсаның бер тактасы каерылган иде, кагылганмы, баян китергәннәрме? Бөтенесен дә кара! Мин конторага кереп чыгам да хәзер килеп җитәрмен! Киттек! Нурания, сау булып тор!

Әхтәм. Сау булыгыз!

Нурания. Пока, егетләр!

Әмир белән Әхтәм китә. Бакчадан Мәстүрә чыга.

Мәстүрә. Кызлар, мунча әзер! Әйдә тиз генә юынып чыгыгыз.

Өйдән Кәүсәрия, Ләйсән чыга.

Минем мунча бәләкәй, шуңа икешәрләп юыныгыз. Кәүсәрия, Ләйсән! Әйдә, күрсәтәм: кая пар салырга, кайдан су алырга.

Мәстүрә, Кәүсәрия, Ләйсән бакча ягына китә. Нурания савыт-саба юа. Себерке тотып, Хәйбулла керә.

Хәйбулла. Мәстүрә апа кайда?

Нурания. Мунчада.

Хәйбулла. Менә себерке китердем, мә, илтеп бир.

Нурания. Үзең илт.

Хәйбулла. Ничек илтим? Ул мунчада, диден бит. Кызлар да андадыр әле.

Нурания. Анда. Нигә, син кызлардан куркасыңмыни?

Хәйбулла. Кара әле, минем вакытым юк. Анда клубны әзерләргә кирәк. Сиңа кыенмыни?

Нурания. Кыен.

Хәйбулла. Әти-әниеңне әйтер идем инде!

Хәйбулла бакчага керә.

Нурания. Ачуланса, тагын да матураеп китә.

Бакча ягыннан Хәйбулла килә.

Син миңа нәрсә әйтергә теләгән идең әле әти-әни хакында?

Хәйбулла. Тәрбия бирмәгәннәр сиңа.

Нурания. Син үзеңне тәрбияле дип уйлыйсыңмы?

Хәйбулла. Мин – авыл малае.

Нурания. Шулай булгач, нигә миңа акыл өйрәтәсең?

Хәйбулла. Кара әле, үткәр, дим!

Нурания. Әйләнеп уз!

Хәйбулла. Ничек узыйм? Монда – койма, монда – өстәл.

Нурания. Шуннан?

Хәйбулла. Кит әле юлдан.

Нурания. Нигә этенәсең?

Хәйбулла. Синең кебекләрне күргән бар. Тизрәк концертыңны куй да табаныңны ялтырат, ярыймы?

Нурания. Ха-ха! Куркытты! Син кем соң шулхәтле?
Хәйбулла. Синең белән сөйләшкән мин җүләр!
Нурания. Тукта!
Хәйбулла. Нәрсә?
Нурания. Синең исемең ничек әле?
Хәйбулла. Иван!
Нурания. Мин чынлап сорыйм.
Хәйбулла. Нәрсәгә сиңа минем исемем? Кала шпаналарына әйтергәме? Авыл егете белән шаярып аласың килдеме? Әнә Әхтәм яки Әмир белән шаяр. Син бу джинсыңны кимә башка. Ул сиңа килешми! *(Китә.)*
Нурания. Ух, бет! Кара ничек телләшә! Үзеңнең киемеңне тикшер, Ваня! Джинсы ошамый аңа... нигә алай диде әле? Кайсы җирен ошатмады? Бөтенесе дә, сиңа килешә, ди торганнар иде бит.

Мәстүрә бакчадан килә.

Мәстүрә. Һаман юып бетермәдеңме? Раилә кайда?
Нурания. Өйдә.
Мәстүрә. Нигә ярдәм итми? Хәзер теге ике кыз чыга, тизрәк юыгыз да сез барырсыз мунчага. *(Өйгә кереп китә.)*

Әхтәм керә.

Әхтәм. Әмир күренмәдеме? Күрше авылда баян бирмәгәннәр. Срочно табарга кирәк!
Нурания. Син бит завклуб, тап!
Әхтәм. Мин ничек табыйм авылда булмаганны?
Нурания. Шушы баянны алып булмыймыни?
Әхтәм. Юк.
Нурания. Нигә?
Әхтәм. Ул... борынгы.
Нурания. Сәнгать кешеләре шул инде: кулыннан берни килми!
Әхтәм. Нигә алай дисең? Сәнгать кешеләре бит шундый...
Нурания. Акчалары булмый.
Әхтәм. Анысы шулай. Әмма эш акчадамыни?
Нурания. Ә нәрсәдә?

Әхтәм. Рухи байлыкта.

Нурания. Кит әле, әкият сөйләмә! Рухи байлыкны киеп буламы яки ашап буламы? Акчаң булмаса яшәрсең рухи байлык белән! Менә безне рухи байлыгыбыз йөртә дисеңме, шушы концертлар куеп? Безнең завод ябылды. Бөтенебез дә эшсез. Җитмәсә, тулай торактан куалар. Ә яшәргә кирәк. Акча йөртә безне. Ә син — «рухи байлык»!

Әхтәм. Акча табыла ул, Нурания, саулыгың булса. Кешегә иң алдан күңел байлыгы һәм мәхәббәт кирәк!

Нурания. Ха! Мәхәббәт! Юк ул мәхәббәт!

Әхтәм. Бар, Нурания! Бар! Менә әгәр син миңа ошыйсың икән...

Нурания. Ошау мәхәббәт түгел.

Әхтәм. Әкренләп мәхәббәткә әверелә ул. Мәхәббәт бит рухи бердәмлек. Менә син, белүемчә, биюче, шулай бит?

Нурания. Әйе. Шуннан?

Әхтәм. Ә мин — баянист. Мин уйныйм, син биисең. Шундый парлар!.. Минем хыялым бар — гаилә ансамбле төзергә. Күз алдыңа китер: ире баянда уйный, хатыны бии, малайлары скрипкада уйный, кызлары җырлый...

Нурания. Юк, малай җырласын, кыз скрипкада...

Әхтәм. Юк-юк, малай кеше берәр инструментта уйнарга тиеш. Ә кызлар...

Нурания. Җенем сөйми кызларның чәрелдәп җырлап торганын! Ләйсән җырлаганда да клубтан чыгып китәм. Ә менә ирләр җырлый ичмасам! Ә кызлар, әйдә...

Әхтәм. Юк, Нурания, син ялгышасың!

Нурания. Тукта! Нигә талашабыз әле? Синең кызың да юк бит әле!

Әхтәм. Бөтен бәла дә шунда — юк шул! Ә миңа талантсыз кыз кирәкми, сәнгать кешесе кирәк.

Нурания. Мин сәнгать кешесе түгел шул, мин — маляр. Завод ябылганга аптырап...

Әхтәм. Бии белү — үзе сәнгать!

Нурания. Яратмыйм ялагайларны! Ярар, минем вакыт юк, синең дә эшең муеннан. Башта баян табыгыз!

Әхтәм. Концерттан соң килеп чыгам әле. Син ялгышасың! Сиңа күп нәрсәне аңлатырга кирәк, Нурания.

Нурания. Ярый, кил, аңлатырсың. Бу киемең сиңа килешми. Костюм киеп кил, галстук.

Әхтәм. Аңладым.

Нурания. Тагын! Миңа концертка бит кремы кирәк иде. Французский, сезнең магазинда бар.

Әхтәм. Ә күпме тора?

Нурания. Магазинда хакы язылган.

Әхтәм. Безгә өч ай акча биргәннәре юк, шуңа әйтүем. Дезодорант бармыймы?

Нурания. Дезодорантны биткә сөртеп буламы? Крем! Пока!

Әхтәм. Пока! (*Китә.*)

Нурания. Моннан ул да тумас, туса да тормас.

Урамнан Әмир керә.

Әмир. Нурания!

Нурания. Уф, куркыттың. Ни булды?

Әмир. Әхтәм кермәдеме?

Нурания. Әле генә килеп китте. Сине эзләп йөри.

Әмир. Ялкау! Халык билет сорый! Әйттем, утырт берәрсен билет сатарга дип. Билеты да юк, үзе дә! Иртәгә үк куам эштән!

Нурания. Усал начальник икәнсең!

Әмир. Шунсыз булмый. Безнең авылда калу ягы ничек?

Нурания. Монда ни эшлим мин?

Өйдән Раилә чыга. Туктап кала
һәм яшеренеп тыңлап тора.

Әмир. Кияүгә чыгасың!

Нурания. Кемгә?

Әмир. Монда миннән башка чыгардай кеше юк!

Нурания. Анысы дөрес! Тик сиңа ничә яшь?

Әмир. Утыз дүрт.

Нурания. Ә миңа егерме өч.

Әмир. Унбер яшь чүп ул!

Нурания. Ә мәхәббәт?

Әмир. Нинди мәхәббәт? Балалар әкияте бит ул! Иң мөһиме: ир кеше ышанычлы булсын! Шулчак хатын-кыз ныклы канат астында була.

Нурания. Син «ныклы канат»мы?

Әмир. Ә кәк же! Клуб кебек өем, өч сыерым, ун сарыгым, егерме умартам, машинам бар.

Нурания. О! Чынлап та әйбәт егет икәнсең, тик син бигрәк бәләкәй начальник бит әле. Ярый, мин уйлап карармын!

Әмир. Аның нәрсәсен уйлап торасың, риза бул һәм вәссәлам.

Нурания. Син риза булырсыңмы алырга? Мин бит озак йокларга ератам.

Әмир. Уятырбыз.

Нурания. Сыер сава белмим.

Әмир. Өйрәтербез.

Нурания. Үпкәчәнмен.

Әмир. Көйләтербез.

Нурания. Анысы ничек?

Әмир. Аңлатырбыз.

Нурания. Чын ир икәнсең! Концерттан соң җавап бирермен.

Әмир. Сөйләштек.

Нурания. Тик менә нәрсә. Бу киемең килешми! Джинсы ки, куртка.

Әмир. Килешерме икән?

Нурания. Менә дигән булачак.

Әмир. Болай минем джинсы бар ул.

Раилә өйгә керен китә.

Нурания. Булгач? Тагы...

Әмир. Әйт.

Нурания. Минем хушбуем беткән.

Әмир. Табам!

Нурания. Концертка кирәк иде.

Әмир. Ничә пол-литр, әй, флакон?

Нурания. Берәү.

Әмир. Икәү! Юк, өчәү!

Нурания. Ауфидерзейн.

Әмир китә.

Менә бу мужик, ичмасам!

Өйдән Мәстүрә чыга.

Мәстүрә. Кызлар чыкмадымы әле мунчадан?

Нурания. Юк... Мәстүрә апа, сез ялгыз яшисезме?

Мәстүрә. Әйе, ялгызым калдым. Мин үзем күрше авылдан. Хәзер ул авыл бетте инде... Унсигез яшемдә килен булып төшкән идем... Шушында яшьлегем, бөтен тормышым үтте. Өч ел элек кенә бабаем үлеп китте. Районда беренче гармунчы иде. Ә узган ел... бердәнбер... кырык яшьлек улым асылынып үлде... Ә мин бит синең кебек килен хакында, оныклар хакында хыяллана идем... Япа-ялгыз торып калдым.

Нурания. Ходаем...

Мунчадан – Ләйсән белән Кәүсәрия, өйдән Раилә чыга.

Мәстүрә. Кырыла егетләр... Эчәләр, аварияләрдә һәлак булалар... Ә ни эшләсеннәр инде? Гаилә кора алмыйлар, бала таптыра алмыйлар, чөнки кызлар юк авылда... Мин сезнең урында булсам, иң әйбәт егетне сайлап алып кияүгә чыгар идем дә... Әй, кызлар чыккан бит мунчадан! Җиңел пар белән!

Раилә.
Нурания. } Җиңел пар белән!

Ләйсән.
Кәүсәрия. } Рәхмәт!

Раилә. Әйдә, Нурания, тиз генә юынып чыгыйк та...

Нурания. Мәстүрә апа, кайгырмагыз... Сез шундый әйбәт...

Мәстүрә. Әй кызым, бәхетле бул.

Раилә. Әйдә тизрәк.

Раилә, Нурания – мунчага, Ләйсән, Кәүсәрия өйгә кереп китә.

Мәстүрә. Әй Ходаем, үзең ярдәм ит!

Мәстүрә өйгә кереп китә. Ут сүнеп ала. Әхтәм керә.

Әхтәм (*җырлый*). Бөтен дөнья матурайды,
Безгә килгәч Нурания.
Аның матурлыгын күреп,
Урман-таулар башын ия.

Ләйсән өйдән чыга.

Ләйсән. Әхтәм, нигә болай киенеп килдең?

Әхтәм. Җитте колхозник кебек киенеп йөрергә. Мин бит завклуб. Культура-агарту работнигы. Бүгеннән костюм-галстуктан гына йөрим. Килешәме?

Ләйсән. Кит әле! Теге киемең мең тапкыр матур иде!

Әхмәт. Әй, син нәрсә аңлыйсың?!

Ләйсән. Бабайларга охшап калгансың. Нәрсә карыйсың?

Әхтәм. Ни... сәгать ничә?

Ләйсән. Җиде.

Әхтәм. Өйдә кем бар?

Ләйсән. Кәүсәр.

Әхтәм. Ә... Мәстүрә апа кайда?

Ләйсән. Ул да өйдә. Әхтәм, син бая ниндидер матур җыр җырладың. Нинди җыр иде ул? Үзеңнекеме?

Әхтәм. Үземнеке, әлбәттә.

Ләйсән. Миңа көе бик ошады. Сүзләрен язып бир әле.

Әхтәм. Сүзләре... Мин оныттым да инде.

Ләйсән. Ничек «оныттым»?

Әхтәм. Мин көненә ун җыр чыгарам. Кичкә шуларның бер-икесе генә истә кала.

Ләйсән. Коточкыч! Син бит үз талантыңны үзең күрмисең, көй башка килү белән язып куярга кирәк. Син һәрчак үзең белән каләм алып йөр.

Әхтәм. Мин бит барыбер нота яза белмим.

Ләйсән. Беләсеңме, сиңа нота яза белә торган кызга өйләнергә кирәк. Сиңа укырга кирәк. Икәүләшеп училищега керерсез, шуннан — институтка. Югыйсә шундый сәләтең әрәм була бит.

Әхтәм. Ә Нурания нота яза беләме икән?

Ләйсән. Юк, белми. Ул бит маляр.

Әхтәм. Ә кайда әле ул?

Ләйсән. Нәрсәгә ул сиңа?

Әхтәм. Ну кирәк инде, кирәк.

Ләйсән. Юк, башта әйт — нигә?

Әхтәм. Ну, әйтәсе сүзем бар.

Ләйсән. Миңа әйт. Мин аңа тапшырырмын.

Әхтәм. Сүз генә түгел шул.

Ләйсән. Әллә төргәгеӊ аӊамы?
Әхтәм. Ипләп, ватасыӊ бит.
Ләйсән. Нәрсә соӊ ул? Крем!
Әхтәм. Әйе, крем.
Ләйсән. Нураниягәме?
Әхтәм. Нураниягә.
Ләйсән. Их, Әхтәм, Әхтәм! Мин сине акылларак дип уйлаган идем. Ә син... син дә шул икән! *(Китә.)*
Әхтәм. Әллә үпкәләде инде? Шултикле нәрсә әйттем? Аӊламыйм. Ах, вакыт! Әмир агай үтерә мине хәзер! Ярар, клубта бирермен! Концерт алдыннан.

Әхтәм китә. Әмир керә.

Әмир. Нурания! Нурания, дим!

Мунчадан Раилә чыга.

Раилә. Кычкырма шултикле! Нигә клоун сыман киенеп килдеӊ?
Әмир. Яшьләрчә! Җиӊел пар белән!
Раилә. Рәхмәт!
Әмир. Нурания кайда?
Раилә. Юк ул. Минем белән сөйләш. Ха-ха! Кит, торма юлымда. Көлдереп үтерәсеӊ.
Әмир. Миӊа син кирәкми, Нурания кирәк.
Раилә. Һаман кызлар кайгысы. Баян таптыӊмы?
Әмир. Әйттем бит була дип, димәк, була.
Раилә. Һаман юкмыни? Коточкыч! Бер сәгатьтән концерт башлана. Аӊлыйсыӊмы шуны? Баянистыгыз әллә уйный белә, әллә юк.
Әмир. Син безнеӊ баянистка сүз әйтмә. Ул районда беренче.
Раилә. Клубны юдыгызмы? Ут булдымы? Тупсагызны рәтләдегезме?
Әмир. Тукта, тукта! Мин сиӊа ике меӊ түлим, авызыӊны яп та тик утыр. Җанга тисәӊ, кудым-җибәрдем булыр. Чакыр Нурманияне.
Раилә. Нигә? Ташландык авылыӊа килеп концерт куйганга рәхмәт әйт! Куам, имеш! Рәтле председатель булсаӊ, клубыӊ рәтле булыр иде. Югыйсә көне буе бер баян таба алмыйсыӊ.

Әмир. Карама, карама ул баянга. Ул – изге баян!

Раилә. Ут юк! Ә ул кызлар артыннан чаба! Юк Нурания!

Әмир. Мин сөйләшермен әле синең белән. Нурания!

Раилә. Ул мунчада. Гомумән, Нурания артыннан чабуыңны ташла... Аның шәһәрдә егете бар. Туйлары була.

Әмир. Булсын! Аертам! Үзем алам мин аны.

Раилә. Ха-ха! Авызың пешәр. Менә сиңа Нурания!

Әмир. Кара әле! Син кем шултикле?

Раилә. Кызларның хуҗасы! Сиңа Кәүсәр бүленгән. Вәт аны чакыр.

Әмир. Хәзер яңадан бүләбез. Миңа Нурания кирәк!

Раилә. Юк инде. Поезд китте. Тю-тю!

Әмир. Китсә... туктатырбыз. Үзебезнең кулда!

Раилә. Их, бабай! Джинсы кигәч, яшәреп киттем дисеңме? Ул сиңа пар түгел. Нурания – матур, син – ямьсез. Ул – яшь, син – карт. Ул – нечкә...

Әмир. Җитте, тукта.

Раилә. Бүлдермә. Ул – нечкә, син – тупас. Ул – озын, син – кыска.

Әмир. Кем кыска? Син нәрсә сөйләгәнеңне уйлап сөйлә.

Раилә. Джинсы сине кыска күрсәтә. Так что, әйдә, бор арбаңны, председатель абзый.

Әмир. Ну мин синең кирәгеңне бирер идем дә! Вакыты түгел... Алайса... ни...

Раилә. Нәрсә?

Әмир. Менә шушыны Нуриягә бирерсең. Бернинди волокитасыз, килү белән үзенә бир. Көтәргә вакытым юк.

Раилә. Нәрсә ул?

Әмир. Анда ни эшең бар? Бир дигәч бир.

Раилә. Духимы әллә?

Әмир. Ай Алла! Нигә кысыласың? Сиңа түгел бит ул.

Раилә. Ничә флакон?

Әмир. Өчәү. Шуннан?

Раилә. Нигә өчәү генә. Без бит дүртәү.

Әмир. Ул сезгә түгел, дим, Нуриягә.

Раилә. Нураниянең духие бар. Безнеке бетте. Рәхмәт!

Әмир. Тукта, кире бир әле.

Раилә. Бирде ди... Аллаһы әкбәр.

Әмир. Нинди шайтан хатын булдың син?

Раилә. Җитәкче. Ә җитәкче кеше бөтенесен дә уйларга тиеш, тәртип белән алып барырга тиеш эшен. Югыйсә хәзер бөтен коллектив сезнең авылда калачак.

Әмир. Безнең авылга ни булган?

Раилә. Бер күрүдә күренеп тора – хуҗа юк. Коймалар җимерек, капкалар буялмаган, урам уртасында су җыелып тора, юлдан үтәрлек түгел.

Әмир. Күп белгәч, әйдә күчеп кайт та урнаштыр тәртип.

Раилә. Урнаштырырмын да. Бүген үтеп барабыз авыл буйлап... читтә бер өй тора. Үзе яңа, зур, матур. Ә коймасы җимерек, авып ята. Шуны төзәтеп куярга була бит.

Әмир. Ул бит минем өй.

Раилә. Аңлашылды. Менә нигә авыл шундый хәлдә икән. Ух! Мин булсаммы! Кирәгегезне биреп бөтенегезне эшләтер идем.

Әмир. Син... Кара әле. Кал чынлап та син безнең авылда.

Раилә. Ничек «кал»?

Әмир. Миңа авыл Советы башлыгы кирәк. Күптән кеше эзлим, таба алмыйм. Кал!

Раилә. Кал! Ә кайда яшәрмен?

Әмир. Кияүгә бирәбез. Шәп, зур өйле егеткә.

Раилә. Кемгә, мәсәлән?

Әмир. Кемгә? Әлегә син Әхтәмгә бүленгән.

Раилә. Кит әле. Яратмыйм бөрчә кебек егетләрне.

Әмир. Шулай дисеңме? Алайса... Хәзер уйларбыз. Тәк, тәк... Хатипның өе иске, Сабирның әнисе усал, Госман эчәргә ярата... Ярый, табарбыз. Главное – кал. Бездә егетләр күп ул. Берәрсенә чыгарсың.

Раилә. Минем синнән кияү сораганым юк, дурак. Үзең чык, белдеңме? Хәзер барабыз клубка, әгәр әзер булмаса, без китәбез. Концерт булмый. *(Кереп китә.)*

Әмир. Аңламадым. Нинди корт чакты? Ә болай әйбәт авыл Советы башлыгы чыга моннан. Усаллыгы бар. Тәртип ярата. Эчми самое главное. Женсовет председателе итеп җибәрсәң. Эчкечелеккә көрәш башлыйбыз. Шәп бит, ә? Юк, мондый кызны кулдан ычкындырырга ярамый. Тик кемгә кияүгә бирергә? Әхтәм иң шәбе дә бит... Бәлки, Хәйбулла? Юк! Шуларның икесенең берәрсенә бирергә кирәк. Ошамый, имеш. Кызларны тыңлый башласаң...

Әмир китә. Өйдән Раилә, Кәүсәрия, Ләйсән чыга.

Раилә. Кәүсәрия, бар, чакыр Нуранияне. Нәрсә эшли ул мунчада шул гомер?

Кәүсәрия бакчага керә.

Гел соңга кала, гел соңлый. Нишләтергә бу Нуранияне, ә?

Ләйсән. Алмаска кирәк иде. Ике шигырь сөйли, бер бию бии. Шуның өчен ияртеп йөрибез, артык кашык итеп.

Раилә. Сез бит: алыйк та алыйк, күңеллерәк булыр...

Бакчадан Кәүсәрия белән Нурания керә.

Нурания. Шундый әйбәт мунча. Чабынып туеп булмый. Их, минә шушындый мунчалы авыл өендә яшәргә иде!

Раилә. Нигә озакладың? Концерт вакыты җитте. Ә син утырасың анда җәелеп.

Нурания. Мин әзер. Хәзер киенәм дә...

Раилә. Мә.

Нурания. Нәрсә ул? Ә, духи! Председатель бирдеме? Ха-ха! Җүләр дә инде бу егетләр, Әмире хушбуйга йөгергән, Әхтәме – кремга. Представляете, икесе дә миңа гашыйк, икесе дә, миңа кияүгә чык, ди. Ни эшләргә? Ә миңа Хәйбулла ошый.

Раилә. Кайсысын сайлавың анысы синең эш. Мин сине кисәтәм: ташла бу гадәтеңне.

Нурания. Нинди?

Раилә. Теләнеп, духи, крем җыюыңны. Бу – мескеннәр, хәерчеләр, саранннар эше.

Нурания. Мин теләнмим. Алар үзләре китерә.

Раилә. Миңа бит беркем дә китерми яки әнә Ләйсәнгә, Кәүсәриягә.

Кәүсәрия. Хәтта булганын да урлыйлар.

Нурания. Нәрсәңне урладылар?

Кәүсәрия. Алкамны.

Раилә. Тукта. Ничек? Син, югалды, дигән идең.

Ләйсән. Юк, урладылар. Һәм мин беләм кем урлаганын.

Нурания. Нигә алай карыйсың? Әллә миннән күрәсеңме?

Ләйсән. Әйе, синнән. Без моңарчы өчәү йөрдек, бернәрсәбез дә югалмады, син килеп кушылган идең... Мин бит күрдем. Син Кәүсәрнең сумкасын актара идең. Иртән, машинада.

Нурания. Әйе, мин актардым шул, шуннан?

Ләйсән. Димәк, син урлагансың алканы.

Нурания. Мин бит көзге эзләдем, дура!

Ләйсән. Дурадан ишетәм, ещё мактанып утыра: өч егет тә миңа гашыйк, имеш. Карап карарбыз, карак икәнлегеңне белгәч ни эшләрләр икән?

Раилә. Нурания, әгәр алсаң, бир алканы.

Нурания. Сез акылдан шаштыгыз мәллә? Юк миндә алка!

Раилә. Эзли башласак, үзеңә оят булыр. Бир!

Нурания. Эзләгез, әнә ята сумкаларым... Ә, тукта! Сез кем әле тентү ясарга? Следовательмы? Мин җинаятьчеме? Менә сезгә! Тентетмим! Мин аңладым: сез миннән үч аласыз.

Раилә. Нинди үч?

Нурания. Хәмит өчен. Әгәр ул, сине ташлап, минем арттан йөри башлаган икән, мин гаеплеме инде?

Раилә. Тфү Хәмитеңә! Мин аны үзем куып җибәрдем!

Нурания. Әйе, үзең. Хәмит миңа синең елап язган хатыңны укытты: «Без бит өйләнешергә сөйләшкән идек, нигә хыянәт итең...»

Раилә. Җитте. Без синеме! Куабыз ансамбльдән! Хәзер үк. Сумкаларыңны җый да, бар, кайтып кит. Карак кына җитмәгән иде безгә.

Нурания. Син кем мине куарга?

Раилә. Мин кемме, кызлар, әйтегез шуңа.

Кәүсәрия. Китсен әйдә.

Ләйсән. Күптән кирәк иде.

Нурания. Эх, кызлар! Нигә мине гел генә иң якын дусларым күралмый башлый?

Ләйсән. Аңлашылмыймыни?

Нурания. Раилә аңлашыла... Кәүсәр матурлыгыма көнләшә. Ә менә син, Ләйсән, нигә мине яратмыйсың? Чәрелдек тавышың белән мактанасыңмы? Юк синең тавышың, юк. Чыкмый синнән җырчы. Лучше менә шунда берәрсенә кияүгә чык та сыер савучы бул.

Ләйсән. Мин күрсәтәм сиңа хәзер савучыны!

Раилә. Ләйсән, нәрсә эшлисең?

Ләйсән. Кит моннан!

Кәүсәрия. Акылдан шаштыңмы әллә?

Ләйсән. Син ул акылдан шашкан!

Нурания. Әй, чукынып китегез!

Нурания өйгә кереп китә.

Кәүсәрия. Нигә акырасың шултиклем?

Ләйсән. Акырам. Чөнки сез, син төшердең мине шушы хәлгә. Эшем дә юк, өем дә. Минем сөйгән егетем бар иде. Ул бит әйтте, китмә авылдан, диде. Ә мин киттем. Ул үч итеп иптәш кызыма өйләнде. Хәзер менә дигән итеп яшәп ята күрше авылда. Ике балалары бар. Ә мин... син дураны тыңлап... Янәсе, шәһәрдә яшәве җиңел. Яшәрсең атаң башы! Менә хәзер экзаменнарга әзерләнәсе урынга... Акча эшлим дип, шушы кулдан килмәгән концертларда...

Раилә. Җитте сиңа! Эшлисең килмәсә, кем тота синe, бар, кайтып кит!

Кәүсәрия. Кычкырма шулай! Ләйсән, тынычлан...

Раилә. Кеше ышандырып елап утырган була, кит шуның яныннан!

Ләйсән. Чәчрәп китегез концертыгыз белән, мин кайтам. *(Өйгә кереп китә.)*

Раилә. Кайт! Җәһәннәмнең аръягына кит! Дура, мин сезне уйлап...

Кәүсәрия. Кычкырма әле. Ләйсән дөрес әйтә: мин алып киттем аны шәһәргә. Мин! Акча да, фатир да – барысы да була, дидем. Нигә авылда тизәккә батып ятасың, диеп. Чөнки үзем авылдан. Синең ял саен матур-матур киенеп, төрле күчтәнәчләр күтәреп кайтуыңа алдандым. Үзем дә шулай ял саен кайтасым, төрле күчтәнәчләр алып кайтып өләшәсем, туганнарымны куандырасым, күршеләрне көнләштерәсем килде. Безгә ияреп, башкалар, Ләйсән дә китте. Авылда бер кыз да калмады. Егетләр эчеп, асылынып үлеп бетте, шуңа да авылыбыз юкка чыкты. Менә син ул авылны бетерүче. Мин бетерүче. Ходай безне җәзалады – бөтенебез дә эшсез, акчасыз, өйсез. Хәтта кире әйләнеп кайтырга авылыбыз да юк. Хәзер менә шушы концертлар белән акча тапмакчыбыз. Бүген табарбыз, ә иртәгә ни эшләрбез? Бер елдан? Концерт куеп йөрергә түгел, язмыш хакында уйларга кирәк. Монда Робертны табармын дигән идем. Юк, булмагач булмый инде, мин дә кайтам.

Раилә. Тукта! Кайтып кая барасың? Сине бит тулай торакка кертмәячәкләр.

Кәүсәрия. Әйбәт кешеләр юк дөньяда. Бәхет юк һәм булмас та. Габдрахман Сабировичка кияүгә чыгам. *(Өйгә кереп китә.)*

Раилә. Әй җүләрләр! Мин аларны уйлап тырышкан булам. Авылдашлар, имеш. Ач булмасыннар, имеш. Кеше арасында кеше булсыннар. Менә аларның рәхмәте. Сезгә кирәкмәгән концерт миңа кирәкмени? Төкерәм бөтенегезгә! Кайтырга икән кайтырга! *(Өйгә кереп китә.)*

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук күренеш. Өйдән, сумкаларын күтәреп, Нурания белән Кәүсәрия чыга.

Нурания. Нурания ашыкмый, Нурания соңга кала, диләр. Менә мин әзер, ә алар һаман юк.

Кәүсәрия. Алар бит концертка әзерләнеп өлгерде, ә син соңга калдың.

Нурания. Әнә шулай, кайбер чакта ашыгырга да ярамый ул. Их! Кайсыбер авылда атна буе яшәсәң, ничектер күңелгә ятмый, ә менә монда ике сәгать булдык, китәсе килми.

Кәүсәрия. Кал алайса.

Нурания. Ә нигә? Калам да кияүгә чыгам. Миңа да гаилә, бала хакында уйларга вакыттыр бит. Югыйсә үземне белгәннән бирле тулай торакта, кеше бусагасында. Мин бит әниемне дә, әтиемне дә белмим. Кайвакыт шулай үз өемдә, үз гаиләмдә яшәп карыйсым килә. Элегрәк бай, зур фатирлы гаилә турында хыяллана идем. Син дә шулаймы?

Кәүсәрия. Юк.

Нурания. Хәзер аңладым: безнең кебек хәерчегә каян килсен андый кеше? Синең, ичмасам, Габдрахман Сабировичың бар, ә минем... Әллә тотарга да әнә шул Хәйбуллага чыгарга? Яши алмаса, аерылып өен бүләм, алимент түләтәм шартлатып. Ичмасам, карт кыз исемен күтәреп йөрмәм, Раилә кебек. Нигә дәшмисең? Һаман да алка өчен үпкәлисеңме, алмадым мин аны, алмадым, ишетәсеңме?! Детдом баласы булгач та. Әллә аларның барысы да карак дип уйлыйсыңмы?

Кәүсәрия. Алла хөкем итәр.

Нурания. Менә ул сине хөкем итәчәк, нахак бәла яккан өчен. Беләсеңме безне детдомда нишләтәләр иде урлашкан өчен? Салкын, караңгы подвалга төне буена биклиләр иде. Ә анда күселәр. Гомергә урлашмаслык иттеләр, төкерәм мин синең алкаңа.

Кәүсәрия. Ә ул сине аламы?

Нурания. Кем?

Кәүсәрия. Хәйбулла.

Нурания. Кая бара ул? Бер елмаеп каравым була. Әнә Әхтәм белән Әмир бер адым да калмыйлар бит.

Кәүсәрия. Хәйбулла андый кеше түгел.

Нурания. Тукта, син әллә үзең гашыйкмы аңа?

Кәүсәрия. Бер дә гашыйк түгел. Сиңа карамаячак ул, дим.

Нурания. Әйдә бәхәсләшәбез!

Кәүсәрия. Бәхәсләшмим дә, карамаячак та.
Нурания. Әтү сиңа караячакмы?
Кәүсәрия. Миңа да карамаячак.
Нурания. Алайса, кемгә? Раиләгәме, әллә чәрелдек Ләйсәнгәме?
Кәүсәрия. Юк.
Нурания. Тукта, нигә алай дисең? Аны кайдан беләсең?
Кәүсәрия. Нигә озаклый әле тегеләр, китсәк тизрәк китик тә...
Нурания. Дөресен әйткәндә, ул егет миңа да ошады.
Кәүсәрия. Ул бит эчәргә ярата.
Нурания. Әһә, миңа өйләнер дип куркасың.
Кәүсәрия. Җүләр син.
Нурания. Курыкма. Аңа чыгып, авыл тиресендә казыныргамы? Икенчедән, чибәрләр хыянәт итүчән була. Син дә аны якын китермә.

Өйдән Мәстүрә чыга.

Мәстүрә. Кызлар, егетләр күренмәдеме?
Нурания. Юк.
Мәстүрә. Алар нигә озаклый икән? Кызлар! Ашыкмагыз, зинһар, концерт күрсәтегез, бездә йокларсыз... Нигә шулай безне тиз ташлап китәсез? Әллә ачуландыгызмы?
Кәүсәрия. Ачуланмадык, тик китәбез...
Мәстүрә. Эх, кызлар, кызлар! Мин бит сезне безнең егетләргә кияүгә чыкмассызмы дип өметләндем, ә сез...
Нурания. Кияүгә?
Мәстүрә. Авылыбыз бетә бит. Әгәр сез китсәгез, авыл корыячак. Әнә күршедә минем туган авылым бетте шулай. Без яшь чакта анда атна саен туйлар була торган иде, ай саен бала туа иде. Ә хәзер... Кызлар китте авылдан, кичке уеннар бетте, гармун тавышы югалды, туйлар бетте, шуннан авыл корыды. Хәзер Зирекле шушы хәлдә. Өч ел элек бабаем үләр алдыннан әйтте: Мәстүрә, бу авылда гармун тавышы югалды, моң китте, авыл бетәчәк, диде. Моң кайтмыйча, туйлар кайтмыйча бу гармунны беркемгә дә бирмә, диде... Былтыр... улым үлгәч... мин аңладым... авыл бетте.

Аны коткарып калу өчен, авылга моң кайтару өчен, туйлар үткәрергә кирәк! Кызлар! Барысы да сездән тора. Коткарыгыз Зиреклене! Безнең егетләр бик әйбәт алар. Сез калсагыз, туйлар башланыр, балалар туар. Коткарыгыз Зиреклене!

Нурания. Мәстүрә апа, сез... ни дип әйтим... Мин калыр идем дә... Ә башкалар... Раилә белән сөйләшегез... Ул безнең җитәкче.

Мәстүрә. Нишлим соң? Тыңламый бит! Бөтенләй тыңламый!

Мәстүрә, Кәүсәрия өйгә кереп китәләр.

Нурания. Менә нинди боларның уйлары... Шундый җәл миңа ул, әнием кебек, дәү әнием кебек күренә башлады.

Урамнан Хәйбулла керә.

Хәйбулла. Әмир белән Әхтәм күренмәдеме?

Нурания. Аларны нигә монда эзлисең? Клубтадыр.

Хәйбулла. Килергә тиешләр, сезне алырга.

Нурания. Соңладыгыз, абзыйлар! Йә, мин күлмәктә ничек? Джинсы килешми, дигән идең бит.

Хәйбулла. Ялгышканмын.

Нурания. Аңлавымча, сез монда безнең кызларны бүлеп алып бетергәнсез. Шуннан, син Ләйсәнгә өйләнәсеңме?

Хәйбулла. Мин композитор түгел.

Нурания. Ичмасам, берәребез ошыймы сиңа?

Хәйбулла. Син түгел.

Нурания. Син бит алдашасың. Мин ошыйм сиңа. Шуны сиздермәс өчен тупас кыланасың син.

Хәйбулла. Минем берданбер әйбәт сыйфатым бар, алдаша белмим мин.

Нурания. Алайса аңлат, нигә ошамыйм. Мин бит матур.

Хәйбулла. Матурлар буш куык була.

Нурания. Син дә буш куыкмы?

Хәйбулла. Әлбәттә, карап торганда гына әйбәт. Ә чынында — эчкече, ышанычсыз һәм башкалар.

Нурания. Нигә үзең хакында начар сөйлисең?

Хәйбулла. Чөнки дөресе шулай.

Нурания. Син барыбер... миңа ошыйсың.

Хәйбулла. Вакытыңны әрәм итәсең, синең төсләләр начальникка чыгарга хыяллана. Әнә Әмирне кара.

Нурания. Алайса, син Раиләгә өйлән.

Хәйбулла. Лутчы төрмәгә утырам.

Нурания. Әнә шул шул. Димәк, син сайланасың...

Хәйбулла. Нәрсәгә ул сиңа?

Нурания. Көнләшәм.

Хәйбулла. Ташла кылануыңны.

Нурания. Чын... Кәүсәрияме?

Хәйбулла. Беренчедән, өйләнергәме-юкмы – мин әле хәл итмәгән.

Нурания. Неужели шуңа өйләнәсең? Ул бит ямьсез.

Хәйбулла. Матурлык туйда гына кирәк.

Нурания. Әйдә миңа өйлән. Мин сиңа әйбәт хатын булырмын.

Хәйбулла. Син әллә болайракмы?

Нурания. Үзең шундый! Нигә килдем мин, җүләр, бу авылга? Ярый. Мин киттем. Син мине башка беркайчан да күрмәячәксең. Тик мине гомер буе оныта алмаячаксың, белдеңме?

Хәйбулла. Матур сүзләр, тик ихлас түгел.

Нурания. Дурак син!

Нурания өйгә кереп китә. Әмир, Әхтәм керә.

Хәйбулла. Сез болай нигә киендегез әле? Берегез – попугайга, икенчегез страуска охшагансыз.

Әмир. Нигә, килешмимени?

Хәйбулла. Килешүен килешә. Тик сезгә карасам... Ха-ха! Күренмичәрәк торыгыз әле.

Әхтәм. Кайда кызлар? Берсе дә күренми.

Әмир. Болар концертны бөтенләй онытканнар.

Әхтәм. Бәлки, мунча керәләрдер?

Әмир. Нинди мунча булсын. Өйдә тавышлары килә. Җыеналар. Ярый, көтик бераз... Егетләр! Безгә бер бик мөһим мәсьәлә буенча сөйләшеп алырга кирәк. Конкрет сөйләшәбез дә хәл итәбез һәм баста! Килегез, утырыгыз. Дөресен әйтегез әле, авылыбызның шушындый хәлдә булуы сезне чак кына булса да борчыймы?

Хәйбулла. Нигә алай дисең? Бу тирәдә безнең авылдан да ямьле авыл юк.

Әхтәм. Әйе шул. Бакча артында ук елга, таулык, урман. Былтыр гәҗиттә дә яздылар бит әле. Зирекле ул – Швейцария, дип.

Әмир. Мин табигатьне әйтмим, авылны әйтәм, урамны. Күрмисезмени, коймалар җимерек... Менә син минем койманы трактор белән аударып киттең дә, кайчан төзәтәсең?

Хәйбулла. Нигә мин? Капкага арт белән чиккәндә, син бит үзең команда бирдең, үзең төзәт.

Әмир. Артка йөри белмәгәч, тракторга утырмыйлар.

Хәйбулла. Анда мин эчмәгән идем, белеп тор.

Әмир. Анда эчмәсәң, башка вакыт эчәсең. Авылда бер айнык кеше табып булмый.

Хәйбулла. Эчмичә ни эшлисең, начальство начар булгач. Эш тә эш, дип кычкыра гына беләсез, акча түләмисез.

Әмир. Әйе, мин начармындыр. Тик мин берүзем өлгерә алмыйм, аңлыйсызмы? Басу эше дә, авыл эше дә миндә.

Хәйбулла. Алган бөтен властьны үзенә, Сталин кебек. Үзе баш, үзе түш. Бир берәр креслоны бүтәнгә.

Әмир. Кемгә? Кеше юк.

Хәйбулла. Эзләсәң табыла ул.

Әмир. Әйдә, менә син бул авыл Советы башлыгы.

Әхтәм. Чынлап та, давай, бул. Клубны зурайтабыз, авылны төзекләндерәбез.

Хәйбулла. Юк. Мин бит эчәм.

Әмир. Әнә шул шул. Юк кеше авылда. Ә безгә әйбәт кенә авыл Советы башлыгы кирәк. Аның белән икәүләшеп тотынсак, аны женсовет председателе итеп җибәрсәк, авылны ялтыратып торыр иде. Тәртип булыр иде.

Хәйбулла. Нигә? Ул хатын кеше булырга тиешмени? Женсовет председателе, дисең?

Әмир. Хатын түгел, кыз.

Хәйбулла. Синең кандидатураң бармы? Кем ул, әйт!

Әмир. Бөтен бәла шунда: безнең авылдан түгел.

Хәйбулла. Анысы начар. Аңа фатир кирәк булачак.

Әмир. Болай эшләргә була... Йортлы егеткә кияүгә бирәбез. Ә? Шәпме? Бер егет кәләшле була. Кыз – фатирлы. Авыл – хуҗалы.

Хәйбулла. Тукта-тукта. Кем ул? Кияүгә чыгарга ризамы?

Әмир. Риза.

Хәйбулла. Кара син аны. Акылы алтын икән. Өй дә булсын аңа, кияү дә. Юк. Якын китермә ул кызны. Ике аягының берсен дә басмасын авылга.

Әмир. Тукта, нигә алай дисең?

Хәйбулла. Аферистка бит ул.

Әмир. Нигә аферистка булсын, нормальный, әйбәт кыз.

Хәйбулла. Кияү дип, өй дип, җитмәсә, авыл Советы председателе булам дип килгән кыз аферистка булмый кем булсын. Ул бит ярты елдан аерылып, өйне бүлеп, авылны талап качып китәчәк.

Әмир. Син салдыңмы әллә?

Хәйбулла. Әллә эчәргә акча биргән идеңме? Ку син ул кызны авылдан, якын җибәрмә.

Әмир. Тукта. Ул кыз күптән безнең авылда!

Хәйбулла. Кем ул?

Әмир. Раилә. «Кызлар» ансамбленең җитәкчесе.

Хәйбулла. Ә, улмыни... Ул чынлап та булдырыр иде тотынса.

Әмир. Әнә шул шул. Ә син «аферистка» дисең.

Хәйбулла. Аферистка булмаса, карьеристлык бар анда. Соң, монда нигә озак уйлап торырга? Без бит бүлештек. Раилә Әхтәмгә чыкты. Әйдә өйләнсен.

Әмир. Мин дә шулай уйлыйм. Язмыштан узмыш юк. Әхтәм, син авыл халкы өчен Раиләгә өйләнергә тиешсең. Син риза бул да, Раиләне үгетли башлыйбыз.

Әхтәм. Тукта, нигә мин?

Әмир. Чөнки бүлешү буенча Раиләгә син өйләнергә тиеш.

Әхтәм. Мин риза түгел. Анда без күрмичә бүлештек. Әнә Хәйбулла өйләнсен. Ул да буйдак.

Хәйбулла. Мин эчкече. Мин бит аның абруен төшерәчәкмен.

Әхтәм. Авылда башка егетләр бетмәгән. Хатипка бирегез.

Әмир. Аның өе иске.

Әхтәм. Сабирга.

Әмир. Әнисе усал.

Әхтәм. Госманга.

Әмир. Ул да эчә. Юк, барысы да уйланган. Ничек кенә боргалансаң да, синнән әйбәт кияү юк авылда. Культура-агарту работнигы, композитор. Эчмисең, үзең өчен түгел, авылның матур киләчәге өчен, кешеләр эчүен ташласын өчен, син Раиләгә өйләнергә тиеш.

Әхтәм. Ә, тукта! Ә нигә син үзең өйләнмисең аңа? Сиңа бигрәк тә уңайлы, син – председатель. Ул – авыл Советы башлыгы. Авылны кулыгызда тотарсыз.

Әмир. Миннән булмый.

Әхтәм. Нигә булмый?

Әмир. Мин өйләнәм. Икенчегә.

Әхтәм. Кемгә?

Әмир. Нураниягә.

Әхтәм. Нураниягә? Ничек Нураниягә? Сиңа бит Кәүсәрия бүленгән.

Әмир. Баштан шулай бүленгән иде, хәзер болай бүлдек. Концерттан соң килешәбез.

Әхтәм. Кара, «син Раиләгә бүленгән» дип тора, ә үзе... Юк, мин дә өйләнмим Раиләгә. Миңа да Нурания ошый. Без хәтта сөйләштек.

Әмир. Нәрсә сөйләштегез?

Әхтәм. Концерттан соң очрашырга.

Әмир. Ул ничек синең белән очрашсын икән, әгәр минем белән загска бара.

Әхтәм. Загс? Нинди загс төн уртасында?

Әмир. Үзебезнең кулда. Теләсәк, төнгә каршы регистрация ясыйбыз. Так что, иптәш бывшый завклуб, сиңа Раиләгә өйләнүдән башка чара юк. Әгәр дә клубтан куыласың килмәсә, әлбәттә. Әгәр клубтан да, авылдан да куылып китәсең килә икән, пожалуйста, өйләнмә Раиләгә. Талаш Нурания өчен.

Әхтәм. Бу дөрес түгел! Бу властьтан файдалану. Мин гәҗиткә язам, судка бирәм. Нурания минеке.

Әмир. Кара, теле чишелде. Менә сиңа Нурания, энем!

Хәйбулла. Туктагыз әле, егетләр! Туктагыз, карап-карап торам да, болай булмый. Монда йә дуэльгә чыгарга, йә шобага тотарга. Икесенең берсе.

Әмир. Никаких! Нурания минеке! Баста!

Әхтәм. Председатель булгач та. Минем дә хокук бар Нураниягә. Хәйбулла дөрес әйтә. Йә атышабыз, йә шобага тотышабыз. Мин атыша белмим. Лучше шобага.

Хәйбулла. Шобага тек шобага. Килегез монда. Хәзер беләбез: кем өйләнергә тиеш.

Әмир. Миңа шобага кирәкми. Әнә, ул тотсын шобаганы. Нураниягә мин өйләнәм.

Хәйбулла. Кил, нигә куркасың? Өскә чыксаң, Нурания бер бәхәссез синеке.

Әмир. Өскә чыкмасам?!

Хәйбулла. Ул чакта атышасыз.

Әмир. Алай булса, ярый. Китер.

Әхтәм. Тукта. Ничек инде алай? Мин өскә чыксам атышабыз?

Хәйбулла. Нигә карап торасың? Тот тизрәк, әнә өскә чыга бит.

Әмир. Турайтма бармакларыңны, турайтма.

Әхтәм. Нигә ике куллап тотасың?

Хәйбулла. Тизрәк, тизрәк! Кем өлгер?

Әхтәм. Мин! Мин өскә чыктым!

Әмир. Күзең чыкканмы әллә, мин өскә чыктым бит!

Әхтәм. Хәйбулла, әйт шуңа! Мин бит!

Хәйбулла. Нигә этешәсез?! Ниндидер кул чыкты өскә. Кемнеке, абайламый калдым, менә шушы җирендә сөяле бар иде.

Әхтәм. Синекендә юк.

Әмир. Синекендә дә юк.

Хәйбулла. Әй, минем кул булган бит. Менә сиңа мә! Кызык бу язмыш, егетләр!

Әмир. Язмыш?

Әхтәм. Әйе! Димәк, Нурания сиңа да, миңа да әләкми.

Әмир. Кит әле, шул таякка ышанасыңмы!

Әхтәм. Тормышта очраклы нәрсә юк.

Хәйбулла. Өйләнәм.

Әмир. Нураниягәме?!

Хәйбулла. Юк, иң акыллысына.

Әхтәм. Кара әле... ә миңа нота белгәне язган микәнни?

Әмир. Нурания – миңа.

Әхтәм. Бушка тырышасың, шобага әйтте, әләкми ул сиңа да!

Әмир. Шулай дип уйлыйсыңмы?

Өйдән кызлар һәм Мәстүрә чыга.

Мәстүрә. Әмир, кайда йөрисез? Әнә кызлар китә бит.

Әмир. Кая китә?

Раилә. Кайтабыз, менә акчагыз. Рәхмәт. Машинаның ачкычы кайда?

Әмир. Ничек кайтасыз? Ә концерт?!

Раилә. Концерт булмый.

Әмир. Анда халык җыелган, сез нәрсә, бездән көләргә җыенасызмы?

Раилә. Менә сез ул бездән көлдегез. Бетте, кайтабыз. Кемдә ачкыч?

Мәстүрә. Ашыкмагыз әле, балалар. Сөйләшик, аңлашыйк.

Раилә. Мәстүрә апа, сезгә рәхмәт сый-хөрмәтегез өчен. Тик бу булдыксыз председателегез аркасында... Әй, аңа әйткәнче. Ачкыч!

Әмир. Тукта, син әйтеп бетер. Ник минем аркада?

Раилә. Сиңа клуб та, концерт та, авыл да кирәкми. Бар уең – уйнашлык.

Әмир. Нигә юкны сөйлисең? Клуб әзер. Баян бар. Халык җыелган. Тагын нәрсә кирәк сиңа?

Ләйсән. Килгәннән бирле, безгә репетиция кирәк, дибез. Күрмәгән-белмәгән баянчы белән мин ничек сәхнәгә чыгыйм?

Кәүсәрия. Минем нинди көйгә биегәнемне дә сорамады бит ул. Син «Таналык» бию көен беләсеңме?

Әхтәм. «Таналык»? Тукта әле, ул бит бию көе түгел.

Кәүсәрия. Әнә бит.

Раилә. Нигә акланасыз, аларга кирәкмәгән концерт безгә нигә кирәк? Киттек, кызлар! Әйдә, яшәсеннәр җимерелеп беткән авылларында. Бирегез минем ачкычны.

Әмир. Син сүз тидермә безнең авылга, ярыймы?

Раилә. Нигә, дөрес түгелмени? Урамыгыз кеше үтәрлек түгел. Егетләрегез эчеп йөри. Бичара Мәстүрә

апа өйләндерәм дип йөргән була. Кем чыксын сезгә? Күреп тор, берничә елда сезнең авыл да таралачак.

Мәстүрә. Таралачак, сез китсәгез бетәчәк. Ух шушы егетләрне! Булдыксызлар сез, нәрсәгә килгән бу кызлар безнең авылга? Мин чакырдым бит аларны. Мин. Үтенеп сорадым. Ярый, Раилә сеңлем, рәхмәт, сүземне тыңладың. Килделәр. Алма кебек дүрт кыз. Сөйләшерсез, килешерсез, өйләнерсез дидем. Юк. Ә сез, кызлар, нигә китәсез? Шәһәрдә сезне ни көтә? Берегезнең дә өе, эше юк. Мин кайда бүлгәнмен, шунда барыгыз. Кияүгә чыгыгыз. Бетермәгез Зиреклене.

Әмир. Дөрес, Мәстүрә апа. Тик менә кызларны син азрак ялгышып бүлгәнсең.

Мәстүрә. Ошамаса, үзегез бүлегез, тик ычкындырмагыз аккошларны.

Кәүсәрия. Юк, апа, рәхмәт. Без китәбез. Мин шул Роберт дигән егетне очратмам микән дип кенә килгән идем. Ул да табылмады...

Хәйбулла. Син бит Рита.

Кәүсәрия. Рита? Ничек белдең?

Раилә. Мәстүрә апа, дөресен әйткәнгә ачуланмагыз, сезнең егетләр безгә ошамый. Шуңа күрә, гафу итегез... Без китәбез.

Әмир. Кара әле! Монда килеп ашап-эчеп алдылар да... Кунак булсаң, тыйнак бул. Егетләр ошамый аңа. Без сездән сорап торырбыз шул. Әлегә сез безнең авылда. Урладык киттек һәм вәссәлам!

Раилә. Кулыңнан килсә.

Әмир. Борчылма, аңа гына килер. Хәйбулла, машинаны карадыңмы?

Хәйбулла. Карадым. Сәгать кебек.

Әмир. Аның өчен туләргә тиеш әле сез. Китер ачкычны. Менә шулай. Бар, китегез хәзер.

Раилә. Бир ачкычны.

Әмир. Әнә шулай ул тормыш. Баштан безгә концерт күрсәтегез матур итеп, шуннан без сезне өйләргә бүлеп алабыз. Үзебез уйлаганча. Иртәгә кайтырсызмы, әллә монда калырсызмы – анысын күз күрер. Ә хәзер без сезне бүлә башлыйбыз. Хәйбулла!

Хәйбулла. Нәрсә?!

Раилә. Оятсызлар! Бандитлар!

Әмир. Зинһар, әнә тегендәрәк барып кычкыр. Югыйсә колакны ярасың.

Раилә. Без сезне судка бирәчәкбез. Белеп торыгыз.

Әмир. Хәйбулла, сайлап ал ошый торган кызның берсен. Кайсысы сездә йоклый бүген?

Раилә. Без беркая да бармыйбыз. Белеп торыгыз.

Мәстүрә. Ай Алла, Ходай сакласын!

Әмир. Хәйбулла, дим.

Хәйбулла. Теләмәгән кешеләрне көчләү шәп эш түгел, әлбәттә.

Әмир. Хәйбулла! Председатель буларак боерам!.. Авылны корытмас өчен! Өйләнеп, балалар үстереп, авылны киредән аякка бастыру өчен! Шушы дүрт кызның берсен сайлап ал!

Хәйбулла. Есть сайлап алырга! Дүртесе дә шәп, кайсысын сайларга? Тукта. Менә машина идәненнән алка табып алдым. Шушы алка кемнеке, шул минеке.

Кәүсәрия. Минем алкам! Бу – язмыш!

Нурания. Урланган алкаң!

Кәүсәрия. Ләйсән... Гафу ит мине, Нурания. Мин бит белмәдем.

Нурания. Башта белергә кирәк.

Хәйбулла. Язмыштан узмыш юк. Рита, Рита, Маргарита! Кәүсәрне сайлыйм. Кәүсәр, кил монда, Роберт мин бит.

Кәүсәрия. Роберт син? Ә нигә Роберт? Син бит Хәйбулла.

Хәйбулла. Яшьлек! Яшь чакта кеше үз исеменнән оялган була бит. Ә син нигә Рита?

Кәүсәрия. Мин үз исемемне яратмадым. Кызлар, ни эшләргә миңа? Раилә?

Раилә. Алар бит бездән көлә, күрмисеңмени? Кайтабыз!

Әмир. Сиңа сүз бирелмәгән. Тик тор! Кәүсәр, бар Хәйбулла янына.

Кәүсәрия. Кызлар, гафу итегез мине. Мин аны җиде ел эзләдем. Миңа инде егерме алты яшь. Әтиәнием дә, өем дә юк. Гафу итегез мине, зинһар.

Раилә. Әй, теләсәң ни эшлә!

Нурания. Кәүсәр, синең характерың йомшак. Ул бит эчкече, син аны тота алмаячаксың.

Хәйбулла. Тотарга мин балык түгел.

Нурания. Вкусыңны әйтер идем инде. Тукта! Ә нигә егетләр сайлый? Нигә без түгел?

Әмир. Чөнки бу авылда без хуҗа. Тавыш! Безнең авылда җитәкче кадрлар җитешми. Авыл Советы башлыгы юк. Женсовет председателе юк. Шундый хәлдә, күрә торып, Раилә кебек әйбәт җитәкчене авылдан ничек чыгарып җибәрик. Шуңа күрә Раиләне бүген үк авыл Советы башлыгы итеп куеп, женсовет председателе итеп сайлап, безнең авыл егетенә кияүгә бирәбез.

Әхтәм. Кемгә?

Раилә. Туктагыз әле! Ә син минем ризалыгымны сорадыңмы?

Әмир. Кирәкми безгә сезнең ризалык. Монда без хуҗа. Бүген кияүгә бирәбез дә, иртәгә эшкә чыгасың!

Раилә. Эш болайга киткәч, сүзне үзем алам. Мине шулай олылап, авыл администрациясе башлыгы, женсовет председателе итүеңә рәхмәт, иптәш председатель абзый. Әлбәттә, минем рөхсәтемне сорамыйча башбаштаклык кылганыңа җаным көеп, баш тарта да алам. Әмма мин риза!

Әхтәм. Риза!

Мәстүрә. Рәхмәт, Раилә кызым, рәхмәт! Йа Алла!

Хәйбулла. Ур-ра!

Әмир. Афәрин! Кил, үбәм шуның өчен берне!

Хәйбулла. Әй-әй! Озак үбешмәгез.

Әмир. Болай булгач, егетләр, авыл бетми!

Раилә. Тик минем шартым бар. Авылны аякка бастыруда авыл Советы берүзе генә эшли алмый.

Әмир. Менә бу кыз!.. Нигә берүзе? Барыбыз белән бергә.

Раилә. Авылларда күреп йөрибез инде... Председательнең үз эше, аларда авыл кайгысы юк. Әгәр без председательне авыл Советына буйсындырмасак, берни дә килеп чыкмаячак.

Әмир. Монысы слишком! Беркайда да председатель авыл Советына буйсынмый, киресенчә...

Раилә. Әнә шул шул. Киресенчә. Әгәр мин авыл Советы башлыгы булсын дисәгез, председатель миңа буйсына.

Әмир. Юкны сөйләмә! Бөтен җирдә дә председатель баш.

Раилә. Булмыймы?

Әмир. Булмый. Бу законга каршы. Конституциягә.

Раилә. Ярый. Председатель авыл Советына буйсынмаса буйсынмасын, әмма син миңа буйсынасың.

Әмир. Ничек?

Раилә. Мин сиңа... өйләнәм!

Әмир. Ничек өйләнәсең?

Раилә. Менә шулай. Риза булсаң, авылда калам, риза булмасаң китәм.

Әхмәт. Ризалаш!

Хәйбулла. Калсын авылда!

Мәстүрә. Раилә кызым, телеңә бал да май!

Әмир. Иптәшләр! Туктагыз әле!

Хәйбулла. Әмир, үзеңне уйлама, авылны уйла!

Әхтәм. Бер елдан авыл чәчәк атачак, яңа клуб булачак.

Барысы бергә. Риза бул! Өйлән! Чык!

Раилә. Бир ачкычны, мин китәм.

Әмир. Тукта!.. Шобага дөрес күрсәткән шул! Их! Авыл өчен ни генә эшләмәссең! Зирекле өчен! Сезнең өчен, чукынмышлар! Риза! Кил, тагын бер үбим!

Барысы бергә. Дөрес! Шулай! Ур-ра!

Әмир. Әхтәм, синең чират! Әйт сүзеңне: кемне сайлыйсың?

Әхтәм. Мин язмышка ышанам. Мин кинәт кенә аңладым: минем кәләшем булырга тиеш...

Ләйсән. Әхтәм, тукта! Башта мин әйтим сүземне.

Барысы бергә. Әйт! Ятып калганчы, атып кал.

Ләйсән. Әхтәм, сиңа яхшылап уйларга кирәк! Бүген Әхтәм ике көй язды, нота яза белмәгәч, икесен дә онытты. Ул сәләтле композитор. Аңа укырга кирәк. Әхтәм, әйдә, икебез дә киттек училищега, укырга.

Әмир. Тукта! Беркем беркая да китми, мин авыл өчен өйләндем, сез дә авыл өчен өйләнеп монда каласыз. Баста!

Раилә. Ә укырлар читтән торып.

Әмир. Дөрес.

Әхтәм. Туктагыз, мин бит кемне сайлаганымны әйтмәдем әле.

Әмир. Шобага әйтте бит!

Әхтәм. Шобага түгел, рухи бердәмлек! Мин көйләр язармын, ә кәләшем җырлар! Ләйсән! Кил!

Нурания. Матурлык – бәхет, диләр. Матурлар иң бәхетсез. Аларга карап сокланалар, ислемайлар бүләк итәләр... Ә өйләнәләр... башкага. Мин...

Мәстүрә. Нурания кызым!

Нурания. Әни!..

Мәстүрә. Кызым минем!.. Мин гомер буе кызым турында хыялландым. Кал бездә, миндә...

Нурания. Син миңа әнием кебек, Мәстүрә апа!.. Мин калам синдә...

Әмир. Дөрес, Нурания! Сиңа да егет табарбыз. Бездә егетләр море! Болай булгач, иртәгә өч туй! Юк, дүрт.

Мәстүрә. Мин бит сезгә туй бүләгем бар дип әйткән идем. Менә ул, хәзер аны сезгә бирергә була. Инде таптатып китмәссез. Сыздыр әле, Әхтәм!

Әхтәм гармунда уйный.

Аллага шөкер, кайтты моң! Гармун тавышы кайтты! Мәхәббәт! Ә бу дөньяны фәкать мәхәббәт коткара бит ул. Димәк, бетмәячәк Зирекле, яшәячәк!

Барысы бергә (*җырлыйлар*).

Моң бетте дип, рух бетте дип,
Калган идек кайгыга.
Кинәт дөнья матурайды:
Кызлар кайтты авылга.

Кызлар белән моңнар кайтты,
Кайтты гармун тавышы.
Кайтты авылны коткарыр
Мәхәббәт һәм кавышу.

Пәрдә.

Талкас, 1998

АЛЫШ-БИРЕШ,
ЯКИ
СИННӘН – ФАТИР, МИННӘН – ИР

Моңсу комедия, ике пәрдәдә

Катнашалар:

Фәрзәнә
Нәҗибә
Хәбибә
Зәйтүнә
Ансар
Мизхәт
} 30–35 яшьләрдә.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ике бүлмәле шәһәр фатиры. Алдагы бүлмәдә ут яна. Анда Фәрзәнә белән Ансар яши. Ансар йоклап ята. Фәрзәнә керә.

Фәрзәнә. Ансар, тор! Сәгать әнә ун тула. Тор!
Ансар. Нәрсә?
Фәрзәнә. Менә әниеңнән телеграмма килде. Безгә бүлмәне бушатырга кирәк.
Ансар. Нәрсә булды?
Фәрзәнә. Күченәбез! Тор! Фатир эзлә! Әй Ходаем! Тагын күченергә!

Ансар торып утыра.

Ансар. Уф! Нәрсә?
Фәрзәнә. Нәрсә-нәрсә? Әнә өч көннән әниең санаторийдан кайта. Нәрсә эшлибез? Ник авызыңа су каптың, әйт, ичмасам, берәр сүз?! Телеңне йоттыңмы әллә?
Ансар. Фәрзәнә... Уф!..
Фәрзәнә. Сиңа шул кирәк!.. Өйдә бит бер тиен акча калмады! Ишетәсеңме?

Ансар. Ишетәм...

Фәрзәнә. Күпме әйтәм мин сиңа, барып сора, дип. Инде өч ай эшлисең. Аванс алырга тиешсеңдер бит! Кайчан бетерәсең шул барельефыңны?

Ансар. Ну... Өч айдан...

Фәрзәнә. Өч айдан? Син нәрсә?! Безне ачтан үтермәкчеме? Нигә өч ай? Нәрсә, син шул өч тиенлек барельефыңны алты ай эшләргә ниятлисеңмени? Башка рәссамнар бер айда әтмәллиләр бит. Нигә сиңа алты ай?

Ансар. Фәрзәнә, зинһар, бәйләнмә. Башым эшләми... Зинһар, чак кына булса да тукта... Үләм бит...

Фәрзәнә. Әй Ходаем! Ничек яшәмәк кирәк шушы ир белән?! Аңлат: кичә нигә эчеп кайттың?

Ансар. Соң бит... Халык рәссамының күргәзмәсен ачтык. Банкетка чакырды, ресторанга. Ул һәркемне чакырмый...

Фәрзәнә. Банкетка чакырса, шулкадәр эчәргәме?

Ансар. Күңел әрни, аңлыйсыңмы? Ирләр нигә эчмәсен хәзер?! Гаиләбезне карый алмыйбыз бит без. Фатир ала алмыйбыз, урамда яшибез.

Фәрзәнә. Җитте, ашама үзеңне. Сиңа главага, администрациягә барырга кирәк... Мин белештем, шәһәр читендә ике йөз меңгә бүлмә саталар. Әгәр шушы эшең өчен аванс алсаң...

Ансар. Юк! Юк! Үлсәм дә бармыйм!

Фәрзәнә. Ансар, ул бит синең классташың...

Ансар. Менә шуңа күрә дә бармыйм. Өч ел элек бер бардым бит инде. Үзен шундый итеп тота. Хан! Минем соранып, баш иеп килүемнән ләззәт таба. Талантсыз бер мәхлук иде бит. Минем талантымнан, данымнан һәрвакыт көнләште, шуның аркасында мине күралмады. Ялагайлык белән глава булып алды да мине кимсетә алуына ләззәтләнә. Ул миңа беркайчан да ярдәм итмәячәк. Чит кешеләргә ярдәм итсә итәчәк, ә миңа – юк. Чөнки ул минем уңышка ирешүемнән курка, минем аска тәгәрәвемне тели. Килгән саен төрлечә мыскыл итеп, кимсетеп чыгарып җибәрәчәк. Ул шулай итеп үзенең булдыксызлыгы, талантсызлыгы өчен миннән үч ала.

Фәрзәнә. Мин бардым.

Ансар. Бардың? Кайчан бардың?

Фәрзәнә. Ярты ай элек. Кабул итмәде. Секретарьшасыннан, Ансарның хатыны мин, дип тә әйттереп карадым. Вакытым юк, диде.

Ансар. Булмаячак та! Минем килүемне тели. Мыскыл итәр өчен. Шиш! Бармыйм!

Фәрзәнә. Теләсә ни эшлә, ике йөз меңне тап.

Ансар. Каян табыйм мин аны?

Фәрзәнә. Вәсил әйтә, ул барельефыңның бер атналык эше калган, ди. Бетер дә акчасын ал.

Ансар. Бер атна!.. Син кемне тыңлыйсың? Вәсил бит рәссам түгел, халтурщик!

Фәрзәнә. Халтурщикмы, түгелме, аның өч бүлмәле фатиры да, мастерское да, машинасы да бар. Синең, шедевр эшләүченең, бернәрсәсе дә юк! Ул барельефыңны бер атнадан бетерәсең! Вәт!

Ансар. Бетерә алмыйм мин аны бер атнада.

Фәрзәнә. Нигә бетерә алмыйсың? Әйт, аңлат! Нигә?

Ансар. Фәрзәнә, ул барельеф тарихта кала, йөзәр ел кала уртасында торачак. Халтура эшләп куйсам, киләчәк буын минем хакта нәрсә дияр? Рәссам түгел, халтурщик булган! Коточкыч!

Фәрзәнә. Киләсе буын сиңа нигә кирәк? Синең бүген гаиләң ач, ялангач, яшәргә урыны юк! Әйт, бетерәсеңме шул барельефыңны бер атнадан, юкмы?

Ансар. Юк, Фәрзәнә, күңелем кушмый... Уф!

Фәрзәнә. Әй Ходаем, нигә кешенең ире кеше кебек, хатынын да, балаларын да уйлый, ә минеке шыр тиле.

Ансар. Фәрзәнә... кадерлем! Хәлем бик хөрт... Юкмы чак кына...

Фәрзәнә. Менә сиңа!

Ансар. Әй Фәрзәнә... Ирең үләргә йөри, ә син... Әнә бер ир махмырдан авыргач, хатыны йөз грамм җәлләгән, ә теге ир яткан да үлгән.

Фәрзәнә. Үл әйдә, дөмек.

Ансар. Үл? Мин... Үлимме? Бәлки, минем сиңа кирәгем юктыр? Бәлки, безгә аерылышыргадыр?

Фәрзәнә. Аерыл! Мондый ирең булганчы...

Ансар. Ярый! Ярый! Аерылабыз! Бүген үк!

Фәрзәнә. Хәзер үк. Бар, чыгып кит!

Ансар. Менә хәзер бер-беребез өчен чынлап та үлдек! Син – минем өчен, мин – синең өчен! Кешеләр! Күршеләр! Үлде! Хатыным үлде! *(Китә.)*

Ут сүнә.

Ут күрше бүлмәне яктырта. Мизхәт ялгызы. Зәйтүнә керә.

Мизхәт. Шуннан? Саулыгы ничек кадерле балдызымның? Операциясе кайчан?

Зәйтүнә. Әй Аллакаем...

Мизхәт. Нәрсә?

Зәйтүнә. Иртәгә кайта.

Мизхәт. Ничек «кайта»? Операция ясамыйлармыни?

Зәйтүнә. Ялгышканнар. Операция дә, бернәрсә дә кирәкми.

Мизхәт. Тфү! Әйттем мин сиңа күчмик дип! Юк! Күчик тә күчик, «фатирга акча түләгәнче, бушлай яшәрбез!» Яшәдең менә бушлай! Тоттырып куйдылар. Ә нинди шәп фатир иде. Арзан! Шәһәр уртасы! Хәзер, бар, тап шундый фатир!

Зәйтүнә. Мизхәт, мин бит яхшырак булсын дигән идем...

Мизхәт. «Яхшырак булсын»! Мин бит сиңа әйттем, аңлаттым! Ә син! Күчик тә күчик! Апам өч ай больницада ятачак! Менә ятты! Күпме әйткәнем бар: тыңламам хатын-кызны дип! Аларны тыңласаң, төп башына утырып каласың, ярык тагаракка. Сезнең бит чәчегез озын, акылыгыз юк! Кабак башлар бит сез! Нервымны кузгаттың... Ашарга бирәр нәрсә бармы?

Зәйтүнә. Менә сөт белән ипи алып кайттым.

Мизхәт. Колбаса алмадыңмыни?

Зәйтүнә. Акчам җитмәде.

Мизхәт. Синең һәрвакыт акчаң җитми. Алып кайтып торасың, суга ыргыткан, ташлаган кебек юк була. Ярый мин эчмим. Әгәр Ансар кебек эчсәм... Соңгы получканы кая куйдың? Өч мең алып кайткан идем бит.

Зәйтүнә. Соң, Мизхәт, балаларга сандали, туфли алдым. Искеләре бөтенләй тузган иде бит. Элек яшәгән фатир өчен бурыч бар иде...

Мизхәт. Башланды! Китер сөтеңне...

Зәйтүнә. Мизхәт, кара әле, әнә теге кош шул ярыкка иртәдән бирле үлән ташый. Нигә икән?

Мизхәт. Нигә? Оя кора, аңгыра. Оясыз кош буламы?

Зәйтүнә. Кошларга да оя кирәк. Ә без – кешеләр... Мизхәт...

Мизхәт. Нәрсә?

Зәйтүнә. Әле генә больницада апам бер хатын белән таныштырды. Шәһәр читендә кечкенә генә өйләре бар икән, бакчасы. Ике йөз меңгә сатам, ди.

Мизхәт. Шуннан?

Зәйтүнә. Әгәр берәр җирдән ике йөз мең табып...

Мизхәт. Зәйтүнә, синең чак кына акылың бармы ул? Ичмасам, шушындый гына, тырнак очыдай...

Зәйтүнә. Мизхәт...

Мизхәт. Безнең хәзергесе минутта колбаса алырлык акчабыз юк. Ә син – ике йөз мең! Каян табасың син аны?

Зәйтүнә. Берәрсеннән бурычка...

Мизхәт. Кемнән? Йә, әйт, кемнән? Хәзер бөтен кеше эшсез, акчасыз утыра. Мактаган илебез миллионлаган кешене эһ тә итми хәерчелеккә ыргытты!

Зәйтүнә. Бөтен туганнардан, танышлардан сорыйк. Егерме кешедән унар мең алсак, менә сиңа ике йөз мең!

Мизхәт. Ха-ха-ха! Менә бүген синнән килеп ун мең сорасалар бирәсеңме?

Зәйтүнә. Без бит ул.

Мизхәт. Бүген бөтен кеше шулай. Беркемнең дә акчасы юк. Булса да бирмәячәкләр. Чөнки беләләр: алган кеше кире кайтара алмый. Менә без шул ике йөз меңне җыеп алдык ди. Ничек кайтарырбыз? Йә, ничек?

Зәйтүнә. Меңәр квадрат метр фатир төзибез дип гәҗитләр яза, көне-төне радио, телевизор сөйли бит. Шуны алып булмый микән соң?

Мизхәт. Җүләр син! Ничек аласың? Ничек? Бер фатир йөз квадрат метр, хакы биш миллион! Беренче взнос бер миллион! Шуны ала аласыңмы?

Зәйтүнә. Әй Ходаем! Нәрсә эшлик соң? Нәрсә? Өйләнешкәнебезгә унбиш ел! Унбиш ел кеше бусагасында, унбиш ел өйсез. Мондый тормышның очыкырые буламы-юкмы? Минем түземем бетте, Мизхәт! Тагын чак кына шушылай яшәсәк, мин йә акылдан шашам, йә асылынып үләм.

Мизхәт. Әй, Зәйтүнә! Дөньялар шуңа киткәч ни эшлисең. Башкалар да шулай яши дип, үзеңне тынычландырасың да, түзәсең инде.

Зәйтүнә. Ичмасам, эше дә юк бит. Әгәр сине кире алмасалар, белмим, ни эшләрбез.

Мизхәт. Җае чыгар әле. Муен булса, камыт табыла ул.

Зәйтүнә. Каян табылсын? Әнә шәһәрдә күпме завод ябыла. Бөтен җирдә сокращение, кешеләрне йөзәрләп урамга чыгарып ыргыталар. Ярты шәһәр эшсез йөри. Каян табасың? Әйбәт кенә эшләп йөри идең бит. Кечкенә генә булса да акчасы бар иде. Нәрсә дип начальнигыңа каршы эндәштең? Үзеңне уйламасаң, мине, балаларыңны уйлар идең!

Мизхәт. Дурак бит ул! Ялагайларны янына җыеп алган да, шуларны яклап, миннән көлеп тора. Әйттем! Белсен! Бөтенесе дә аннан курыкмый!

Зәйтүнә. Ну, әйттең, шуннан? Менә эштән куалар. Хәзер кая барасың?

Мизхәт. Кызып кителде шул. Нервылар беткән. Бу Чечня псих ясады миннән. Кайчак шундый җан әрни, Зәйтүнә. Каршымда торган кешене үтергәнче кыйныйсы килә. Чак-чак кына тотам үземне. Куркам. Бер кызганда ычкынырмын, үз-үземне тоталмам дип куркам.

Зәйтүнә. Аллам сакласын. Син андый чакта, Мизхәт, үзеңне уйлама, безне, балаларыңны күз алдыңа китер. Синсез без ни эшләрбез? Безнең хакка син бүген барып гафу үтен начальнигыңнан...

Мизхәт. Шул гына җитмәгән иде. Ул дурактан гафу үтенгәнче эшсез утырам, ачтан үләм.

Зәйтүнә. Мизхәт, кадерлем, хәзерге заманда алай горур булырга ярамый. Чак кына юха, чак кына ялагай булырга кирәк.

Мизхәт. Менә син ялагай булып нәрсә кырдың? Арт ягыңа тибеп эшеңнән чыгардылар.

Зәйтүнә. Монда күршебез Фәрзәнә гаепле, кәнтәй! Гали инженерга кереп әллә нәрсәләр сөйләгән. Алла бар ул. Әнә хәзер үзен түләүсез отпускыга җибәргәннәр. Сөйләшкәннәрен ишетеп калдым. Алар авылдан өй алалар, имеш. Әниләрен дә үзләренә чакыралар, ди, бала карарга.

Мизхәт. Шуннан?

Зәйтүнә. Ул чакта аларның бүлмәсе дә сеңлемә күчсә...

Мизхәт. Әйе, тоттырдылар ди. Әй, Зәйтүнә! Бигрәк беркатлысың инде...

Зәйтүнә. Нәрсә эшлим соң? Яшәргә урыныбыз юк бит, юк... Нигә шушы безнең кебекләр өчен, ичмасам, тулай торак төземиләр микән? *(Елый.)*

Мизхәт. Совет властен әрлиләр. Менә алар яшьләрне уйлый иде, тулай тораклар төзи иделәр. Ә болар... Эх! Кил, кочаклыйм әле үзеңне. Син үпкәләмә, яме, миңа. Нервыларымны бетерделәр бит, сволочьлар. Мин бит сине яратам, Зәйтүнәкәй. Тик кайчакта... Ярый, елама инде...

Ишек шакыйлар.

Ансар тавышы. Ачыгыз! Үлде! Фәрзәнә үлде! Ачыгыз!

Зәйтүнә. Нәрсә ди? Үлде, диме?

Мизхәт. Шулай ди шикелле.

Мизхәт ишекне ача. Ансар керә.

Мизхәт. Ни булды?

Ансар. Уф!.. Юкмы йөз грамм?

Мизхәт. Син бит беләсең минем биш ел эчмәгәнне.

Ансар. Эшләр хөрт...

Мизхәт. Кем үлде?

Ансар. Фәрзәнә! Бетте! Мин — аның өчен, ул — минем өчен! Үлде! Уф! Табыгыз инде!

Зәйтүнә. Нәрсә? Фәрзәнә үлдеме?

Мизхәт. Ничек «үлде»?

Ансар. Бөтен күңелем актарыла. Салыгыз чак кына.

Зәйтүнә. Кунаклардан калган тора иде. Салып бирик. Йөзе ап-ак бит!

Мизхәт. Булгач сал. Нигә юкны сөйлисең? Бүген тере иде бит.

Ансар. Бүген тере иде, ә хәзер... Бетте! Күңелдә берни калмады... *(Эчә.)*

Зәйтүнә. Йа Ходай! Иртәнчәк кенә кухняда йөри иде.

Ансар. Йөри иде. Тагын сал әле!

Мизхәт. Врач чакырттыңмы? *(Шешәне кулына ала.)*

Ансар. Нигә?

Мизхәт. Соң, врачлар карарга тиеш бит. *(Рюмкага аракы сала.)*

Ансар. Кемне? *(Рюмканы ала.)*

Мизхәт. Фәрзәнәне! Бәлки, үлмәгәндер.

Ансар. Юк, үлде! Ул юк минем өчен. Хәзер мин буйдак.

Зәйтүнә. Менә кайгы!

Мизхәт. Врачлар килдеме?

Ансар. Килде, килде. *(Эчмәкче була.)*

Мизхәт. Моргка алып киттеләрме?

Ансар. Күңел, бүлмә буп-буш! *(Эчә.)*

Мизхәт. Да-а!.. Беркем дә кайчан үләрен белми. Кайгыңны уртаклашам, брат. Эч, эч, кайгыны баса ул.

Ансар. Рәхмәт...

Зәйтүнә. Шундый әйбәт кеше иде. Күрсә, саулык сораша торган иде.

Ансар. Менә шулай... Хәзер ничек... яшәргә? Юк, икенче тапкыр өйләнмим!

Мизхәт. Да, брат! Кайгың бик зур. Зәйтүнә, сал!

Зәйтүнә. Күп эчмәсен, исерә бит.

Мизхәт. Сал, сал! Монда кеше ялгыз калган.

Ансар. Сезгә рәхмәт. Хәлемне аңладыгыз. Бераз җиңеләйтте. Югыйсә өйдә аңлаучы юк.

Зәйтүнә. Ялгыз калгач... Бу вакытлыча гына җиңеләю инде.

Ансар. Ярый, мин кайтыйм.

Мизхәт. Утырып тор. Мондый чакта кеше арасында булырга кирәк. Да, брат, авыры айныгач башланачак. Ул китте, сиңа әле яшәргә кирәк. Ялгыз калган күпме ирләрне беләм, барысы да харап була.

Зәйтүнә. Чөнки вакытында өйләнмиләр. Сиңа да озакка сузмый...

Ансар. Юк-юк! Башкача өйләнү юк.

Мизхәт. Кайгыдан алкашка әйләнәчәксең. Өйлән, брат, тизрәк өйлән. Чечня ветераны буларак әйтәм. Мин Чечняда егетләрнең барысына да әйтә торган идем, кайтыгыз да өйләнегез, дип. Югыйсә харап буласыз. Тыңламадылар. Барысы да эчеп үлеп бетте. Бер мин өйләндем. Һәм менә исәнмен әле. Өйлән, брат, немедленно өйлән.

Ансар. Ярый, күндердең, өйләнермен. Хушыгыз.

Мизхәт. Афәрин! Менә бу егетләрчә! Тукта! Кая киттең? Утыр! Бүген үк өйлән!

Ансар. Бүген? Нигә алай тиз?!

Мизхәт. Мондый вакытта беләсеңме күпме мәшәкать? Яңа хатының ярдәм итәр.

Зәйтүнә. Мизхәт, бәлки, хатынын күмгәч...

Мизхәт. Тик тор! Без сиңа фатирлы хатын табабыз. Өч бүлмәле! Син анда әниең белән күчәсең. Ә бу бүлмәгез безгә кала. Ризамы?

Ансар. Ничек?

Мизхәт. Брат, иртәгә Зәйтүнәнең апасы больницадан кайта. Без бу бүлмәдән чыгып китәргә тиеш. Аңлыйсыңмы?

Ансар. Аңладым. Тик...

Зәйтүнә. Чынлап та! Мизхәт, син – гений!

Мизхәт. Зәйтүнә, сал! Ансар! Өч бүлмәле яңа хатының саулыгына! Тату яшәгез!

Ансар. Рәхмәт! Сез... аны беләсезме?

Мизхәт. Зәйтүнәнең андый берничә подругасы бар. Анда хәтта дүрт бүлмәлеләре дә бар. Зәйтүнә, список төзе. Яшен күрсәтергә онытма. Хәзер сайлыйбыз. Иң элек әйберләреңне җыеп төйнибез. Зәйтүнә, теге коробкалар кайда?

Зәйтүнә. Нинди коробкалар?

Мизхәт. Тавык баш! Күченгәндә әйберләр салган коробкалар! Ташламадыңмы?

Зәйтүнә. Юк.

Мизхәт. Бир Ансарга. Тутыра башласын.

Зәйтүнә. Менә.

Мизхәт. Кайткач, бар әйберләреңне шушында тутырып куй.

Ансар. Мин... Күченәммени?

Мизхәт. Бер сәгатьтән. Зәйтүнә, кайда списогың?

Зәйтүнә. Монда әле бераү генә.

Мизхәт. Кем бу? Ә-ә, теге! Укытучы! Укытучыларга мөнәсәбәтең ничек? Мәктәптә аларны ярата идеңме?

Ансар. Мин беренче класста үзебезнең укытучыга гашыйк идем.

Мизхәт. Хыялың тормышка ашты, брат! Укытучы белән яшәячәксең! О! О! Моның ике фатиры бар! Ишеттеңме, ике! Бәхет бер килсә килә икән! Бер бүлмәле! Һәм ике бүлмәле! Бер бүлмәлесен әниеңә бирәсез. Ике бүлмәлесендә укытучы белән яшисез.

Ансар. Уф! Хәлем җиңеләйде. Рәхмәт. Мин кайтыйм.

Мизхәт. Тукта! Коробкаларын ал.

Ансар. Нәрсәгә?

Мизхәт. Әйберләреңне тутырырга. Әйдә, мин дә ярдәм итәм.

Ансар. Тукта! Тын алырга бирегез... Өйгә кайтып... бераз... үзем генә кайгырып утырыйм.

Мизхәт. Кешене, брат, кайгылы хәлендә ялгыз калдырырга ярамый. Бездә утырып тор. Соңрак икәүләп керербез. Зәйтүнә, нигә карап каттың? Бар, алып кил укытучыңны. Сиңа ун минут!

Ансар. Нинди укытучыны?

Мизхәт. Ике фатирлы. Ну бәхетлесең! Зәйтүнә, йөгер!

Ансар. Туктагыз әле! Мин бит әле ризалык бирмәдем. Бәлки, ул миңа ошамас. Иң элек фотосын күрсәтегез.

Мизхәт. Фотосын алып килергә онытма! Бар!

Зәйтүнә китә.

Ансар. Мизхәт, син ничек миннән сорамыйча...

Мизхәт. Синең хәзер кайгыдан башың эшләми. Шуңа күрә... Утыр, брат!

Ансар. Матурмы соң, ичмасам?

Мизхәт. Нормально. Эчсәң, вообще матур күренәчәк.

Ансар. Кара аны, ошамаса, мин аның белән сөйләшмим дә.

Мизхәт. Брат! Ошаганга егермедә өйләнәләр, утызда фатирлыга.

Ансар. Ну сез... Без бит әле аерылышмаган.

Мизхәт. Үлгән хатынны шунда ук аералар.

Ансар. Ну сез... Ә дөресен әйткәндә, Фәрзәнә бит...

Мизхәт. Нәрсә?

Ансар. Фәрзәнә бит... үлмәде.

Мизхәт. Аңлыйм, брат. Минем беренче хатынның үлгәненә унөч ел. Ә һаман тере кебек. Беренче мәлдә өйгә кайтсаң, бүлмәдә көтеп утырадыр кебек тоела иде. Чак кына акылдан шашмадым.

Ансар. Фәрзәнә үлмәде! Үлмәде, аңлыйсыңмы?

Мизхәт. Тынычлан. Мә, эч. Үлгән артыннан үлеп булмый, яшәргә кирәк, брат. Әнә шуңа да тизрәк өйлән. Акылдан шашмас өчен.

Ансар. Үлмәде! Фәрзәнә үлмәде!

Мизхәт. Димәк, яраткансың. Фәрзәнәнең үлеме – синең өчен бәхет.

Ансар. Бәхет? Ни өчен?

Мизхәт. Фатир, фатир дип елый идең. Хәзер фатирлы хатынга өйләнәсең. Менә мин, Чечнядан кайткач, хата җибәрдем. Фатиры бармы, юкмы – сорап тору юк, тот та шушы Зәйтүнәгә өйлән. Дурак! Мәхәббәт, имеш. Хәзер шул сүзне ишетсәм, косасы килә. Кайчак уйлап та куям: әллә моны аерып, фатирлыга өйләнергәме дип? Тик Зәйтүнә жәл. Ярый. Минем язмыш харап булды. Әйдә, сине коткарыйк. Ну бәхетле кеше син, ә! Хатының үлде! Фатирлы хатын аласың. Ну, брат! Давай, бәхетеңнең бер очын миңа да татыт. Әниеңнең бүлмәсен безгә бир. Бирәсеңме? Әйт сүзеңне, йә?!

Ансар. Ярый, ал!

Мизхәт. Рәхмәт, брат! Гомергә онытмам. Әйдә, новоселье белән!

Ансар. Новоселье белән! Ә син нигә эчмисең?

Мизхәт. Мин бит инде биш ел эчмим.

Ансар. Кит әле! Әйтәм гел усал йөрисең!

Мизхәт. Кара әле, син художник бит әле.

Ансар. Алдан әйтәм, мин халтура эшләмим.

Мизхәт. Халтура түгел, шедевр. Минем начальникның портретын эшлә әле. Иртәгә аның туган көне. Ул мине эштән куа. Бәлки...

Ансар. Халтура – юк.

Мизхәт. Кара әле. Мин сиңа кәләшле фатир таптым, ә син...

Ансар. Халтура – юк.

Мизхәт. Эшлисең бүген үк. Менә гәҗиттә фотосы чыккан иде. Мә.

Ансар. Халтура – юк.

Мизхәт. Кара аны: мин – псих! Мин Чечняны үткән. Кыздырма мине. Яхшылык белән әйтәм.

Ансар. Халтура – юк.

Мизхәт. Ах, шулаймы?! Мин сиңа кешечә, ә син, сволочь. *(Ансарга ябыша.)* Эшлисеңме, әйт! Эшлисеңме?

Ансар. Юк! Юк! Кәләшегез дә, фатирыгыз да кирәкми! Фәрзәнә тере!

Зәйтүнә белән Нәҗибә керә.

Зәйтүнә. Мизхәт! Ансар! Нәрсә булды?

Мизхәт. Нәҗибә, саумы!

Нәҗибә. Саумысыз!

Мизхәт. Таныш булыгыз: Нәҗибә. Ансар.

Ансар. Бик шатмын.

Нәҗибә. Мин дә.

Зәйтүнә. Теге укытучыны табып булмады. Аның исеменнән сөйләшергә Нәҗибә килде. Алар якын ахирәтләр. Ансар, мин Нәҗибәгә хәлне аңлаттым. Теге укытучы турында ул сөйләр.

Нәҗибә. Ул сине белә, Ансар. Картиналарыңны бик ярата. Иҗатыңа гашыйк. Исеме... Нажия...

Мизхәт. Исеме нәрсәгә аның? Фатиры ничәү?

Нәҗибә. Фатиры... икәү.

Мизхәт. Ничә бүлмәле?

Нәҗибә. Бер һәм ике бүлмәле.

Мизхәт. Бәй...

Зәйтүнә. Мизхәт, соңрак аңлатырмын. Хәзер, иң мөһиме, Ансар риза булсын. Менә фотосы.

Мизхәт. О! Мисс России!

Ансар. Ничә яшь соң аңа?

Нәҗибә. Ә-ә... Утыз ике.

Ансар. Монда бит егерме тирәсе.

Мизхәт. Яшь чагында төшкән.

Ансар. Бик таныш. Мин аны кайдадыр күргән кебекмен.

Мизхәт. Димәк, хәл иттек. Өйләнәсең. Хәзер әйберләреңне...

Ансар. Тукта! Нигә ул утыз икегә тиклем кияүгә чыкмаган?

Нәҗибә. Чыккан иде. Ире үлде.

Ансар. Үлгән? Бу тиккә түгел.

Зәйтүнә. Нәҗибә, яшереп тормыйбыз инде, әйе бит. Эчкән, соңыннан асылынган.

Ансар. Асылынган?! Йа Ходай! Укыган идем: ирләрне асылынырга хатыннары алып барып җиткерә икән.

Зәйтүнә. Моның ире үзе...

Ансар. Ә ничек ике фатир эләктергән? Безгә бирәү дә юк, ә аңа – икәү! Аферистка түгелме?

Нәҗибә. Берсе әнисеннән калган, ә икенчесе – иреннән.

Мизхәт. Җитте! Өйләнгәндә күп сөйләмиләр! Киттек!

Ансар. Юк! Мин ул хатынга өйләнмим! Мин вообще өйләнмим! Минем Фәрзәнәм бар! Аннан китсәм, ялгыз яшим!

Зәйтүнә. Бахыр!.. Бүген генә үлгәч, онытуы кыен шул.

Ансар. Мин кайтам!

Мизхәт. Син нәрсә? Безне тилегә санныйсыңмы? Өйләнәм дип безнең аракыны эчте-эчте дә, качарга ниятлисеңме? Юк инде, брат, өйләнәсең!

Нәҗибә. Ярый, китсен! Ул хатын артыннан йөрүчеләр эт көтүе кадәр! Җүләр син, рәссам Ансар! Җүләр! Теләсә, Нажия менә дигән иргә чыга ала. Сайлап. Просто мәктәптә ирләр юк. Гел хатыннар. Бер физруктан башка. Ул да өйләнгән... Нажия иҗат кешеләрен ярата. Синең хатыныңың үлгәнен белгәч, бик шатланды, куанды. Ул сиңа, синең иҗатыңа бөтен гомерен корбан итәргә әзер! Ә син... син... Шундый хатынның күңеленә төкереп... Йөрәксез син!

Зәйтүнә. Нәҗибә, тынычлан... *(Ансарга.)* Бәгырьсез!

Мизхәт. Сволочь!

Ансар. Туктагыз әле! Мин нәрсә эшләгән? Минем Фәрзәнәм тере, Фәрзәнәм үлмәде, ә сез...

Мизхәт. Җитте! Ялкытты. Нәҗибә, үпкәләмә. Ансар хәзер әйткән сүзләрен кире ала.

Ансар. Нинди сүзләрне! Мин бернәрсә дә әйтмәдем.

Мизхәт. Ещё ничек кенә әйттең! «Өйләнмим! Миңа ике бүлмәле фатирлы кәләш кирәкми, әниемә бер бүлмәле фатир кирәкми, бу бүлмәне сезгә бирмим!» Кабахәт син!

Ансар. Тукта әле. Мин...

Зәйтүнә. Үзеңне уйламасаң, безне уйлар идең! Әй Ходаем! Ни өчен шултиклем рәхимсез икән безгә язмыш?!

Мизхәт. Зәйтүнә, тын... Ансар уйламыйчарак ычкындырды. Ул начар кеше түгел.

Ишек шакыйлар.

Керегез!

Хәбирә керә.

Хәбирә. Саумысыз!

Барысы бергә. Саубыз әле!

Хәбирә. Ансар биредә яшиме? Ә-ә, Ансар, саумы! Таныйсыңмы?

Ансар. Хәбирә! Саумы!

Хәбирә. Котлыйм! Әй, кайгыңны уртаклашам. Хатының үлгән икән.

Ансар. Ә-ә... Рәхмәт!

Хәбирә. Биредә яшисеңме?

Ансар. Юк, күрше бүлмәдә.

Хәбирә. Әйдә, керик әле.

Ансар. Юк-юк!

Хәбирә. Хәер, мәет чыккан бүлмәдә кырык көн яшәргә ярамый. Бүгеннән үземә күчәсең. Бер бүлмәм барыбер буш тора.

Мизхәт. Тукта, мадам! Син кем һәм ни өчен?

Хәбирә. Абзый, тик тор. Сиңа сүз бирелмәгән.

Нәҗибә. Карагыз әле, сез бик кызык кеше.

Хәбирә. Түтәй, сиңа нәрсә ошамый?

Нәҗибә. Нишләп әле мин сиңа түтәй булыйм ди. Мин бит синнән яшь!

Хәбирә. Ха-ха! Син, апа, ирләрне алда. Мин бит күрәм. Күзем чыкмаган. Битеңә ничә кило крем сөрттең?

Нәҗибә. Сез, сез!..

Хәбирә. Сүзең беттеме?

Мизхәт. Минем сүзем бетмәде!

Хәбирә. Туктап тор! Сиңа чират җитмәгән. Димәк, Ансар, болай. Хатыныңны күмдеңме?

Ансар. Юк...

Хәбирә. Менә сиңа ун мең. Хатыныңны җирләү өчен.

Ансар. Юк! Кирәкми!

Хәбирә. Ал! Җирләргә күпме акча киткәнен беләбез. Димәк!..

Мизхәт. Мадам! Тыңла! Үзең чыгып китәсеңме, әллә ярдәм итимме?

Хәбирә. Бу кем?

Мизхәт. Шушы бүлмәнең хуҗасы.

Хәбирә. Сине мәктәптә хатын-кыз белән ничек сөйләшергә өйрәтмәделәрмени, иптәш грубиян?

Мизхәт. Өйрәттеләр. Һәрчак өчкә кадәр сана, диделәр. Әгәр өч дигәндә... чыгып китмәсәң...

Ансар. Мизхәт, тукта әле.

Мизхәт. Үзем чыгарып ыргытам! Бер!

Ансар. Мизхәт, Хәбирә – бизнесменша!

Мизхәт. Ике!

Ансар. Ул сине үзенә эшкә ала!

Мизхәт. Ике ярым!.. Бу дөресме?

Хәбирә. Әйе, миңа ярдәмче кирәк. Грузчик та, водитель дә булсын. Мин әлегә Ансарны алам.

Мизхәт. Ә мин?

Хәбирә. Ә син көтеп тор. Ансар, менә сиңа ике йөз мең. Бүген үк Тольяттига барып, машина алып кайтасың. Синең эш: мине Төркиягә озатып, йөк белән каршы алу, базарга илтү. Калган вакытыңда картиналар язарсың. Сораулар бармы?

Нәҗибә. Сез нигә...

Хәбирә. Тавыш!

Ансар. Тукта әле, Хәбирә...

Хәбирә. Ярты сәгатьтән юлга! Машинаны бүген үк алып кайтырга! Иртәгә Төркиядән йөк килә. Каршы алырга кирәк!

Ансар. Мин бүген бара алмыйм.

Хәбирә. Аңлат.

Ансар. Ну... беренчедән...

Хәбирә. Аңладым... Синсез җирләрбез. Әле ул кайда? Моргтамы?

Ансар. Мин бара алмыйм! Мин җиде кат уйларга яратам. Мин әкрен! Мин кинәт кенә күчә алмыйм. Капыл гына өйләнә алмыйм. Һәм вообще минем хатыным тере! Аңлыйсызмы шуны?!

Хәбирә. Нервы! Стресс! Аракы бармы?

Мизхәт. Менә.

Хәбирә. Эч. Иң әйбәт дәва.

Ансар. Эчмим! Үлмәде минем бичәм! Ул тере, тере! Фәрзәнә! Фәрзәнә!

Хәбирә. Тот! Утыр! Хәзер үтә ул.

Мизхәт ишеккә ташланган Ансарны, тотып, диванга утырта.

Ансар. Җибәр мине! Җибәр!

Мизхәт. Тукта, брат! Тыпырчынма! Югыйсә бәйләп салам!

Ансар. Мин кайтам! Җибәрегез мине! Кайтам! Анда мине хатыным көтә!

Нәҗибә. Нигә сез шулай... Кулын авырттырасыз бит. Җибәрегез аны!..

Мизхәт *(Нәҗибәгә)*. Кит әле моннан! *(Ансарга.)* Тынычландыңмы? Әнә шулай... Шаярма, брат! Югыйсә менә... бау әзер!

Нәҗибә. Тынычлан, Ансар. Алар... Авыртамы?

Ансар. Йөрәксезләр! Роботлар! Сез кешенең күңелен... Сез бит... *(Елый.)*

Хәбирә. Йөз грамм!

Зәйтүнә. Бетте!

Хәбирә. Мә! Тиз генә барып кил! *(Акча бирә.)*

Зәйтүнә чыга да кире керә.

Зәйтүнә. Анда тагы ике хатын килгән.

Мизхәт. Нәрсә кирәк аларга?

Зәйтүнә. Ансарның кайгысын уртаклашырга телиләр.

Мизхәт. Ку! Якын йөрмәсеннәр!

Зәйтүнә чыгып китә.

Ансат кына ир тапканнар!.. Ә син бик тәвәккәл хатын!.. *(Кулын суза.)* Мизхәт.

Хәбирә. Хәбирә.

Мизхәт. Конкрет сөйләшәбез. Әнә теге утырган хатынның исеме Нәҗибә. Бүген үк ул Ансарны да, Ансарның әнисен дә үзенә алып кайта. Шул чакта Ансарның бүлмәсе безгә кала. Ә син нәрсә тәкъдим итәсең?

Хәбирә. Ансарны алып китәм.

Мизхәт. Ә әнисен?

Хәбирә. Әнисендә эшем юк.

Мизхәт. Бармый. Бүлмә безгә калырга тиеш. Безнең бүлмә юк.

Хәбирә. Ул синең проблемаң.

Мизхәт. Мадам, Ансар минем сүздән чыкмый. Әгәр шушы хатынга өйлән дисәм, өйләнәчәк. Сиңа өйлән дисәм, сиңа өйләнәчәк.

Хәбирә. Миңа посредник кирәкми. Ансар!

Мизхәт. Тукта! Нигә шул Ансарга чат ябыштың? Сиңа водитель кирәкме, әллә ирме?

Хәбирә. Водитель дә кирәк, ир дә эчне тишмәс иде.

Мизхәт. Мин барам сиңа водитель булып. Ирне иртәгә табып бирәм.

Хәбирә. Каян? Безнең шәһәрдә нормальный ир юк. Бердәнбер настоящий ир бүген пәйда булды. Шәһәрнең барлык ялгыз хатыннары ыргып тора. Ансар! Кил монда!

Ансар. Нәрсә?

Хәбирә. Кил монда, димен. Түтәй, апа, сиңа әйтәм, җибәр, нигә аңа ябыштың?

Нәҗибә. Нигә чакырасың аны? Без хәзер миңа китәбез.

Хәбирә. Бар, апа, кайтып чәй кайната тор. Без хәзер киләбез.

Нәҗибә. Юк, мин Ансарсыз беркая да китмим.

Хәбирә. Китмәсәң, читтәрәк тор! Ансар! Нигә җебеп төштең? Ну-ка, смирно! Живот убрать!

Ансар. Миңа кыен. Хәлем юк...

Хәбирә. Кичә күп эчтеңмени?

Ансар. Банкет булган иде.

Хәбирә. Аңлашылды. Болай итәбез. Хәзер миңа барабыз. Бүген ял итәсең. Иртәгә – Тольяттига. Сораулар бармы?

Нәҗибә. Мин...

Мизхәт. Бар! Әнисен кая куябыз?

Хәбирә. Ай Алла! Әниең кайда?

Ансар. Санаторийда. Өч көннән кайта.

Хәбирә. Кайткач та үзебезгә алабыз. Тагын сораулар?

Мизхәт. Димәк, бүлмә...

Хәбирә. Сиңа кала.

Нәҗибә. Сезнең хакыгыз юк! Сез не имеете право! Ансар! Ул бит сине урлый. Сатып ала. Ансар, ишетәсеңме?

Ансар. Нәҗибә, борчылма. Мин беркая да бармыйм.

Мизхәт. Барасың, брат! Тор!

Нәҗибә. Тимәгез аңа! Хакыгыз юк! Ансар, торма!

Мизхәт. Кит яныннан! Бер!

Нәҗибә. Ул бит Ансарны үзенә өйләндермәкче, кол итмәкче! Ансар – талантлы рәссам! Ул йөк ташырга түгел, иҗат итәргә тиеш!

Хәбирә. Яп әле шуның авызын.

Мизхәт. Ике!

Нәҗибә. Ансар!

Ансар. Мизхәт, тимә! Зинһар!..

Мизхәт. Ярый. Тагын тавышыңны чыгарсаң, мадам, коридорда булачаксың!

Хәбирә. Ансар, мин дә синең талантыңны хөрмәт итәм. Мин сиңа акча бирәм, фатир. Аена 3–4 көн эшләячәксең. Калган 25 көн сурәт ясаячаксың. Сораулар?

Ансар. Моның өчен мин сиңа өйләнергә тиешме?

Хәбирә. Аннан күз күрер.

Ансар. Юк, ни өчен мин? Сиңа башка ирләр беткәнме?

Хәбирә. Беткән.

Ансар. Ничек «беткән»? Урам тулы ир!

Хәбирә. Кайда? Кайда? Белмим, син кайда күргәнсеңдер ирләрне. Урам тулы хатыннар! Аена ике тапкыр Төркиягә очам. Самолёт тулы хатыннар. Шифоньер зурлыгындагы чемоданнарын күтәреп йөгерешәләр. Базарда сата хатыннар. Юл төзәтә хатыннар. Ялгыз дөнья көтә хатыннар. Бөтен җирдә хатыннар. Юк ирләр. Кырылып бетте. Минем ирем дә эчеп авариядә һәлак булды. Булдыклы ирләр өйләнгән. Өйләнмәгәннәре йә бернәрсәгә дә ярамый, йә эчкече. Юк ирләр. Бүген синең хатының үлгән дигән хәбәр «ә» дигәнче бөтен шәһәргә таралды. Бөтен ялгыз хатыннар тревога белән күтәрелде. Барысы да сине эләктерергә тырыша. Менә шуңа мин дә биредә.

Ансар. Мин дә бернәрсәгә дә ярамыйм. Мин дә эчкече!

Хәбирә. Син – талант! Син – күренекле рәссам! Безнең шәһәрдә синнән дә шәп ир юк, Ансар!

Нәҗибә. Дөрес! Тик...

Мизхәт. Менә мин сезне тыңлап торам да... Ну и дуры вы, хатыннар. Куропатки! Карагыз монда! Көч бар. Төс бар. Баш бар. Характер бар. Правам бар. Каратист. Телохранитель. Ә Ансар? Фу! Ул бит чүпрәк! Бозау! Аны бит бер кул белән! Менә кара! *(Ансарны эләктереп ала.)*

Ансар *(аптырап)*. Әләй, нишләвең?

Нәҗибә. Кулын сындырасың бит!

Мизхәт. Хәбирә, ул синең бар эшеңне юкка чыгарачак! Мине ал грузчик, учётчик, валютчик, водитель, строитель, телохранитель итеп! Не подведу!

Хәбирә. Синең хатының үлмәгән.

Мизхәт. Хатын не стена, отодвинем! Ике йөз меңгә өй алып бирәбез дә шунда күчерәбез.

Хәбирә. Юк, мин кеше бәхетен бозып, үз бәхетемне корырга теләмим.

Мизхәт. Мин аңа икенче ир табып бирәм. Иртәгә үк!

Хәбирә. Кара, син бик деловой икәнсең... Яратам тәвәккәл кешеләрне. Кил әле бирерәк.

Нәҗибә. Ансар! Мин сине алдадым!

Ансар. Ничек?

Нәҗибә. Нажия юк ул. Нажия ул – мин, Нәҗибә. Баштан әйтергә оялдым. Мин бит сине мәктәп елларыннан яратам. Тик син мине күрми дә идең. Синең иҗатыңа гашыйкмын. Һәр күргәзмәгә йөри идем. Син миңа игътибар да итмәдең. Мин сине яратам, Ансар!

Ансар. Син дә миңа охшыйсың да ул...

Нәҗибә. Шулай булгач! Бер фатирда без яшәрбез, икенчесендә – әниең.

Ансар. Әнием? Тукта, башка уй килде!.. Син көтеп тор. Мин киңәшләшеп килим.

Нәҗибә. Кем белән?

Ансар. Хатыным белән... түгел! Рухы белән!.. *(Чыгып китә.)*

Ут сүнә.

Икенче бүлмә яктыра. Фәрзәнә ялгызы. Ансар керә.

Фәрзәнә. Йә, туйдыңмы эчеп?

Ансар. Туйдым.

Фәрзәнә. Кайда эчтең?

Ансар. Күршеләрдә.

Фәрзәнә. Син үзеңнән үзең көләсең. Алар сине түбәнсетү өчен юри башыңнан коя.

Ансар. Коярга бик теләмиләр шул. Койсыннар өчен сине үлде дип әйтергә туры килде.

Фәрзәнә. Нәрсә?! Мине «үлде» дидеңме?!

Ансар. Син үзең «үл» дидең бит. Мин дә сине «үлде» дидем. Зато сразу койдылар.

Фәрзәнә. Йа Ходай! Бетте! Бу – крах! Соңгы нокта! Син – беткән алкаш. Сине немедленно больницага салырга кирәк! Киен, киттек!

Ансар. Фәрзәнә, тукта әле!

Фәрзәнә. Юк-юк, туктамыйм! Больницага, хәзер үк больницага.

Ансар. Барам, барам. Тик син тыңла. Безнең шәһәрдә бер дә ирләр калмаган, шәһәр ялгыз хатыннар белән тулган икән.

Фәрзәнә. Всё! Белая горячка!

Ансар. «Хатыным үлде» дигәч, дүртәүләп килеп җиткәннәр.

Фәрзанә. Нигә?
Ансар. Мине ир итеп алырга.
Фәрзанә. Син алкаш кемгә кирәк?
Ансар. Берсе – безнесменша! Менә ун мең бирде. Сине җирләргә.
Фәрзанә. Нәрсә эшләргә?
Ансар. Сине җирләргә. Тагы ике йөз мең бирде машина алырга.
Фәрзанә. Йа Ходай! Ә ул ике йөз мең кайда?
Ансар. Алмадым.
Фәрзанә. Алырга кирәк иде. Шәһәр читендә фатир...
Ансар. Ул бит мине үзенә ир итеп алырга тели. Ә икенче хатын... фатир бирә!
Фәрзанә. Аның шулай фатиры күпмени?
Ансар. Ике фатиры бар. Берсендә без яшәрбез, ди. Икенчесендә әниең яшәр, ди.
Фәрзанә. Бу дөнья акылдан шашканмы әллә? Эчкече, алкаш ир өчен ике йөз мең, фатир! Бернәрсә дә аңламыйм. Әллә мин җүләрләнеп бараммы?
Ансар. Фәрзанә, әгәр шушы мөмкинчелектән файдаланып калмасак, без чынлап та җүләр!
Фәрзанә. Нәрсә әйтмәкчесең?
Ансар. Безгә ике йөз меңне яки фатирны алырга кирәк.
Фәрзанә. Ничек?
Ансар. Ничек-ничек! Белмим ничек! Минем баш эшләми. Син бит аек. Әйт берәр сүз!
Фәрзанә. Алар бит мине үлгән дип уйлый.
Ансар. Ну?
Фәрзанә. Нәрсә «ну»?
Ансар. Бәлки, уйласыннар әйдә сине үлгән дип, ә? Ә мин бизнесменшадан ике йөз меңне алам. Аны фатир өчен кредитка түлибез. Яки икенче вариант. Икенче хатынның бер бүлмәле фатирына балалар белән сине күчерәбез!
Фәрзанә. Ә син?
Ансар. Нәрсә мин?
Фәрзанә. Син кайда яшәрсең димен.
Ансар. Мин ни... яшәрмен әле шунда берәр җирдә.

Фәрзәнә. Ах син, уйнаш! Мине ике йөз мең белән, фатир белән алмаштырып, качарга телисеңме?!

Ансар. Фәрзәнә, алай түгел! Алай түгел!..

Фәрзәнә. Миннән ялыктыңмы?! Яңа хатын кирәк булдымы?! Мә сиңа яңа хатын! Мә! *(Суга.)*

Ансар. Фәрзәнә, син дөрес аңламадың! Син...

Фәрзәнә. Ә ул хатыннар?! Нинди йөзләре белән балалы хатынның закунлы ирен тартып алмакчылар?! Мин бит аларны! Күрмәгәннәрен күрсәтәм! Кайда алар?!

Фәрзәнә чыга, аңа Ансар иярә.

Ут сүнә.

Мизхәтләрнең бүлмәсендә ут яна. Мизхәт белән Хәбирә бииләр. Нәҗибә ары-бире йөренә.

Нәҗибә. Нигә озаклый ул?.. Нигә?

Мизхәт. Фигураң бик матур, Хәбирә!

Хәбирә. Синеке дә ничего!.. Акчага хатыныңа өй алсак... Ә машинасыз безгә ярамый. Товарларны...

Мизхәт. Әтидән миңа иске «Запорожец» калган иде. Шул ярап торыр. Соңрак берәр нәрсә әтмәлләрбез!

Хәбирә. Яратам тәвәккәл ирләрне!

Мизхәт. Син мине белмисең әле! Мин ул – у-ух! *(Үбә.)*

Хәбирә. Ай-ай! Тынымны бетерәсең!

Нәҗибә. Нигә озаклый ул?!

Зәйтүнә кайтып керә.

Зәйтүнә. Магазинда чират... Бәй, нәрсә эшлисез сез?

Мизхәт. Ә-ә, кайттыңмы?

Зәйтүнә. Юк, әле генә сез нәрсә эшләп тора идегез?

Мизхәт. Нәрсә-нәрсә! Үбешеп тора идек.

Зәйтүнә. Ах, кәнтәй! Кеше ирен тартып алырга йөрисеңме?!

Мизхәт. Тукта әле! Тукта!

Зәйтүнә. Юк, туктамыйм! Көпә-көндез!..

Мизхәт. Тукта, димен! Тынычлан! Сиңа фатир кирәкме? Фатир?

Зәйтүнә. Фатир? Кайда ул?

Мизхәт. Хәбирә ике йөз бирә. Шәһәр читеннән бакчалы өй сатып аласың. Шәпме?

Зәйтүнә. Кайчан?

Мизхәт. Бүген үк аласың.

Зәйтүнә. Нигә «аласың»? Алабыз.

Мизхәт. Юк, кадерлем, аласың. Син ун ел фатирсыз азапланасың. Ун ел кеше бусагасында йөрисең. Мин сине уйлап, сине өйле, фатирлы итәм дип... Аңлыйсыңмы?

Зәйтүнә. Юк, аңламыйм.

Мизхәт. Аңгыра! Мин Хәбирәгә грузчик, водитель булып күчәм!

Зәйтүнә. Нигә күчәсең? Эшкә урнашам, диген.

Мизхәт. Урнашмыйм шул, күчәм. Анда көне-төне эш. Кайтып йөреп булмас.

Зәйтүнә. Бу бит... Бу бит...

Мизхәт. Әйе, дөрес. Башың бар икән.

Зәйтүнә. Ах син, уйнаш! Күрсәтәм мин сезгә «көне-төне эш»не! *(Суга.)* Мә! Мә! Мә сиңа да!

Хәбирә. Ай!

Мизхәт. Зәйтүнә, тукта!

Фәрзәнә белән Ансар керә.

Фәрзәнә. Кемгә монда ир кирәк?! Кемгә?

Нәҗибә. Фәрзәнә?!

Хәбирә. Йа Ходай!

Мизхәт. Брат, бу нәрсә?!

Зәйтүнә. Син бит үлдең!

Фәрзәнә. Мин үлдем! Үлдем! Бу минем җаным. Сездән үч алырга килдем! Сиңа ир кирәкме? Сиңамы? Мә сезгә ир! Мә!

Нәҗибә. А-а!

Хәбирә. А-а!

Тавыш. Игътибар! Игътибар! Безнең шәһәрдә фатирлар төзү киң темп белән алга бара. Быел йөз дә иллешәр квадрат метрлы ике мең фатир, ягъни өч миллион квадрат метрлык фатирлар төзелде... *(Тавыш музыкага күмелеп югала.)*

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зәйтүнә бүлмәсе.
Зәйтүнә белән Нәҗибә.

Нәҗибә. Данлыклы рәссам! Көн дә телевизордан күрсәтәләр, гәҗиттә язалар! Ә ул!.. Шундый кыен!..

Зәйтүнә. Мин ул дип, балалар дип, көне-төне чабам, аны өрмәгән җиргә дә утыртмыйм. Менә аның рәхмәте! Бөтен ирләр дә сволочь!

Нәҗибә. Минемчә, барысының да хатыны гаепле, Фәрзәнә. Ул бит Ансарны кимсетә, бөтенләй кешегә санамый... Ансар шундый жәл...

Зәйтүнә. Бөтен ирләр бер! Яшь, бай хатын күрсәләр, ияреп китәргә генә торалар. Ә хатыны белән балалары теләсә ни эшләсен!

Нәҗибә. Фәрзәнә аның кадерен бөтенләй белми. Кеше алдында ничек әрләп ташлады. Чит кешеләр алдында йөзен ертты, мыскыл итте. Шундый сүзләрдән соң мескен ирләр нәрсә эшләсен инде? Менә мин үлгән иремне еш исемә төшерәм. Шундый әйбәт кеше иде бит ул! Өрмәгән җиргә дә утыртмый иде. Аның үлемендә еш кына үземне дә гаеплим. Бер юкка да әрли торган идем мәрхүмне!.. Бер кирәкмәгәнгә. Шунда әйбәтләп кенә утырып аңлашып булмады микәнни? Бер кирәкмәгәнгә хәтерен калдырып...

Зәйтүнә. Бәй... Нигә елыйсың?

Нәҗибә. Ирем жәл...

Зәйтүнә. Кит, җүләрләнеп үзе асылынып үлгән ирне жәлләп утырмасаң... Беләсең килсә, син бәхетле. Ирең асылынган, ичмасам. Ә менә минекен асылындырырсың! Үзеңне асылынырга мәҗбүр итәр! Күз алдында икенче хатын белән үбешеп тора, сволочь! Хәзер әнә чыкты да китте. Мөгаен, шушы минутта тагы теге хатыны белән берәр җирдә үбешеп торадыр әле, кабахәт!

Нәҗибә. Ул бит Ансар артыннан чыгып китте.

Зәйтүнә. Теге хатын да юк булды. Эзләп килим әле. Югыйсә хәзер ирсез дә, фатирсыз да торып калам.

Хәбирә керә.

Хәбирә. Мөмкинме?

Зәйтүнә. Оятың юк икән! Нигә килдең?

Хәбирә. Фәрзәнә киттеме? Шиньоным төшеп калган. Вәт дура!

Зәйтүнә. Үтермәгәнгә рәхмәт әйт.

Хәбирә. Ул бит әнә Нәҗибәне үтерергә тиеш.

Зәйтүнә. Ә мин – сине! Кайда Мизхәт?

Хәбирә. Мин каян белим синең псих иреңне?

Зәйтүнә. Хәзер психка әйләндемени? Бая үбешеп торганда бер дә псих димәгән идең.

Хәбирә. Син бит аны үзең псих дидең... Ярый, мин китим. Йә чынлап та үтереп куярсыз. Ә син нәрсә карап утырасың? Кач исән чакта.

Нәҗибә. Белмим... Хәзер ни эшләргә дә белмим. Сез мине ир кирәккә килгән дисезме? Мин бит... Ансарны... мәктәп елларыннан... Ул шундый жәл. Яшисем килми.

Хәбирә. Әллә чынлап яратасың? Күптән гашыйк адәмне күргәнем юк иде. Музей экспонаты!

Нәҗибә. Мин бит күреп торам: Фәрзәнә аны яратмый, кеше алдында мыскыл итә. Ә ул, мескен... түзә... Бермәл Фәрзәнә акылга утырыр дип өметләнә... Ә андый хатыннар беркайчан да акылга утырмый!..

Зәйтүнә. Син дөрес әйтәсең. Мин бер тапкыр кухняда Фәрзәнәнең Ансарны әрләгәнен күрдем. Мин дә Мизхәтне әрләп алам. Әмма монда... Ансар бер чынаякны ваткан икән. Өе янганмыни! Шундый җәнҗал күтәрде, шундый пычрак сүзләр кычкырды. Мин килеп керсәм дә туктамады. Ансар укучы бала кебек башын аска иеп торган була. Оялып чыгып киттем...

Нәҗибә. Всё! Ансарны аннан коткарырга кирәк! Ул бит бөек рәссам! Аның иҗаты халыкка кирәк. Аның үзе, таланты кирәк! Шундый шартларда ул ничек иҗат итсен? Ул бит... Күңеле сызлаганга эчә, аптырап. Нәрсә эшләргә белмичә эчә. Йөрер-йөрер дә, эчеп асылынып куйса?! Аллам сакласын!

Хәбирә. Ә бәлки, ул синең белән бергә булса асылыныр? Бер ирең бит...

Нәҗибә. Ул эчте, эчте! Минем гаебем юк! Белдеңме? Эчте дә нәрсә эшләгәнен белмичә...

Хәбирә. Ә нигә эчте? Ирләр бит үзләреннән-үзләре эчә башламый. Менә минем ирем дә эчте. Хәзер аңлыйм. Мин аңа йөкне кирәгеннән артык төягәнмен. Атка йөкне артык төясәң ни эшли? Тәртәгә тибә башлый. Ә ирем эчә башлады. Мин аның сәбәбен аңламыйча төйи дә төйи идем. Ә ул аның саен эчте. Айныса, ат кебек эшли, бизнесы шәп китә, акчаны көрәп ала. Һәм кинәт эчә башлый. Тапкан акчасының яртысын эчеп бетерә. Мин һич тә аңламый идем. Нигә алай итә? Хәзер аңлыйм. Мин аңа ял бирмәгәнмен. Эшләткәнмен дә эшләткәнмен. Төягәнмен дә төягәнмен. Ә кешенең психикасы, тәне арый, аның көченең чиге бар. Ул ял сорый. Ял бирмәсәләр, ул эчә башлый. Эчкән чакта аның тәне дә, психикасы да ял итә. Их, хатыннар! Без бит ирләребезне эшләтә генә беләбез! Ял иттерә белмибез! Бөтен бәла дә шунда. Әгәр бүген тере булса, иремне утыртып куяр идем дә, эшләмә, ял ит, телевизор кара, гәҗит укы, футболга бар, теләгәнчә сыра эч, дияр идем. Ял итәргә бирер идем. Соңыннан ул бер көндә ун көнлек эшләр иде... Ансыз шундый кыен... Әмма мин бирешмәм! Түзәрмен! Ирләр юк икән, ирсез яшәрмен! Мин көчле! Мин көчле!

Зәйтүнә. Ходаем! Мин дә Мизхәтемне кайчакта бер кирәкмәстән әрләп ташлыйм! Мескенкәемне! Берәр вакыт акчасы да, фатиры да булыр иде әле...

Хәбирә. Бөтен бәла шунда: сезнең акчагыз да, фатирыгыз да булмаячак.

Зәйтүнә. Нигә алай дисең? Мизхәткә эшкә урнашырга кирәк. Шуннан...

Хәбирә. Эшкә дә урнашыр. Кечкенә генә зарплата алачак. Ул ашаудан артмаячак. Фатир төзибез дип мактаналар. Алар бит йөз метрлык, хакы миллион! Мизхәттә андый акча гомергә дә булмаячак.

Зәйтүнә. Син каян беләсең? Син кем шултиклем?

Хәбирә. Мизхәт – исполнитель. Ул кушкан эшне җиренә җиткереп эшли торган кеше. Ләкин үзе уйлап олы эш башкара алмый. Лидер гына бу дөньяда уңыш яулый. Ә Мизхәтең лидер түгел.

Зәйтүнә. Ай Алла!.. Алайса, безгә нишләргә соң? Ничек фатир алырга?

Хәбирә. Белмим, кадерлем. Ул сезнең проблема.

Зәйтүнә. Әй Ходаем! Иртәгә янә моннан чыгып китәргә. Кайда күчәрбез? Күчеп тә ничек түләрбез? Кеше бит хәзер фатир өчен акчаны ярты елга алдан сорый. Шултиклем ялыктым шушы фатирсыз тормыштан...

Хәбирә. Әнә Нәҗибә белән сөйләш. Ул сиңа бер фатирын бирсен, ә син аңа – Мизхәтне. И ноу проблем!

Нәҗибә. Миңа ошамый Мизхәт кебек ирләр.

Зәйтүнә. Бахыр! Аның нәрсәсе ошамый сиңа? Мизхәт кебек ир эләксә, сикереп төшеп биер идең әле! Ошамый, имеш! Ошамый икән, бар, чыгып китегез! Кем чакырды сезне монда?

Нәҗибә. Зәйтүнә, Зәйтүнәкәй, үпкәләмә, зинһар. Җәберләсәм, гафу ит. Мин бит... Хәбирә әйткәнгә генә. Болай Мизхәт әйбәт ул...

Зәйтүнә. Әй Ходаем, ниләр генә эшлим икән? Шушындый вакытта Мизхәте дә әллә кайда йөри. Ә мин монда берүзем... Хәзер балалар мәктәптән кайта. Алар да ялыкты мондый тормыштан. Әни, мәктәптән мәктәпкә күчеп йөрүе кыен бит, кайчан үзебезнең өебез була, диләр. Йөрәгем өзелеп төшә шул мәл... Бәгырькәйләрем!.. Нәрсә дип кенә җавап бирим инде мин аларга? Хәзер кайтып керәләр, тагы күченәбез, дисәм... Әй Ходаем!.. Хөкүмәт нигә шушы безнең кебек ярлыларга яшәргә арзанлырак йортлар, малосемейкалар төземи икән? Менә тиздән шәһәрдә бар врачлар, укытучылар картаешып, эшкә алырдай яшьләр булмаса, терсәкләрен тешләрләр дә, соң булыр!

Нәҗибә. Мин кертер идем дә бер фатирыма. Анда әле туганнарым яши.

Хәбирә. Зәйтүнә, беләсеңме нәрсә? Күченегез минем бер бүлмәгә. Барыбер буш тора.

Зәйтүнә. Сиңа?.. Синең фатирыңа?

Хәбирә. Әйе. Бер тиен акчагыз кирәкми. Яшәгез!

Зәйтүнә. Син моны чынлап әйтәсеңме?

Хәбирә. Әлбәттә. Ә Мизхәтне үземә эшкә алырмын.

Зәйтүнә. Юк! Мин аңладым сине! Син шулай итеп Мизхәтне миннән тартып алмакчысың.

Хәбирә. Җүләр син! Әгәр бик теләсәм, Мизхәтеңне болай да тартып ала алам. Бушлай. Просто сезне кыз-

ганам. Иртәгә кая барасыз, күз алдыма китерә алмыйм.

Зәйтүнә. Әй Ходаем! Нигә тормыш шултиклем рәхимсез икән?.. Ичмасам, кечкенә генә өебез булса... Тик үзебезнең өебез... Беркем дә куа алмый... Әй Ходаем! Үземнең өемне күрер көнем булырмы икән? Булмас ул беркайчан да... Булмас. *(Елый.)*

Хәбирә. Әй хәзерге хатын-кызның язмышы!.. Ире булса, фатиры юк, фатиры булса, башкасы юк. Бәхетсез без, бәхетсез! *(Елый.)*

Нәҗибә. Әллә нинди тормыш... Шундый сабый бала сөясем килә... Урамда күкрәк баласы күтәргән хатыннарны күрсәм, көнләшүемнән... күземә яшьләр килә. Нинди бәхетле алар!.. Ә минем... Балам юк!.. Нигә? Нигә шулай?.. *(Елый.)*

Хәбирә. Зәйтүнә, куй, елама, тын! Миңа күчеп тор!.. Күчәсеңме-юкмы?!

Зәйтүнә. Юк! Күчмим. Куркам мин синнән.

Хәбирә. Күчмисеңме? Соңгы тапкыр сорыйм!

Зәйтүнә. Күчмим.

Хәбирә. Дура! Урамда яшә алайса!

Зәйтүнә. Җай табылыр әле...

Хәбирә. Әйе, көт! Табылыр... Ирең – эшсез, үзең – өйсез, балаларың ач-ялангач урамда үләчәксез! Хәерче кебек! Йа Ходай! Коточкыч хәлдә бит сез! Зәйтүнәкәем, бәгырькәем! Ничек ярдәм итим соң сезгә? Тукта! Әгәр кемдер азап чигә икән... Нәрсәгә миңа акча, байлык?.. Мә! *(Акча суза.)*

Зәйтүнә. Нәрсә ул? Акча? Ни өчен?

Хәбирә. Ике йөз мең! Сатып ал шәһәр читендәге теге өйне! Бар!

Зәйтүнә. Юк. Ә нигә син миңа бу акчаны бирәсең? Мин бит аны беркайчан да кайтара алмыйм.

Хәбирә. Кайтарырсың әле. Ал.

Нәҗибә. Хәбирә! Син нинди изге күңелле кеше! Мин сине бөтенләй икенче кеше дип уйлаган идем. Син – искиткеч!

Зәйтүнә. Юк-юк! Мин алмыйм. Ала алмыйм.

Нәҗибә. Зәйтүнә, ал, ал! Хәбирә бит чын күңелдән! Ул безнесмен. Аңа ике йөз мең берни тормый. Ал!

Зәйтүнә. Әй Ходаем! Нәрсә эшлим? Кулым бармый бит. Алыйммы икән? Ярый! Ни булса, шул булыр! Алам!.. Син шундый әйбәт! Син гафу ит мине баягы сүзләрем өчен.

Хәбирә. Ярый, ярый, булды.

Зәйтүнә. Йа Ходай! Ике йөз мең! Минем өем була! Үземнең өем! Бу төш түгелме? Мин бит еш кына төш күрәм, имеш, фатир, өй алганбыз икән. Уянып китсәм – төш! Шундый кыен була, хәтта елаганым бар. Куркам: бу төш түгелме ул? Төштә шушылай бастырылып, уянып китәм... Юк, уяна алмыйм!..

Нәҗибә. Зәйтүнә, өн бу, өн!.. Котлыйм!

Зәйтүнә. Рәхмәт... Тик миңа нигәдер уңайсыз, кыен. Кешенең акчасын тартып алган, урлаган кебекмен... Гафу ит мине, Хәбирә. Ачуланма миңа, яме. Мин шулай начармын, кешенең күңелен аңламый әйтеп ташлыйм да...

Хәбирә. Ярый инде. Бетеренмә.

Зәйтүнә. Ничек бетеренмим? Бушка! Ике йөз мең! Мин шултиклем акчаны беркайчан да бирә алмас идем. Мин хәтта үз иремә, Мизхәткә, ун сум биргәндә дә җәллим. Чын. Ә син! Син искиткеч изге кеше, Хәбирә! Рәхмәт! Зур-зур рәхмәт!.. Күңелем тынычлана алмый. Юк! Рәхмәт кенә аз. Рәхмәт аз. Мин моның өчен сиңа... Беләсеңме нәрсә? Мин...

Хәбирә. Миңа бернәрсә дә кирәкми.

Зәйтүнә. Юк-юк! Мин... Мин һәрьяклап уйладым... Мин бу тиклем акчаны шул көе ала алмыйм... Мин...

Хәбирә. Нигә ала алмыйсың?

Нәҗибә. Хәбирә бит сиңа чын күңелдән бирде.

Зәйтүнә. Әйе, Хәбирә чын күңелдән. Ә мин... Мин – комсыз, саран! Мин начар хатын... Хәбирә! Кил монда! Акчаң өчен тагын бер кат олы рәхмәт! Син балаларымны өйле иттең! Аларга мәктәптән соң үз өенә кайту бәхете бүләк иттең. Минем үз йокы бүлмәм, үз кухням булачак! Мин сиңа моның өчен... Ал Мизхәтне! Барыбер миннән аңа бер файда да юк. Ал! Всё!

Хәбирә. Нәрсә? Нәрсә дисең?

Нәҗибә. Зәйтүнә! Син нәрсә? Акылдан шаштыңмы?

Зәйтүнә. Бетте! Мин барысын да уйладым. Мизхәт чынлап та минем белән бернәрсәгә дә ирешә алмаячак. Ә синең белән... Мизхәт бит бик эшчән. Аңа әйбәт җитәкче генә кирәк. Аның белән командовать итә белергә кирәк. Ул таулар актарачак. Сез тагы да ныграк баерсыз. Безгә дә ара-тирә ярдәм итеп торырсыз. Ал!

Хәбирә. Кызык тәкъдим, әлбәттә. Ләкин син яхшылап уйладыңмы?

Зәйтүнә. Бик яхшылап уйладым. Әгәр Мизхәтне алмасаң, мин дә бу акчаны алмыйм.

Нәҗибә. Бәлки, чынлап та шулай кирәктер, Хәбирә. Ике йөз мең ике йөз сум түгел. Йөз сумны да бушлай алуы кыен.

Хәбирә. Менә сиңа мә! Көпә-көндез кешенең ирен тартып алдым. Хәзер миңа уңайсыз.

Зәйтүнә. Бушка түгел бит. Син миңа, балаларыма – өй! Мин сиңа – ир!

Хәбирә. Ирне сатып алдым булып чыга инде.

Зәйтүнә. Зато икебезнең дә күңел тыныч!

Хәбирә. Ха-ха! Килештек!

Нәҗибә. Нинди акыллы сез! Сөйләштегез дә килештегез. Мин көнләшәм сездән. Хәзерге кешеләр шулай булырга тиештер ул. Бу – интеллегентлык билгесе. Менә Фәрзәнәдә ул юк.

Хәбирә. Тукта!.. Ул да Зәйтүнә хәлендә бит. Әгәр аңлатсаң...

Нәҗибә. Аңа аңлатып буламыни? Чәчеңне йолкып бетерер.

Зәйтүнә. Юк, сез Фәрзәнәне белмисез. Аның да әйбәт чагы була.

Хәбирә. Әллә тәвәккәллисеңме?

Нәҗибә. Әгәр бер бүлмәле фатирымны бирәм дисәм, әйе бит?

Зәйтүнә. Юк, ул синең белән сөйләшмәс. Менә, Хәбирә, син керсәң, син сөйләшә беләсең, бәлки...

Хәбирә. Юк, миннән булмый. Бая чәчсез калдыра язды.

Зәйтүнә. Ул бит Ансарны син алып китәргә йөрисең дип уйлады. Соңыннан аңлагач, Нәҗибәгә ташланды.

Нәҗибә. Һаман да башым авырта, дура! Хәбирә, әллә сөйләшеп карыйсыңмы?

Хәбирә. Ай-һай, андый хатын белән сөйләшкәнче, пантера белән алышам.

Нәҗибә. Хәбирә, моны син генә булдыра аласың. Үтенеп сорыйм, Хәбирәкәй. Буш итмәм.

Хәбирә. Буш итмәм дип, нәрсә бирәсең?

Нәҗибә. Нәрсә? Сиңа нәрсә кирәк соң? Синең бөтенесе дә бар. Ә-ә, синең бит машинаң юк! Машинага дигән акчаңны Зәйтүнәгә бирдең. Ирем үлгәннән бирле машинабыз тик тора. Шуны бирәм! Арзан хакка!

Ут сүнә.

Ут Фәрзәнәнең бүлмәсендә яна.
Фәрзәнә ялгызы. Хәбирә керә.

Фәрзәнә. Нәрсә кирәк?

Хәбирә. Бая син миңа юкка бәйләндең.

Фәрзәнә. Шуннан?

Хәбирә. Минем гаебем юк синең алда.

Фәрзәнә. Хатынлы ирләр янында йөргән ялгыз хатыннар һәрвакыт гаепле.

Хәбирә. Акыллы сүзләр. Язып куярга кирәк. Шушында яшисезме?

Фәрзәнә. Нәрсәгә килдең?

Хәбирә. Ни... Зәйтүнәләргә килгән идем. Ишекләре бикле. Записка тора: «Егерме минуттан кайтабыз». Синдә көтәргә мөмкинме?

Фәрзәнә. Юк. Урамда көт.

Хәбирә. Кара әле, син нигә шултиклем ачулы? Әйтерсең мин синең иреңне тартып алган.

Фәрзәнә. Менә сиңа ир! *(Кукиш күрсәтә.)* Бар, чыгып кит!

Хәбирә. Нигә этләшәсең? Җаныма тиясең... Бөтенләй чыкмавым бар.

Фәрзәнә. Хәзер милиция чакыртам!

Хәбирә. Чакырт! Мин аңа егерме мең бирәм дә, син мине тукмады, димен. Ул сине кулга алачак.

Фәрзәнә. Мин үз өемдә. Басып кергән кешене үтерә дә алам.

Хәбирә. Беренчедән, үз өең түгел... Ансарның энисе кайткач, кая күченәсез?

Фәрзанә. Ул синең эшең түгел.

Хәбирә. Әлбәттә, минеке түгел. Жәллим мин сезне. Фатирыгыз юк. Һәм булмаячак та.

Фәрзанә. Кара әле. Көтәсең икән, тыныч кына көт. Нервыга тимә!

Хәбирә. Барыбер совет вакытында әйбәт иде, әйе бит. Чиратта ун ел торсаң торасың, әмма барыбер фатир аласың. Ә хәзер... байлар өчен зур фатирлар төзиләр, ә ярлылар өчен кечкенә метражлы, арзанны төземиләр.

Фәрзанә. Җитте дим!..

Хәбирә. Бетте, бетте... Ха-ха-ха! Зинһар, гафу ит... Ха-ха-ха! Гафу ит, тыела алмыйм... Ну комедия! Ансарны әйтәм... «Хатыным үлде!» Ну комик!..

Фәрзанә. Әгәр тагын бер сүз әйтсәң.

Хәбирә. Бетте... Рюмкаң бармы? Зәйтүнәләргә бер вино алып килгән идем. Настроение юк. Бер рюмка эчәм әле...

Фәрзанә. Мә! Тыгыл!

Хәбирә. Рәхмәт! Эчәсеңме?

Фәрзанә. Мин эчкече түгел.

Хәбирә. Сүз уңаеннан, киңәш итәм. Арыган чакта, ачу килгәндә, эш бармаганда бер рюмка эчсәң, шундый җиңел булып китә. Бар кайгылар, проблемалар онытыла... Менә әле сиңа кергәндә курка-курка гына кергән идем, хәзер бөтенләй курыкмыйм. Бая син шундый ямьсез, усал күренгән идең, хәзер ягымлы, матур гына кебексең... Тагы бер рюмка эчәм әле... О! Син инде «Сылукай»да уйнаган кызга охшый башладың!

Фәрзанә. Якын килмә! Җенем сөйми исерек хатыннарны!

Хәбирә. Торма инде уксус эчкән кеше сыман. Мә, эч!

Фәрзанә. Юк, дидем.

Хәбирә. Сорама каян алганын, эчеп җибәр салганын! Эч! Мин бит күрәм, син эчтән янасың, үз-үзеңне ашыйсың. Эч. Җиңелрәк булыр.

Фәрзанә. Ну бәйләнчек икәнсең... Ярый. Кәефем дә юк.

Хәбирә. Әнә шулай! Беләсеңме, минем сиңа киңәшем бар.

Фәрзанә. Йә?

Хәбирә. Юк, әйтмим. Син усалсың, аңламаячаксың, үртәлә башлаячаксың.

Фәрзанә. Үртәлерлек булгач әйтмә.

Хәбирә. Ләкин шунысы гаҗәп: бу киңәш синең өчен иң акыллы, иң кирәкле. Шулай эшләсәң, синең тормышың яхшы якка үзгәрәчәк, бөтен проблемаларың юкка чыгачак. Син бәхетле хатынга әвереләчәксең.

Фәрзанә. Алай эшләп булмый.

Хәбирә. Була, әйдә бәхәсләшәбез!

Фәрзанә. Бәхәсләшмим дә, булмый да.

Хәбирә. Була, димен мин сиңа. Була! Башымны кисәргә бирәм, була!

Фәрзанә. Ярый, әйтеп кара.

Хәбирә. Юк, әйтмим.

Фәрзанә. Нигә?

Хәбирә. Чөнки син һаман да усал.

Фәрзанә. Кайдан беләсең?

Хәбирә. Күзләреңнән күренеп тора. Күңелеңдә миңа карата һаман да ачу ята. Мә, эч әле тагын берне.

Фәрзанә. Син мине эчкечегә әйләндереп бетерәсең икән.

Хәбирә. Эчкечегә әйләнер өчен бер цистерна эчәргә кирәк. Әйдә, танышу өчен... Әнә күзләреңдә нур барлыкка килде. Мин дә сиңа матур булып күренә башладым, әйе бит?

Фәрзанә. Син килеп кергәндә үк матур күренә идең.

Хәбирә. Ялгышасың. Кергән чакта мин сиңа убырлы карчык булып күрендем. Онытгыңмы?

Фәрзанә. Юк. Убырлы карчык бит мондый матур күлмәк кими. Шушы күлмәгең күпме тора?

Хәбирә. Егерме мең.

Фәрзанә. Егерме мең?! Андый акчаның минем төшемә дә кергәне юк. Ансар инде ярты ел акча алып кайтмый. Әгәр бүтән фатирга күчсәк, белмим, взносны ничек түләрбез.

Хәбирә. Фәрзанә, бер сорау биримме?

Фәрзанә. Йә?

Хәбирә. Син Ансарны яратасыңмы?

Фәрзәнә. Нигә аны сорыйсың?

Хәбирә. Миңа калса, син аны яратмыйсың кебек.

Фәрзәнә. Белмим. Элек ярата идем. Хәзер белмим. Акчасыз, фатирсыз тормыш шултиклем арытты, күңелем катты, хәтта кайбер чакларда Ансарны күралмыйм. Үтерәсе килгән чакларым да була. Әй Ходаем, гафу ит инде мине. Бөтен уңышсызлыкларыма Ансар гына гаепле кебек тоела башлый... Әгәр теләсә, ул бит акча эшли ала. Юк, теләми. Принцип саклыйм дип, миңа да, балаларына да төкереп карый. Әнә шулай итеп бөтен яхшы тойгыларны үтереп бетерде. Юк, ярату беткән инде. Хәзер күнегелгән инде, шуңа бергә яшибез. Кайбер чакларда аны күрүгә саруым кайный башлый. Аңа шундый ачуым килә... Мин аны хәзер, мөгаен, күралмыймдыр.

Хәбирә. Фәрзәнә! Син чын сөйлисеңме?

Фәрзәнә. Белмим. Нәрсә уйлаганымны әйттем инде.

Хәбирә. Мин бит сезнең ара бу тиклем дип уйламаган идем. Бу бит коточкыч!

Фәрзәнә. Әйт киңәшеңне.

Хәбирә. Хәзер... Башта шуны әйтим. Без бит Зәйтүнә белән алмаштык. Мин ике йөз сум акча бирдем. Ул бүген шәһәр читеннән өй сатып ала. Бетте аның фатирсыз тормышы! Бүгеннән ул кеше бусагасында йөрми!

Фәрзәнә. Ә ул сиңа нәрсә бирде?

Хәбирә. Нәрсә дип уйлыйсың? Мизхәтне!

Фәрзәнә. Мизхәтне?!

Хәбирә. Нигә аптырыйсың? Бизнес заманы. Икенчедән, Мизхәт тә, мин дә Зәйтүнәгә, балаларга ярдәм итеп торачакбыз.

Фәрзәнә. Мизхәтне ике йөз меңгә сатты инде...

Хәбирә. Сатты дисәң, ничектер начар яңгырый. Бартер. Алмаштык.

Фәрзәнә. Мин аңладым синең киңәшеңне.

Хәбирә. Фәрзәнә, син бит акыллы хатын. Барыбер Ансарны күралмыйсың. Теләсәң, бүген үк фатирлы буласың.

Фәрзәнә. Ансарны сат дисең инде?

Хәбирә. Сатмыйсың. Алла сакласын. Фатирга алмаштырасың.

Фәрзәнә. Ничә бүлмәле?

Хәбирә. Бер.

Фәрзәнә. Нигә бер? Ансар ни дисәң дә данлыклы рәссам. Бөтен республикага билгеле. Лауреат! Бер генә бүлмәле фатир аз.

Хәбирә. Анысын үзегез сөйләшерсез. Иң мөһиме: син алмашырга риза бул.

Фәрзәнә. Әй, барыбер аның белән бәхет күргәнем юк! Әрләшүдән баш чыкмый. Ирле хатын булып яшәдем, фатирлы булып яшәп карыйм әле. Иң мөһиме, балаларым фатирлы булыр. Аңлыйсыңмы, әнә шул балалар җәл. Бер фатирга күнегергә өлгермиләр, икенчесенә күчәбез. Мәктәптән мәктәпкә күчә-күчә арып беттеләр, мескеннәрем. Ә фатир өчен ай саен бишәр мең түләргә! Ансар ярты ел инде акча алмый! Ялкытты бу тормыш, шундый ялкытты! Гаиләсенә, балаларына рәтле тормыш көйли алмаган ирне ничек яратасың?

Хәбирә. Димәк, алмаштырасың?!

Фәрзәнә. Юк, алмаштырмыйм, сатам! Иремне сатам! Сатам иремне!

Ут сүнә.

Парк. Эскәмия. Ансар белән Мизхәт.

Мизхәт. Ну кызык кеше син, брат!

Ансар. Нигә?

Мизхәт. «Хатыным үлде!» Ха-ха-ха! Андый уй иң гениаль кешенең генә башына килә!

Ансар. Килмәде. Сез үзегез бит, килеп керүемә, кем үлде дә кем үлде, дип тезеп киттегез. Тоттым да шуннан әйттем инде.

Мизхәт. Юк, син бит ишек артында ук, кергәнче, «үлде» дидең.

Ансар. Без аерылышырга җыенган идек. Шуңа «үлде» дигән идем. Ягъни, минем өчен үлде. Җитмәсә, үзем дә үлеп бара идем. Йөрәк туктый язган иде. Син бит саран кеше. Хатын үлде, димәсәм, тамчы да салмый идең.

Мизхәт. Нигә эчәсең син, брат? Ташларга кирәк.

Ансар. Ә син нигә эчмисең?

Мизхәт. Биш ел элек үземә сүз бирдем. Эчмим и баста!

Ансар. Молодец! Ә мин эчәм! Ничек эчмисең? Ат кебек эшлисең, акча да юк, фатир да! Өйгә кайтсаң, хатын утыра. Бүген бөтен яшьләр шушы хәлдә бит. Нигә эчәсез, нигә аерылышасыз? Эчми кая барасың? Урамда яши бит бөтен яшьләр. Шуңа аерылыша, шуңа балалар ата-анасыз. Менә хәзер без дә Фәрзәнә белән аерылышабыз. Эх! Күңел әрни! Түзеп булмый. *(Эчә.)*

Мизхәт. Бу фатирсызлык үтерә бит безне, брат! Дәүләт, байлар өчен биш миллионлык фатирлар төзелә, дип мактана. Бездә каян андый акча? Яшьләр өчен күп итеп кечкенәрәк, арзан фатирлар төзергә кирәк. Алар юк! Менә бөтенесе дә аерылыша башласа белерләр! Нәрсә эшләргә соң?!

Ансар. Төкер! Ни булса, шул булыр. *(Җырлый.)*

Бакчаларда чәчкә ата
Без утырткан бөрлегән!

Мизхәт. Сиңа рәхәт, эчеп алдың да бөтен кайгың онытылды.

Ансар. Син дә эч. Эчмәвеңнең биш ел тулу хөрмәтенә.

Мизхәт. Әй, чынлап та, сал әле!

Ансар. Тукта! Син нәрсә! Син чынлапмы?

Мизхәт. Эчми йөреп уңмадым. Бәлки, эчсәм...

Ансар. Мизхәт, эчмә!

Мизхәт. Син кем әле мине тыярга?

Ансар. Мин бит шаярттым. Гафу ит мине! Әгәр мин «эч» димәсәм, син...

Мизхәт. Сал!

Ансар. Зинһар, эчмә! Эчү шултиклем начар. Мин үзем күптәннән ташларга җыенам. Тик... Тукта! Әгәр син эчмәсәң, мин хәзер үк ташлыйм. Шушы минутта, әйе!

Мизхәт. Ташлыйсың?

Ансар. Ант итәм!

Мизхәт. Булды! Эчмим!

Ансар. Дөрес! Бетте! *(Шешәне ташлый.)*

Мизхәт. Молодец! Күптән кирәк иде! *(Газета карый.)* Кара! Таҗиклар закон чыгарган: ирләргә күп хатын алырга рөхсәт бирәләр икән.

Ансар. Кит әле! Кая?

Мизхәт. Менә! Вәт бәхетле кешеләр, ә! Биш хатын аласың да, көн дә берсе белән, ә?

Ансар. Ул биш хатынны ашатырга да кирәк бит әле. Киендерергә.

Мизхәт. Эшли бит алар. Үзләрен үзләре карый алар.

Ансар. Эш юк бит хәзер. Синең хатын да, минем хатын да эшсез утыра.

Мизхәт. Анысы дөрес, брат. Шулай да берьюлы ике хатын белән яшәп карарга иде. Ничек икән? Элек бит күп хатын алырга рөхсәт булган. Менә минем бабамның ике хатыны бар иде.

Ансар. Ничек? Кайсы чорда яшәде соң ул?

Мизхәт. Егерме ел элек үлде.

Ансар. Бәй, яңарак кына яшәгән бит. Ничек рөхсәт иткәннәр?

Мизхәт. Карт хәйләкәр булган, берсе белән генә загста торган. Ике өе бар иде. Берсендә карт әби яшәде, икенчесендә – яшь әби. Бабай бер төн берсендә куна, икенче төн – икенчесендә. Вәт бәхетле булган, ә!

Ансар. Аның ике өе булган. Безнең берәү дә юк.

Мизхәт. Без фатирсыз кәләш алып харап булдык. Кара әле, брат! Бу хатаны төзәтеп була бит!

Ансар. Ничек?

Мизхәт. Икенче хатын алабыз! Аңлыйсыңмы, брат? Ике фатирлы хатын! Үзләре кулга керергә тора бит! Авызны ачып калырга ярамый! Шул фатирларында яшәрбез ике хатын белән! Хатыннарны да ташламыйбыз, фатирлы да булабыз! Ә, брат?!

Ансар. Юк, закон бит рөхсәт итми.

Мизхәт. Төкердем мин ул законыңа лач иттереп! Әйбәт закон икән, бирсен фатир. Бирми икән, икенче хатын бирсен! Фатирлысын!

Ансар. Бездә беркайчан да андый закон булмаячак.

Мизхәт. Чөнки без исәр, дурак! Шуңа булмый. Тукта әле! Закон булмаса, икенче хатын белән загссыз яшим, язылмыйча. Бабам кебек. Идея бу! Давай, брат, тәвәккәллик! Ялкытты бит фатирсыз тормыш! Балаларыбыз урамда яши бит! Хатыннарны күндерәбез дә, син Нәҗибәне аласың. Ике фатирда ике хатын! Мин Хәбирәнең акчасына Зәйтүнәгә шәһәр читеннән өй алып бирәм дә, ике өйдә – ике хатын. Типтереп яшибез! Ансар, давай!

Ансар. Син нәрсә? Чынлап әйтәсеңме?

Мизхәт. Брат, мәхәббәт белән шаярмыйлар.

Ансар. Юк, булмый. Беренчедән, Фәрзәнә риза булмаячак...

Мизхәт. Их, Нәҗибә әрәм була. Ике фатиры белән. Тукта! Беткән баш беткән! Хәбирәгә дә, Нәҗибәгә дә үзем өйләнәм. Өч хатын белән яшим!

Ансар. Ярамый. Зәйтүнә каршы булачак.

Мизхәт. Зәйтүнә – пүчтәк! Мин нәрсә әйтсәм, шул закон аңа!

Ансар. Ә Нәҗибә белән Хәбирә!

Мизхәт. Аларга ир кирәк, бала! Минем кебек ир урамда ятмый, брат. Хәбирә акыллы хатын! Моны шунда ук аңлады!

Ансар. Юк, син ике хатын белән яшә. Нәҗибәгә тимә.

Мизхәт. Нигә тимәскә? Ул да ирсез азаплана бит. Баласыз!

Ансар. Аңа тимә, дим!

Мизхәт. Җәл бит.

Ансар. Аңа өйләнмә! Ишеттеңме? Өйләнмә! И всё!

Мизхәт. Кара әле! Нигә этәсең? Син кем миңа боерык бирергә? Кемгә телим, шуңа өйләнәм! Нәҗибәне өченче хатынлыкка алам! Бүген үк!

Ансар. Юк, димен!

Мизхәт. Өйләнәм! Әйттем – бетте!

Ансар. Алайса, мин... ярый, күндерден! Үзем өйләнәм Нәҗибәгә!

Мизхәт. Ах, шайтан! Эшне боздың! Өч хатын белән яшәп карыйсым килгән иде!

Ансар. Өйләнәм Нәҗибәгә! Ике бүлмәле фатирының бер бүлмәсен мастерской итәм. Бер атнадан Мәскәүдә күргәзмә ачыла. Картинамны өлгертәм. Рәхмәт, брат! Акыллы киңәш бирдең! Кара әле, әйдә рәхмәт йөзеннән начальнигыңның портретын эшләп бирәм. Бир фотосын.

Мизхәт. Кирәкми миңа аның портреты. Мин хәзер Хәбирәдә эшлим. Давай Хәбирәнең портретын яз! Ул бит хәзер минем начальник та, хатын да! Давай!

Ансар. Язам! Тик, тукта әле! Без монда ике хатын алып бетердек тә ул. Ә безнең хатыннар риза

булырлармы соң? Бөтен эшне харап итүләре бар. Бигрәк тә Фәрзәнә.

Мизхәт. Яхшылап аңлатсаң, беркая да бармаслар.

Ансар. Әйе, яхшылап аңлатырга кирәк, фәлсәфи яктан нигезләп, экономик һәм демографик яктан исбатлап. Рәсәйдә бит елына ике миллион кеше үлә, бер миллион гына туа. Халык саны елына бер миллион кешегә кими! Ялгыз хатыннар күп, ә балалар тумый, чөнки ирләр җитешми. Кырылып бетте ирләр. Ситуацияне төзәтер өчен булган ирләр ике хатын алырга тиеш!

Мизхәт. Дөрес! Ирләр ике хатын алса, ике хатын ирле була. Тагын балалар туа. Главное – ике хатынның да балалары аталы була. Шәпме? Шушыларны хатыннарыбызның күңелләренә тиярлек итеп әйтергә кирәк, брат. Сез нигә моңарчы ике хатын белән яшәмәдегез, дип елап җибәрсеннәр.

Ансар. Хәтта, давай өченче хатын алыгыз, дип үтенсеннәр.

Мизхәт. Брат! Киттек!

Ут сүнә.

Зәйтүнәнең бүлмәсе. Бүлмәдә Зәйтүнә, Фәрзәнә, Хәбирә, Нәҗибә.

Зәйтүнә. Алар риза булырмы икән?

Фәрзәнә. Риза булмасалар, фатир тапсыннар!

Нәҗибә. Кинәт әйтергә ярамый. Җайлап әйтергә кирәк, әзерләп.

Хәбирә. Куегыз әле! Аның нәрсәсен әзерләп торасың. Тотасың да әйтәсең. Һәм баста!

Фәрзәнә. Дөрес!

Нәҗибә. Юк-юк! Алай итсәк, эшне бозабыз. Бөтен яктан әзерләп, фәлсәфи яктан нигезләп, демографик һәм экономик яктан исбатлап әйтик.

Зәйтүнә. Әйе шул! Шуннан алар риза булмый беркая да бармас!

Хәбирә. Алайса, Нәҗибә, бу эшне сиңа йөклибез инде. Укытучы буларак, әйдә, матурлап, нигезләп, укучыларга аңлаткан кебек чәйнәп каптыр. Минем түземем җитмәс, турысын әйтермен дә салырмын.

Мизхәт белән Ансар керә.

Ансар. Саумысыз!

Хатыннар. Саубыз әле.

Мизхәт. Бәй, сез нигә бергә җыелдыгыз?

Нәҗибә. Сезне көтәбез.

Мизхәт. Ә нигә безне көтәсез?

Хәбирә. Сагындык!

Мизхәт. Сагындыгыз? Ха-ха-ха!

Барысы да көләләр.

Мизхәт. Тукта! Нигә көләсез?!

Нәҗибә. Сез көлгәнгә көләбез. Ә сез нигә көләсез?

Мизхәт. Без дә сез көлгәнгә көләбез... Ярый, кәефегез әйбәт булуына без бик шат. Без, ягъни Ансар белән мин, шуны әйтергә телибез. Менә сез көләсез дә ул. Ә уйлап карасаң, дүртегез дә бәхетсез.

Нәҗибә. Әйе шул. Аны аңлавыгыз бик әйбәт.

Мизхәт. Зәйтүнәнең дә, Фәрзәнәнең дә фатиры юк. Икесе дә бу бүлмәләрдән чыгып китәргә тиеш. Янәдән балалары белән урамда калалар.

Нәҗибә. Ә Хәбирә белән минем фатирларыбыз бар да, ирләребез юк. Хәзерге заманда, бигрәк тә безнең шәһәрдә, кияүгә чыгарлык ирне көндез шәм яндырып эзләсәң дә табарлык түгел. Шулай бит, кызлар?

Хатыннар. Шулай.

Мизхәт. Во-во! Юк ирләр, юк!.. Юк диярлек.

Нәҗибә. Әйе, дөрес! Юк диярлек.

Мизхәт. Бик эзләсәң табып була. Шулай бит?

Хатыннар. Шулай, шулай!

Мизхәт. Менә, мәсәлән, без, әйе бит? Мин һәм Ансар!

Нәҗибә. Кызлар! Алар да безнең кебек уйлый! Әйе, әйе, сез! Сездән дә әйбәт ирләр юк бүген безнең шәһәрдә.

Мизхәт. Рәхмәт, Нәҗибә, шундый югары бәяләгәнең өчен. Иптәш хатын-кызлар! Сезнең дүртегезне дә бәхетле итеп була!

Нәҗибә. Әйе! Фәрзәнә белән Зәйтүнәне — фатирлы, Хәбирә белән мине... ирле итеп була.

Мизхәт. Ай, афәрин! Каян башыгыз җитте?

Хатыннар. Җитте инде, җитте!

Мизхәт. Димәк, сез... риза?!

Нәҗибә. Риза, әлбәттә, риза! Риза бит, кызлар?

Хатыннар. Риза! Риза!

Нәҗибә. Ә сез үзегез ризамы соң?

Ансар. Риза, әлбәттә, риза!

Мизхәт. Андый бәхет кемгә тәти әле! Күрәсеңме, Ансар, нинди акыллы безнең хатыннар. Ә син курыккан буласың.

Ансар. Фәрзәнә, син дә ризамы?

Фәрзәнә. Риза булмый кая барасың, син фатирлы итмәгәч? Минем дә үз фатирымда яшәп карыйсым килә. Бигрәк тә балаларыбыз.

Ансар. Рәхмәт, Фәрзәнә. Мин сезне беркайчан да җәберләмәм.

Мизхәт. Зәйтүнә, мин синең акыллы икәнлегеңне сизенә идем. Ләкин бу тиклем...

Зәйтүнә. Мизхәт! Минем үз өем була! Балаларымның! Ышанасы килми!

Мизхәт. Моны юарга кирәк, иптәшләр! Ансар, ач шәрабны! Кая рюмкалар? Салыгыз!.. Яңа кәләшләр, яңа фатирлар өчен!

Барысы бергә. Яңа кәләшләр, яңа фатирлар, яңа ирләр өчен!

Мизхәт. Үзебезчә яшибез! Төкердек законга! *(Җырлый.)*

Бар кагыйдә уйлап чыгарылган,
Бар законнар – уйдырма.
Катып калган законнарга
Син ябышып утырма.

Барысы бергә.

Яшик, дуслар, ирекле –
Күңелебез кушканча.
Шулчак кына булыр бәхет
Башыбыздан ашканча.

Мизхәт. Иптәшләр! Бүген Башкортстан өчен тарихи көн! Таҗиклар закон чыгарып маташкан була. Ә без законны алдадык! Ха-ха! Ике хатын!

Ансар. Ике хатын! Ну баш үзебездә! Ну ирләр көнләшеп үләчәк хәзер!

Мизхәт } *(бергә).* Икебезгә ике хатын! Икебезгә
Ансар } ике хатын!

Хәбирә. Тукта, ничек «ике хатын»?

Мизхәт. Ничек-ничек? Ничек сөйләштек, шулай, ике хатын!

Хәбирә. Бернинди дә ике хатын дип сөйләшмәдек. Син – миңа, Ансар – Нәҗибәгә, ә боларга – фатир.

Мизхәт. Дөрес түгел! Зәйтүнәгә өй алып бирәбез дә, мин аның өендә дә, синең фатирыңда да яшим. Көнаралаш синдә. Көнаралаш анда. Ансар Фәрзәнә, Нәҗибә белән – ике фатирда да! Алмашып!

Хатыннар. Юк! Юк!!! Риза түгел!

Хәбирә. Мин сине сатып алдым! Кил монда!

Нәҗибә. Мин – сине, Ансар!

Мизхәт. Безне сатканнар! Әйбер кебек!

Ансар. Кол кебек!

Мизхәт. Юк!!!

Ансар. Юк!!!

Пәрдә.

Уфа, 2001

ЭЧТӘЛЕК

Татарстанда да ул үз кеше. *Д. Салихов* 3
Яучы Җиһан, яки Ничек кияүгә чыгарга? 7
Әстәгъфирулла! 53
Студентлар, яки, Кызлар, ишек ачыгыз! 104
Үз хатыныма өйләнәм 143
Аты барның дәрте бар 195
Авылга кызлар килде, яки Моңнар кайтсын авылга 235
Алыш-биреш, яки Синнән – фатир, миннән – ир 278

Литературно-художественное издание

Гаитбай Наиль
(**Гаитбаев** Наиль Асхатович)

КОМЕДИИ

Казань. Татарское книжное издательство. 2012
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Гаетбай Наил
(**Гаетбаев** Наил Әсгать улы)

КОМЕДИЯЛӘР

Мөхәррире *Л. Ә. Гыйззәтуллина.*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова.*
Корректоры *Л. Р. Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.09.2012.
Форматы 84×108 1/32. Шартлы басма табагы 16,8.
Тиражы 2000 д. Заказ М-1104.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге.
Тел.: (843) 519-45-35.

Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете.
Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Мин тамашачының спектакль буена геройларның сүзләреннән, холыкларыннан туктаусыз көлеп утыруларын телим. Ә инде театрдан кайтып барганда болай дип уйлансыннар: «Тукта, тукта! Көлүен көлдек тә ул, пьесада бик җитди проблема күтәрелә. Аны ничек тә хәл итәргә кирәк бит!

Н. Гаетбай

9 785298 022934